# КАЗАН УТЛАРЫ

12
ДЕКАБРЬ
1978

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

12
ДЕКАБРЬ
1978

## Бу санда

К. ТИМБИКОВА. Агым уртасында. Повесть . . . 3
Р. МИНГАЛИМОВ. Кышкы шигырь. Шигырьләр . 60
М. ХӘБИБУЛЛИН. Туй балдагы. Хикәя . . . . . 63

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ш. МАННАПОВ. Күпләр чакыра мине... Шигырьләр . . . 76
Р. ХӘЛИУЛЛИНА. Җирeңнең ал гөле. Шигырьләр 79
Н. ГАББАСОВ. Төн — караңгы, төн — кара... Шигырьләр . . . 82
Ф. МӘҮЛЕТОВ. Кичке якта. Шигырьләр . . . . 85

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

Ш. БИКЧУРИН. Рекомендация. Хикәя . . . . . . 87

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВКА 50 ЯШЬ

М. ГОСМАНОВ. Олы мәхәббәт, якты моң җырчысы . . . 94
Ч. АЙТМАТОВ. Әйләнеп кошлар кайтканчы . . . 96

КЛАССИК ПОЭЗИЯДӘН ҮРНӘКЛӘР

А. С. Пушкиннан яңа тәрҗемәләр . . . . . . 113

ОЧЕРКЛАР

М. МӨЛЕКОВ. Егерме алтының берсе . . . . . . 116
И. ХӘБИБ. Полкташыбыз Муса Җәлил . . . . . . 123

Ш. УСМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

А. ЯХИН. «Пуля тизлегенә иялəшкән каләм» . . 125
М. МАННУРОВА. Ш. Усманов әсәрләрендә интернационализм идеяләренең чагылышы . . 129
Ш. УСМАНОВ. Беренче адым . . . . . . . . 132

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Р. ХАРИС, М. ВӘЛИЕВ. Шигърият шәхестән башлана . . . 138
Ф. САФИН. Шигырьләр янәшәлеге . . . . . . 145

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Б. ГЫЙЗЗӘТ.** Хәй Вахит һәм аның геройлары . . 150

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ш. САДРЕТДИНОВ.** Идеалга тугрылык . . . . 157
**Г. МОРАТОВ.** Йолдыздан да заман җиле исә . . 162

ХАЛЫК ИҖАТЫ

**Д. ГАРИФУЛЛИН.** Бабайлардан калган истәлек . 164

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**М. МӨХӘММӘДИЕВ.** Фәнни кыюлык . . . . . 168
В. Монасыйповка 50 яшь . . . . . . . . . . 173

УКУЧЫ СҮЗЕ

**Р. МИҢНУЛЛИН.** Укучы уйлана, шатлана, борчыла 174

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Мари мәзәкләре . . . . . . . . . . . . . . 177

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 182

1978 елда журнал битләрендә басылган әсәрләр 185

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев**, **Аяз Гыйләҗев**, **Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур**, **Туфан Миңнуллин**, **Рәфыйк Нәфиков**, **Атилла Расих**, **Гали Халит**, **Сибгат Хәким**, **Нил Юзиев**, **Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 21/VIII-1978 ел. Басарга кул куелды 1/XI-1978 ел. ПФ 09017. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91 000 экз. Заказ В-285. Бәясе 50 тиен.


КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

**Кояш Тимбикова**

# АГЫМ УРТАСЫНДА

ПОВЕСТЬ



Яз житте. Уяныпкитеп, күзне ачуга, бүлмәгә тулган нурлар тәэсиреннән үк җанны рәхәтлек биләп өлгерә. Урамга чыксаң, күңелләр күккә ашардай була. Кама ярына басып, уелып-уелып аккан суны күзәтсәң, инде яшелләнә башлаган урманына керсәң, кыш буе өнсез яткан җирнең тигез итеп тын алуын ишетәсең сыман. Нечкә күңеллеләрнең уйларын җырга тоташтыра торган, җыр сузарга осталарны елатып ук җибәрүчән бу көннәр кызлар тормышының астын-өскә әйләндереп ташлады. Әле моннан бер-ике генә атна элек кем дә булса бу хәлләр турында әйтсә, Зөһрә: син безнең кызларны бөтенләй белмисең икән, алар андый түгел, дип, ул кешедән көләр генә иде. Хәтта хәзер дә, вакыйгалар күз алдында үзгәреп торганда да, аларның чынлыгына ышануы шактый кыен.

Табибә, буш минут табып алса, көзге каршында бөтерелергә тотына. Табибә, моңарчы башына кепка, өстенә кыска куртка белән тар чалбар киеп, кыяфәтенә малайлар сыйфаты кертергә тырышып йөргән Табибә, шау чәчәкле ап-ак челтәрдән туй күлмәге тегә. Борынгы заманның купшы хатыннарыныкы кебек җирдән сөйрәлерлек озын, бишек чаршавы урынына элеп куярлык киң итәкле күлмәк.

Марина Майна, төзелеш мәйданында куна-төнә эшләп ятучы тынгысыз бригадир, чираттагы ялына чыккан. Әнисе янына, юлга җыена. Дус-ишләре аңардан, әллә шаяртып, әллә ихластан: «Миңлеәхмәтеңне дә алып кайтасыңмы соң?» — дип сорыйлар. Үчекләүләредер, мөгаен. Беләләр бит инде: Миңлеәхмәтнең сулу алырга да вакыты юк, диплом якларга әзерләнә. Марина ялга үзе генә китәчәк. Бу бәлки кыз баланың ата-ана йортына ялгыз килеш соңгы тапкыр кайтуы булыр.

Матрена түти, тулай торак кызларының барысының да серләрен сыйдырып саклаучы, уңган җыештыручы, Степан агай белән никах яңартырга ризалашкан. Тәмам бозылышканнар, аерылышу ыгы-зыгысы судка барып ирешкән иде бит инде. Бүлмәдәшенең мут егете, кызны алдап, шәһәрдән китеп баргач, Матрена түтинең ачуы шиндә дә куйды.

Мәрвиянең язны ничек каршылавын бер-ике сүз белән генә аңлату авыр. Хәер, ул үзе сер бирми. Әле комсомол комитетыннан яңа хәбәр алып кайтты. Аны кою заводының иң алдынгы эшчеләре белән бергә Тольяттига, автомобиль төзүче яшьләр слетына җибәрергә булганнар.

Табибә туена кайтып өлгерерме? Әллә, эше бетсә дә, кайтмый калуны хуп күрерме — моны берәү дә белми. Бу ике кыз, Табибә белән Мәрвия, үзләре һаман дустанә мөнәсәбәттә. Булса да булыр икән сабырлык! Өметләренең чәлпәрәмә килгән вакытында да Мәрвия башкалар язмышы турында кайгыртып йөри бит әле ул. Кичә генә Зөһрәне башын күккә тидерерлек итеп шатландырды.

Зөһрә, Мәрвия сүзләреннән канатланган җанын кая куярга белмичә, шәһәр урамнары буйлап әрле-бирле йөргәч, китап кибетенә барып керде. Инглизчә китаплар сатып алды. Бер кочак. Арада һичнинди гадиләштерүсез, саф инглизчә басылган новеллалар китабы да бар. Җером Җером новеллалары. Бәлки аңлашылып та җитмәс, укып та булмас үзләрен. Шулай да алды Зөһрә. Аңа хәзер кеше кулыннан килмәс эш юк кебек тоела. Кызларның ни белән мәшгуль булуын гына күр син! Зөһрәнең алар белән танышуына әле бер ел да тулмады— ниләр генә эшләмәделәр инде.

Юк, юк, бу хәлләрне болай бер сулудан гына хәтерләп бетерү мөмкин түгел. Баштан ук, Зөһрәнең шәһәргә аяк баскан беренче көннәреннән алып, барын да үз тәртибендә, бәйнә-бәйнә искә төшерергә кирәк. Алдан уйлаганнары, урта мәктәпне тәмамлаганда корган планнары бөтенләй башка иде бит аның, бөтенләй башка иде.

## Кызлар бүлмәсендә

— Син, Зөһрә, яхшы чакта кит бездән! Кит!

— Мәрвия апа, син бит миңа «сеңелем» дип эндәшә идең?

Зөһрә, кырт борылып, Мәрвиягә карады. Бу сүзне бер әйтерләр әле дип, шикләнебрәк йөрсә дә, беренче булып Мәрвиядән ишетүне башына да китерми иде ул. Бүген алар заводтан икәү чыктылар. Бер трамвайдан күчеп, икенчесенә утырдылар. Бер-берсенә әйтер сүз табылмады.

Зөһрә, Мәрвиянең таләбенә җавап биреп тормастан, өстен алмаштыра башлады. «Ачулы чакта кем нәрсә әйтмәс? Үтәр әле. Ачуы яшен ташы кебек эчтә бөтерелер-бөтерелер дә сүнәр...»

— Чаллыдан ук китмәсәң, безнең заводтан кит! — Мәрвия тиз генә тукталырга җыенмый иде, күрәсең, яңадан башлады. Ул шундый инде. Бер дә юктан гына авыз ачмый.—Син киткәннән генә Чаллы җимерелмәс. Беренче елларда, килгән йөз кешенең утызы, алтмышы кире китә барды. Харап булмадык. Салынырга тиеш шәһәр салынды, эшләргә тиеш завод эшли башлады. Сиңа барыбер бит: бүген — монда, иртәгә — Казанда, аннары — Лондон, Австралия...

Соңгы сүз Зөһрәнең үзәгенә барып кадалды. «Ничек шул кадәр катлаулы була ала бу кеше? Бөтен җан ияләренә бары яхшылык кына күрсәтергә яратылгандай мәрхәмәтле Мәрвия шундый усал сүзне ничек уйлап чыгара алган?»

Зөһрә сабырлык сакларга тырышты. Бәхәсне шаяруга борып карарга азапланды.

— Ә-ә! Миннән башка рәхәтләнеп яшәрләр иде бугай! Китмим әле менә! — диде.

Мәрвиянең тавышы тагын да җитдиләнә төште.

— Шаярма син, кызый! Чаллы сиңа — бер ел вакытны үткәрер өчен сайланган тамаша урыны гына, безгә ул... — Мәрвия үтемлерәк сүз эзләде. — Безнең язмыш ул Чаллы. Чаллысы да, КамАЗы да. Кешеләр язмышы белән шаярма син, ямә!

Әллә үз сүзенә үзенең күңеле тулды инде, соңгы сүзләр еламсырабрак яңгырады. Аннары ул, каршы сүз ишетергә теләмәвен сиздереп, Зөһрәнең ялгызын калдырды.

Зөһрә гаҗәпләнә башлады: ни өчен иң якын күреп йөргән кешесенең бу сүзләре аңа авыр булып тоелмый соң? Ачу да килми, үпкәләп тә булмый. Чөнки Зөһрә үзенең бу кешеләргә карата һичнинди яманлык та кылмавын белә. Мәрвиянең аңардан котылырга чамалавы да, заводтагы башка кешеләрнең Зөһрәгә каршы күтәрелеп алуы да вакытлы хәл. Кайнарлыктан. Мәсьәләне берьяклы аңлаудан, аның зыянын гына күрә алудан, житди уйларга иренүдән. Хаклык — Зөһрә ягында. Заводка күпме файда киләчәк! Калып «ояларын» үзгәрткәләгәнче бәлки план үтәү кыенлашыр, хезмәт хаклары кимрәк төшәр, аның каравы, яңача эшләү җайга салынгач, завод күпме материалны янга калдыра алачак! Яңалык һәрчак каршылыкларны җимерә-җимерә генә җиңүгә ирешә ул. Зөһрәне куып җибәреп кенә яңалыктан барыбер котылып калып булмый. Зөһрә әйтмәсә, бу фикерне, кайчан да булса, башка берәү күтәреп чыгар иде. Үсеш, яңалык, алга этәрүче мәшәкать — дөнья тоткасы бит ул.

Үзе ачкан яңалык тәэсиреннән, тиздән бу ачышны башкалар да күтәреп алуына ышанудан кыз аңлатып бетергесез бәхет кичерә. Бәхет тойгысы Мәрвия кадәр Марвиянең: «Кит!» — дип таләп итүеннән күп тапкырлар көчлерәк. Шунлыктан Зөһрә үкереп елыйсы урынга елмаеп утыра. Дөрес, «кит!» дигән сүз коточкыч ямьсез яңгырый. Җан өшеткеч бу таләп әле дә колак төбендә зыңгылдый кебек: «Кит!»

Кыз, гаҗәпкә каршы, бик теләсә дә моннан китә алмый. Кая китсен? Ничек китсен? Ник китсен? Ул бит бик яхшы белә: мондый шәһәр башка беркайда да юк, Зөһрәнеке кебек, шоп-шома калыплар коя торган, күндәм станок дөньяның башка бер генә заводына да куелмаган әле. Уйлана торгач, кыз үзалдына көлеп җибәрде. «Их, телемә килмәгән. Мәрвия апа чыгып киткәләгәнче сорыйсым калган икән: әйт соң алай булгач, синең кебек Мәрвия апаны, Марина Майнаны, Табибәне, Бәхтине тагын кайдан табып була, әйт! — диясем калган.»

Чаллыга аяк баскан беренче көнендә шундый кешеләргә тап булмаса, Зөһрәнең монда калырга исенә дә килмәс иде. Мәрвия аңларга тиеш. Ул бит барын да күреп торды. Телгә алганнары юк югын. Кем идең дә, безгә килгәч, кем булдың, дип, кабатлап сорамыйлар. Зөһрә җуләр түгел, әйтмәсәләр дә бик яхшы белә. Кайсы хәйләләп, кайсы турыдан-туры үгетләп, Зөһрәне бәхет юлына алар бастырды. Кыз бу хакыйкатьне бер мизгелгә дә онытып тормый.

... Август киче иде. Кызлар тулай торагының өч кешелек бүлмәсендә шактый караңгы. Киң тәрәзәдән урамдагы биек баганалар башындагы лампочкалар яктылыгы төшмәсә, монда кеше барлыгын белмәс тә идең. Кыз исә төн якынлашып килүен сизми кебек. Ул урамга караган. Анда якты. Анда барысы да уч төбендәге кебек аермачык күренеп тора. Кинотеатрдан чыккан кешеләр, төркем-төркем булып, трамвай тукталышына килеп басты. Көтәләр.

Ишек шакыган тавыш кызны сискәндереп җибәрде. Ул рөхсәт итәргә дә өлгерми калды, ишек ачылып та китте. Керүчеләрнең берсе:

— Әллә өйдә дә юклар инде болар? — дип сорады.

Түрдәге тумбочка өстендә лампа кабынды.

— Өйдә мин.

— Ә-ә, менә, Марина өйдә икән бит! Исәнмесез!

— Исән, исән! Син, Бәхти, кызык, шакыган булып кыланасың, рөхсәтме-түгелме икәнен көтеп тә тормыйсың, бәреп килеп керәсең...

— Нә-ә, ачуланма инде, Марина, ашыгам, машина көтә, болай да тугызынчы катка менә-менә алҗып беттек.

— Нигә, лифт эшләмимени?

— Эшләсә дә, тугызынчы кат — тугызынчы кат инде ул!

Беренче сүзләр бетеп, егет кабат чыгып китәргә борылгач кына, артта басып торган кызга игътибар иттеләр.

— Ә-ә, ни бит әле... — дип, Бәхти чыгу юлыннан кире борылып, Маринага карады. — Минем монда керүем дә шуңа иде, менә, кунак кызы калдырам сезгә! Мәрвия янына сыяр әле, әйтерсең. Үзе төнгедәме?

— Төнгедә. — Марина кулына кечкенә генә чемодан тотып ишек төбендә басып торучы зур күзле, калын коңгырт толымлы кызга текәлде. — Нәрсә, эшкәме?

Кыз урынына Бәхти җавап кайтарды.

— Ю-ук, аның Казаннан кайтышы, пристаньнан утыртып алып мендем. Аның әтисе мине укыткан иде. Авылларына китәргә соң, кундырып чыгарырсыз... Ярый, мин киттем.

— Соң, кунак кызың белән таныштыр ичмасам! Мин аңа, Бәхтине укыткан абзый кызы, дип эндәшмәм бит инде.

— Ә-ә, ни... — Бәхти бу кадәресен үзе дә белми иде әле. Кунак кызның урмандагыдай яңгыравыклы тавышы ишетелде.

— Зөһрә исемле мин. Зөһрә Алмаева.

— Зоя дияргә дә була икән.

— Юк, Зоя түгел. Грамматика кагыйдәсе буенча ялгызлык исемнәр башка телгә тәрҗемә ителми. Зөһрә мин.

Бер аягы керсә, икенчесе бусагадан атламас борын, тулай торакның эчке тәртибен бозып, аңа яхшылык күрсәтергә ризалык биргән хуҗа белән бәхәсләшә башлау Бәхтине аптырашта калдырды. Ул, болар үзара әйткәләшә башлаганчы, дигәндәй, чыгу ягына ашыга башлады.

— Менә таныштыгыз да инде. Мин сызыйм, кызлар, — диде. Чыгып киткәнче, ул тагын бер мәртәбә үзе алып кергән кызга карады. — Ни, ә-ә, Зөһрә, Мәрвиянең караваты әнә тегесе!..

Маринага бу бөтенләй ошамады. Бәхти тагын бер генә минутка бүлмәдә калса да, яман сүз ишетүе бик ихтимал иде. Зөһрә дә моны сизде. Аңлашыла: кешегә вакыт-вакыт япа-ялгыз калу да бик кирәк. Күңел мондый чакларда чакырылмаган кунак килеп керүен түгел, ут яктысын да артык күрә. Тик Зөһрәнең бүген башка чарасы юк иде.

«Метеор»дан төшкәч, Бәхтинең очравы ярады әле. Югыйсә Зөһрә урам уртасында басып калачак иде. Күндәм шофер башта кызны танышларына илтергә ризалашты.

— Кайсы урамда соң алар? — дип кенә сорады.

— Кооператив урамында, базар янында.

Самосвал, выжлап, базар урамына килеп керде, Зөһрәләрнең танышы яши торган чатка борылды. Шуннан ары китә алмадылар. Элекке кечкенә, агач йортлар сүтеп алынган, урам биек коймa белән уратылган, киң капкага: «Монда ундүрт катлы йорт салына. Участок начальнигы — Соломник М., прораб — Иванов В., мастер — Гайнетдинов» дигән язулы такта кадакланган.

Зөһрә коелып төште. Аның башка бер генә белгән кешесе дә юк иде. Ярый әле, Бәхти сизгер күңелле кеше булып чыкты.

— Һә-әй! Кайгырып торган юк, сеңел, хәзер болай итәбез аны! — диде дә, машинасын әүвәлгедән дә яманрак выжлатып, борып алып китте. Кая барасын аңлатып тормады ул, Зөһрә дә авыз ачарга кыймады, эндәшми-нитми бардылар да бардылар. Машина шәһәрнең бик киң, якты озын урамына килеп чыкты. Кыз, шәһәрнең гаҗәеп матур салынган йортларыннан күзен ала алмый хозурлана-хозурлана әлеге тулай торакка килеп җитүләрен тоймый да калды...

Инде менә Бәхти дә юк. Калганын Зөһрә үзе хәл итәргә тиеш. Ул, Маринаның: «Әйдә, уз!» — дигәнен көтеп тормастан, Бәхти күрсәтеп калдырган караватъ ягына атлады. Аның бар курыкканы Маринаның усалланып китүе, бүлмәдә чит кешене кундырырга ярамавы турындагы кагыйдәне кабатлый башлавы иде.

— Син Мәрвиянең берәр туганымы әллә?

— Кем соң ул Мәрвия, мин аны белмим, — диде Зөһрә. Ул мондый сорауны һич көтмәгән иде. Күрәсең, Бәхти машинасына ничек эләгүне аңлатырга кирәктер — Бәхти абыйны да хәтерләми идем мин. Ул, күрше авылдан йөреп, безнең мәктәптә укыган икән. Минем әтине бик ярата торган булган. Әти физикадан керә.

— Кызык та кеше инде бу Бәхти! Мәрвиягә Чаллыда яши башларга бер ярдәм иткән дә хәзер аңа теләсә нинди йомыш сыя дип белә. Тегесе дә, җүләр, Бәхтинең килделе-киттеле үтенечәнә сөенеп йөри...

Марина, үзе әйткән сүзләрдән һични аңламаган Зөһрәне ялгыз калдырып, бүлмәдән чыгып китте. Кызга гүя шул гына кирәк булган, ул тирән итеп сулу алды да иркенләп торып бүлмәне тикшерергә тотынды. Почмактагы тумбочка өстеннән бөркелгән ут шактый зур бүлмәгә серлелек салган. Караватлардагы ак җәймәләр зәңгәрсуланып күренә. Ишек төбендә — кием шкафы. Уртада — өстәл. Аның шоп-шома яссылыгында көзгедәге кебек чагылып, урындык аркалары күренә. Зөһрә буй-сынының шәүләсе дә, ут астан яктырткангa, сәер озынаеп, шома шкаф ишегенә төшкән. Киң тәрәзә төбенә радиоалгыч куйганнар, аннан калган урынны китаплар тутырган. Китапларның ниндиләгенә карап, монда яшәүчеләрнең нинди һөнәр ияләре икәнен белү мөмкиндер бәлки? Зөһрә укый башлады: «Физика», «Халык җырлары», «Горячий снег», «Кулинария», «Чыңгыз Айтматов», «Экран», «Литературная газета»... Белерсең, бар! Китап-журналларга карап фикер йөртсәң, бүлмәдәгеләрне югары уку йорты студентлары итеп тә, әдәбиятчылар яки физика укытучылары дип тә хисапларга була.

Марина ишектән керә-керешли үк сөйләнә башлады.

— Әйдә, иркенләп урнаш! — диде. — Комендант белән дә, тәрбияче белән дә, үпкәләмәсен өчен, вахтер белән дә сөйләшеп куйдым. Кунсын, диделәр. Вахтер: «Паспортын бирсен!» — дип, властен күрсәтә башлаган иде дә, мин әйтәм: «Соң, кунакка кем паспорт алып йөри инде?» — дим. Ризалаштылар.

Зөһрә, кабаланып, чемоданына барып ябышты.

— Бар бит минем паспорт! Мин кунакка дип чыгып киткән кеше түгел.

Документлар күрсәтүнең кирәге калмаган иде инде. Куна калырга рөхсәт алу өчен Маринаның шәхси авторитеты да җиткән. Әмма, юл йөрүнең сәбәбе турында сүз кузгалгач, Зөһрә Чаллыга ни йомыш белән аяк басуын аңлатырга кирәк тапты.

Мәрвия кайткалаганчы, Марина Зөһрә хакында аның үзеннән дә күбрәк белә иде инде. Кыз кичкә каршы шәһәрдә ничек боегып калуны гына сөйләп бирим дип тотынган иде, бүлмә хуҗасы судьяларныкыдай бер-бер артлы бирелгән кыска сораулары белән тәмам җелеккә төште.

Мәрвия кайтып керү белән, Марина:

— Сиңа кунак кызы килде, — дип тәфсилләргә тотынды. — Әле, бездә юынмыйча урын-җир өстенә ятмыйлар, дип, куркытып, душка төшереп җибәрдем үзен!

Мәрвиянең үз мәшәкате үзенә җитеп ашкан иде, күрәсең, ул кем соң дип тә сорамады. Бүлмәдә инде тамырланып өлгергән гадәт буенча, Марина да аңа сораулар бирмәде. Күңеле бераз утыргач, кеше үзе башлап җибәрә ул. Кайгы-хәсрәтне дә, шатлык-куанычны да ялгыз кичерү мөмкин түгел. Башкалар белән уртаклашсаң, шатлыгың дуслар санынча арткандай була, кайгың дус-иш санынча кими, бүлгәләнә. Тиздән Мәрвия дә үз мәшәкатьләрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирәчәк. Марина белә аны, азрак сабыр итәргә генә кирәк. Ул, Мәрвия караваты ягына аягы белән генә төртеп ишарәләде дә, кунак кызының кем икәнен тасвирларга тотынды.

— Эштән кайтып кына кергән идем әле, шул, бөтен дөньяны бәхетле итүне үзенә бурыч дип алган Бәхти ишек шакый. — «Бәхти» сүзен ишетүгә Мәрвиянең йөзе комачланды. Өстенә йөкләнгән мең мәшәкате юкка чыккан сыман булды. Авызы-күзе елмаерга тотынды. Марина аны-моны сизмәгәндәй сөйләде дә сөйләде. — Бер кыз бала ияртеп килеп керде бу. Мин аны я синең, я үзенең берәр туганыдыр дип торам. Ул икән, Казаннан кайтып килә. Мең дә беренче хыялый башның мең дә беренче ялгышуы! — Марина ләззәтләнеп көлеп җибәрде. — Шул ук хәл: институтка барган да, имтиханын бирә алмыйча, кире борылган. Хыялы хыял төсле булса, көлмәс тә идең аны. Бу бит чит телләр бүлегенә керергә уйлаган, тәрҗемәче булырга хыяллана. Ул анын сүзләрен тыңлап торсаң, кытыкларга шүрәле дә кирәкми, көлеп үләсең. Үзе елмаеп та карамый, мин анда барыбер керәм, ди. — Кыз ике кулын җәеп җибәрде. — Кемнең инде бер караңгы төбәктәге татар мәктәбеннән китеп, чит илләргә йөрерлек тәрҗемәче була алганы бар? Казанда бит аның бөтен фәннәрне чит телдә генә укыта торган мәктәпләре тулып ята! Бу җүләр шулар белән бер конкурска барып кергән.

Ниһаять, Мәрвия дә телгә килде.

— Алай авыл мәктәпләреннән чыккан кешеләргә юлны кырт кисеп куйма әле син, Марина. Программалар бер үк ич. Институтларга да гел шәһәр балаларын гына алып утырмыйлар. Тәрҗемәче булмаса, үз авылына укытучы булып кайтыр.

— Һай, шулай синең кебек, акылга сыярлык уйласа! Мин аңа үзем дә хәер-фатиха бирер идем. Бу бит аңа гына риза түгел. Моның күңел — күктә! Бу «кош», безнең кебек «телсез»ләрне җыеп, чит илләргә сәяхәткә йөрмәкче: Англия, Америка, Мисыр, Австралия... Белдеңме! Инглиз теленә өйрәнсәң, җир шарын әйләнеп чыгарга була, ди. Берничә чит телне аңламаган кеше — шыр надан ул, ди.

Марина, Мәрвиянең ачуын кабартырга тырышып, Зөһрәдән ишеткәннәрнең берсен дә калдырмый тәфсилләргә тотынды. Менә ул, егерме-утыз сәяхәтчене ияртеп, Нил буена китә. Башын күккә чөйгән хөрмәләр, ком сахрасы, Хеопс пирамидалары, ап-ак галәбияләргә төренгән гарәпләр, дөяләр. Урам тулы — бала-чага. Алары, чит ил туристларын күреп, кул сузалар: «Бакшиш! Бакшиш!» — дип, ни дә булса сорыйлар, арттан калмый ияреп йөриләр. Гид аларга бер генә сүз әйтә, хәер сораучылар минут эчендә юкка чыга. Сәяхәтчеләр аптырый, нинди сүздән шулай куркалар соң балалар? Зөһрә исә хәлне бик яхшы белә, балаларны: «Мин сезне полициягә тапшырам», — дип куып җибәрделәр.

Монысы болай, аяк астан чыккан бик бәләкәй генә вакыйга әле. Андыйларны Зөһрә группага әйтеп тә тормый. Ул бит тарихи вакыйгаларга бәйле, сәяхәтче һичшиксез белергә тиешле төп аңлатманы гына тәрҗемә итәргә тиеш. Зөһрә үзе барачак илнең тарихын да, үсеш юлларын, сәнгатен, культурасын — барын да алдан өйрәнәчәк. Гид текстында ул-бу җитеп бетмәсә, Зөһрә аны, һичшиксез, үзлегеннән өстәп җибәрәчәк. Әйтик, Мисырдагы мәшһүр Асуан буасына сәяхәт ясалачак, ди. Зөһрә анда күпме совет төзүчесенеңниләр башкаруын белә. Ул, әлбәттә, боларның һәммәсен сөйләячәк, чөнки ил белән ил арасындагы мөнәсәбәтнең асылын аңлата торган факт бу. Сөйләячәк Зөһрә, Асуаннан кайткан кешеләрнең бүген дә илнең иң зур төзелешләрендә — БАМнарында, КамАЗларында иң җаваплы эш башкаруларын кушып алып китәчәк...

Марина никадәр генә куертып маташса да, Мәрвия әле үз күзе белән күрмәгән кызны гаеп итәргә ашыкмады.

— Соң? Шуннан ни булган? — дип кенә сорады.

— Ни булсын, мәшһүр Казан каласының йөз яшәр институтыннан кызның ике аягын бер кунычка тыгып җибәргәннәр. Хәзер бу калай әтәчнең кире үзләренең Бәрәңге Тамак авылларына кайтып барышы. Төнгә калган. Кунар җире булмаганга, синең караватка килеп егылды.

— Син болай кеше бәхетсезлегеннән көлми торган идең бит, Марина?

— Мин ул тутый кошның шул тузга язмаган хыялыннан, бәхетсезлек ясап йөрүеннән көләм. —Марина җитдиләнде. — Без, КамАЗ сүзен ишетеп, төзүчеләр җитми дигән сүзне күңелгә якын алып, җәһәннәм асларыннан монда җыелдык, ә ул, ахмак, борын төбендәге төзелешне күрмәмешкә салышып, Австралиягә сәяхәт ясамакчы! — Кыз бераз уйланып торды да, тавышын акрынайта төшеп: — Беләсеңме, Мәрвия, — диде. — Әйдә, кызык итәбез үзен!

— Ник? Ничек?

— Синең бригадаңа да кеше җитми, минекенә дә... Бу якның авыл кызлары эшчән алар. Алып калып, койрыгын Чаллы җиренә ябыштырыйк!

— Бу якта Бәрәңге Тамак дигән авыл юк бит.

Ишек ачылып китте. Зөһрәнең керүе кызларның сүзен бүлде. Башта Мәрвия аның кем икәнենә төшенмирәк торды. Кайнар суда коенып, бит алмалары алсуланган, бөтенләй сабый бала хәленә килгән бу кыз белән Марина сурәтләгән мактанчык тәрҗемәче арасында һичнинди уртаклык юк иде. Мәрвия бу кызны пар үркәчле дөя өстендә үк килеп кермәсә дә, иләмсез зур, карасу пыялалы күзлек кигән, борынын болытка чөйгән кыяфәттә күз алдына китергән иде.

Зөһрә Мәрвия карашыннан тагы да каушый төште. Авызы кипте, теле әйләнмәс булды. Сәламен дә көчкә генә бирде. Маринасы, ичмасам, башына килгән һәр уен әйләндерә дә сала. Сорыйсы килгәнен сорый, ачуы чыкса, тирги. Андый кеше белән ни күрәсеңне көтеп азапланасы юк.

Шактый вакыт узгач кына:

— Мин Мәрвия апаң булам, — дигән сүз ишетелде.

Зөһрә, идәнгә текәлеп калган күзләрен күтәреп, аңа карады. Елмайды. Әмма ләкин болай сүзсез генә котылып калып булмаячак иде. Прожектордай гел бер юнәлешкә генә, Зөһрә өстенә генә төбәлгән караш бу бүлмәгә ник килеп керүне тәфсилләп аңлатуны таләп итә иде.

— Минем Казаннан кайтып барыш... — Шул сүздән соң бәлки артыгын сөйләтеп азаплатмас дигән өмет тулы күзләрен Зөһрә тагын Мәрвиягә карарга мәҗбүр итте.

— Соң?

Булмады. Димәк, сөйләми калу чарасы юк.

— Казанда минем беренче көннән үк юл уңмады. Абитуриентлар өчен билгеләнгән бүлмәләрдә урыннар беткән булып чыкты...

... Казанда көтелмәгән каршылыкка очрагаииан соң Чаллыда үзен кирәксенгән кешеләргә тап булу Зөһрәнең бөтен зиһенен томалагандыр әле. Җылылык та үзәк өзгеч суыктан соң аеруча кадерле була.

Чаллыда ул кирәк иде. Монда ул җанына урын тапты. Ник китсен? Ничек китсен?

Казанда этелә-төртелә йөргән көннәре искә төшсә, ул хәзер дә куырылып кала.

Тулай тортактан урын бирелмәячәген белгәч, Зөһрә институтка якын гына өйдә яшәүче бер бабайга фатирга урнашты. Берүзе өч бүлмәле өйдә тора икән. Кызның кай яктан икәнен белгәч, бабай ачылып китте.

— Сезнең яклар — безнең яклар инде ул, барыбер шул Чулман су буе, — диде.

— Мин бит, бабай, Кама буеннан.

— Мин хәзергәчә сөйләшә белмим, бәбкәм, ул суның безнең бабайлар кушкан аты — Чулман.

Зөһрә бәхәсләшмәскә булды.

— Син кемлеккә укырга килдең инде?

— Инглиз теленә өйрәнергә исәп, бабай. Тәрҗемәче буласым килә.

— Толмач, ягъни мәсәлән. — Бабай бераздан: — Ху-уш! — дип, бик тирән мәгънәле итеп сулап куйды.

Августның беренче көненә кадәр Зөһрә Казанның гел матур якларын гына күреп, кешеләренә сокланып, тәртипләренә һичсүзсез буйсынып яшәде. Дөнья матур, дөнья киң, күңеле күтәренке иде.

Ниһаять, беренче имтихан көне житте. Зөһрә үзе белән көч сынашачак егет-кызларның барын берьюлы күрде. Иртә иде, аларны институтка кертми тордылар. Болак күпереннән алып базар тыкрыгына чаклы араны абитуриентлар тутырды.

Зөһрә, чит телләр бүлегенә бер урынга җиде кеше гариза язган, дигән хәбәрне ишеткән иде инде. Моңа ул әллә ни игътибар да итмәде, дөресрәге, моның ни икәнен аңлап житкермәде. Хәзер, ишектән эчкә керергә теләп җыелган яшьтәшләренең бихисап булуы аның уйларын конкурсның коточкыч зур икәнлегенә китереп тоташтырды. «Бер урынга — җиде кеше. Димәк, институтта уку бәхетенә җиденең бере генә ирешәчәк...» Кыз, янындагы кешеләрне санап, алты кешене бүлеп алды, җиденчегә үзен куйды. Чагыштырды. Калган алты кыз да аңардан һич ким-хур күренми. Кайсын төшереп калдырырга? «Бәлки алар инглиз бүлегенә килүчеләр түгелдер?»

Ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Сез кайсы бүлеккә? — дип, янында торган беренче кызга эндәште.

— Английский!

Җавапның бик горур яңгыравы Зөһрәне дә сүзсез калдырмады.

— Мин дә! — диде ул.

Теге кыз исә инглизчә сөйләшүгә күчте.

— Оул райд! (Бик әйбәт!)

Аның сүзләре генә түгел, килеш-килбәте дә башкаларныкыннан үзгә сыман. Күзлегенең пыяласы да түм-түгәрәк, зур, караңгы. Иреннәре дә киртләч-киртләч, сызып ясаган кебек. Бөтен кыяфәт: «Сез кем дә мин кем!» — дип кычкырып тора. Коеп куйган тәрҗемәче, нәкъ чит илгә йөри торганы! Ходаем, монда җыелганнарның барысы да шундыйдыр инде. Алар Казанның саф инглизчә укытыла торган мәктәпләреннәндер... Белә иде Зөһрә ул турыларда. Кайберләренең җәен Казан янындагы халыкара «Волга» лагерында эшләвен, ялга килгән чит ил яшьләре белән аралашып, тел чарлауларын да чамалый иде.

Мәрвия гаҗәпләнә калды. «Бу бала үз хәленең ни дәрәҗә өметсез икәнен дә белә, имтиханнар биреп тә азаплана...»

— Сугалмаган зур күтәрә, диләр. Син дә шундыйрак кеше икәнсең, — диде ул.

Зөһрә аз гына туктап торды. Мәрвия соравының иң авырткан җиренә кагылуын сизмәмешкә салышып, киреләнеп җавап кайтарды.

— Мин сочинениены бик әйбәт яздым. Курыккан идем үзе...
Зөһрә үзенең куркуын институт ишеге төбендә танышкан инглизчә сөйләшә торган кыздан да яшермәгән иде. Җанын тынычландырырлык сүз ишетүенә өметләнеп сораган иде.
— Язып булыр микән?
Һавалы кыз бу юлы да җавапсыз калмады.
— Болар бармы соң синдә? — Ул өзелеп төшәргә торган нечкә билен буган киң путаны әйләндереп күрсәтте. Анда вак-вак кесәләр ясалган, һәрберсенә китапчыклар салынган.
— Анысы ни тагын?
Карасу күзлекле кыз: «Син әле безнең белән сынашырга өлгереп җитмәгән!» — дигән кебек иттереп, борын аша гына әйтте:
— Һе! Ни булсын, кырык биш сочинение.
Сүз бетте. Нәкъ шул вакытта институтның кара тимер рамлы ишеген ачып җибәрделәр.
Зөһрә кайтып кергәндә, квартир хуҗасының йөзе качкан, кашыкүзе җимерелгән иде. Ул ачуын яшерергә тырышып:
— Нәрсә уйларга да белмәдем, диваналар була яздым, бәбкәм, син мине алай кара кайгыга салып йөрмә! — диде. — Синекеннән башка үземнеке үземә дә бик житү.
— Ник, бабай, ни булган?
— Ник? Ник? Әллә син мине бөтенләй берни дә уйламый торган адәмгә санийсыңмы? Фикереңә җиңеллек теләп ничә дога гына укыдым.
Зөһрә көләргә дә, еларга да белмәде. Русча сочинение язганда гарәп догасыннан нинди файда килсен ди инде. Кыз көлүдән көчкә тыелды.
— И-и, бабай, рәхмәт инде! — диде. — Белмәдем бит. Язып чыккач, шәһәр буйлап йөрдем дә йөрдем. Көткәнеңне уйласам, әллә кайчан очыплар кайтып житә идем!
— Нинди билге куйдылар соң?
— Анысын берсекөнгә генә әйтәчәкләр, бабай. Кайгырма, начар язмадым, дүртледән дә ким булмас!
— Алаймы? Син әнә шул «берсекөненнән» соң шатланырсың, яме?..
Зөһрәнеңниләр кичерүен тыңлап утыручы Мәрвия уфылдап куйды.
— Бабайлар күпне күргән шул алар, — диде.
Мәрвиянең мондый нәтиҗә чыгаруы сүзне түгәрәкләргә рөхсәт кебек ишетелде. Тик хәзер Зөһрәнең үзенең тукталып каласы килми иде инде. Сөйли бирде.
Сочинение язганнан соң ике көн узгач, ул институтка китте. Белдерүләр, расписаниеләр язылган тактага якын барырлык түгел — аны оясыннан аерылып чыккан корт кучедәй абитуриент халкы сырып алган. Кайберләре, бер-ике адым читкә китеп баскан да, инде нишләргә, дигән кыяфәттә өнсез калган. Бер ишеләре, шул исәпсез халык алдында, хәсрәтен яшерми-нитми үкси-үкси елый.
Зөһрә үзенә очраган беренче кешедән:
— Ни бар анда? — дип сорады.
Озын чәчле егет.
— Двоечникларның фамилияләре эленгән, — диде. Аннары, Зөһрәнең кызыксыну-кызыксынмавын белергә дә теләмичә, өстәргә ашыкты. — Минем исем, слава богу, юк! Икеле түгел!
Зөһрә такта янына килде. Сөлге буе исемлекләр арасыннан үз группасын эзләп тапты. Калганын артык азапланып эзлисе юк иде, чөнки 24 нче группаның сочинениены начар язучылар төркемен аның фамилиясе — Алмаева З. Һ. башлап җибәргән.
Кыз күзләрен йомды. Тизрәк чыгып китәргә, таныш-фәлән очраганчы кешеләр тирәсеннән югалырга кирәк иде! Шул чак Зөһрәнең колак

төбендә: «Ну ничек?» — дигән үтергеч сорау яңгырады. Баягы «озын чәч» икән.

— Тишек! — диде Зөһрә. Учы белән маңгаена бөркеп чыккан салкын тирне сөртеп алды. — Мин ышанмыйм моңа, икеле булмаска тиеш.

— Алайса син кер дә сора! Күрсәтсеннәр ошибкасын!

— Кайдан табарга соң аларны?

— Әйдә, бергә керәбез!

Рәхмәт яусын ул егеткә! Үзе генә булса, Зөһрә ул юлларда йөри алмаган булыр иде, мөгаен. Әллә укытучы гаиләсендә үскәнгә, Зөһрә укытучыларның һәр эшен изгеләштереп карый.

Сочинениены җәзбә белән сызып ясагандай түм-түгәрәк йөзле хатын тикшергән булып чыкты. Башка язмалардан аралап, сочинениены кулына алгач, ул Зөһрәгә, озаклап, сынап карап торды. Аннары, көткәнгә һич туры китермичә, язманы мактарга тотынды.

— Күпләр китапча язалар. Синең үз фикерләрең күп кергән. Оригинально! Мин рәхәтләнеп укыдым. — Ул әле кәгазьгә күз дә салмый, сочинение битләрен актармый, шунлыктан хаталар күренми иде. Ниһаять, укытучы кәгазьләрне таратып җибәрде. — Но-о... — диде. Язманы кул сырты белән төйгечләргә тотынды. — Бер генә рус җөмләсе дә юк монда!

Зөһрә үз язуының һәр җөмләсе астына кызыл карандаш белән сызылган тоташ юлларга карап катып калды. Шома чәчле, йомры башлы ханым аның каршысында утырмый да кебек. Авазлар әллә кайдан ерактан иңә сыман.

— Бирелгән тема буенча башыңда туган фикерләрне син тоткансың да аягын аякка, кулын-кулга русчага тәрҗемә иткәнсең. Русча сочинение түгел бу. Татарча! Мин сиңа, сеңелем, татар бүлегенә кереп укырга киңәш бирер идем. Теләсәң, шул ук сочинение белән үткәрергә була. Тик гаризаңны үзгәртеп язарга кирәк!

Дөнья тынып калды. Күрәсең, хәзер Зөһрә сүз әйтергә тиеш. Тик ул тел әйләндерерлек хәлдә түгел. Шактый вакыттан соң укытучы кабатлады.

— Ну, ничек, керикме татар теле кафедрасына?

— Рәхмәт, апа җаным. Бабай белән кайтып киңәшим әле!

Урамга чыккач, озын чәчле егет Зөһрәнең беләгеннән кысып куйды.

— Браво! Бабайка турысында дөрес әйттең! Шулай да син юкка гына баш тарттың, институтка керү важно: кайсы бүлек булуы, минемчә, барыбер.

— Миңа барыбер түгел. Мин бары тик инглиз теле бүлегенә генә керәчәкмен!

Ул шушы көнне үк Чаллы белән Казан арасында йөри торган «Метеор»га утырып китте. Портка алар квартир хуҗасы белән бергә төштеләр. «Йөрмә, бабай, кирәкми!» — дип, кат-кат әйтсә дә, күндерә алмады. «Мин барыбер көнгә бер мәртәбә ул якларны урап кайтам, — диде бабай. — Парахутыңа кул болгап калырмын».

«Метеор»га кереп китәр алдыннан Зөһрә калтыранган кулын бабайга сузды.

— Хуш, бабай, рәхмәт, рәнҗеп калма!

— Хәерлегә! Казанга үпкәләп китмә!

Соңгы сүз кыз күңеленә укмашкан рәнҗешне чиште дә җибәрде. Ул, бабайның олы гәүдәсенә капланды да:

— Әй, бабай, юк икән шул Казаныгызда дөреслек, — дип, еларга тотынды. — Үземчә уйлап язган өчен икеле куйдылар бит, хакмыни?

— Сабыр, бала, сабыр! Сезнең бу хәсрәтләрегез минем йөрәккә дә кан саудырып бетерде. Ел да шулай бер-ике баланы озатып калам

мин. Гомерләр агышы белән нисбәтән карасаң, бик кечкенә хәсрәт бу. Институт биргән гыйлемең булмаса да, дөньяда яшәү — биниһая рәхәт нәрсә! Гөнаһ шомлыгына каршы, үтеп китеп кенә начар итә. Аңларсың әле, сабыр бул!..

Мәрвия, шул сүзгә ялгап китеп, Зөһрәнең Чаллыда калу-калмау теләгеннән дә чамаларга булды.

— Бабай дөрес әйткән ул, — диде. — Бөтен кешенең югары белемле булуы мәҗбүри түгел ич! Әнә безнең заводка эшче җитми, җаның теләгән һөнәргә өйрәтергә торалар. Ник шунда гына урнашмаска?! Эшли-эшли дә укырга була.

— Сүз бит кешенең алга куйган максаты турында бара. — Зөһрә үзе сайлаган юлның иң дөрес юл икәненә теләсә кем белән бәхәсләшергә өйрәнеп беткән иде инде. — Берәү заводта эшләүдән бәхет таба, ә миңа югары белемле телче булу кирәк. Әтием дә хупламаган иде мине.

Кызы филология факультетын сайлаганын белгәч, Һади абый кыскача гына аңлатып биргән иде.

— Авыр булыр сиңа, — диде. — Әдәбият белән телне белгәне дә, белмәгәне дә кыйный аны. Нигә физикага бармыйсың? Мондагы законнарга каршы чыгу өчен, һич кемгә дә, аны белергә, ник каршы икәненне аңлатып бирердәй яңа закон табарга тиеш буласың. Физика — табигатьнең үзе ул. Әдәбият — авыр юл. Кыз балага бигрәк тә...

— Син бит авыр юлдан курыкмаска өйрәттең.

— Юк, мин кисәтәм генә. Үзе егылган еламас...

— Бик кире балага ошыйсың, алайса мине дә тыңламассың инде син. — Мәрвия, Марина да ишетсен өчен, тавышын көчәйтебрәк әйтте. — Әтиең сүзенә дә колак салмагансың, укытучы тәкъдимен дә кире каккансың.

Марина шуны гына көтеп торган икән.

— Шуңа күрә эше уңайга бармый да аның, — дип, утка ялкын өстәде.

— Олы сүзен тыңламаган олыгаймаган, диләр. Син, сеңелем, зур ялгышлар җибәргәләгәнче башкалар киңәшенә дә бераз колак сал, — диде Мәрвия. — Минемчә, сиңа хәзер тиз генә эшкә урнашу ягын карарга кирәк. Әйтик, безнең янга...

Зөһрә сүзсез калды. Мондагы кызлар аның өчен иң мөһим булган мәсьәләне шулай гади генә, кичке чәйгә ак күмәч кирәкме, әллә арыш ипие дә ярармы, дигән төсле иттереп, тиз генә хәл кылмакчылар. Болар белән бәхәсләшү урынсыз, әйдә, сөйли бирсеннәр. Зөһрә үз хәлен үзе белә. Көтелмәгән уңышсызлыклар аның теләген аз гына да какшатмады. Ул барыбер инглиз теле белгече булачак.

Кызның киреләнеп эндәшми торуы Маринаның җен ачуларын чыгарды.

— Ник бер сүз дә әйтмисең? — дип, кырт кисеп сорады ул. Әйтерсең лә Зөһрәнең ни уйлавын белеп торган. — Киләсе елга тагын бер кат көч сынап карамакчы булсаң да, уникé ай буе ишләп ятармын дип беләсең?

Җавап ишетелмәде...

... Боларыннан шулай эндәшми торып котылып та калган булыр иде әле ул. Табибә исемлесе Зөһрәне икенче яклап үзенә каратты. Кыш уртасында яз исе алып килгән җил кебек, кара төндә ялтырап үткән балкыш кебек күңелне иләсләндерде. Табибә кебек дусны каян табарсың? «Кит!» дип әйтүе генә җиңел. Мондый кызлар янынннан китеп кара син! Тиз генә җыенып бетерә алырсың микән?

Мәрвия карават читендә сулу алырга да, кымшанырга да читенсенеп утыручы Зөһрәнең елап җибәрүеннән шикләнеп, ипләбрәк аңлата башлады.

— Авыл җирендә эше дә юк бит әле аның. Сыер савучылар, пенсия яшьләре җитми, фермадан китмиләр. Кырчылары кыш буе тик ята. Тәвәккәллә, сеңелем. Әнә, Марина бригадасында бер атна эчендә менә дигән төзүче итәләр үзеңне!

— Аңламыйм. Төзелеш белән инглиз теле арасында нинди бәйләнеш бар соң? — Зөһрә үзенең аптырап калуын да, башын ташка орырдай булып хәсрәтләнүен дә боларга сиздерәсе килми иде.— Ел буе имтиханга әзерләнәм.

— Абау, җаным, кирелегеңә күз тимәсен! Кайсы авылныкы соң син?

— Айлы Яр.

— И-и-и! — Мәрвиянең тавышы кинәт ширбәткә әйләнде.— Бәхти, Айлы Яр ди-ди, үлепләр китә инде. Шулай бик матурмыни соң?

— Әллә тагын. Авыл авыл инде. Урта мәктәбе бар. Шуңа күрә бөтен тирә-як авыл балалары безгә йөри. Бәхти абый кайсы авылдан?

— Гөберле.

Ул арада коридор ягыннан дыркылдап лифт туктаганы тавыш ишетелде. Аннан чыккан кешеләр, шаулашып, ишек төбеннән үтеп киттеләр. Мәрвия, Зөһрә белән сөйләшеп утырса да, колагын шул тавышка салган икән, сүзне кырт туктатып, ишеккә атылды.

— Табибә, якты күзем, бер генә минутка кер әле, зинһар!

Марина да көзге каршыннан борылып, Мәрвия чакырган кызны көтеп алды. Хәер, алай озак көтәргә туры килмәде, Табибә дигәннәре бүлмәдә иде инде.

— Әссәламегаләйкем, йөз каз! — диде ул.

Башында тар гына козыреклы аксыл кепка, өстендә киң путалы кыска кофта белән джинси чалбар. Гаскәри кешеләрнеке кебек гаҗәп төз буй. Йөзенең нинди икәнен дә белә алмыйсың: зур коңгырт күзләр биттәге башка сыйфатларга игътибар бирергә урын калдырмый. Көләч. Шат.

— Исәнме, Табибә, исәнме! — диде Марина.

— Син миңа бик кирәк бит әле, Табибә! — диде Мәрвия.

— Сез минем сәламгә игътибар да итмисез! — Кызның кәефе кырылды. — Ничә тапкыр шулай сәлам бирәм, ник алай кыланасың, дип сораучы юк кына бит.

Зөһрәнең болай да теле кычытып тора иде. Ул Табибә сәламенә тиешле җавапны әйтергә җөрьәт итте.

— Кайдан килеп без йөз каз булыйк соң? — диде.

Сөенеченнән Табибәнең күзләренә тагы да нур өстәлде.

— Ничәү соң сез, алай булгач? — дип, сәер сәламенең дәвамын элеп алып китте ул.

— Әгәр дә мәгәр безнең төркем янына безнең кадәр тагын бер төркем, аннары шуның яртысы, тагы да шуның чиреге һәм син үзең килеп кушылсаң, без, чыннан да, төп-төгәл йөз каз булыр идек!

Зөһрә Табибәгә, бүлмә кызлары Зөһрәгә карап, шактый ара тын тордылар. Зөһрә сәламнең соңгы сүзләрен кабатлады.

— Иә, исәпләгез инде, төркемдә ничә каз бар?

Табибәне үз кирәгенә чакырып керткән Мәрвия аптырый калды.

— Туктагыз әле, нинди каз үрчетәсез соң сез монда?

Табибәнең хәле башкаларны ишетерлек түгел иде. Ул Зөһрәгә:

— Кем син? — дип кадалды.

— Зөһрә.

— Һе! — Ул, Марина белән Мәрвиягә карап, кызның исемен кабатлады. — Зөһрә! Кешенең исеменнән генә барын да аңлап булмый.

— Ул минем янга кунарга гына кергән. — Мәрвиянең үз йомышын хәл кыласы бар иде. — Табибә...

Табибәсе, кулы белән ишарәләп, сүзне туктатырга кирәклеген белдерде.

— Әйтергә дә, кабатлап сорарга да куркам, — диде. Ул Зөһрәгә якын ук килде. — Кай яктан син? Казлар кыйссасын кемнән ишеттең?

— Әтиемнән.

— Әтиең Һади абый түгелме, Һади Алмаев?

— Әйе.

Өйләреннән чыгып китүгә әтисенең укучыларына очрый-очрый туеп беткән Зөһрәгә моның әллә ни гаҗәпләнерлек нәрсәсе юк иде. Әллә кай якларда кырык ел буе укытып йөргән Һади абыйны күпләр белә. Аның сәер гадәтләре турында телдән-телгә мәзәкләр йөри. Мәзәкчән кеше ул Зөһрәнең әтисе. Дәресләрен дә башкалар кебек план буенча гына алып бармый. Класска керә-керешли үк укучыларга сорау бирә.

— Мәсьәләне берәрегез чишә алдымы?

— Юк шул, абый.

— Әллә нинди бит ул, абый.

— Булмады, абый.

Шул чак арада берәү кул күтәрә.

— Йә.

— Тактага чыгыйммы, абый, дәфтәрне күрсәтимме?

Укытучы аның янына бара, дәфтәренә күз сала.

— Син интернатта яшисеңме?

— Әйе, абый.

— Анда сезнең класс укучылар юкмыни?

— Бар, абый. Унау без анда.

— Утыр. Икеле. Башка чакта белгәнеңне иптәшләреңә дә әйт!

Һади абыйның сәерлеге баштин ашкан. Хәзер Табибә шул мажараларның берәрсен сөйли башлар, дип, Зөһрә тынып калды. Әтисен бик яратса да, кешеләр авызыннан аның турында мәзәк ишетүне кыз өнәми иде.

Табибә Зөһрәне иңбашыннан кочып алды.

— Җаныемдыр ла! Һади абый кызы! Һади абый бит ул миңа әтием сымак кеше! Без аны детдомда барыбыз да «Папаша» дип йөри идек. Үзе директор да түгел, завхоз да түгел, гади бер укытучы гына иде, арада иң ятраканыбыз шул иде. — Табибә кызларга карап: — Нишлим икән? — дип сорады. — Нишләтим икән бу «Папаша» кызын?

Зөһрә җиңел сулап куйды.

— Ә-ә, безнең әти Чистай ягындагы бер детдомда укытты шул, — диде. — Хәзер без анда түгел инде.

— Беләм, Әлмәт ягына киткәнегезне беләм. — Табибә Зөһрә курыккан сүзләрне теленә алмады, Һади абыйның мәзәкләрен сөйләүгә бирелеп китмәде. Үзенең сәламен генә аңлатып үтте. — Берсендә Һади абый класска керде дә: «Әссәламегаләйкем, йөз каз!» — дип исәнләште. Әй көләргә тотындык без, әй көләбез рәхәтләнеп. Ул житди. Бу сезне көлдерер өчен бирелгән сәлам түгел, бу — бер билгесез тигезләмә чишү өчен мәсьәлә, ди.

Тигезләмәсен чиштек чишүен. Ул төркемдә утыз алты каз булганын исәпләп таптык. Тик бу исәнләшүнең кызыгы мәсьәләне чишү белән генә бетмәде. Башта безнең класс, аннары бөтен детдом балалары берберсе белән: «Әссәламегаләйкем, йөз каз!» — дип исәнләшә башлады. Мин, детдомнан киткәннән бирле, татарлар очратсам, шул сүзләрне кабатлап йөрим. Кешеләр көлә, мин, үз танышларымны очрата алмауга уфырам. — Табибә тавышындагы моңсулык озакка бармады. Ул

Зөһрәгә елмайды да.— Менә, таптым бит, тәки,— диде.— Нindиен генә әле, «Папаша» кызын. Мин сине хәзер үзебезнең «пятачок»ка алып барам!

Мәрвия бу фикерне хупларга ашыкты. Аңа тизрәк үз сүзен әйтергә җай кирәк иде.

— Шулай ит, Табибә! Тик башта миңа вәгъдәңне бир, синең баян кирәк иде бит миңа.

— Сез гел шулай инде, башта, син кирәк, дисез, аннары я баян, я шахмат, я машина кирәк булып чыга. Үзем бер катализатор кебек.

— Алай түгел лә инде! Үзең булмагач, баяның белән нишлим? — Мәрвия кызның киреләнүеннән шикләнеп куйды. — Үзең кирәк, әнә шул бозау чаклы баяныңны кочаклаган хәлдә кирәксең!

— Нишләмәкче буласың соң? — Сүзен Мәрвия белән алып барса да, Табибәнең күзе — Зөһрәдә. Әйтерсең лә алар сөйләшкән арада кыз, күккә ашып, юкка чыгарга тора. Табибә иң кадерле кешесеннән колак кагарга җыенган кеше кебек кылана. — Әйт, әйт, Мәрвия! Мин бүген, Зөһрә белән очрашу хакына, әллә ниләр үтәргә риза. Зөһрә бит ул! «Папаша» исемне дә белеп кушкан. Йолдыз бит ул, таң йолдызы! Җаныемдыр ла, үзем кияүгә чыгып, ялгышып-нитеп кыз бала табып куйсам, бу исәр әйткән иде, диярсез, ул бала Зөһрә атлы булачак!

— О господи! Әллә ычкындың инде син! — Марина Табибә ягына кул селтәде.— Бигрәк артыгын кыланасың инде.

— Их, сез, мондый шатлыкның ни икәнен беләсезмени соң! — Табибә Маринага үпкәләп тормады. Мәрвиянең йомышын аңлап бетерер өчен генә тагын сорады. — Әйтеп кал, ник кирәк инде сиңа ул баян? Нәрсә уйнарга, кемгә, кайчан?

— «Молдавский танец» уйнарга. Иртәгә. — Мәрвия үз хәлен сөйләп күрсәтте. Кою заводы комсомоллары «Дуслык» кичәсе уздырачаклар икән. Комитетның культура эшләре өчен җаваплы члены Мәрвия концерт программасын төзергә тиеш. — Төрле телләрдә җыр яңгыратачакбыз, биюләр биемәкчебез...

— Кайчан соң ул сезнең?

— Иртәгә кич. Сменаң туры киләме?

— Бүген минем өчен туры килми торган бер генә нәрсә дә юк.

— Һай, рәхмәт яугыры! Бер мәшәкатьтән коткардың.

— Ярый, сөйләштек, — диде Табибә. Ул, Мәрвия белән эшен бетереп, Зөһрәгә борылды. Назлы тавыш белән эндәште. — Бер кая да кузгаласы булма. Мин хәзер өс-башымны гына алмаштырып керәм дә «пятачок»ка китәбез, яме?

— Соң бит инде, апа.

— Һа! — Табибә шук малайларча гайрәт орып сөйләшүгә күчте. — Ничек соң? Чаллының иң күңелле тормышы кичке сигездән соң башлана. Көндез — җитди эш. Беләсеңдер бит инде, җаныемдыр ла, үзеңнең башың җитмәгән булса, Һади абый сөйләми калмагандыр — көпәкөндез биеп-җырлап йөрсәң, КамАЗ кебек баһадирны салып булмый аны. Сез ничек уйлыйсыз, кызлар? Биеми генә дә яшисе килми. Гомер бер генә бит безнең. Ике булсын иде ул: берсе — завод салырга, икенчесе уйнап-көлеп яшәргә, ә, кызлар? Анда көпә-көндез дә сиптерергә ярар иде. Юк, гомер бер, һәм, рәхим итеп, шунда барына да өлгерергә кирәк. Аңладыңмы? Килештекме?

Кыз чыгып киткәч, Марина белән Мәрвия, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, Табибәнең кемлеген тасвирларга тотындылар.

Табибә — аяклы роман. Аның турында сөйли китсәң, телең тала. Балалар йортында үскән. Табибәнең үз сүзенә ышансаң, әтисе белән әнисе, кечкенә кызны күрше карчыгына калдырып, Кавказ ягына ялга киткәннәр дә утырган самолетлары бәлага очраган. Балалар йортыннан соң кыз төзелеш училищесын тәмамлаган. Кама буенда, Табибә

тәрбияләнгән җирләрдән ерак та түгел зур завод салыначагын ишеткәндә, ул Пермьдә кранчы булган.

— Мин Чаллыга китәм! — дип, гариза тотып, кадрлар бүлегенә кергән кыз. — Анда хәзер крановщикларның иң кирәк вакыты.

— Училищедан соң син бездә ике ел эшләргә тиеш! — дигәннәр аңа. — Бу — закон.

Табибә шул законны уратып үтү өчен әллә нинди чаралар эзләгән. Мәскәүгә язган, Чаллыдан сораган. Төрле яктан рөхсәт кәгазьләре, путевкалар, чакыру язулары килеп төшкәч, тота алмаганнар. Тик Чаллыга килгәч тә, барысы да ул теләгәнчә генә бармаган. Завод дигәннәренең казыгы да кагылмаган, торыр урын юк. Шәһәрдән егерме чакрымдагы керәшен авылына квартирга урнашкан, кулына көрәк тотып җир казырга чыккан.

Көннәрнең берендә ул бер төркем әзмәвердәй ирләрнең өр-яңа кранны торгызып ятуын күрә. Яннарына барган. Сораган.

— Крановщигы кем?

Ирләр башта аның белән сөйләшергә дә теләмәгән.

— Сездән сорыйм бит, ник дәшмисез? Кем эшләячәк бу кранда?

Усал карашлы бер агай, бәйләнчек чебенне куып җибәрергә селтәнгәндәй, теләр-теләмәс кенә:

— А что? — дип, сорау белән үк җавап кайтара. — Мин дисәм?

— Син булмассың, мин булырмын! — ди Табибә.

Ирләрнең шаркылдавыннан әле куелып та бетмәгән кран үзе дә чайкалып киткәндәй тоела. Кызның бу көлүгә дә ачуы килмәгәч, икенче бер агай сорарга мәҗбүр була.

— Кем соң син, наный?

— Бишенче разрядлы кранчы.

Усал агай:

— Минеке — өченче генә, — ди. — Начальникка барсаң, мөгаен, алыр да, миннән ничек котылырга белми ул. «Беларусь»ка күчерәм дип, котны алып тора.

Табибә, башын югары чөеп, начальникны эзләп китә.

— Әллә кайчан шулай әйтәсегез бар иде, вакыт әрәм итеп торасыз, — ди.

— Синең авырлык житенкерәмәс шул, наный.

— Житенкерәмәгән өлешенә, абый кеше, сине бәйләп тагармын!

Икенче көннән Табибә кранда эшли иде инде. Кранчыларның күбесе — ир-ат. Әмма Табибә белән бәхәскә керергә, аннан уздырырга берәү дә алынмый. Кыз беренчелекне барыбер бирми. Кран кабинасына кереп алса, һич туктатыр хәл юк үзен. Астагы ярдәмчеләре ял итә башласа, ник тик торасыз, дигән кебек кран сигналын чыңлата башлый. Тәмәке тартырга да ирек бирмәвенә ачуы чыгып, җирдәге агай аңа ике кулын аркылы-торкылы куеп күрсәтә. Бу ым: «Житте, булды. Хәзергә бүтән эш юк», — дигәнне аңлата.

Эштән соң Табибә кырыкмаса-кырык түгәрәккә йөри. Ул ясаган рәсемнәрдән аерым бер күргәзмә дә оештырганнар иде. Рәсемнәрнең авторы кранчы кыз икәнлекне белеп, район газетасы вәкиле аңа сораулар бирде.

— Бу һөнәрегез нәрсәдән башланып китте соң сезнең? — диде.

— Бу гадәтем нәселдән килә минем, әтием художник бит, — Табибә уйлап та тормый шундый җавап биргән. — Әтием художник.

Ул үзе һич хәтерләми дә торган әти-әниләре турында тузга язмаган уйдырмалар сөйләргә ярата. Баян уйнау осталыгын абыйсына китереп тоташтыра, биюен — әнисенә.

Әгәр аның шул хыялый сүзләренә каршы төшсәң, кыз кисәктән өнсез кала. Берәү аңа, аны-моны исәпләмичә:

— Юкны такылдама инде. Син — авыл баласы. Кайсы художникның авылда яшәгәнен күргәнең бар? — дип бәйләнгән булган. — Алдаласаң да кеше ышанырдай итебрәк алдала син!

Табибә рәсем ясап утыра торган җиреннән сикереп торган да берәүгә бер сүз әйтмичә, чыгып киткән. Кунарга да кайтмаган. Икенче көнне кран кабинасында күргәннәр. Аннан төш ашарга да төшмәгән, кичен, башкалар кайтып киткәндә дә шунда калган.

Кыз аена өчәр-дүртәр йөз сум акча эшли. Беренче елында, акчасы бик күп җыелгач, бөтен байлыгын балалар йортына җибәргән булган. Кабул итмәгәннәр. «Жигули» алган да, кемнең йөрисе килә, шуңа биреп тора икән.

Кулына юка гына папка тотып, бүлмәгә кабат Табибә килеп керде. Өс-башына караганда, аның «пятачок»ка бару теләге үзгәргән иде. Ул гафу үтенгән тавыш белән Зөһрәгә эндәште.

— Җаныемдыр ла, үзем эштә чакта «Шифалы яңгыр»га чакырып язу килгән. «Пятачок»ка барып булмый.

Зөһрәгә ни, ул бит бу атамаларның ни-нәрсә икәнен дә белми әле.

— Мин бит үзегез әйткәнгә генә әзерләнгән идем, Табибә апа. Барыгыз. Ни икәннәрен дә белмим.

— «Пятачог»ы — уен мәйданы инде, авыллардагы чишмә буендагы кечке уен төсле, «Шифалы яңгыр»ы — әдәби түгәрәк. Җыелып шигырьләребезне укыйбыз анда, тәнкыйтьләшәбез. — Табибәнең йөзе үзгәреп китте. — Карале, син үзең дә әдәбиятны яратырга тиеш, сиңа анда бик кызык булачак, әйдә, киттекме?

Кызлар үзара бәхәсләшә башладылар.

Марина:

— Ярар инде, ул сиңа уенчык түгел! — диде. — Әнә Мәрвия белән «пятачок»ка барырлар.

Мәрвия Маринага каршы төште.

— Мин заводтагы эшемне калдырып концерт оештырырга кайттым, син миңа «пятачок»ка барырга кушасың.

Зөһрәгә кыен булып китте.

— Зинһар, үз эшләрегезне генә карагыз, мин беркая да бармыйм, ятам да йоклыйм хәзер, — диде.

Табибәгә монысы бөтенләй ярамады.

— Юк инде, үскәнем, — диде. — Чаллы җирендә караңгы төшмәс борын ятып йоклау берәүгә дә эләкми. Һади абый кызы булдым дигәч тә. Әйдә, киттек!..

...Зөһрә хәзер генә, Мәрвия апасы: «Кит!» дигәч кенә аңлагандай булды. Бу шәһәрдә торып калуының беренче сәбәбе Табибә катнашында узган әдәби түгәрәк кичәсенә барып тоташа. Кыз нәкъ менә шунда үз хыялы белән Чаллы тормышы арасында әллә ни зур аерма юклыгын тойды. Бу кичәдә кыз Казанда көеп куырылган канатларының кабат талпынуын сизде.

## Шигырь язасым килә!

«Шифалы яңгыр»ның август аена билгеләнгән дәресе башланган иде инде. Түгәрәк әгъзалары культура сараеның иң тыныч бүлмәсенә кергәннәр. Барлыгы ун-унбиш кеше килгән. Идәндә — йомшак палас, гөлләр. Тәбәнәк кенә кечкенә өстәлләр. Әдәбият сөючеләр кайда икәү, кайда өчәү-өчәү шул журнал өстәлләре янына куелган креслоларга чумган. Өстәлләрендә — куен дәфтәрләре, кәгазь битләре.

Табибә, Зөһрәне җитәкләгән хәлдә, түрдәге өстәл янына узды. Болар урнашуга, күрше өстәлдәге бер кыз Зөһрә белән Табибә каршына уймак кадәре генә кечкенә чынаякларга салынган кофе китереп куйды.

Каушатырдай беренче мизгелләр үтеп киткәч, Зөһрә бүлмәдә утыручы кешеләрне күздән кичерде. Монда чигә чәчләре агара башлаган агайлар да, күз төпләре эчкә баткан өлкән үк хатыннар да бар. Яшь кенә кызлар арашында да — олылар чалымы. Иң түр өстәлдә бер генә абый утыра. Җитәкчедер, мөгаен. Аның бөтен йөзен калын иренле ерык авыз тутырган. Күзләрендә елмаю елтырый. Үзе көрәктәй зур учлары белән өзлексез чәчен сыйпый. Чәчләре тыңлаусыз, шуышырга гына торалар, күзләрен каплыйлар.

— Исеме — Идел аның. — Табибә Зөһрәнең кемгә карап күзен ала алмый утыруын чамалаган икән. — Әтисе кушкан исем Фәсхетдин булган, үзгәрткән. Идел Гатин. Инженер, шигырьләр яза.

— Йә, җәмәгать, тагын кем үзенең шигырьләрен укып, шатлыгын безнең белән уртаклашырга тели?

Зөһрәләр килеп җиткәләгәнче, мондагылар кемнеңдер әсәрләрен укыганнар иде, күрәсең.

— Сез нәрсә язасыз, туташ? — Гатинның бу соравы Зөһрәгә төбәп әйтелде. — Шигырьме?

— Юк, проза яза ул. — Ярдәмгә Табибә ашыкты. — Анысы да безнеңчә түгел, инглизчә.

— Бик мөмкин.

— Табибә апа шаярта ул. Мин болай гына килдем, тыңларга гына.

— Язык сез, кызлар! Үзең язмасаң, кеше язган шигырьне ятла да сөйләп йөр! Хис белән яшәргә кирәк, хис белән! — Гатин бу сүзләрне Зөһрәгә генә түгел, күбрәк үзенә сөйли сыман иде. — Хиссез тормыш ашау өчен генә яшәүгә кайтып кала. Нинди хурлык!

Ул арада ишек төбенә үк терәтеп куйган өстәл ягыннан:

— Минекеләрне дә тыңлап карагыз әле, зинһар! — дигән үтенеч ишетелде.

Аңа берәү дә җавап-фәлән биреп тормады. Без тыңларга әзер дигәндәй, бары берьюлы тынып кына калдылар. Шигырь яңгырады.

...Җитди, кырыс, зәһәр карашларың
Ни турында?
Белмим.
Теләгеңне яшермәле миннән.
Сөйлә әле!
Шикләнмә син!
Мин үзем дә шуны гына көтәм:
Аңла әле мине, яле!
Ә аннары...
«Гомерлегем!» — димә,
Артык йөкләр такма сүзеңә.
Миңа хәзер шунысы җитеп ашкан,
Җылыт йөрәгемне,
Гашыйк ит син мине үзеңә!

Зөһрә колакларына ышанырга да, ышанмаска да белми, аптырап калды. Бу сүзләрдән аңа оят иде. Тик бүлмәдәгеләр рәхәтләнеп тыңлый. Алар гүя җирдәге гадилектән аерылдылар. Шигырь укучы кыз тәмам күкләргә үк ашты кебек. Соңгы шигыре укылып бетеп кабат креслосына утыргач кына ул, оялгандай итеп, битен каплады, күзләрен йомды. Тик Идел Гатин:

— Монда бәхәсләшер урыннар бар, — дип, фикер алышырга теләүчеләргә киңәш бирә башлаган иде, кыз тагын сикереп торды.

— Тик, зинһар, теге шагыйрьдәгечә, бу шагыйрьдәгечә дип, каны-

ма тоз салмагыз, — диде. — Башка бер кешенең дә катышы юк, үземнең кичерешләр, үз формам!

— Сабыр итик, — диде Гатин. — Башка иптәшләрнең сүзен ишетик!

Берәм-берәм сөйли башладылар. Чәченә чал кунган агай, сүз сорап алгач, башта кофесын йотып куйды. Аннан шигырьләрне мактап узды. Алдан бер-ике хуплау сүзе әйтү — барысының да уртак гадәте икән.

— Мин нәрсәсен яраттыммы? — диде дә килештергән сыйфатларын санады. — Кыю әйтә. Ихластан әйтә, прәме эчен ачып күрсәтә. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә ирешә, дигәндәй, тыңлавы рәхәт моны, әмма, мин әйтәмен, татар шигырен бу кадәр дә бозу ярыймы?

Шуннан алып китте агай, элеп алып селкеп салды. Алда әйтелгән сүзләрнең исе дә калмады.

Шигырь уку чираты юашлыгы йөзенә чыккан бер егеткә җиткәч, тагын бер кызык хәл булды. Егет башта гадәти генә иттереп, көйгә салып, шигырен укырга да тотынган иде.

...Әнкәй миңа көн дә хатлар яза,  
Хат китерә аның моңнарын.  
Атна уза, хәтта айлар уза,  
Хәбәр итә алмыйм ни барын...

Моның шигырен тыңлаганда бүлмә кинәт тараеп киткән кебек тоела башлады. Алдарак укылган шигырьләрнең дөньяви булмаган өндәмәләреннән ямәреп, дәртләнеп утырган чал агай дөньяны йотардай иттереп иснәп куйды.

Кулындагы кәгазь битләренә караганда, юаш егетнең укыйсы шигырьләре шактый иде әле, тик ул, бүлмәдә утыручыларның йөзенә бәреп чыккан битарафлыктан гарьләнеп булса кирәк, кинәт:

— Әй, укымыйм ла мин! — диде.

Актан, карадан сүз катучы булмады. Егет лап итеп креслосына утырды, уңга-сулга бәргәләнеп алды. Ашыгып кәгазьләрен җыештыргалады, сабырсызланып, кабат сикереп торды, бөгелә-сыгыла, аркылыга атлый-атлый бүлмәдән үк чыгып китте.

Бераздан кемдер:

— Ник китте инде, җүләр? — дип үзенең гаҗәпләнүен белдерде.

Йокымсырый башлаган чал агай:

— Ашамаган бәрәңгесе калгандыр, әйдә, кайгырышмыйк! — диде.

Зөһрә Табибә шигырьләренең язмышы өчен кайгыра башлады. «Әнә нинди кырыслар, ай-ваена карамыйлар, ошамаганны йөзенә бәреп әйтәләр. Ярый ла телгә алып сөйләрлекләре булса! Папка да тоткан үзе, кәгазь бозган, вакыт әрәм иткән, шуларның җыенысы — адәм көлкесе генә дисәләр. Әй, бигрәк кыен икән лә бу шигырь язу».

— Табибә, синең байлыкта ниләр бар? — Гатин да нәкъ Зөһрә кебек, бераз шикләнеп, әмма яхшыга юрап сорады. — Әйдә, укы!

Зөһрә, башын арткарак ташлап, Табибәгә карап тора башлады. Кранчы кыз, күзләрен түшәмгә текәп, сүзсез калды. Кулындагы кәгазь битләренең аңа һич кирәге юк икән, язганнарын ул яттан белә.

Йокымсырый башлаган кешеләр кабат дәртләнеп киттеләр. Бүлмә дә иркенәеп, һавасы сафланып калды сыман. Тәрәзә буйларына идәнгә куелган гөлләр дә кызның очына-очына әйтелгән сүзләрен тыңлый кебек иде.

...Таулар биек диgән булалар.  
Кранымны көйләп куярмын да  
Сез: «Иң биек!» дигән тауларга,  
Иртән килеп, очып менәрмен лә:  
Сезнең якка кабат карарга,  
Җыр сузармын, сагыну җырымны  
Сез ишетсен өчен түгел лә!

Таулар тыңлар әле, яңгыратырлар,
Кабатларлар җырны, таратырлар!
Беркем белмәс миннән чыкканны.
Сез әйтерсез тагын: таулар биек!
Таулар түгел, биек таулар түгел,
Бөек җаннар тота дөньяны!..

Кыз сүзләрне, күзләре текәлгән түшәмнән чүпләгән кебек, тоташ бер тын алу белән тезде-тезде дә шул шигырьләрнең дәвамы кебек үк иттереп:

— Иә, сүтегез инде хәзер! — диде. — Бетте.

Табибәгә кагылышлы тәнкыйтьне тыңлау Зөһрә өчен бигрәк кыен булды. Ул аларның күбесен ишетмәде дә, ишетергә дә теләмәде. Шулай да берәүгә дә сүз әйтмичә калмаучы чал агайның:

— Син, сеңел, кран очына очып менүләреңне оныт әле! — дигәне колакны ертып керде. — Башкачарак итеп әйт, или үзеңнең краңчы булуыңны онытып тор!

Кызлар бүлмәсендә бер сүзгә мең җавап табучы Табибә, кешеләр үз шигырен тәнкыйтьләгәндә, ләм-мим бер сүз дә әйтә алмады. Бая югарыга караган күзләре идәнгә текәлгән, үзе комач булган.

Зөһрәнең аны үзе кебек иттереп: «Җаныемдыр ла, Табибә апа, хыялый җанымдыр ла!» — дип, иркәлисе килеп китте.

Чыгышларны Идел Гатин үзе йомгаклап куя. Ул түгәрәк члennарының кечкенә генә табышын, матур чагыштыруларын, фикер байлыкларын — һәммәсен билгеләп үтте. Яңа шигырьләр турындагы сүзләрне утырышка гомуми йомгак ясауга китереп чыгарды.

— Эшебезне житди алып барсак, — диде, — мин шәһәребездәге әдәбият сөючеләр, яшь иҗат көчләре әсәрләреннән төзелгән җыентык чыгару турында сүз кузгатачакмын. Аңарчы Казандагы газета-журналларда үзебезгә багышланган битләр оештырып булмасмы әле. — Ул кылдай чәчләрен сыйпаудан туктап, башын чайкап җибәрде. — Теләгебезне аңларлар, шәт.

Житәкченең һәр сүзен илаһиландырып тыңлаучы Табибә:

— Таләп итәргә кирәк, Идел ага! — диде.

— Чыннан да, инәлеп-нитеп тормаска! Бер баржа цемент сорамыйбыз! — Чал чәчле агай да сүзгә кушылды. — Бер кочак шигырь илтергә дә тоттырырга үзләренә!

— Их, җәмәгать, — диде Идел Гатин, — без күп нәрсәне аңлап җиткермибез. Миңа шул мәгълүм: хәзер редакцияләргә алына торган корреспонденцияләрнең туксан процентлабы шигырь калыбына кертеп язылган.

Кемдер аваз салды.

— Безгә язып азапланасы да калмаган инде алайса...

— Без гаять әһәмиятле эш башкаручы кешеләр арасында яшибез, үзебез дә шул ук хезмәт кешеләре. — Гатин саксызлык белән башлаган сүзне хәзер ничек очларга белми аптырады. — Дөньяның бер шагыйренә дә тимәгән зур бәхет бу. Безнең шигырьләр дөньяның иң зур заводы гөрләгән җирдә язылуларын әллә кайдан кычкырып торырга тиеш. Отсак, шуның белән отарбыз.

Кешеләр йөзеннән елмаю йөгереп узды. Шул арада Гатин да фикерен ныгытырдай яңа дәлилләр тапты.

— Нигә куркып калырга? Тормышта һәр эш мең көрәш, мең газап аша гына җиңеп чыкмыймыни? Хәтерегездәдер: «КамАЗ» маркалы беренче машинаны җыю өчен, аңа кирәк детальне кою өчен, аны сынап карау өчен нинди ярыш оештырылган иде. Беренче кабинаны җыю хокукына ирешкән Рамазанованы беләсез бит, иң өлгер дигән бәяне ул үзе кебек йөзләгән җыючылар белән сынашып яулап алды

Йөзләр житдиләнде. Хәзер инде кабат шигырьләр турында сөйли башларга да мөмкин иде.

— Әдәби осталыкны секундомерда да, бизмәнгә салып та исәпләп булмый. Әдәбият кеше күңеленә ничек тәэсир итүе белән кадерле. Укучы синнән сафлык көтә, син бер генә ясалма аваз җибәрсәң дә, кичерми. Ни өчен дөнья ябырылып Мусаны, Айтматов, Гамзатов, Шолохов, Межелайтис әсәрләрен укый?..

Җитәкче үз сүзләреннән үзе үк рухланып китте бугай, аны хәзер бер көч тә туктата алмас төсле иде, сөйли дә сөйли.

— Без бер генә мизгелгә дә онытып тормаска тиешбез: һәр тармакта өзлексез көрәш бара. Такташ аны гаҗәеп төгәл һәм матур итеп шигырендә дә әйтә алган.

...Табигатьнең иркен күкрәгендә
Мәңге көрәш,
Мәңге хәрәкәт,
Мәңге туу,
Мәңге артып тору
Белән бергә
Үлем — һәлакәт!..

Өзекне укып бетерер алдыннан Гатинның тавышы ишетелер-ишетелмәс булды.

— Әдәбияттагы көрәш — иң кискен көрәш, әдәбият кешеләрнең җанын даулый, акылларын яулап алуны максат итеп куя!..

...Шушы түгәрәк тәэсире булды бугай: Зөһрә Чаллыдагы бөтен кешенең күңеле шигърилеккә тартымдыр дип йөри. Җаннары күкләрдә йөзгән шул кешеләрнең хезмәтенә бәләкәй генә үзгәреш кертергә, яңалык өстәргә теләгән өчен, аңа: «Кит!» диләр. Ничек кыюлыгы җиткән ул Мәрвиянең?

Әллә бу яман сүзне ул үз җанын кая куярга белмәүдән, ачуын кемнән алырга аптыраганнан гына ычкындырды микән? Гашыйк булган кыз баланың: «Кит!» диюен әллә ни тирәнгә алмыйча үткәреп җибәрергә кирәктер, мөгаен.

## Кемне юксына егет?

Кайтырга чыкканда, Зөһрәнең гаҗәпләнүенә каршы, шактый соң иде инде. Вакыт узганы тоелмый да калган. Культура сарае кызлар тулай торагына яп-якын. Табибә белән Зөһрә бер-ике минуттан бүлмәләрендә булачак. Зөһрәнең никтер анда керәсе килми. Табибә белән гәпләшәсе килә. Зөһрә адымын бик акрынга көйләде.

— Кай арада язасың соң син, Табибә апа? Шимбә көнне дә эшлисез, институтта да укыйсың.

— Шигырь җене кагылса, кайчан язганыңны үзең дә сизми каласың аны. — Табибә бик теләп, һич иренмичә сөйли башлады. — Кран кабинасында да блокнот тора минем. Әллә шуңа инде эшкә шул кадәр ашыгып барам, кранны әллә кая алып киткәннәрдер төсле. Җаныемдыр ла, Зөһрә, мин бит, кранчы булам дип, бик тырыштым. Инде менә сигез ел эшлим. Разрядым — иң югарысы. Ярышларда үз идарәбез буенча гел алда барам, ирләрнең ачуын китереп бетерәм, күңелем әле һаман кранда эшләвемә ышанмый. Шигырьне дә миннән шул кран кайнатып чыгара инде.

Киң урамның аргы ягыннан гармун тавышы ишетелде, берәү аңа кушылып җыр башлады. Чыңгылдык трамвай тавышы да, узгынчы

машиналар гүелдәве дә, якындагы төзелешләр шавы да яшь егет моңына комачаулый алмый.

Зөһрә аны башта ишетмәде. Табибәнең, ачылып китеп, үз мавыгулары хакында сөйләве мөһимрәк иде. Табибә исә барган җиреннән шып туктап калды. Әлләниләр сөйләргә ниятләгән теле әйләнмәс булды. Кыз көй ишетелгән якка караган да, дөньясын онытткан. Зөһрә шуннан соң гына игътибар итте.

— Әллә Илһам Шакиров инде? Бигрәк көчле тавышы!

Табибә, Зөһрәгә җавап бирүдән бигрәк, үзен-үзе ышандырырга теләп, бу могҗизаның шушында, аның янында гына булып торуын расларга ашыгып:

— Ул! — диде.— Ул! Үзе уйный, үзе җырлый!

— Кит әле, Табибә апа, нишләп Илһам Шакиров урамда гармун уйнап йөрсен?

Табибә җырчының артист түгеллеген әйтеп тормады, иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдатып, «ул» дигәненең исемен атады.

— Бәхти! — диде. — «Пятачок»тан таралышалар. Анда мин бара алмаган көнне баянда Бәхти уйный.

— Үзең уйнап җырлау кыен микән ул?

— Юк. Җырлаганда уйнамый, аккордлар гына биреп тора бит ул, тартып-тартып кына ала, менә тыңлап кара!

Чыннан да, шулай икән: егет җырның сүзләрен тәэсирләнеп җырлый башласа, баян тавышы бөтенләй ишетелмәс булып кала.

> ...Утлар сүнде, йолдызлар да сүнде,
> Таң нурында йөзә болытлар.
> Сүнсә сүнсен утлар, йолдызлар да,
> Миндә әле сүнмәс өмет бар!

— Бигрәк матур җырлый инде!

Табибә дәшмәде, аның күзләре җырда телгә алынган йолдызлар, нурлар кебек балкый иде.

— Мәрвия апага җырлыйдыр инде ул аны?

— Юк. Аңа түгел.

> ...Синә тагын мин бер килэм әле,
> Йолдызларда минем эшем юк!

Табибә, елмаеп, кулын селтәп куйды.

— Ну, Бәхти, тәки ялгыш җырлый бит! Һаман төшереп калдыра!

Зөһрә Табибәнең тиктән генә хата эзләп маташуын яратмады, кайда ялгыш китүен җентеклəбрәк тыңлап карарга булды.

> ...Сине тагын мин бер күрәм әле,
> Синнән башка сөяр кешем юк!

— Дөрес ич, Табибә апа, радиода да гел шулай җырлыйлар.

— Дөрес сиңа! «Ля»ны төшерә дә калдыра, төшерә дә калдыра.

Зөһрәнең аерым ноталарны атый-атый бәхәсләшерлек музыкаль тыйлеме юк иде шул.

— Ә-э, — дип сүздан ары китә алмады. — Мин ул кадәресен белмим шул. Сез нотный грамотаны да беләсезмени?

— Баян уйнарга өйрәнгәндә, иң элек нота ятлый башлыйсың инде. Бәхти белән бергә йөрергә тотынган идек без. Ул авылда чакта ук уйнаган, минем кулга беренче алу. Нота ятлата башладылар да, Бәхти түгәрәкне ташлап китте. Ул бөтен көйне яттан уйнап йөри. Иң матур авазлары коелып кала... — Табибә көлеп җибәрде. — Мин аңа аңлатырга тырышам, колагына да элми, «минем күңелем тулы нота, үз моңым да җитеп ашкан», — ди...

Табибәнең сүзе кырт өзелде, өй чатына Бәхти килеп чыккан иде. Япа-ялгыз, кырдай киң урамны бер итеп, салмак кына атлап, җырлый бирә. Бер сулу җыры тәмамлангач, егет барган җиреннән туктый, баянын каерып сузып җибәрә, гүя ул: «Мин генә аңлатып бирә алмыйм, әйдә, баян, син дә тырышып кара әле, йөрәк ярсуымны син аңлата алмассыңмы ичмасам!» — ди кебек. Баян, үкертеп, көйне яңадан уйнап чыга, җырны тагын да ераккарак илтә, биеккәрәк күтәрә, йолдызларның үзләренә үк иштеттермәкче була сыман.

Табибәнең бөтен барлыгы Бәхти ягына омтылды. Юк, аяк атлап аның янына китмәде ул. Җаны шул моң ягына очты, күзләре егет гәүдәсеннән аерылмас булды, сулуына кадәр: «Менә ул!», «Менә ул!» дип алына кебек иде.

Әйтерсең лә шул омтылыш тартып китерде, кызлар аны-моны абайламыйча да калдылар, каршыда Бәхти басып тора иде.

— Табибә! — диде ул.

Аның тавышы җырлагандагысына да, моннан берничә сәгать элек пристаньда Зөһрә белән сөйләшкәндәгесенә дә һич охшамаган. Әллә нинди: үтенечле дә, моңлы да, горур да, һавалы да.

Табибәсе исә сүзне сәламләшүдән дә, әле генә тыңлаган җырны бәяләүдән дә башламады.

— Беләсеңме, Бәхти, мин кемне таптым! — диде.

Егете дә, гомере буе Табибәнең шул сүзен генә көтеп торган кеше шикелле, авызын ерып җибәрде, хәтта буйга да бер карыш үсеп киткәндәй булды.

— Кемне, Табибә?

— Менә! — Табибә учы белән Зөһрәнең аркасын сыйпарга тотынды. — «Папаша»ның кызы Зөһрә!

Бәхти ике кулы белән Табибәнең иңбашларына килеп ябышты. Зөһрәне үзенең дә белүен, аның Бәхти өчен дә кадерле кеше икәнен аңлатырга тотынды.

— Җаныемдыр ла, Һади абый әле ул сине дә укыттымыни соң, Бәхти? — Табибәнең куанычы эченә сыймый иде. — Ник син аны миңа әллә кайчан сөйләмәдең?

— Кем белә бит, кем белә? Син һаман «папаша» да «папаша» дисең, ә без Һади абыйга андый кушаматлар такмаган ич!

Сүз башлары Зөһрә булса да, болар кунак кызын бөтенләй онытсылар. Берсеннән-берсе уздырып, Һади абыйга бәйле истәлекләр сөйләш китте. Бәхтие тузга язмаган бер кыйссаны исенә төшерә дә, Табибәсе, аңа ялгап, икенчесен сөйләргә тотына. Табибәнең истәлекләре бихисап күп, кызыклы иде. Ул алар хакында мавыктыргыч итеп, бөртеген дә түкми-чәчми, тәмләп сөйли дә белә.

— Син минем буемны ничә сантиметр дип уйлыйсың? — дип, чираттагы истәлеген башлар алдыннан ул Бәхтидән сорады.

— Ну-у, — егет бераз чамалап торды. — Йөз алтмышлар бардыр.

— Минем буем йөз дә илле дүрт сантиметр. — Кыз Бәхтинең ялгыш әйтүеннән бик канәгать иде. — Һәммәсе шулай ялгыша. Менә карагыз! — Табибә, бераз читкәрәк атлап, тыңлаучыларның кабат үз буена игътибар итүләрен үтенде. — Мин һәрчак буемның төзлеген саклыйм: басып торганда да, йөргәндә дә. Бу хәл буйны чынбарлыктан озынрак итеп күрсәтә. Ә ник мин төз?

— Атаң-бабаң шундый булгандыр, Табибә.

— Юк, бу — ялкаулар сүзе, Бәхти-күз алмам. Теләсә, һәркем гәүдәсен шәм күк итеп саклый ала.

Шул сүзенә ялгап китеп, Табибә Һади абыйның яңа мәзәген китереп чыгарды.

Бер дәресне тәмамлар алдыннан укытучы такта янына ике баланы чакыра. Ул аларны физкультура дәресендәге кебек үз командасына

йөртә, уңга-сулга борылырга, «смирно»га басарга куша. Соңыннан классска сорау бирә.

— Йә, ни күрдегез?

Төрле яктан әйткәлиләр.

— Нигә, абый, дөрес йөрделәр ич?

— Аз гына артка калды берсе...

Укытучы бөтен сүзләрне тыңлап бетергән дә:

— Берегездән дә мин көткән сүз чыкмады, — дигән. — Бик беләсегез килсә, әйтим, болар йөри дә, борыла да, хәтта басып тора да белмиләр! Кызганычка каршы, арада күпләрегезнең гәүдә тотышы дөрес түгел. Бездә этика, эстетика дәресләренә вакыт бирелми, ә үз-үзеңне тота белүнең мең кагыйдәсе була. Сез аларны белергә тиеш. Өйдә өйрәтер кешеләрегез юк сезнең, бүгеннән башлап бу вазифаны мин үз өстемә алам. Яшьтән өйрәнмәсәң, соң була.

Һади абый өйрәтә башлаган.

— Үз-үзеңне дөрес тоту дөрес утыру, дөрес басып тору, дөрес йөрүдән башлана. Кәкрәеп, боргаланып-сыргаланып тору кешенең табигать биргән матурлыгына кимчелек китерә, аның горур кыяфәтен кимсетә...

Зөһрәгә әтисенең бу өйрәтмәләре яхшы таныш. Һади абый өйдә дә үз балаларын дөрес йөрергә, өстәл янында дөрес утырырга өйрәтә-өйрәтә алҗытып бетерә. Аның бу «дәресләрендә»ге иң кыен бер күнегүне Табибә Бәхтигә дә аңлатып бирде. Күнегү моннан гыйбарәт: арканы, үкчәләрне, башны артка терәтеп, стена буена басасың. Баш өстенә мөлдерәмә су тутырылган стакан куела. Син шул хәлдә йөреп китәргә тиеш. Аз гына боргалана башласаң да, стакандагы су сине чылата. Бала ничек тә төзлеген сакларга тырыша. Күнегүне көн саен кабатласаң, ай дигәндә гәүдәне төз тоту гадәткә керә.

Зөһрәнең бу сүзләргә һич тә кәефе китмәде. Хәтта ул әңгәмәгә кушылды, өстәп-өстәп җибәргәләде.

Монда сөйләшеп тору барысына да бик рәхәт иде. Бәхти аеруча шат. Тик Табибә сүзне «кырт» туктатты, тулай торак ягына борылды.

— Карале, Табибә, дим, Һади абый кызы белән очрашуыгызның шатлыгы хакына мине дә тулай торакка алып кер әле, ә! — Бәхти, Зөһрәгә һич аңлашылмаганча, әрсезләнеп китеп, кызларның юлына аркылы басты. — Син әйтсәң, кертәләр бит инде...

— Юк, Бәхти, таралышыйк! — Табибә үзе егет сүзен кире кага, тавышы башкача яңгырый. «Үзем дә шулай итәр идем, минем дә синең белән кара-каршы утырып чәй эчәсем бик килә!» ди сыман. Күзләре дә тирә-юньне күрми, мөлдерәтеп Бәхтигә караган. Тел дигәне генә кирәкмәгәнне такылдый. — Тәмле аш күп булмый дигәндәй... — Ул сүзләренең ихластан чыкмавына үзе дә уңайсызланып китте, сүзен икенчеләйгә борды. — Җаныкайларым ла, иртәгә алтыдан кузгалып эшкә китәселәр барын онытмыйк!

Зөһрә лифтта башына сыймаган буталчыкны чишәргә теләп:

— Бәхти абый кереп чыкса да буладыр иде инде, — диде. — Мәрвия апаның да өйдә чагы.

Табибәнең җавабы авызга суккандай итте.

— Ул Мәрвия апаң булмасына керергә сорамады бит! Күпне кочакласаң, аз учларсың, дигәннәр. Тыела белергә дә кирәк.

— Ай-һай, бигрәк кырысланып киттең әле, Табибә апа.

— Син барын да аңламыйсың. Шулай кирәк. Егет халкы янында җәянең катырак тартылуы хәерле. Әтиең безне өйрәтә иде, җәя каты булсын, кызлар, җәя каты булса, синга таба ныграк тартылырлар.

Ул сүзен тагын «кырт» борып куйды, китә башлады.

— Ярый, сеңел, тыныч йокы, — диде. — Иртәгә эшкә!

Зөһрәнең эче «жу-у» итте. Иртәгәге көн аңа таңы атмас төн шикелле. Аның бөтенләй тумавы хәерлерәк. Караңгыда авылга кайтып керүе җиңелрәк булыр иде. Берәү дә күрмәс, берәү дә артыннан: «Кара, Һади кызы икеле алып кайткан!» — дип калмас. Зөһрә мыштым гына өйгә узар, әнисенең кочагына атылып елап җибәрер.

— И-и, бәбкәм, булдыралмадыңмыни?

Зөһрә калтыранып куйды. Аһ, бу өскә ябырылган күңелсезлекләр шулай дерелдәп киткәндә коелып төшә торган булса икән!

Мәрвияләр бүлмәсенең ишеген ачканда, Зөһрәне тагын да күңелсезрәк уйлар биләп алган иде. Тик кыз юкка гына борчылган булып чыкты. Бүлмәдәгеләр әле йокларга җыенмаганнар да, өстәл янына утырган бер карчык белән гәпләшәләр. Карчык борчулы, аның тавышы да кемгәдер янаулы, ачулы чыга.

Бу — тулай торакның коридорларына, кызыл почмагына күз-колак булып, идәннәрен юып, тузаннарын сөртеп торучы чуваш карчыгы Матрена түти икән.

Ул кызлардан судка гариза яздыртырга кергән. Гомер иткән карты Степан дәдәйдән аерылырга ниятләп йөрүе. Кызлар, үз башларына андый хәлләр әле төшмәгән кешеләр булсалар да, карчыкның бу адымын хупламыйлар. Кайсы көлеп, кайсы үгетләп, Матрена түтине ниятеннән кире кайтарырга тели.

Эш болай булган. Карт белән карчык, гомерләрен шәһәр шартларында җыеп бетерергә чамалап, Чаллыга килгәннәр. Степан дәдәй каравылчы икән.

Тик боларга баштан ук квартира бирә алмаганнар, икесе ике тулай торакта яши башлаган. Шәһәрдәге тәртип буенча, билгеле бер сәгать җиткәч, кызлар торагына ир-атны якын да җибәрмиләр.

Карт белән карчыкка бу шарт та әллә ни куркыныч тоелмаган. Берничә айга түзмәслек нәрсә түгел. Әмма ләкин бу дөньядагы хәлләр гел син дигәнчә генә бармый. Матрена түти бүлмәсендә тәмам пешеп житкән тагын бер кыз яши икән. Ул кызга теле төк ярырдай сүзчән бер егет гашыйк булып та өлгергән. Ике яшь-җилкенчәк исә төне буе аерым торуны һич өнәп бетерә алмый. Кызы янына ишектән керергә рөхсәт булмагач, егет су торбасы буйлап үрмәли-үрмәли икенче катка менеп-төшеп йөрергә өйрәнгән.

Яңгырлы салкын бер кичтә әби әйтә куя:

— Әй, улым,— ди.— Менә син монда рәхәтләнеп кайнар чәй эчеп утырасың, минем Степан анда, юеш кожанын кыштырдатып, малай-салай арасына кайтып бара инде... Өйрәт әле аны да! Менсен әле яныма шул синең торба буйлатып!

Карт та коткыга бирелә. Каравыл чиратын уздыргач, мут егет куышканча, карчыгының тәрәзәсе төбенә килеп баса. Егет алга-артка карангалап ала да, үрмәләп менеп китә. Үзе бабайга:

— Әйдә, калма минем арттан! — дип кычкыра.

Кеше кылана бит әле, дип, Степан дәдәй дә, бичара, кылкынып куя, ике куллап, ике аяклап калай торбага ябыша. Бер-ике сөям өскә дә үрмәли. Артыгын булдыра алмый, хәле китә, башы әйләнә, шул чак каттан дружиначы егетләр килеп җитә.

Эш зурдан куба. Сорау алулар, акт төзүләр. Бабай гел бер сүзне кабатлый. «Карчыгым коткысына бирелеп хур булдым»,— ди.

Матрена түти исә кызыл бәйләгән егетләр алдында мондый гаепне үз өстенә алырга теләми. Әй, гарьләнә, әй, үртәлә! Ачуыннан ирен аерырга ниятли.

Мәрвия белән Марина никадәр генә үгетләсәләр дә, ул, үз теләгеннән кире борылмады. Ике сүзнең берендә: «Аерылам булгач, аерылам! — дип яный.— Башта ук хаталан-

ганмын. Акылы бар кеше Степан атлы адәмгә кияүгә чыгамы? Ул бит, син фәрештәгә әйләнеп күккә күтәрелә торган җан булсаң да, артыңа тибеп калу ягын карый торган имансыз нәрсә!..»

Үзе битәрли, үзе елый карчык. Мөлдер-мөлдер аккан күз яшьләре карчык күзенең төсен җебетә сыман, яшькелт-зәңгәр күзләр төссезләнә, сыегая бара кебек.

Зөһрә бу тамашаны читтән генә карап торды. Әбинең хәлендә һичнинди фаҗига күрмәде. Яшең алтмыштан ашкач, иреңнән аерылып кай җәһәннәмгә бармак кирәк? Әйтерсең лә ул юри, үз башына төшкән бер кызыкны сөйләп, кызларны көлдерергә генә кергән.

Кайгы кайгыга охшамый, кайгы савыты бушамый дигәндәй, Зөһрәнең үз хәле — юл башында аттан төшеп калган җәяүле хәле. Башын җүләргә салып кына чыдый. Кешеләр сүзеннән арынган арада, кайгысы исенә төшә дә йөрәге «жу» итә.

Төне йокысыз үтте. Аны үзе башка шәһәргә, һөнәре буенча тәҗрибә тупларга киткән кызның буш караватына салганнар иде. Шактый арылган. Йокла да йокла бит инде изрәп! Юк. Йокы дигәне керфек очына кагылып та карамады. Әйләнде дә тулганды кыз. Кызлар йоклап киткәч, аларны уятудан куркып, әйләнергә дә шикләнә башлады. Күңелне эч пошуның һич чыдап булмастае басты. Алдагы көнгә терәк итеп санардай бер генә таяныч та таба алмый интекте ул. Азга гына онытылып торып, йокы сөреме сыман нәрсә басса, Зөһрә коточкыч хәлләрдән торган төшләр, саташулар дөньясына килеп керә. Коты алынып, тагын уянып китә.

Таң яктылыгы сизелә башлагач, җанны кая куярга белми кыйналу тагын көчәйде.

Мондагы кызларның күңелле тормышын күрү Зөһрәдәге үкенечле уйларны куертып кына җибәрде. Хәзер ул үз хәленә җиңеллек китерердәй бер генә аклану да тапмый.

Күзеннән агып чыккан кайнар яшькә Зөһрә башта игътибар да итмәде. Елагач, рәхәтрәк булып китте әле. Уйлар тоныклана төште, җанга битарафлык сарылды. Кайнар тамчылар мендәрне чылаткач кына, кыз сискәнеп куйды. «Кеше урын-җире бит бу! Лышкылдап, җебеп ятуыңны, мендәр тышын тапландыруыңны бик тансыклап торалардыр дип беләңме?!.»

Еларга да хакы юк иде аның. Тик ни хәл генә итәргә соң: елавы да, көлүе дә — бер кнопкага гына басып башлана да, бетә дә торган хәлләр түгел. Үз иркендә генә булса, кеше елау дигәнен, кайгы дигәнен бөтенләйгә белмәскә дә бик ризалашыр иде.

Елау-еламау турында уйлана башлагач, хәсрәт тагын тирәнәйде. Керфекләр арасыннан тыенкы гына агып ятучы күз яше хәзер бүленеп-бүленеп чыга, үксетә башлады. Пыскып ятуын кызлар сизеп алуыннан коты алынып, Зөһрә мендәргә капланды. «Үксегәнемне ишетә күрмәсеннәр!»

Таш астында баш асрарга өйрәнеп өлгергән бу кызлардан ни дә булса яшерү мөмкинме? Мәрвиясе ничектер, Марина әллә кайчан сизгән. «Ни булды?» — дип сорап та тормады. Сәбәбен дә аңлый, димәк. Сүзен коры башлады ул.

— Мышкылдап ятма, әйдә, тор!— диде.— Мин сине үзем белән алып китәм. Казаннан сөенечле хәбәр алып кайтмыйсың, ичмасам, әниеңә КамАЗ төзүчеләре хакында сөйләрсең. Күреп кит!

Мәрвия юынырга чыккан иде. Кергәч, Зөһрәнең җыенуын күреп, киңәшләр бирә башлады. Күрәсең, кызны Мариналарга илтүне алар икәү алдан ук сөйләшкәннәр.

— Каралырак күлмәгеңне ки, сеңелем, кер күтәрердәен. Хәер, Марина комбинезон да табар әле...

— Мин бит авылга кайтырга тиеш идем.— Зөһрә өзеп кенә баш тартырга да кыймый, кеше сүзен аяк аска салу була.— Автобус ничәләрдә икән соң?

Марина икеләнүләргә юл калмаслык итеп аңлатты.

— Беренчедән, син әле авылга кайтырга тиешле кеше түгел; икенчедән, Бәрәңге Тамак авылының юлы такыр, сменадан соң да китеп өлгерерсең. Берәүнең дә күзенә күренмичә, бәрәңге бакчасы артыннан кайтып керү өчен, караңгы төшкәч, иң кулай вакыт була.

Ишетмәсәң, ишет әнә! Дөресен әйтә бит. Зөһрә бүген телдән имтихан бирергә тиеш кеше. Кич кайтып керү турында да Зөһрә нәкъ шулай уйлый иде.

Мәрвия, Мариканың артык кырыс әйтеп ташлавы эшне җимереп куймаса ярар иде, дип, өркебрәк калган иде. Мондый чакта исә кырыслану хәерлерәк. Зөһрәнең уфыруы кимеде. Кыз, Марина ни кушса, шуңа күнеп, эшкә җыена башлады...

...Авылга кайту кирәклеген сүзгә кыстырып маташса да, шушы адымының хәлиткечлеген тойган иде инде Зөһрә. Маринага ияреп, төзүчеләр арасына керергә бер җөрьәт иткәч, ни йөзең белән, юк, мин сезнең арада эшләр өчен тумаган, дип, кире чигенмәк кирәк? Эш урыны — музей түгел, аны тамаша кылырга гына йөрмиләр, анда тир агызып эшлиләр. Зөһрә хезмәт юлын шушы ачы хакыйкатьне тирәннән аңлап башлады. Чаллыда калды. Беркая дә китмәячәк.

## Кызларны туйлар көтә

Марина Майна бригадасы эшли торган төзелеш мәйданы тулай тораактан ерак түгел иде. Алар җәяү генә бардылар. Капкадан керүгә Марина:

— Тагын нидер булган,— диде.— Эшкә тотынмыйча, мине көтәләр.

Шикләнү дөрескә чыкты. Кызлар, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, Маринага бригада өчен бик үк куанычлы булмаган хәбәрне җиткерделәр.

— Безгә, итәкләребезне җыештырып, юлга әзер торырга, синең участок начальнигына керергә куштылар.

— Отчаливать итәргә әмер килде, бригадир.

Хәбәр таңнан ук бригадирның кәефен бозачагын белгәнгә, икенчеләре, мәсьәләгә җиңел төсмер өстәргә тырышып, тиз-тиз сүзгә кушылдылар.

— Сөенчегә — бәрәңге! Әйеме, Марина?

— Китсәк китәрбез инде, әллә беренче китүме, дөнья харап булмаган.

— Әйтмә дә генә, баш ярылып, күз чыкмаган әле, кая да эш...

— Яхшылап кына берегез генә аңлатыгыз әле, көзге сыерчыклар кебек чыркылдашасыз. Кем участогына җибәрәләр икән?

Марина Майнаның кәефен кырам дигән кешегә ике юл бар. Берсе — бригада буяп, сылап, тәмам әзер хәлгә китереп калдырган бинага вакытында эшләргә өлгермәгән сантехникларны кертеп җибәр. Ачуы чыкмый хәле дә юк: буяучы агарта торсын, икенче яктан, слесаре, сантехнигы кереп, стенаны тишеп чыгып китсен. Бу башбаштаклыкка юл куйсаң, бригадаң гел бер бинадан чыгып китә алмый интегәчәк. Син стена шомарт, ә слесарь аны тишә торсын, торба сузсын. Син аның артыннан тагын кер, тагын шомарт, тагын агарт. Эш гел бер урында әйләнә дә тора.

Ул чагында Марина бригадир да түгел иде әле, Шакирә бригадасында эшли генә башлаган иде. Үзе әле генә бизәп чыккан бүлмәгә алып-

тай слесарьның тешле тишкеч тотып кереп китүен күргәч, зур тавыш күтәрде. Шакирә аны тынычландырмакчы булды.

— Тавышланма, күзалмам,— диде.— Без шуңа өйрәнгән инде. Җитешми бит сантехниклар.—Чаллыга бу яшь-җилкенчәкләр килгәнче үк төзелештә унбиш ел эшләгән Шакирә мондый хәлләргә янган-көйгән дә, хәзер аның өчен болар гадәти хәлгә әйләнгән.— Тавышланма!

— Буяучыларыгыз җитеп ашканмыни? — Марина үз таләбенең урынлы икәненә һич шикләнми.— Буяучылар да җитешми бит!

— Күрәсең, дәрәҗәбез түбәнрәктер инде, күзалмам, башкача ничек кенә аңлатыйм соң?! Ямьсезләнешүдән ни файда, стенаны шомартмый китмибез бит инде барыбер дә...

Марина да килешкән кебек күренгән иде. Ат башы сыешлы яңа тишекне дә дәшми-тынмый гына кабаттан сылап куйды. Әмма ачуын эчтә калдырган икән. Башта сүзне комсомол җыелышында күтәреп чыккан, «ду-у» килешкәннәр. Аннары төзүчеләр слетында. Тирә-юньнән җыелган егет-кызлар, берсеннән-берсе уздырып, үз эшләре белән мактанышып торганда, Марина әлеге бәхәсне әйләндереп салган.

Слеттан соң Шакирәне участок начальнигына чакырдылар. Сүз күперде. Усаллыкка киткәч, Шакирә бригадир да: «Күзалмам»,— дип кенә калмады, еллар буе эчендә саклаган үпкәләрен чыгарып селкеде.

— Түзегез, түзегез, ди-ди, уналтынчы ел мине алдап килдегез, чыдамадым түгел чыдадым,— диде.— Бер-бер бүлмәне дүртәр кат буяп йөргән чаклар булды. Инде бер генә минем сүзне дә тыңлап карагыз: йә иртәгәдән ул исерек сантехникларыгызны графикка буйсындырасыз, йә мин китәм бригадирлыктан.

Шакирәнең кырт кисеп әйтүе тәэсир иткәндерме, әллә Маринаның республика күләм тавыш күтәрүе ярап куйгандырмы — анысын белү мөһим түгел, әмма ләкин эшнең бу ягы тәмам җайга салынды.

Төзелештә әле аннан башка да җанны телгәли торган хәлләр бер олау. Маринаның җен ачуын чыгара торган икенче нәрсә — күченеп йөрү. Үз участогында, үз прорабың, үз мастерың, үз күршеләрең белән ярыша-ярыша эшләп ятканда, тоталар да сине, планын үти алмаган икенче бер бригада эшен башкарырга, ят участокка илтеп ташлыйлар. Монда әллә ни кәҗәләнеп тә булмый, чөнки бу эш иң уңган коллективка батканны коткару төсендә тапшырыла. Шакирә кулы астында эшләгәндә, Марина моның ни икәнен дә белми иде әле. Аларны аердылар.

Училищены әле генә тәмамлаган ябь-яшь кызлар бирделәр дә, Маринаның үзен бригадир иттеләр. Башта кая барып бәрелергә белми интекте Марина. Яшьләре унҗидегә дә җитмәгән. Аркылыны буйга алып сала да белмиләр. Берсе, Клава исемлесе, көпә-көндез кинога китеп барган.

— Бусы нинди гадәт инде тагын? — диде аңа Марина.

— Нигә шул кадәр гаҗәпләнәсез, миңа бит әле егерме биш түгел, унҗиде генә. Сез миндәге теләкләрне үзегезнеке белән чагыштырмагыз, ялгышырсыз,— диде дә кыз Марина битенә төтенен өрде, тәмәке төтенен.

— Тарта да белмисең, ичмасам! — Марина үзе дә акыл сатучы карчыкларга охшап калырга теләми, кызларның гадәтләрен аңларга тырышты.— Бир әле сигаретыңны, менә болай суырсаң, килешәрәк төшә ул.— Ул Клаваның сигаретын үзенә алды. Суырган булды.— Әй, бик начар нәрсә тартасың икән,— дип, җиргә ташлады.

Бригада башта норма дигән нәрсәне һич үти алмады. Марина, елап, Шакирә апасы янына китте.

— Син, күзалмам, алардан норма өмет тә итмә.— Шакирә сабыр гына аңлатып бирде.— Кайсының кулы ниндирәк эшкә ятышлы икәнен күзлә, осталыкка, пөхтәлеккә өйрәт. Тизлек соңыннан үзе килә ул.

Сөйләшкәннең икенче көнендә Шакирә, үз бригадасындагы ике унганын ияртеп, Марина кызлары янына килде.

— Ягез әле, эшләп күрсәтегез әле! — диде ул.— Берегезне килен итеп сайларга кирәк. Сынап карамыйча, сүз кушмыйбыз.

Үзенең унҗиде яшьтә генә булуы белән мактанучан Клава ятьмәгә беренче эләкте.

— Кемгә димләмәкче буласыз?— диде.— Сездә бит сазаган кызлар гына... Ха-ха-ха!

Шакирәнең җавабы әзер икән.

— Белеп сөйләмисең, күзалмам! Кыз сазамый, бал сасымый диләр. Син әнә растворыңны сыегайта төш, куерып беткән, тигез ятмый! Егет кирәк булса, буш итмәбез, безнең бригада хәзер комплексный, сөлектәй электрикларыбыз бар! Бер күрсәң, төшеңә кереп йөдәтеп бетерерләр.

Кызлар акрынлап кысага керә башлады. Чаллыда эшләрнең шунысы рәхәт, монда тырышканыңны тиз күрәләр. Әйтерсең лә эшләгәненне читтән карап торучы бар. Башкаралмастай бер бурычны, илле алла, җиде мулла белән дигәндәй, үтәп кенә чыгасың:

— Һай, рәхмәт яугыры! — дип күтәреп алып китәләр.— Һай, молодец!

Мактыйлар-мактыйлар да, белеп тор, сиңа тагын да җаваплырак яңа эш чәпәп куялар. Бер участоктан икенчесенә план үти алмаучыларга ярдәмче булып йөрү юлына да Марина шулай басты. Мондый эшкә иң булдыклы коллективны гына җибәрәләр. Үз кызларын мактыймактый тапшырылган бу эштән Марина һичничек баш тарта алмый. Дөресен генә әйткәндә, туйдырды инде. Тыныч кына үз кешеләрең арасында эшләп ятуга ни җитә?

Начальникның яңа әмерен ишетергә кергәндә дә ул ачулы иде. «Ничек тә каршы торырга, күченеп йөрүләрдән котылырга иде».

Тик вагонга кергәч, әллә ни чәчелеп китә алмады. Шулай да сүзен үпкәле кинаяләрдән башлады.

— Сез минем бригаданың таркалып бетүен телисез бугай инде? — диде.— Бер генә дә басылып эшли алганыбыз юк бит.

Начальникның сүзе кыска булды.

— Аңлагыз әле, Майна иптәш: трест планының өзелүе сезнең бригадага да матурлык өстәми, шулай бит? Начар трестта, ягъни планын үти алмаган трестта яхшы бригада күзгә дә күренми. Шулай бит?

— Шулай, шулай!

Мариналың үчекләү өчен кабатлаган сүзләрен начальник үз файдасына кабул итте.

— Бик әйбәт. Менә бу договорга кул куй да, әнә, ТЭЦның «вахтовые» килде, җыештырып кит кызларыңны! Унбишәр сумнан «аккордный».

Хезмәт хакының зур булуына да бригадирның исе китмәде. Кызлар акчаны болай да кая куярга белми. Клава кебегенә зыяны да тия әле аның! Акча алган көннән соң эшкә чыкмаган чаклары да була. Начальник, бригадирның ни турында уйланганын сизеп:

— Сүз тыңлаган өчен, көзгә биш кызыңны Болгариягә ял итәргә җибәрәм! Әйткән иде диярсең. Шулай бит!?

Күрше илгә сәяхәт путевкасын һавадагы торнага исәпләп, Марина теләр-теләмәс кенә елмаеп куйды. Монысын кызларга әйтеп тә торасы түгел. Тыңлату кыен булмаячак: «аккордный» наряд белән эшләргә яраталар алар. Бригадир, артык бәхәсләшүне файдасызга санап, килешүгә имзасын куйды.

Бригада эше белән мавыгып китеп, Зөһрәне ул исеннән үк чыгарган иде. Начальник яныннан кире борылганда, кинәт хәтеренә алып куркып катып уйга калды. «Берсеннән-берсе җоррак телле минем кызлар ара-

сында кая керер урын таба алмыйдыр, бичара». Тик аның борчылулары урынсыз булып чыкты. Зөһрә аңа елмаеп сүз кушты.

— Клава исемле кызыгыз килмәгән, миңа аның комбинезонын киярга ярармы?

Маринаны тагын кайгы басты.

— Нәрсә булды икән инде? — Ул бераз тукталып торды. Аннан, эшне исенә алып, кызларына хәлне сөйләп бирде.— Әйдәгез,— диде.— Бер айлык чамасы эш. Йомры бер бинаның эчен сылыйсы бар, ди. ТЭЦның яңа чиратын кызулыйлар...

Көн төшкә авышканда, цилиндр сыман бу бинаның хуҗасы да килде. Ярдәмгә җибәрелгәннәрнең осталыгын, мөмкинлеген тикшермәкче булгандыр.

— Килеп тә җиттегезмени, рәхмәт төшкерләре! Эшли дә башладыгызмы? — Аның күзе маңгаена менеп китте. Иртән сәгать сигезләрдә үк килгән «ярдәмчеләр»нең ваемсыз кыяфәте аны телсез калдырды. Идәннең төрле ягына сибелгәннәр дә кайсы кая чүмәшеп, язып-сызып, китап укып яталар. Берсе кулына сантиметрлы тасма тоткан, бина буйлап нидер үлчи. Читтән карап торган кеше боларны һич тә колактан балчыкка батып стена сыларга тиешле кешеләр дип белмәс, бер фәнни учреждение хезмәткәрләре дип уйлар иде.

— Кайда сезнең бригадир? — Бина яман янгырап китте.— Кайда?

— Исемегез ничек, агай? Танышыйк! — Марина әкрен генә сөйли, тынычлыкны бозмаска тырыша иде.— Мин ул — сез эзли торган бригадир, исемем — Марина, фамилиям — Майна.

— Сезнең исемнең ни шалканыма кирәге бар миңа! Эш кирәк, эш! Килгәнегезгә ярты көн үтте — бер кашык растворны да сыламагансыз.

Марина пышылдауга күчте. Дәфтәр битенә нидер язып-сызып маташучы кызларына ишарәләп күрсәтте.

— Комачаулыйбыз, агай, әйдә, моннан чыгып торыйк, иплән кенә сөйләшик!

Майна бригадасының гадәте шул: «аккордный» наряд булдымы — иң алдан бөтен эшнең күләмен исәпләп чыгаралар. Бригададагы һәр кешенең сәләте, мөмкинлеге дә исәпкә алына. Шул исәпләүләр нигезендә көнгә күпме эш төшүе билгеләнә. Аннары бердәм тотыналар: маңгайларыннан пелт-пелт тир тама, әмма кулларының мастерок тотар хәлләре булганда, алдан билгеләнгән «кирәк»не түгәрәкләмичә туктап калу юк. Мондый чакта аларга кабат-кабат әйтмисең дә. Күп очракта эш күләме гадәти нормадан артык була. Шулай да куркып калмыйлар. «Аккордный» сүзен ишетүгә, бригададагы гадәт буенча:

— Әй, математиклар, әйдә, исәпләп бирегез! — дип, үз араларыннан берәүне эш күләмен үлчәргә, икенчесен эшче көчне чамаларга утырталар. Кайчак беренче чамалауларга шактый вакыт уза.

— Көне буе тик ятабыз, диген ичмаса! — Маринаның аңлатмасы агайны тынычландыра алмады.— Биш сәгатьтән артык китап укып ятырасыз.

— Мин әйтәсе сүземне әйттем, ышанмасагыз, кайтабыз да китәбез,— диде Марина.— Безнең мондый стенаны сылаганыбыз юк. Исәпләп чыгаруы да авыр, үзе конус сыман, үзенең цилиндрик өлеше дә бар, шарга охшаган дияргә дә була. Әйтегез, ничек исәпләргә соң моның өс-йөзен? Берәр формуласын хәтерләмисезме?

Эш таләп итүче агай геометриядән кычкырышуга караганда көчсезрәк иде бугай, ике куллап кирегә селтәнде.

— Һә-әй, җибәргәннәр монда бала-чага, тот дәфтәреңне, яз, бирәм сиңа формула!— дип, китү ягына борылды.—Миңа ыштубы иртәгә иртәдән күрсәтерлек эшең булсын! Бригадирлыктан төшертәм юкса!

Марина елмайды.

— И, агай,— диде.—Кулым — балчыкта, аягым — җирдә, шуннан түбән кая төшермәкче буласың?

Шул чак «цилиндр» эченнән кызларның шат тавышы ишетелде.

— Майна, кер тизрәк, бас пичәтеңне!

Бригадир кәгазьдәге эре-эре саннарга күз йөртеп чыкты. «Оho!», «Эhе», дип, авыз эченнән үзенә генә аңлаешлы сүзләр әйткәләде.

— Барын да исәпкә алдыгызмы, кызлар?

— Менә, яңа кыз, кем, Зөhрәмәле, шул ярдәм итте. Хәтере шәп икән, башта ук аңа кушасы калган!— Кәгазьне кире кулына тартып алган кыз аңлатып бирде.— Шәhәргә кайтып-нитеп йөрмибез. Әлеге агай безгә бер вагонның ачкычын бирсен. Раствор килми торса да, договорда күрсәтелгән көннәргә сыябыз. Растворда тоткарлык булмаса, бер-ике көн алдан ычкынабыз.

— Шуңа барыгыз да ризамы?—Марина эш шартларын кабат әйтеп узды.— Шәhәргә кайтасыгыз килмәсме?

Кемнең дә булса каршы төшүеннән куркып, «баш хисапчы» өстәргә ашыкты:

— Свиданиеләр отменяются. Түзәрсез! Егетләрегезне сынарга бер сәбәп тә булыр: аерым тору мәхәббәт өчен көчле җил кебек тәэсир итә. Сүлпән мәхәббәтне сүндерә, ялкынлысын дөрләтә...

Көлешә-көлешә эшкә тотындылар. Мәйданын исәпләү шактый кыен булса да, цилиндрик стенаны сылау әллә ни җайсыз түгел иде. Почмакфәлән, тәрәзә яңагы, ишек борыслары булмаганга, хәтта җайлырак та әле. Сыла да сыла! Объекты бик әhәмиятле булгангадыр, мөгаен, измәнең дә каймактай үзлесен китергәннәр. Эшне дә кулдан гына эшләтәләр, сиптергечтән өрдерергә ярамый, ди. Кыскасы, тиенделәр кызлар рәхәткә. Башкорт ягыннан килгәне җыр сузды.

...Алыстардан, ай, күренә
Ирәндеккәй тауның ак ташы...

Бөтен бригада җыр моңына изрәп китте. Марина үзенең Украинасын искә төшерде. Гаҗәп бу халык көйләре: бер-берсеннән ни ерак урнашкан халыкларныкы булса да, борынгы җырларында никадәр уртаклык! Сүз белән аңлатып кына да булмый.

Шулай да башкорт кызының икенче куплетын башлатмадылар, «баш хисапчы»ның гайрәтле тавышы ишетелде.

— Әй, солистка! Икенчеләйрәк көй башла әле. Сузасың да сузасың, куллар кыймылдамас булды. Темпны үзгәрт, темпны!

Тегесе дә кыстатып тормады тагын. Бөгелмәле керфекләрен аска иелдереп аз гына чамалап алды да «хисапчы» га: «Әйдә, кушыл!»— дигәндәге кебек ым какты. Аларның җыры дымлы бинада гаҗәеп темп белән яңгырап китте.

...Бу дөньяда без яшибез икән:
Юкка түгел,
Юкка түгелдер!..

Җырда гына түгел, эштә дә кызларның темпы үзен тиз сиздерде. Зөhрәгә дә бер генә минут тик торыр ара булмады. Башта ул бинаның тышкы ягына бушатып калдырылган измәне кызларның зур-зур әрҗәләренә ташыды. Кайсына су кирәк, кайсының шомарткычын-фәләнен китереп бирергә кушалар. Берсе янында эш бетмәстән, икенчесе кычкыра:

— Зөhрә, матурым, бер генә минутка минем янга да кил әле!

Бөтенесе бер җайга төшеп җиткәндә, Марина аңа ашау ягын кайгыртырга кушты. hәммәсе берәр сум акча бирделәр дә төшке аш табуны, кайнар чәй булдыруны Зөhрәгә йөкләделәр.

Ул башта бу зур бурычны үти алуына шикләнеп калган иде, тик баш тартырга кыюлыгы житмәде. Күреп тора бит, мондагы эшен ташлап, башка берәү дә чәй артыннан йөри алмый.

Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, ди. Зөһрә дә, очраган бер кешедән сораша торгач, буфет кебек урын тапты, «цилиндр»дан якында гына бер вагонда чәй кайнатырга мөмкин икәнен белде. Табынны яшел чирәм өстенә тезде.

Җыр тынып калган иде. Кызларның измә чәпелдәтүләре, шомарткыч йөртүләреннән сәер бер көй чыга. Өсләренә карап торсаң, хәйран булырсың. Бер генә артык хәрәкәт тә, кирәкмәгән якка күз карашы салып алучысы да юк. Ашыгу-кабалану да сизелми. Зөһрә бер мәлгә аларга сүз кушарга, табынның әзер икәнен, чәйнекнең чирәм өстендәге табын түренә менеп кунаклаганын әйтергә кыймый торды. Шул юк кына сүз тигез ритмга салынган эшне таркатып ташлар да кабат бу эзгә төшү авыр булыр кебек иде. Кызның нидер әйтергә теләвен беренче булып Марина күреп алды.

— Нәрсә, Зөһрә, син безне ашатмыйча гына эшләтергә уйлыйсың мәллә?

Бөтенесе, борылып, Зөһрәгә карадылар. Аңа шул гына кирәк иде. Ул этисенең сигезенче март көннәрендә, табын тезеп, өйдәге кыз-хатыннарны чакырган чагындагы сүзләрне кабатлады:

— Дәстәрханга тәгам куелды, туташлар! Рәхим итәсез!

Кызлар әле эңгер-меңгер төшкәндә дә эшли иде. Марина гына бүгенгә сылаудан тукталуын аңлатып, эш коралларын юып, чиләгенә тутырып куйды.

— Әйдә, Зөһрә, минем белән!—диде ул.—Мин бер-ике сәгатькә китәм, кызлар. Клаваны эзләп тапмыйча ярамас, җаным тыныч түгел.

Башта алар Клава яши торган тулай торакка бардылар. Кыз өйдә кунмаган булып чыкты. Бүлмәдәгеләр дә аның турында әллә ни сөйләргә атлыгып тормый. Сораган берсе «һе!» ди дә иңбашын сикертә. Һич ачык кына җавап алып булмый. Шулай да җеп очы табылды. Клава үз йортларында эти-әнисе янында яшәүче бер егет янына барып-килеп йөри икән. Адресын да бирделәр.

Егетнең әнисе Маринаның үзен гаепләргә тотынды.

— Ник бер чара тапмыйсыз сез аңа?— диде. —Яратмыйм мин сезнең ул кызыгызны. Улкаемның башларын харап итә бит! Этисе белән мин гел эштә. Виталийның әле эштән чыккан чагы...

Улын яклап маташуын сизгәч, хатыны сүзенә ата кеше дә, боксер эт чыраена охшаш йөзле ир кеше дә, кушылды.

— Эштән чыккан чагы дигән була! Бармы соң аның эшкә кергән чагы? Үз ишен тапкан инде. Өйгә кайтып керәсе булмасын, менә шул!

Ир белән хатын, яннарында чит кешеләр барлыгын онытып, үзара кычкырышырга тотынды. Аларның сүзеннән шул гына аңлашылды: болар эштә чакта, Клава белән Виталий бу өйдә рәхәт сөрәләр. Көне буе сыйланалар, музыка тыңлыйлар, тегеләрнең кайтып керер вакыты җиткәч, өйнең астын-өскә әйләндереп, бер өем юылмаган савыт-саба калдырып, чыгып сызалар икән. Тынычланырлык бер генә нәрсә бар монда: башы исән кызның.

Егетнең әнисе, ире белән кычкырыша торгач, тәмам кызып җитте.

— Бердәнберемне сезнең ул әчкече нәмәрсәгезгә әрәм итәр хәлем юк!—дип, Маринага җикеренә башлады.—Табып бир улкаемны!

— Тавышланмагыз әле, зинһар! — Марина авыр хәлдә иде.— Әйдәгез соң, бергәләп эзлик алай булгач!

Алар өчәүләшеп баягы тулай торак ягына киттеләр. Зөһрә эндәшми. Ул хәтта хатынның Марина колагына тукылдап барган аһ-зарын да ишетми. Аны үз язмышы турындагы кайгылы уй биләгән. Хәзер, кисәктән, кабат эч поша башлады. Елыйсы килә.

Кинәт Марина кычкырып җибәрде.

— Әнә ич минем кызым!

Хатын да, ике кулын алга сузып, Марина күрсәткән якка омтылды.

— Витя! Улым, туктале!

Егет белән кыз, бер күрүдән үк, бу кешеләрнең үзләрен әзли чыкканлыгын сизеп алып, теләр-теләмәс кенә тукталдылар. Егет кулын, Клава биленнән алып, чалбар кесәсенә тыкты. Әнисенә:

— Ну, чево еще?—диде.

Клава, Витясыннан аерыла төшеп, Марина белән Зөһрә янына килде.

Марина сүзне ничек башлап китәргә кирәген белми иде.

— Ял итеп туеп булмыймы, матурым?—Сүз үзеннән-үзе ачу катыш чыга башлады.—Очраган бер егет белән дөньяларны онытып йөрергә тотынсак, салабыз инде без КамАЗны, ә?

— Мин китәргә булдым сездән, Марина.

— Хакың юк! ГПТУдан соң ике ел эшләргә тиеш әле син!

— Ул законны белә-әм.— Маринаның ачуын китереп, Клава елмая да елмая.—Аны любоебыз белә-ә. Ул закон тирәсендә тычканнар да таякка таянып кына йөри...

— Җитте! Бар эшеңә!

Клаваның тавышы кинәт юашланып калды.

— Мин шаяртмыйм, бригадир. Китәм. Кияүгә чыктым мин, ачуланма!

— Кияүгә чыккан һәр кеше бригададан китә башласа, таралып бетәбез бит без, барыбызны да туйлар көтә лабаса!

— Виталийның Чаллыда каласы килми. Безнең билетлар алынган.

Марина бөтенләй аптырады. Бер кагыйдәгә дә буйсынмаучан шушы Клаваны ярата иде бит ул. Кыз кеше кияүгә чыкканда аңа иң изге теләкләр теләргә кирәген дә белә. Тик эче тулы үпкә-сагыш, тешләр кысылган.

— Туйсыз-нисез, бүләкләрсез, теләкләрсез өйләнешүнең ни кызыгын таптыгыз?—Марина бераз тынычлана төште.—Барган җиреңдә кыен булса, кайтыгыз кире, кабул итәрбез. Бездән сиңа туй бүләге шул булыр.

Клава аны-моны әйтеп өлгермәде, әнисе белән бәхәсләшеп тәмам кызып беткән Виталий йөгереп килеп, кызны җитәкләп тә алды, җилтерәтеп, кире якка алып та китте.

Хатын:

— Витя дим, тукта! Тукта!— дип, кычкырып калды.

Ул җикеренә төшкән саен, егет белән кыз адымнарын кызулата бара, ике ара ераклаша гына иде. Инде сүзләрен барыбер ишетмәячәгенә ышангач кына, хатын, кычкыруыннан туктап, Маринага игътибар итте. Ул хәзер бөтен ачуын аңа юнәлтте.

— Кызым, кызым, дип йөрисең, кызың җилен җибәргән!—диде.— Бала көтәләр икән бит!

Марина баскан җирендә чайкалып китте. Зөһрә аны беләгеннән җитәкләде дә, юлларының кай якка илтәсен дә искәреп тормастан, усал хатын яныннан китүне ашыктырды.

Күпме барганнардыр. Марина тирә-юньне күзәтә башлады. Каршыда гына автобуслар тукталышы икән.

— Син менә шунысына утырып өйгә кайт,— диде.— «КамАЗ дирекциясе» дигән тукталышка кадәр бар, төшкәч, күрерсең, безнең өй якын гына. Куркып торма, кер, анда сөйләшенгән.

— Үзең нишлисең соң, Марина?

— Бригадага китәм. Без анда кунып эшләргә булдык бит...

Мариналың мөлдерәп торган күзләре; «Я инде, әйт инде, мин дә сезнең янда эшләргә телим, дип әйтеп әйт!»—дип, өздереп карасалар да, Зөһрә үзен-үзе мәҗбүр итә алмады.

Кызлар, икесе ике автобуска утырып, икесе ике якка китеп барды. Мариналың бөтен җанын үкенечле уй биләгән иде. «Көне нинди туры килде бит аның, көне. Елга бер була торган күңелсезлекләрнең бөтенесе берьюлы Зөһрә килгәнне көтеп торганнар диярсең...

...Зөһрә төзелештән тәмам гайрәте чигеп кайткан иде инде. Сүнгән дәртне Мәрвия үзе яңадан кабызды. Соңыннан: «Кит!»—диярлек булгач, ник чакырды, ник Зөһрәне хыял белән Чаллы җире арасына сузылган киң күпергә чыгарып бастырды?

## Янында калыр идем!

Зөһрә кайткалаганчы, Айлы Ярга йөри торган автобуслар әллә кайчан тукталган, автовокзал төнгелеккә ябылган иде инде. Кызлар бүлмәсендә икенче кичкә куна калу аны әллә ни борчуга салмады. Авылга кайтсаң, очраган берсе шул имтихан хәлләрен сорашып, каныңа тоз салыр иде әле. Монда ул яктан җан тыныч, институтка керә алмауны кысыр хәсрәттән саныйлар. Бөтенесенең үз мәшәкате баштин ашкан. Җаныңны кая куярга белми интегәсең икән, рәхим итеп, теләгән эшеңне сайлап ал.

Тулай торакның ишеген ачуга, Зөһрә каршына Табибә килеп басты.

— Китә алмадыңмыни?—диде.

— Юк. Мин бүген Марина апа бригадасына барган идем.

Сөйләшә-сөйләшә өскә менделәр, Табибәләр бүлмәсенә керделәр. Кранчының эшләре мөшкел икән. Көне буе рәтләп эшли алмаган. Зөһрәнең гаҗәпләнеп соравына да ул җенләнеп кенә җавап кайтарды.

— Томан ич! Августтан ук башланды. Әле көз кергәч, интектереп узәккә үткәнен белсәң син аның.

— Берәр әмәлен табып булмыймы?

Табибә Зөһрәнең аркасын сыйпарга тотынды.

— Менә кеше! Нәкъ тиешенчә уйлыйсың! Әмәл булмый буламы соң? Бар. Валлаһи-билләһи бар ул әмәл! Үзем таптым. Ризалаштырып кына булмый. Менә иртәгә тагын бер абый янына керәм дә, аннан җүнле сүз ишетә алмасам, Мәскәүгә язам.

— И-и, син биграк инде, Табибә апа, аңганчы томаны да таралып бетә бит инде аның?

— Көтеп утырсаң, таралмый ул, тарату юлын табарга кирәк.—Табибәнең күңеле күтәрелә төште.—Менә син дә, җаныемдыр ла, бер дә юкка авыз-борыныңны салындырып йөрисең. Кыюрак бул, бу кызлар начар кызлар түгел алар. Яманга өйрәтмәсләр. Табибә Мәрвияләр бүлмәсенә ишарәләде.—Алар сине үзләре янында эшкә калдырырга кызыгалар. Миңа да әйткәннәр иде. Кеше җитми бит, кая карама —кеше кирәк. Төзелешенә дә...

— Мин төзүче була алмыйм, Табибә апа!

— Юк, син мине димли дип уйлый күрмә. Һади абый кызы минем киңәшкә мохтаҗ түгелдер. Шулай да, Чаллыда булган булган, күреп кит, зыяны тимәс. Мин эшли торган җиргә дә кил, кабинама алып менәрмен. Беләсеңме, шәһәр, аннан караганда, нинди булып күренә — нәкъ әкияттәгечә, тегс төн чыкканчы пәриләр төзегән зиннәтле сарайлар тезмәсе кебек! Заводларга да бар! Кешеләр безнең заводларны күрер өчен экскурсияләргә киләләр. Синең бер үзеңә Мәрвия кадәр Мәрвия экскурсовод булырга әзер. Йөр рәхәтләнеп, күр!..

Томан куера гына барды. Чаллының һавасы гаҗәп аның. Әллә Кама суы якын булганга шулай инде. Яңгыр коя башласа, күк белән җир тоташкан сыман тоела. Томаны сөт кебек. Әйтерсең Кама астына учак якканнар да бөтен суын парга әйләндереп, шәһәр өстенә таратканнар.

Мондый көннәрдә Мәрвиянең елыйсы килүчән. Еларлык кайгысы да юк үзе. Эч пошуның сәбәбен эзли башласа, уйлары Бәхти белән очрашкан көннәргә килеп тоташа. Юк, егетнең күңел калдырырлык сүз әйткәне юк югын. Үз итеп, туган сеңелесенә тиң күреп йөри.

— Бигрәк ерак инде,—диде Зөһрә. Трамвайда сүзсез бару аны алҗыткан иде.—Җир читендә.

Мәрвия гүя янына Зөһрә утырганын онытып ук җибәргән. Хәзер дә, сүз юктан:

— Әйе шул,—дип кенә куйды.—Безнең литейный иң соңгы остановкада.

Шулай да алар трамвай тәрәлеп калганчы бармадылар, алдарак төштеләр. Заводның Мәрвия эшли торган соры һәм чүкелүчән чуен кою корпусы бер тукталышка якынрак икән.

Беренче күргәндә хәйраннарга калдырырлык бина бу. Әллә нинди бөгелешле юан бүрәнәдәй торбалар. Чакрымнарга сузылган корпуслар — бары да металл. Җир, бичара, шул кадәр авырлыкны ничек күтәреп тора икән?

Тик Зөһрә бу хикмәтләргә игътибар да итмәде. «Завод булгач, тимер дә торба буласы билгеле инде...» Мәрвия кызны кызыктырырдай нәрсә күзгә чалынмый калмас, дип, адымын акрынайта төште. Җаны таш түгелдер ләбаса! Зурлыгына кызыкмаса, морҗаларының матур төсләргә буялуына гына булса да сокланырга тиеш бит инде! Үзе алга барды Мәрвия, үзе Зөһрәнең: «Абау, апа җаным, моны да сез ясадыгызмы?» — дигәнрәк бер сүзен көтте. Әле кайчан гына монда җирнең асты-өскә килгән, бөтен тирә-юнь упкындай чокырлардан тора иде. Мәрвия заводны шул хәлендә күрде. Ул хәтта шунысына да канәгать, шуңа да шат иде. Балчыгының сарылыгы, чокырының тирәнлеге дә аңарда соклану уята иде. Ә бу кыз сарык кебек бара да бара, күңел өчен, ник бер хуплау сүзе әйтсен! Шатлану түгел, күзен тутырып карамый да бугай әле ул.

Мәрвия арткарак калган Зөһрәгә борылды. Матурлыкны заводны урап алган төрле төстәге торбалардан, күккә ашкан морҗалардан күрсәтергә тырышкан Мәрвия аптырап китте. Зөһрә аяк астындагы, яндырырга өеп калдырылган иске-москы әрҗә такталарына карап шаккаткан. Авызы көлә, күзе көлә.

— Көлмә, менә киләсе өмәдә себереп түгәбез без аларны, әле кул җитми тора,—диде Мәрвия.

Зөһрә аны ишетми дә, әле бер тактаны, әле икенчесен карый, сыйпап-сыйпап ала, тузаннарын сөртә.

— Кайдан килгән соң алар монда, Мәрвия апа?

— Әй, исең китте бит инде бер юк нәрсәгә. Ат аунаган җирдә төк кала, диләр. Кая сырье, кая берәр станок—шуларның тышчасы инде болар, кабыгы.

— Соң, апа җаным, боларга бит инглизчә язылган!—Зөһрә кош тоткандай кылана. Бер тактадан икенчесенә күчә-күчә Мәрвиягә укырга, тәрҗемә итәргә ашыкты.—Менә бит: «Аударманска!» дигән, «Өсте!» дигән, «Игътибар, пыяла!» дигән... Апа җаным, аңлашыла бит, аңлыйм бит! Кайдан китерелгәннәр соң алар?

Мәрвия кулына бик зур табыш килеп кергән кеше сыман бер мәл онытылып торды. Тик әллә ни уйларга, Зөһрәне һич чыга алмастай ятьмәгә кертерлек сүзләр эзләп азапланырга сабырлыгы җитмәде, теләнә килгән беренче сүздән башлады.

— И-и, кара инде мин җүләрне, сиңа иң кирәк нәрсәне әйтми торам икән бит! — диде.— Безнең станоклар Америкадан эшләтеп алдырылды бит, махсус заказ белән!

Зөһрә сораулар биреп маташмады. Заводның эченә кергәч, кайнар сыеклык хәленә килгән металл тулы казаннарга, түбә өстендә асылмалы рельстан выж да вож үтеп торучы сап-сары кечкенә трамвайчыкларга карап өнсез калды. Машиналарның кабиналарында кызлар утыра.

— Әнеккәйгенәм! Курыкмыйлар микән?

Зөһрәнең бу сүзләре Мәрвиягә хуш килде.

— Өйрәнгәч, ник курыксыннар? Егылып төшсәң дә, үз жирең!

Көлештеләр. Тик монда көлү дә, үзара сөйләшү дә ишетелмәс булды. Кызлар Мәрвия эшли торган участокка, калып коючылар янына житкәннәр иде. Рәт-рәт тезелгән зәңгәрсу станоклар баһадир жанварны хәтерләтә.

— Менә моңа да инглизчә язылган: «Суттер».— Мәрвия станогының маңгаена төртеп күрсәтте.

— Алай укылмый ул, Мәрвия апа, «Сатә» дип укыла. Сүз азагындагы «р» авазы яңгырашны югалта...

Калганын әйтеп, күрсәтеп торуның кирәге калмады. Зөһрә цех буйлап китте дә китте. Кайда нинди язу күрә, туктала, укый, мәгънәсенә төшенергә тырыша.

Мәрвия жилкәсеннән тау төшкәндәй хис итте. «Болай мавыккач, тиз генә ташлап китә алмас, шәт».

Зөһрә, цехлар буйлап йөри-йөри, адашып бетте. Бер урында ике егет ниндидер балкаларны ябыштырып маташа иде. Эретеп ябыштыргычларыннан көлтә-көлтә ут чәчелә. Кыз ут чаткысы астында кала язды. Егетләрнең берсе шаяртты.

— Курыкма!—дип кычкырды.—Күлмәгеңә борчак-борчак тишекле бизәкләр генә өстәлер!

Икенчесе начальниграк иде, ахры, ачуланды.

— Монда йөргәндә, башыгызга каска кими күзгә күренәсе булмагыз, дип ничә әйтелде? Һаман тыңламыйлар, ычкын моннан!

Зөһрә үзен монда эшләүче кешегә санауларын аңлап, эчтән генә сөенеп куйды. Елмайды.

— Ярар, абый, сезнең янга икенче килгәндә, каскасыз килмәм!— диде.

Тегесенең ачуы алай да басылмады әле.

— Кою эшенә кыз-кыркынны якын китерәсе түгел аны, башын бәладән чыкмас,—дип, һаман үзенекен такылдап калды.

Мәрвия янына килгәндә, Зөһрәнең бөтен торышы көлә иде. Алар бер-берсенә сүз катышып тормадылар. Мәрвия агрегатының эшен күзәтте. Минут саен «пешеп» чыгып торган калыпларны, станогыннан алып, конвейер тасмасына куеп торды. Айлы Ярның инеше кебек өзлексез агып торган бу киң тасма Мәрвиянең калыпларын күз күреме ирешмәс ераклыкларга илтә. Зөһрә белә инде: алда бу жирән комташ калыпларны шомартып, майлап бирергә әзерләнгән кызлар бар. Алардан соң калыплар металл белән эш итүче, эретүче агайлар кулына барып керә.

Шактый вакыт эндәшми-нитми басып торгач, Зөһрә:

— Мин дә монда эшли алырмын микән, Мәрвия апа?—диде.

Станокның астында гөжләп янган газ, күрше агрегаттагы кыз кулындагы көпшәдән чыккан көчле һава агымы тавышларыннан Зөһрәнең кыяр-кыймас әйткән соравы берәүгә дә ишетелмәде. Гүя завод аны сыный, гүя һәр күзәнәк кыз фикеренең ныклыгын тикшерә. «Авыз ачып сүз әйтәсең икән, кычкырып әйт! Тавышың завод гөрелтесен жиңеп яңгырарлык булсын!» — диләр гүя.

— Мәрвия апа!

Коючы Зөһрәгә карап тагын елмайды. Кып-кызыл каскасының тар козырегы астында ташкүмердәй кара, кысык күзләр елтырый. Коючы сизенә: Зөһрәнең бу тавышы бер дә юкка гына шул кадәр көчле чыкмады.

— Кем тия?

Зөһрә, беткән баш — беткән, дигәндәге сыман, күңелендәгене бер сулудан әйтеп салды.

— Мине дә өйрәтерсеңме?

Мәрвия баш какты. «Саксызрак сүз әйтсәң, кызның әле туып кына килүче, өрфиядәй юка теләген юкка чыгарып куюың да бик мөмкин»...

Эш көне, эш атнасы кысасына кергәч, Зөһрәнең эч пошулары юып алгандай булды. Казан юлында йөреп югалткан шуклыгы, шаянлыгы кире кайтты. Инде имтиханнарга бүленгән көннәр бетеп килүне исенә төшереп, ул өйләренә хат язарга утырды. Хәлен аңлату өчен, әтисенең элек-электән сөйләп йөри торган мәзәгеннән файдаланды.

Мәзәк моннан гыйбарәт. Элекке чорның бер агае, колынлы бияне җигеп, улын калага озата. Малай, базарда йөри торгач, колынны адаштырып калдыра. Кире кайтып килә бу. Ата кеше, капка төбенә чыгып, улын көтеп тора икән. Аның исән-имин кайтып килүен күргәч, шатлана.

— Ай, улым, бик вакытлы әйләндең әле син!—ди.—Ну, калада ниләр бар?

Үз кайгысыннан башка берни дә күрә алмаган малай:

— Әй, эти,—ди.—Анда нәрсә булсын соң, бөтен кеше тай югалта.

Үз өйләрендә гадәткә кергән алым булганга, Зөһрә имтихан хәлләрен шул сүз белән аңлатты. «..Институтта бөтен кеше тай югалта. Мин дә башкалардан калышмадым. Югалган тайны эзли китеп Чаллыга кайтып төшкән идем, монда бөтен кеше тай таба икән. Мин дә таптым,—дип язды.—Бүгенге көндә КамАЗның коюю заводында яңа һөнәргә өйрәнеп киләм».

Мәрвия янында эшкә өйрәнүнең әллә ни кыенлыгы булмады. Ул үзенең ни эшләячәген аңлата, калыпларны коеп күрсәтә, аннары бөтен хокукны синең үзеңә тапшыра.

— Мә, хәзер син яса!—ди.

Минут эчендә кайнар металл салырлык форма әзер була. Калып коючы кызларны монда «стерженщицалар» дип йөртәләр. Аларның житезлегенә коюю заводы өлгертеп чыгара торган бөтен продукция бәйле. Чуен олы чаннарда чымырдап кайнап утырырга мөмкин. Калыплар әзер булмаса, металлны тиешле формага салып суыту соңара, машиналарга кирәкле деталь өчен кулланма житеп бетми дигән сүз.

Зөһрә, атна-ун көн дигәндә, «стерженщицалар» белергә тиешле төп операцияләрне үти ала иде инде. Кыз, Мәрвияне шаккатырып, үз һөнәренә бәйле эшләрне башкару ягын гына карамый, барысының да сәбәбен белергә тели, төпченә иде. Дөньяны яңа таный башлаган сабый кебек минут саен: «Ник?», «Алай итмәсәң, нәрсә була?» шикелле сораулар бирә. Мәрвиянең вакыт-вакыт ачуы да чыга иде, чөнки кайбер сораулар эшкә турыдан-туры бәйләнмәгән була. Җавап табуы кыен. Әмма станок-агрегат каршына үзе баскач, калып коюю аның мөстәкыйльлегенә күчкәч, Зөһрә бер генә ялгыш хәрәкәт тә ясамый. Кабаланмый. Курыкмый.

Өйрәнү-өйрәтүләрнең болай бик тиз, һичнинди сикәлтәләрсез баруына хәтта борчыла да башлады Мәрвия. Кызга завод эшенең житдилеген, җаваплылыгын, еш кына борчый торган катлаулылыкларын да күрсәтәсе килә иде. Мәрвиянең үзенә бу цехның бүгенгесен күргәнче мең дә бер киртәне үтәргә туры килгән иде.

Мәрвия—коюю заводның беренче казыгын кагып, эшкә шунда калган кеше. Заводның беренче чиратын сафка керткәндә, беренче калыпны коюю хокукын яулап ярыш ачылгач, җиңеп чыккан калып коючы ул.

Монда эш башланыр алдыннан аны Волгоград трактор заводына тәҗрибә тупларга җибәрделәр.

Практикасы турында кәгазьнең иң шәбен эләктереп, КамАЗның калып коючысы булдым, дип, түш киереп Чаллыга кайтты.

— Уһу-һу, бик вакытында өлгердең, балакай! — дип, цех начальнигы аны сөенеп каршы алды.— Какраз станоклар монтажлау бара, күз-колак булырсың.

Мәрвия, шатланып, сумкасындагы документларны чыгарды. Йөзендә: «Минем кайтып өлгерү—мәсьәләнең баласы гына, менә монда аның анасы!»—дигән сыман горурлык чалымы уйный. Тик Мәрвиянең холкында үзен мактаганны тыңлап торырлык сабырлык юк икән, ул Волгоград заводыннан алган кыйммәтле язуларын начальникка сузды да:

— Участокны карыйм әле,— дип бүлмәдән чыгып шылды.— Яңа станокларны күрәсем килә!

Очар коштай талпынып, цехка барып кергәч, Мәрвия «аһ!» итте. Монда монтажланып ята торган алыптай агрегатлар ул күргәннәргә, Волгоградтагы язу өстәле чаклы гына машиналарга һич охшамаган иде. Кыз үзалдына:

— Сахара дөяләремени?! И-и, мәхәббәтсезләр!—дип сукранды.

— Нәрсә, нәрсә?

Мәрвиягә таныш түгел иде бу кеше. Аңа җавап кайтаруны кирәксенмичә, кыз станокның икенче ягына чыкты.

Теге кешенең дә үз сиксәне сиксән, кыздан бер адым да калмады. Мәрвия эндәшми-нитми йөргәч, кабат кайтарып сорады.

— Кем син? Нишләп йөрисең?

— Әй, абый, бәйләндең бит инде! Мин менә шушы станокта эшләргә тиешле кеше, бик кызыксынсаң!

— Рәзрәтең?

— Нәрсә, «рәзрәтең»?

— Рәзрәтең, дим, ничәнче?

— Анысы җитәрлек лә аның! Станогын гына беренче күрү, кай ягыннан килеп сәлам бирергә аптырыйм.

— Рәзрәтең ничәнче диләр сиңа?

— Ай, аллам, бәйләндең бит инде, разрядтамыни соң эш? Анысы иң югары минем, дүртенче. Ник кирәк булды соң әле ул сезгә?

Теге кешенең йөзе агарынып китте.

— Менә, менә, әйтәм бит: җыен чыпчыкка теләсә нинди рәзрәт биреп утыралар!—Ул ашыга-ашыга китеп барды.—Үзләренең заводка аяк басканнарына бер көн юк. Станокны су чиләгеннән аера алмыйлар. Оялмый да, кызармый да: «Дүртенче!» — дип тора бит!

Агайның тиктомалдан тузынуын һич аңлый алмады Мәрвия. Кәеф бозып йөри шунда! Чүп өстенә чүмәлә, әле аннан башка да эч поша, станогын һич аңлар хәл юк.

Мәрвия яңадан начальник бүлмәсенә кергәндә, ачулы агай шунда, «ду» килеп кычкырыша иде.

— Мин алар белән ничек эшләргә тиеш дип беләсез? Ишшу, рәзрәтем дүртенче, дип кукыраялар. Мин унбиш ел кою заводында эшләгән кеше, иту да рәзрәт өченче генә. Ничек эшлим мин моның ишеләр белән? Борыннары күктә...

Бүлмәгә Мәрвия кергәнен күрсәләр дә, алар бәхәсне туктатмады. Кызып китеп, сүзенә оятсыз әйләнмә кыстырып җибәргәч кенә агайга начальник ым какты. Янәсе, кыз бала алдында алай ук килешеп бетми. Тегесе, киресенчә, әйткәннәренә дәлил табуына сөенеп, тагы да дуамаллана төште. Күргәзмә әсбап урынына санап, Мәрвия ягына төртеп күрсәтте.

— Бак сана, бак сана син аның кыяфәтенә генә! Әнкәсе итәгендә курчак уйнап утырасы нәмәрсә! Болар белән нинди эш, нинди план?

Хурлыгы ни тора: мин, мастер башым белән дә, өченче генә рәзрәттә утырам, унбиш ел металл белән чиләнгән кеше...

Агайның үз мастеры икәнен аңлагач, сүзгә Мәрвия дә кушылды.

— И-и, абый,—диде.—Минем разряд өчен генә булса, борчылма шул тиклем, төшерерсез. Эшләргә өйрәнгәч, яңадан карарга да була бит ул разрядны.

Начальник каршы килде.

— Хакыбыз юк. Училищедан килгәндә үк синең өченче разряд иде. Андагы кешеләргә ышанмаска бернинди нигез дә юк, анда да үз кешеләребез үк укыта. Волгоградта син шактый озак эшләдең, бер разрядка күтәреп җибәргәннәр икән, ничек шикләнәсең?

— Нишләп булмасын, бик шикләнәм! Ул бит анда американский станокларда эшләмәгән.—Мәрвиянең разряды агайның бугазына таш булып утырган икән.— Монда әле бөтенесенең рәзрәтен бер буынга төшереп торырга, эшләп күрсәтсеннәр әүвәл башта!

— Күрсәтерләр, күрсәтерләр,— диде начальник. Анын да үз сүзен бирәсе килмәде.—Бу станокларда безнең кызларның гына түгел, дөньядагы бер кешенең дә эшләп караганы юк. Беренче тапкыр безнең заказ белән ясалганнар алар.

— Яннарына барып басарга куркыныч, Сахара дөяләре сыман..

Начальник, Мәрвияне тынычландырырга теләп:

— Кайгырырга кирәкми,—диде.—Эшебез тәмам җайга салынмыйча торып, проектлаучы оешма вәкилләре монда булачак, мастерлар стажировканы Америкада үтәчәк. Күбесе әйләнеп тә кайтты инде.

— Менә бу дүртенче рәзрәтле кызны мастер итәрсез алайса!—Агай һаман кирегә тырнавында булды.—Мин унбиш ел эшләп тә...

Начальникның да сабырлыгы чамасыз түгел икән.

— Ярар!—дип кычкырды ул кинәт.—Инде бик зарланасың икән, башка мастер табарга туры килер!

Агаең «шып» булды. Бүлмәдән чыгып китү уңаенда гына:

— Алар бит, эшли белмим, дип тормый, сиңнән-миннән күбрәк акча каерырга тотына!—дип үзалдына зарланып барды.

Агай чыгып китүгә, начальник аны мактый башлады:

— Һәр коючысын шундый иләк аша үткәреп җыйса, шәп мастер чыгачак аннан. Син дә кайгырма, сеңел! Бәлки безгә ул разрядлар мәсьәләсен, КамАЗ өчен дигән булып, чыннан да, яңабаштан карыйсы булыр.

Шулай иттеләр дә. Участокта эшли башлаганда, һәркемнең разряды бер баскычка төшереп торылды.

Ул чакта бер генә тыныч көн дә юк иде. Разрядларны киметү турындагы хәбәрне ишеткәч тә зур тавыш күтәрделәр. Барысы да Мәрвия кебек: «Киметегез!»—дип тормады. Пәрмә-пәр килделәр. Заводны ташлаучылар, шул ачудан шәһәреннән үк китеп баручылар булды.

КамАЗ кешеләрнең чыдамлыгын торып-торып сыный ул. Зөһрә исә әлегә тормышын да, эшен дә тамашага санап кына йөри. Аңа әле заводтагы бер бәләкәй генә мәсьәләне дә үзбаш хәл итәргә туры килгәне юк. Ансыз булмый. Кыенлык алдында калса, түземлеге җитәрме? Мәрвия шуны көтте, көткәне аны шактый шикләндерә, өркетә иде. «Өйрәтеп азапланулар җилгә очмасмы? Беренче авырлыкта ук сыгылып төшеп, Айлы Ярына кайтып китмәсме? Әнә бит—Марина бригадасындагы ыгы-зыгылы көнгә әләгеп, шунда ук тәртәгә типте...»

...Кем уйлаган? «Кит!» дип торганда ябышып ятачагын кем башына китергән? Бу кадәресен Зөһрә үзе дә белми иде әле. Төпченә китсәң, әллә ни гаҗәпләнер урыны да юк икән. Ул бит беренче көннән үк мондагы кешеләрнең шатлыгын да, кайгысын да үзенекедәй кабул итте. Уртаклашып, кайгыларын кимет алса, сөенеп, шатлыкларын арттырса,

Зөһрәдән бәхетле кеше юк иде. Марина белән Миңлеәхмәтне шатландырган көне генә дә ни тора! Егет белән кыз, үз бәхетләреннән и[illegible]реп, Зөһрәнең бу матур язмышка шаһитлыктан нинди шатлык кичерүен белми дә калганнардыр, мөгаен.

Чаллыдан китү — шундый тирәнгә кергән бәхеттән аерылу бит ул. Юк, Зөһрәнең моңа көче житми.

## Сине анда яраткан...

Беркөнне кич бүлмәгә алыптай дәү гәүдәле, кара чәчле, кара күзле егет килеп керде. Кызлар белән иплэп кенә сәламләшкәч, ул Мәрвиядән кычкырып сорап куйды.

— Кая югалды соң бу Марина?

Бүлмәнең күптәнге дусты Миңлеәхмәт иде бу. Мәрвия, гадәтенчә, аңа үз белгәннәрен сөйләп бирде, егетне тынычландырырга теләде.

— Күп калмагандыр инде,—диде.—Кайтыр. Башка кызлары берәмберәм кайткалап та китәләр, Марина күзгә-башка чалынмады шул.

Егет эченә җыелган үпкәсен әйтми калдыра алмады.

— Акыл диген инде, әй! Кайтып китсә, ни була? Мин бит аның объектын да белмим.

Шуны гына көтеп торган кебек, Зөһрә өстәде.

— Мин беләм ул объектны,—диде.—Бер көн булдым мин анда, ТЭЦта эшлиләр алар.

Егет, очып кунардай булып, Зөһрәгә талпынды.

— Аһ, шайтан алгыры! Бер күрергә зар-интизар иткәннәр [illegible]кән! Бигрәк ерак инде. Безнекеләр ГЭС төбенә бетон салуны кызул[illegible]лар, арматура монтажлыйбыз. Ашыгыч эш, ташлап китә торган түг[illegible] үзен беләсең...

Егет сүзләрендә үтенечле яңгыраш тоеп, Мәрвия Зөһрәгә [illegible]рып карады. Зөһрә дә аңлады.

— Ник, үтмәс йомышыгыз булса, иртәгә эштән кайтышлый кичләтеп кагылырмын мин анда, абый.

— Кичләтеп түгел, иртән, сменага чаклы бар син анда! —диде дә, йөзенә нур балкытып, елмайды егет.—Җүнле хәбәр иртәдән йөри!

Измә ташучы машина да килеп житмәгән иде әле. Зөһрә, кызлар куна торган вагон ишеген шакып, Маринаны сорады. Марина исә, ал таң нуры эчендә Зөһрәне күреп, ни уйларга да белмәде. Аның Мәрвия янында калачагына әллә ни шикләнмәгән иде ул. Тик менә монда ник килгән? Берәр күңелсезлекме? Кызның йөзендә шомлы билгеләр юк. Тавышы хәтта шаянланган да әле.

—Син безнең дөньядалыкны да онытгың, иптәш бригадир,—диде Зөһрә.—Бер ара табып кайтып китсәң, ни була инде?

Марина эштәге хәлләрен тәфсилләп торуның кирәген тапмады.

— Өйдә ниләр бар соң, өйдә?—дип, тиз-тиз үзе сорарга тотынды.

— Өйдә норма!—Зөһрә шулай да иң соңгы яңалыкны әйтми булдыра алмады.—Матрена түти белән Степан агай никах яңартырга исәп тоталар.

Матрена түтинең эссесе кышкы җилле көндә ягылган мунчаныкы кебек тиз узды. Хәзер: «Степа, а, Степ!» — димәгән сулуы юк. Тулай торакның беренче катындагы бер бүлмәне дә биргәннәр инде үзләренә. Әле агартасылары бар. Шулай да карчыкның акылга утыруының сәбәбе башкада. Әбиең «пыр» килеп милиция, суд юлында йөргәндә, торба буйлап үрмәләргә остарган егет юкка чыкты. Әбекәй башта: «Бу ни хәл?» — дип гаҗәпләнгән иде. Кинәттән уйчанланып, боегып калган бүлмәдәше, Мәрвияләр янына кергәч, үзе аңлатып бирде.

— Куркак егет ул,— диде Матрenaның бүлмәдәше.— Шуңа күренми хәзер

— Һи-и, икенче катка торба буйлап менеп йөргән кеше куркак була димени?

Ә бүлмәдәш кыз куркаклыкның икенче төрлесен белә икән шул. Сөйләде.

— Матрена түтәем Чувашстанга киткән кичне, җиде төн уртасында, тагын шулай менде бу. Мин, җүләр, тәрәзәмне ачып тордым. Табыным тезелгән. Өстәл янына утыргач, егетем, кесәсеннән чыгарып, бер шешә аракы утыртты. Гомеремдә беренче тапкыр ярты гына стакан эчтем...

Бүлмәдәш кызның тавышына үзәк өзгеч үкенү өстәлде. Әмма сөйләүдән тукталмады ул. Аның бөтен торышы, сез мепә мин ахмакның ни күргәнен ишетегез дә, минем хатаны кабатламагыз, ди сыман иде.

— Эчтем. Исердем. Исереккә диңгез тубыктан: китте тозсыз сүз, мәгънәсез уен-көлке, шаяру... Мепә шул көн дә саен торбадан төшеп китә торган егетем бу төндә тәрәзәдән аска күз ташларга да куркучан булып китте. Эчкән дә бит инде. Әллә нинди бәлагә юлыгыр дип, үзем дә аска таба бик кыстамадым. Бу да бер ананың газиз баласы бит, мин әйтәм, харап булса, үкенечен кая куярсың?—Кыз йөзеннән аналарда гына очрый торган мөлаемлык чагылып үтте. Тик бу нур бер мизгел эчендә үк юкка да чыкты.—Шул төндә безнең арадагы ихласлык беткән икән. Башта сизмәдем әле. Бала табачагымны әйткән идем, егетемнең коты очты. Миңа әйтми-нитми шәһәрдән үк китеп барган.

Әңгәмәне Матрена түти очлап куйды.

— Та-а, кысла-ар!—диде. Татарлар арасында ул гел татарча сөйләшә.—Торпадан үрмәләргә күп акыл кирәкмәс у-ул!Меңгәннән соң нәстә эшли ул, шунсы фашно... Әнә минем Степа, слава богу!

Кызлар аның сүзен тыңлап бетерә алмадылар, пырхылдашып көлешә башладылар. «Әле кайчан дуслашып өлгергәннәр соң бу карт белән карчык?»

Зөһрәнең бу хәлне сөйләвен Марина бригадасындагылар барысы да тыңлап торды. Маринаның бик исе китмәгән дә иде. Арадан бер кыз:

— Бәй, болай булгач, аларның мәхәббәте кая киткән соң?—дип сорау ташлады.

Башта сорауга җавап табылмады. Бераздан өлкәнрәк апа үзенчә аңлатты.

— Мәхәббәтме? —дип кабатлап сорады. Аннары, усалланып:— Мәхәббәт ул, алдыңны-артыңны карамый, итәк-чабуларыңны җыймый йөрсәң, ике аяк араңнан очып чыга да юк була! —диде.— Каз бәбкәсе түгел, кире куып кертеп, оясына утырта алмыйсың...

Зөһрә ашыга иде. Ул бу бәхәскә артык игътибар итеп тормады. Тавышын кырыслатып:

— Өйдәгеләр тагын шуны әйтергә куштылар,— диде.— Сезнең бу куна-төнә эшләү методыгызны бетерергә вакыт!

Марина акланырга тотынды.

— Безнең бригада тулы түгел бит, Зөһрә, үзең күреп торасың. Теләсә кемне алып тутырасы да килми. Мепә син дә калмадың.

Зөһрә бу коллективтан шыпан гына сызуын искә төшерүне яратмады.

— Ярый, үткән эшкә салават! Бер җае чыгар әле. Хәзергә менә боларына риза бул! — Зөһрә Маринага ике хат сузды.— Әллә кайчан көтеп яталар үзеңне!

Марина хатларның кемнән булуын ерактан ук танып өлгерде. Берсе — әнисенеке. Аның эченә ни язылганы да мәгълүм. Ярты бит буе сәлам тезелгән була. Аннары хуҗалыктагы һәр җан иясенең, һәр түтәлнең хәле хакында сөйләнә.

Зөһрә алып килгән икенче хатка почта мөһере сугылмаган. Аньсын, кызларның очлы күзеннән саклап калу өчен, Марина кофта изүенә тыгып куйды. Игътибарларын читкә җибәрү өчен, әнисенең хатын кычкырып укый да башлады.

Әниләргә генә хас сабырлык белән сөлге буе итеп тезелгән сәламне кызлар тын алмый тыңладылар. Кайсы елмая, кайсы, үз туган йортын күз алдына китереп, сагышланып утыра. Хат укылып беткәч, һәркем үз әнисенә бәйле иң кадерле истәлекне телгә алды, үз якларындагы хәлләр турында сөйләп калырга теләде.

Марина бу сүзләргә кушылып тормады инде. Эшкә тотыну хәстәрен күрергә кирәк иде. Ашыкты ул, кабаланды. Бригаданы тизрәк эш ритмына салырга да төштәге хат кисәген укырга ашкынды.

Икенче хат — Миңлеәхмәттән. Күрәсең, көткән-көткән дә, Марина кайтмагач, хат җибәрергә булган. Ни генә язды икән?

Сәгатькә карамыйча эшләгәч, «цилиндр»ның шактый өлеше сыланып та беткән иде инде. Бригадирның күңеле тыныч. Шуңа күрә ул:

— Кызлар, мин измә машинасын каршыларга киттем, — диде дә тышка чыкты. Төзелеш мәйданыннан шактый читкә атлады.

Дымсу иртә. Марина, машиналар йөри торган юлдан эчкә ук кереп, чирәмгә күмелеп утырды. Тиктомалдан көләсе, елыйсы, җырлыйсы килә. Билгеле инде: җан шул Миңлеәхмәт хатына була талпына, шашына.

Кыз калтыранган куллары белән комбинезон изүен чиште, ап-ак кофтасы эченә керде, шул арада җылынып та өлгергән хат кисәген алды. Ачты. Укыды. Укыды да, тыела алмыйча, чирәмгә егылып ятып тәгәри-тәгәри көләргә тотынды. Ап-ак кәгазь битендә егет белән кызның икесенә генә мәгълүм җыр язылган.

...Тебя там-а сотворил,
Меня здесь сотворил,
А меж нами, как назло,
Большое море сообразил...

Ну, бу Миңлеәхмәтне! Шунда матур гына, колакка ятышлы гына тагын бер-ике сүз өстәп куйса, ни була? Марина, хыялый баш, хатны кулына алгач, ниләр генә уйлап бетермәде. Ә ул, исәр, һаман шул җыры белән булаша. Белә бит, каһәр, кызның үзенә нәкъ менә шул җыры белән үтеп керәсен, дөньяларының тынычлыгын җуйдырасын белә. Әнә, Марина ут булып яна башлады. Йөрәге урыныннан купты, күңеле яңа гына күтәрелеп килүче кояш янына ук менеп китте. Кирәксә, кояш тиклем кояш Маринаның күңеленнән дәрт алсын, куәт алсын, кайнарлык алсын! Белсен ул: Миңлеәхмәттән хат бар, җыр бар! Бу җыр Марина белән Миңлеәхмәтнең танышу гимны ләбаса!

Җитмеш беренче елның язгы ташу вакыты иде. Марина, тулай торакка ордер алып, очар кош сыман, үзенә билгеләнгән йортны эзләп китте. Таш пулатларга якын барырлык та түгел — барысы да билдән су эчендә утыра. Маринаның аягында кыска кунычлы резина итек иде. Үзенчә, ул ышанып атлый, аягына су үтеп кермәсен белә. Тик язгы су, аның итеге белән ярыш ачканмыни, һаман киңәя, тирәнәя. Ниһаять, үзенә кирәкле йорт янына җиткәч кенә, Марина бер карыш та алга бара алмас булды. Кузгалдың исә, кунычка, гөлдердәп, кар суы тулачак.

Шулчак күлләвекнең икенче ягында погоннары яңа гына салдырылган яшел гимнастеркалы, озын кунычлы солдат итеге кигән, култык астына ап-ак тышлы мендәр кыстырган, көләч йөзле, чегәннәрнеке кебек кара чәчле егет пәйда булды.

Аның мендәр күтәреп торуы һич гаҗәп түгел иде: монда килгән бер генә кешене дә йомшак ястыклар әзерләп каршылаучы юк. Һәркем кунар җирен дә, ятагын да үзе таба, үзе булдыра иде.

Егет, Маринаның чарасызлыгын бик тиз аңлады да, көлә-көлә такмакларга тотынды.

— Сине анда яр-рраткан ла,
Мин-не монда яр-раткан.
Икебезнең ар-ра-бызга
Ол-луг дәрья яраткан...

Су ташкынынннан ничек котылырга белми азапланган Марина:
— Чево там бормочешь! — дип кычкырды. — Юньле кеше ярдәм итү ягын карар иде!
— Ии-и, түтәем, минем телне аңламагач та, алай ямьсез итеп, «бормочешь» димә әле. Аңлашылмый гына диген, хәзер аңлатам мин аны, ашыкма, аңлашырбыз как-нибудь!
Егет шул ук ераклыкта торып, ике сүзнең берендә татарча исемнәр кыстыра-кыстыра хикәяләргә тотынды.
— Борын-борын заманда безнең авылның бер егете күрше авыл кызына гашыйк булган, ди. Кышның кыш буе күрше авылга, кызны күрергә барып-килеп йөргән, ди бу. Инде менә бүгенге көн кебек, күнелләрне жилкендереп яз житкән, ди. Егет беркөнне, күнгән гадәте буенча, кыз янына барыйм, дип юлга чыккан. Тик ерак китә алмаган, ике авыл арасын су баскан икән. Нишләргә? Егет, бичара, бер аягындагы чабаталарга, бер зәңгәрләнеп торган күрше авыл ягына караган да, иң биек бер өянке башына үрмәләп менеп утырган. Шул биеклектән торып, мәгъшукасына багышлап, жыр сузып жибәргән, ди.
Егет жырның сүзләрен, ничек туры килсә шулай рифмалаштырып, русчага да тәржемә итте. Марина чайкала-чайкала көләргә тотынды. Кыз көлеп туктаганда, егет инде аның каршында, тездән су эчендә басып тора иде.
— Кил, Маруся, — диде ул, Маринаны тәмам гажәпкә калдырып. — Кер куеныма! Жир читенә кирәксә, анда да илтеп куям, тамчы да тидермәм! Тот минем мендәрне!
— Мин — Маруся түгел! Сез мине кем беләндер бутыйсыз. Маруся түгел мин!
Шиккә төшкән кызны тынычландырып егет тагын аңлатты.
— Ә-әй, аппасы, — диде ул татарчалатып. — Татар егетләре рус кызларының барысына да Маруся диләр бит!
— Мин рус кызы да түгел шул. Украинка мин.
— И-и, аптырадың бит юк нәрсәгә, нинди аермасы бар дип торасың — барысы да үзебезнеке!
Кыз аны-моны абайлап өлгергәнче, егет Маринаны күтәреп тә алды, суның иң тирән төшенә таба алып та китте.
Чырылдау, тыпырчынулар үзе өчен үк куркыныч булганга, кыз бер кулы белән иплән кенә егетнең муенын урап өлгерде, икенчесендә мендәр иде. Кулләвекнең кыл уртасына житкәч, егет «шып» туктады.
— Йә, хәзер әйт инде: исемең ничек?
— Марина. — Егет һаман кузгалырга уйламагач, тулырак итеп әйтте. — Марина Майна.
— Мин Миңлеәхмәт. — Үзе һаман кузгалмый, тик тора. — Хәзер тагын бер сорау, әйт: сөйгәнең кем?
Марина Миңлеәхмәтне дә калтырата-калтырата көлә башлады.
— Төшер алайса, әйдә, тездән суда калсам калырмын, төшер, бер алым жир илткән өчен, мең төрле сорау биреп аптыратасың, төшер!
— Әйт: «Сөйгәнем — син, Миңлеәхмәт!» — диген, аннары китәрбез яме?!
— Ай, Миннахмет, Миннахмет! — Марина көлә-көлә егетнең бит уртасыннан үбеп алды. — Син, син, минем монда беркемем дә юк! — диде. — Життеме инде?!

Егеткә шул гына кирәк булган икән, ул, корт чаккан кеше кебек, дулаттырып алып китте. Суны кичкәч тә кызны куенынннан чыгармады, кирәкле йорт янына җиткәнче күтәреп алып барды.

Алар тулай торак ишегеннән шау-гөр килеп керделәр. Миңлеәхмәт комендантны эзли башлады.

— Әй, хуҗалар, сез кайда? Мин сезнең йортка КамАЗның иң уңган кызын ышанып калдырып китмәкче булам, кайда югалдыгыз?!

Егетне берәр җитәкче дип кабул иттеләр, ахры, коридорның аргы башыннан абына-сөртенә килеп чыккан хатын аклану эзләп маташты.

— Әнә бит, ни бит, торбадан су саркый бит...

— Иң әйбәт бүлмәгә! — Миңлеәхмәт Маринага күз кысты. — Кайсысы ул сезнең иң әйбәт бүлмәгез! Ничәнчегә урнаштырачаксыз?

Шулай итеп, Миңлеәхмәт Маринаның төгәл адресын кызның үзеннән алдарак белде. Шул беренче очрашудан ук аларның күңелләре талпынып калган иде.

Миңлеәхмәт «Гидромонтаж» трестында монтажчы булып эшли икән. Алар икесе дә муеннан эшкә чумганнар иде. Марина — техникумда, егет — институтта укый. Шуңа күрә эштән бушаган чакта да озын-озак сөйләшүләргә вакыт юк. Маринаның гаҗәпләнүенә каршы, егет тоткан җиреннән сындыручан холыклы булып чыкты. Берсендә ул, һичнинди икеләнүләргә урын калдырмаслык итеп кисәтеп куйды:

— Менә болай, Марина, — диде. — Безнең фигли-мигли уйнап йөрер ара юк. Әйткән сүз — каккан кадак булсын: кулларыбызга дипломнар алгач, өйләнешәбез! Әниеңә күп итеп сәлам яз, әйт, самогонын күбрәк кусын!

Егетнең җитди йөзенә карап, кыз да мөмкин кадәр тормышчанрак итеп җавап бирергә тырышты.

— Карале, Миннахмет, бездә бит самогон кумыйлар, бездә виноград виносы гына...

Миңлеәхмәтнең хәйлә тозагына эләгеп, үзе дә сизмәстән, кияүгә чыгарга ризалык белдергәнен ишеткәч, егетнең башы күккә тия язды.

— Әй, әллә кайчан шулай дигән булсаңчы! Маруся, Маринакаем! Бер эчемлекнең дә кирәге юк, син бит — үзең исерткеч! Ризалык кына бир — башкасы ике дөнья, бер морҗа мина!

Алар үзләренә-үзләре шушындый ярәшү сыман бер нәрсә, килешү ясап куйдылар. Марина, авылларына ялга кайткач, кешесе барлыкны әнисенә дә сиздереп куйды. Карчык башта сөенде. Вакыты бик җиткән. Кыз баланың үз чиратында никахлануы мәслихәт. Туйны да бик озакка сузарга кирәкмәс! Ул, кызының тел төбен тикшереп карар өчен:

— Кияү булачак кешенең исеме ничек соң, балакаем? — диде.

— Миннахмет, әни.

— Ә-ә? Кайсы як кешесе соң ул?

— Чаллының үз ягыныкы, әни, татар егете.

Карчык елый башлады.

— Ишеткәнем бар иде инде татарлар хакында, — диде. — Кысык күзлеләр, чем каралар...

Ул җәйдә Марина әнисе белән үпкәләшеп килде. Чаллыга вакытыннан алда кайтуының сәбәбен сораштыра башлагач, бу күңелсезлекне Миңлеәхмәткә дә чишеп салды. Егет ул вакытта актан-карадан сүз әйтмәде. Октябрь бәйрәме җитәрәк, бу вакыйганы яңартып:

— Мин эштән бер-ике көн сорадым, әйдә, Маринам, әниеңнең хәлен белеп килик! — диде. — Әниләр белән ачуланышып яту — эш түгел!

Әллә кайчан кайтып күренәселәре генә калган икән. Миңлеәхмәтне Мариналарның бөтен поселогы, чират төзеп, кунакка йөртте. Әни карчык канаты чыккан кош кебек талпынды.

— Әллә туйны да хәзер үк ясыйкмы, Миннахматушка? — диде хәтта.

— Диплом алгач, — диде Миңлеәхмәт. — Алдан ук шулай сөйләштек, маманя, хәзер килеп җитә ул, самогонны әзерли тор!

Яшьләрне Чаллыга озатканда, поселоктагы бөтен халык үзара туганлашып беткән иде инде. Бер-берсенә иң кадерле сүзләрен, иң изге теләкләрен әйтештеләр. Миңлеәхмәт тамбурдан:

— Хай живе, раданська Украина! — дип кычкырды. Бу — аның украинча белгән бердәнбер җөмләсе иде.

Аңа җавап итеп, украин картлары:

— Рахмат, рахмат! — дип кул болгадылар.

... Марина иртәнге нурга өртелгән дымсу үлән арасында ауный. Кыз баланың күңелләрен күккә күтәрергә күп кирәкме? Шул кара егетнең килделе-киттеле җыры сызгаланган кәгазь кисәге дә җитеп ашкан! Каян гына болай таң-иртәдән кулга килеп керде соң әле? Марина сискәнеп китте. «Зөһрә ничек монда килеп чыккан соң? Чаллыда бөтенләйгә калганмы ул? Кайда эшли? Кайда яши? Ник боларның берсен дә сорашмады ул? Кеше кайгысы төштән соң дигәннәре шул микәнни соң?»

... Сизә Зөһрә: Маринаның түе да озакламаячак. Туйда сикереп-сикереп бииселәр бар әле! Иң очып биючесе Зөһрә булачак. Ул, шыпырт кына, украинча бию өйрәнеп йөри. Башына кияргә мең тасмалы такыя да әзерләде. Шундый чакта китәләр димени?..

## Көч сынашканда

Участок кызларын сменадан соң цех начальнигы бүлмәсенә чакырдылар. Зөһрә җыелышларны яратмый. Бүген ул иртәдән үк чаңгылар күтәреп килгән иде — эштән соң завод белән ГЭС поселогы арасын шуа-шуа үтмәкче. Җыелышка калсаң, чаңгылы сәфәр турындагы ният барып чыкмый. Шулай да бүгенге җыелыш турындагы хәбәр Зөһрәнең ачуын кабартмады. Җыелышы чаңгыга караганда кызыклырак, файдалырак булачак. Кыз бу көнне күптән көтеп йөрде.

Начальник җыелышның максатын бер-ике сүз белән генә аңлатты. Һәр ел башында булып уза торган вакыйга иде бу. Коючылар ел дәвамында башкарылырга тиеш эшне билгеләләр, планда каралганга өстәп, йөкләмәләр алалар. Ярыш оештыралар. Ярышның һәр шарты, йөкләмәнең күләме һәм сыйфаты кәгазьгә теркәлә, үзара ярышучылар, шунда язылганнар белән ризалыкларын белдереп, имзаларын куялар.

Башта коллективлар арасында килешүләр төзелде. Аннары аерым эшчеләр үзләренә тиң кеше сайлаштылар, көч сынашыр иптәшләрен билгеләделәр. Чират Зөһрәгә дә җитте.

— Я, Алмаева! — диде цех начальнигы. — Сине остазың Мәрвия апаң үзе ярышка чакыра. Ни диярсең? Икенче разрядың белән Мәрвия апаңа каршы тору кыенрак булыр булуын...

Разрядының түбәнлегенә Зөһрә зур әһәмият бирми. Мәрвия койган катлаулы калыпларны инде аның да койганы бар. Брак бирмәде. Аерма хезмәт хакында гына. Бер үк эш өчен югары разрядлылар күбрәк ала. Хикмәт анда түгел. Зөһрә тәвәккәлләде.

— Мин риза! — диде. — Тик килешүдә алдан каралган шартларга өстисе бер шартым бар.

Бөтен ыгы-зыгы шуннан башланды. Зөһрә кою заводында чималны янга калдыру турында сүз кузгатты. Моның гаҗәеп зур мөмкинлеген ачты.

— Безнең болванкалардан бармак башы чаклы деталь килеп чыга. Металлның яртысыннан артыгы яңадан чималга әйләнеп кала, әрәм була. Юкны бушка бушатабыз...

Әле биш-алты ел гына элек бу җирдә шып-шыр басу иде. Хәзер монда баһадир завод эшләп утыра. Коючыларның май кебек җылы бүлмәсендә, авыз җәеп, шул сүзләрне әйтергә кирәк бит, ә?! Кем сөйли диген әле син аны? Аягы керсә, башы кермәгән, бүген эшләсә, иртәгә заводыңны ташлап шәһәргә, институтка сызарга торган бер кыз бала.

— Син нәрсәне нәрсәгә бушатасыңдыр, сеңел? — дип, цех начальнигы кара көеп, кисәтү ясады. — Мондагы күпчелек заводның нигезен салуда катнашкан кадровый рабочийлар. Егерме биш яшьләре тулмас борын заводның ветераннарына әйләнгән кешеләр алар. Авызыңны сөйләгәнне колагың ишетсен!

Зөһрә аңа да үпкәләмәде. Беренчедән, сүзенең хаклыгына ышануы көчле иде аның, икенчедән, фикеренең каршылыкка очравын алдан белеп, көтеп торды.

Ул, үзе койган калыпларның кайда барып керүе, нинди эшкә яравы белән кызыксынып йөри торгач, гаҗәеп бер хакыйкатьне ачыклады. Калыплар үзләре дә коточкыч калын итеп коела, аларга салып катырыла торган металл да, ясалачак детальгә караганда, искиткеч зур иде. Кыз чималның шул кадәр күпләп исраф ителүенә гаҗәпкә калды. Ярты гына миллиметр юкарак итеп коелса да, смена саен әллә ничә тонна калыплык балчык һәм металлны саклап калырга мөмкин.

Башына мондый уй кергәч, Зөһрә үзе ачкан яңалыкка ирешү юлларын да эзләп карады. Бик катлаулы булып чыкты. Зөһрә башы гына җитәрлек түгел. Күп исәпләргә, сынаулар үткәрергә кирәк. Эш калыплар ясала торган формаларның үзен үзгәртүдән башлана. Станокларны туктатырга кирәк. Конвейер дигәнең исә бер генә минут та тукталмаска тиеш. Завод дәүләт тарафыннан кабул ителгән, димәк, аңа план салынган. Минут саен диярлек заводның баш конвейерыннан машина килеп чыгып торырга тиеш. Ун меңнәрчә эшчеләр әнә шул машина ясалсын өчен көч сарыф итә. Зөһрә дигән бер кыз әмере белән кинәт шул бөек хәрәкәт тукталып калсын, имеш. Белә Зөһрә, үз сүзенең зур гауга куптарасын бик яхшы белә. Әмма әйткәненнән кире чигәргә теләми ул.

— Исраф малның күплеген исәпләп караган идем — чәчләр үрә торды. Күз йоммыйк әле, җәмәгать! Яңа шартым менә шул: кем дә кем яңа төр калыпка күчеп, экономия өлкәсендә моңарчы күрелмәгән резервтан файдаланырга риза, әйдәгез минем белән ярышка! Станокларның барын берьюлы туктатмабыз, берәм-берәм. Аның каравы, соңыннан тагын да ныграк тырышачакбыз. Башлангычы куркыныч булса, тәвәккәллекнең нәтиҗәсен күзаллап карагыз! Тонна-тонна җирән балчыгыбыз янга калачак. Балчык кына дисәк тә, аның составына кергән кайбер матдәләр әллә кайлардан китертелә бит, үзегез беләсез, алтын бәясенә төшә...

Бу кадәресе һәркемгә аңлашыла иде. Кызлар кайчак ул балчыкның җитешмәвен дә татыйлар. Смена азагына балчык җитми кала. Измәгә салынырга тиешле ниндидер бер матдә юклык аркасында балчык әзерләүчеләр чарасыз утыра. Балчыкны янга калдыра башласаң, эштәге өзеклекләрдән котылыр идең.

— Нигә аптырап калдыгыз?

Зөһрәнең бу соравы партоешма секретарен айнытып җибәргәндәй итте. Ул әлегәчә сүзгә кушылмый утырды. Мәсьәләнең җитдилеге ашыгуларга урын калдырмый.

— Син, сеңел, кем, Алмаева иптәш, хәзергә, элекке шартларга нигезләп төзелгән килешүгә кул куй. Ә бу яңа фикереңне рационализаторлык бюросына җиткерергә кирәк. Икесе ике төрлерәк нәрсәләр болар. — Секретарь бик аңлаешлы итеп сөйләде. — Эштә арыганбыз, сүзне озакка сузмыйк. Ярышка тәвәккәлләсәң, кул куй!

— Мин ел саен кабатланучан шаблон шартларга риза түгел.

Зөһрәнең кыланышы кырдан узды. Һәрхәлдә, җыелыштагыларга бу шулай тәэсир итте.

— Ярый алайса, фикер алышыйк! — диде секретарь. — Алмаева иптәшнең тәкъдимен кем кабул итә?

Мәрвия урыныннан сикереп торды.

— Нигә без һәр капризга җавап биреп торырга тиеш әле? Без ачкан ярыш станокларны туктатачак, кем риза булсын аңа?

Мәрвия үзе белән ярышырлык башка кеше тапты. Зөһрәнең сүзен үргә алган кеше булмады. Секретарь гына бу фикерне, алдан бик җитди әзерләп, завод күләм киңәшмәдә кузгатачагын әйтте. Зөһрәне шул кадәресе дә шатландырды. Димәк, аның башына тузга язмаган борчу кермәгән, кирәкле уй кунган!

Бөтен коллектив бер булып ярыш килешүләре төзегәннән соң, эш ялгызы читкә тибәрелеп калса да, өйгә кайтканда, Зөһрәнең кәефе начар түгел иде. Мәрвиянең эндәшми торуын да, ул, үтәр әле, диг, көтте. Әйтер әле бер сүз — күңелләр арасына салкын өрүче җил тынар да куяр.

Аһ, бу кеше күңеле шул җилләр, сулар, бозлар кебек кенә булсачы! Җиленнән ышыкланып котылырга; бозын, ут ягып, эретергә; суының агым юнәлешләренә кадәр үзгәртеп бетерергә мөмкин. Кеше күңеленең бер генә талпынышын үз теләгеңә буйсындырып кара син! Зөһрә хәзер Мәрвия апасының борчуларын басарга, ике арага кереп оялаган аңлашылмаучылыкны юкка чыгарырга җанын да кызганмас иде. Әйтсен иде бер сүз!

— Син, Зөһрә, яхшы чакта, кит бездән, кит!..

Барыбер беркая да китә алмасын белеп әйтүе микән?

Мәрвия бүлмәдән чыккач, Зөһрә үзенә шөгыль таба алмый интекте. Киң тәрәзә төбендәге радиоалгычны да боргалап карады. Уйларын басарлык сүз дә, җыр да ишетмәде. Газеталарга күз йөгертеп чыкты. Күзләре генә сүзләр укыды, башындагы борчу сөреме барыбер таралмады. Китаплар актарды. Җан тынычланмады, Мәрвиянең рәнҗеше йөрәккә кан саудырган.

Зөһрә, бер китапны ачты да, диалоглар күп булуын хуп күреп, шуны укырга ниятләде. Караватына барып утырды. Әсәрдәге вакыйгалар эченә кереп чумарга, үз хәлләрен онытырга теләде. Булмады. Әгәр шул вакытта, ишек ачылып китеп, аннан авызы-күзе көлеп торучы Табибә килеп кермәсә, барыбер дә тынычлана алмаган булыр иде ул.

Табибә, исәнлек-саулык та сорашып тормастан:

— И-и, җаныемдыр ла, ярый әле, син өйдә туры килден! — дип, Зөһрә янына килеп утырды. — Очам, очам, кая барып кунар җир тапмыйм.

Зөһрә ни дияргә дә белми иде әле.

— Бәхти әйтә, син — хыялбаш, ди. — Табибә кыткылдап көләргә тотынды. — Хыялбаш, имеш! Бу сүзнең бит, мин әйтәм, ике мәгънәсе бар. Кайсыдыр якта тиле-миле кешегә хыялый диләр. Җыры да бар әле.

...Суга балык оялый,
Я булырмын бик бәхетле,
Я булырмын хыялый.

Табибә, җырлап туктагач, аңлатып та бирде.

— Менә мондагы «хыялый» дигән сүз саташу, акылдан язуны аңлата бит.

Табибәнең шулай тиктомалдан җыр көйләве, такмак уңаена биепбиеп алуы сәер иде.

— Ни булды соң сиңа, Табибә апа?

— Бәхти әйтә, син, Табибә, җир ярыгы майлап йөрисең, ди.

— Кайчан күрдең? Мәрвия апа янына килгәнмени?

— Юк. Мәрвия янына түгел. Бәхти әйтә, синең кебек җир ярыгы майлаучылар булмаса, ди, бу дөнья күңелсезләнеп калыр иде, ди.

— Ник алай әйтә? Нәрсәне җир майлау ди соң ул?

Ниһаять, Табибә тыныч кына аңлатуга күчте. Хикмәт шунда — кыз күздән юк тавыш күтәреп йөргән иде. Ул чакта Табибә җылылык үзәгенең яңа бинасын салуда эшләде. Вакыт тар булгач, ул тирәгә шәһәрнең иң уңган төзүчеләрен җыйдылар. Нәкъ шул чакта, үч иткәндәй, шәһәр өстен сөттәй томан каплады. Куркынычсызлык техникасы кагыйдәсе мондый көннәрдә манара краннарын эштән тыя.

Кая барып бәрелер урын тапмады Табибә. Өзгәләнде. Төзелеш начальнигыннан:

— Нишләп прожекторлар көйләп куймыйбыз соң? — дип тә сорап карады.

Анысы:

— Аны син генә уйламаган, мин дә бик яхшы беләм, баш катырып йөрмә! — диде. — Шул кадәр краннарга прожектор каян алып бетермәк кирәк?

Начальникның вагоныннан чыгып барганда, Табибә дүрт ягыннан дүрт прожектор белән яктыртылган бер плакатны күреп алды. Аңа «ТЭЦның яңа чиратын срогыннан алда сафка бастырыйк!» дигән сүзләр язылган. Кызның башына уй килде: «Бу плакат өчен көн яктысы да җиткән бит инде!» Ул кире борылып начальнигына керде. Үсеп җитмәс борын кәкрәйгән кыяр сыйфатлы агай бу юлы аны ачуланып куып чыгарды.

— Кушмаган эш артыннан аяк киеме туздырып йөрмә! — диде. — Бар, кайт та ял ит! Синең средниең түләнә, атаң башы кирәкме тагын?

Табибә юл буенча үзалдына үртәлеп кайтты. «Средний да средний, диләр. Әйтерсең мин акча сорарга кергән!» Бу юлы кыз шәһәр үзәгенә, партия комитетына ук килде. Беренче секретарьның ишек төбендә утыручы ханым Табибәгә:

— Сүзең эш турында булса гына, биш минутка кертәм, — диде.

— Миңа биш минут кирәкми, ике минуты да җиткән!

Керде Табибә. Аңлатты. Башта ул сораулар тезеп куйды:

— ТЭЦның икенче чиратын сафка бастырырга кирәкме? Ашыгычмы?

— Кирәк һәм ашыгыч, — диде секретарь. — Тәкъдимегез нинди?

— Минем утыз-утыз биш тонна күтәрә торган краным менә инде өч көн тик тора. Кран эшенә бәйле алты әзмәвердәй ир вагонда, кырын ятып, шашка шакмагы шуыштыра. Ә плакат тора. Көндез дә, кич тә. Безне мыскыл иткән кебек тора. Кирәкми аңа ул прожекторлар! Көн яктысы да бик җиткән!

Секретарьның йөзендә теләктәшлек галәмәтләре күрмәгәч, үзенең «җаныемдыр ла»ларын кыстырып инәлергә тотынды Табибә.

— Томан беткәч, кире илтеп куярмын, үзем җавап бирермен! — дип тә карады.

Секретарь телефонга сузылды.

Икенче көнне томан тагын да куерак иде. Куркынычсызлык саклау техникасы инженеры, койрыгы пешкән песи кебек, кран тирәли сәгатьләр буе әйләнеп йөрде. Табибәгә бәйләнер урын тапмады, кыз кагыйдәне һич кенә дә бозмаган хәлдә, рәхәтләнеп эшли бирде.

Кызның кәефе әнә шуңа күрә күтәренке.

— Менә шуны, Бәхти әйтә, җир ярыгы майлау, ди. Бер дә җир ярыгы түгел, дим, мин әйтәм, әнә хәзер башка кранчылар да кызып йөриләр. Прожектор даулыйлар. Беләсеңме, күпме вакытны отабыз без! Бу яклардагы томанның беткәнен көтеп торсаң... Хәзер әнә һәр кранның прожекторы бар, ди. Әй, шатландым, әй, куандым! Бәхти әйтә, аны син башлап җибәргәнне белгән кеше дә юк бит инде хәзер, ди. Мин әйтәм, син элекке, аерым хуҗалык белән яшәүче крестьян карты кебек фикер йөртәсең, дим. Бәхти әйтә...

— Карале, Табибә апа, бүген мин дә шундыйрак хәлдә калдым бит. — Зөһрә эчен көйдергән утны тышка чыгарыр җай табылуга сөенде. — Мәрвия апа белән дә шуның аркасында ачуланыштык.

Табибә сүзнең җитдилеген аңлап, очыну-калкынуларыннан туктады. Зөһрәнең борчуларын басардай сүзләр эзләп маташты. Таба алмады, андый сүз юк иде.

— Бу, җаныемдыр ла, минем прожектор эше генә түгел шул. Металл белән эш итүче һәр кеше бу хакта уйларга тиеш иде югыйсә. Җир астыннан чыга дигәч тә, җирдә дә әндри казнасы юк бит, чамаламый тотсаң, бетә дә куя ул. Аннары ничек ясыйбыз ди ул машинаны? Ярый әле, башыңа килгән?

— Килде дә бит, яратмадылар, әнә.

— Ашыкма. Исәпләсеннәр, сынасыннар. Табышның тәме йөгерсен! Аннары үзеңне уч төбенә генә утыртып, кадерләп йөртерләр.

— Сине йөрткән кебекме, Табибә апа? — Зөһрә Табибәне үчекләвен яшереп тә тормады. — Прожекторлар өчен диюем.

— Әй, миңа нәрсәгә ул уч төбе? Сүземне сүз иткәннәре өчен мин үзем аларны, юк, аларны гына түгел, бөтен Җир шарын уч төбемә алып сөяр идем әле!

— Миңа Чаллыдан китәргә кушалар бит. — Зөһрә Мәрвиянең исемен телгә алырга батырчылык итмәде. — Яхшылык теләгәнем өчен, үзләрен яратканым өчен...

— Борчылма, борчылма! Чаллы шулай итә инде ул, бер утка, бер суга сала. Кайбер эшең исән башка тимер таяк булып төшә. Тоташ бәйрәмнән генә торса, бу дөнья әллә кайчан туйдырган булыр иде инде. Монда туеп өлгерергә ара юк, шатлыгы янына, тупырдап, кайгысы килеп баса. Гел аралашып торалар.

— Китә алмыйм бит мин, Табибә апа. Китәсем килми.

— Беләм, китәрдәй булсаң, мин синең белән сөйләшеп тә тормас идем.

Зөһрә Табибәнең башка сүзләрен ишетмәде. Көне буе күңелне бу-ып торган мең төрле каршылыклы хисләр, Табибәнең юатучан сүзләрен ишеткәч, җай гына бер юлга тезелделәр дә, кайнар яшькә әйләнеп, тышка бәреп чыктылар.

Ела, бала! Ела, чибәр кыз! Еламыйча гына бу дөньяны аңлап бетереп булмый.

## «Һелоу, мистер Майкл!»

Дөньяны яз рәхәте биләп алды. Яз килүен төрле кеше төрлечә тоя. Берәве, гөрләвекләр акканны күргәч кенә: «Кара, тагын яз җитте!» — дип куя. Сизгеррәкләр аны тирә-юньгә шыгырдавык карлы кыш хуҗа чакта ук, һаваның хуш исеннән үк тоеп ала: «У-ух! Яз исе килә бит!» — диләр.

Чаллыда исә яз җитүне бөтен кешегә берьюлы хәбәр итә торган тагын бер нәрсә бар. Бию мәйданчыкларына җан керә, «пятачок»лар эшли башлый. КамАЗ төзелеше башлануның беренче елында ук бар-

лыкка килделәр алар. Яңа йортлар арасындагы буш мәйданга яшьләр җыела иде. Клубларның, культура сарайларының житешмәвеннән башлангандыр инде ул. Буш урынга җыелалар, музыканты да табыла, җырлап та җибәрәләр, җир җимертеп, биеп тә алалар. Яңгырлардан соң мәйданнар сазга әйләнеп калучан булгач, йортлар идарәләре бу урыннарны хәтта асфальтлап та куйды. Кыскасы, яшьләрнең уен мәйданы законлы төс алды. Хәзер дә, инде кинотеатрлар, клублар, культура сарайлары салынганнан соң да, егет-кызлар «пятачок»ларны ташламый әле.

Мәрвияләр бүлмәсе кызлары да атнага бер-ике тапкыр бу рәхәтне татый. Яз шулай итте: кызлардан йокы качты. «Пятачок»тан унберләр тирәсендә генә кайтып, йомшак караватка чумгач та озак кына сөйләшеп яталар алар. Сүзнең күбесе бию мәйданындагы вакыйгаларга бәйле була: кем кем белән биегән, кем нинди кием белән чыккан, музыканты кем булган...

Эшкә бәйле ыгы-зыгылар шомарып, бер җайга салынган иде инде. Зөһрә чималны янга калдырырдай яңа төр калыплар турындагы фикерен язма рәвештә тиешле бүлеккә кертеп тапшырды.

— Ярар, — диделәр. — Бу турыда уйларга күптән вакыт булган икән. Җитди эш бу!

Мәрвияне исә шәһәрдә уздырылган бер зур җыелышта мактап чыктылар. Нәрсә өчен диген — яшьләрне дөрес тәрбияләгәне өчен. Мисалга Зөһрә Алмаеваны — «Экономияләүнең өр-яңа һәм иң әһәмиятле резервын ачкан яшь эшчене» телгә алганнар.

Шул рәвешле мөнәсәбәтләр тәмам әйбәтләнеп беткән иде инде. Зөһрә уйламаганда гына тагын бер ялгыш җибәреп куйды. «Пятачок»тан кайткач сөйләнә торган килделе-киттеле сүзләргә кыстырып, Зөһрә:

— Кара, Мәрвия апа, бу арада синең Бәхти күренмибашлады бит әле, — диде. — Әллә бүтән кызга күзе төшкәнме ул явызның?

Шаркылдашып ятучы кызлар тып-тын булды. Бүлмә мәет чыккан йорт шикелле шыксыз салкынлыкка өртелде.

— Ник дәшмисез? Ник көлмисез? Мин бит шаяртып кына әйттем.

— Башың яшь әле, — диде Мәрвия. Үзе кабалана-кабалана халатын әлде дә бүлмәдән чыгып китте. — Башың яшь.

Марина да озак кына берни әйтми торды. Аннары:

— Кирәкми, Зөһрә! — диде. — Сөйләшмик бу турыда.

Марина белә иде. Йөрәгенә чыдаша алмый йөргән көнне Мәрвия үзе сөйләде.

Бәхтигә хат язган иде ул. Иске авыздан яңа сүз — ике көннең берендә очрашып йөри торган кешегә Мәрвия хат язды. Фәлән көннең фәлән сәгатендә фәлән җиргә кил әле, бик кирәк, диде.

Машинасын җан-фәрманга куып килеп җитте Бәхти. Сәлам бирмәс борын:

— Моннан да таррак вакыт тапмадыңмы? — диде. — Эшнең бигрәк кызу чагы бит!

— Эшеңнән сорап килмәдеңмени?

— Нигә эш калдырырга? Нәрсә булды соң?

Мәрвия бу сөйләшүне бөтенләй башкача күзаллаган иде. Очрашу вакытын ул төшкә таба сайлады. Башта юк-барны сөйләшеп урамда йөрербез, аннары «Кама» ресторанына кереп утырырбыз, дип өметләнде. Оялачагын, сүзне кирәк эзгә салып җибәрә алмыйча шактый вакыт уздырачагын да белде. Тик Бәхти бу очрашуга самосвалы белән «дулаттырып» килер дә, минутына кырык сорау биреп, җелеккә төшәр, дип, башына да кертеп чыгармады. Бу уйланылмаган хәлдән каушап төште, тел әйләндереп сүз әйтә алмас булды Мәрвия. Көмачтай кызарып:

— Ничек соң эшләрең? Кәефең? — дип сорады.

Озын, кара керфекләренең җиргә кадалып калуыннан, сүзләренең калтыранып чыгуыннан, бармакларының, иреннәренең дерелдәп торуыннан Бәхти Мәрвия хәленең мөшкеллеген аңлагандай булды. «Башына бәла килгән моның. Миннән бүтәнгә аңлата алмаслык бәла»...

— Кер әле кабинага! — диде егет. — Син — анда, аста, мин монда килеш әллә ни сөйләшә алмабыз.

Мәрвия, йөгереп, кабинаның икенче ишегенә килде, эчкә керде.

— Йә, кыска гына итеп, ачык кына, иң мөһимен генә әйт. Тартынма! Кулымнан килгәннең барын да эшләрмен. Нәрсә кирәк?

— Үзең кирәк миңа, Бәхти! — Мәрвиянең башка чарасы калмаган иде инде. Күзләрен, кабина тәрәзәсе аша, туры юлга төбәде дә әйтеп салды. — Үзең кирәк!

Бәхти бөтен гәүдәсе белән баранкага капланды. Тонык кына сигнал тавышы чыгып куйды. Егеткә рәхәт иде. Мәрвия кебек акыллы, уңган, чибәр кыз шулай әйтеп торса, Бәхти генә түгел, җирнең теләсә кайсы егете сөенер иде. Бу дөньяда үзеңнең башкаларга кирәклегеңне тоюдан да куанычлырак тойгы бармыни? Кеше булып яшәүнең төп мәгънәсе дә шул түгелмени? Бу хисне Бәхтидән дә ныграк аңлаучы кеше юктыр да әле! Ул кешеләрнең генә түгел, җир өстендәге бөтен җан ияләренең, үсемлекләрнең дә хәтта үз ярдәмен кирәксенүләрен тели. Тереклекне бәхетле итү юлында җаны жәл түгел. Ул тырышачак, бөтен белгәнен, көчен, ихтыярын бары тик шул юлга гына, дөньядагы бәхет хакына гына сарыф итәчәк.

— Я, ник дәшмисең?

«Мәрвия кулдан килмәстәйне сорый бит, нишләргә соң?»

— Туктале, Мәрвия!

— Үзең ашыктырдың.

— Әйбәт син, Мәрвия, бик әйбәт...

— Кирәкми!

— Ничек кенә аңлатыйм соң? Андый чакта Табибә: «И-и, җаныемдыр ла, гомеркәйләрне берне генә биргән бит, ике булса, берсен тоташы белән синә тапшырыр идем», — дип котыла...

Кабинаның кыз ягындагы ишеге тавышсыз гына ачылып китте. Мәрвия, йөктән төшеп калган мал күк, машинадан читкә аерылды. Бераздан Бәхти самосвалының үкерүе тирә-юньне тутырды. Егет эшенә ашыга иде.

Ул көнне кич бүлмәгә иң алдан Марина кайтып керде. Ни булган? Урамда яз. Кояш нурлары әллә нинди төмсә кешеләрне дә елмайта, көлдерә. Бу бүлмәгә, бөтен тулай торагында иң рәхәт бүлмәгә, кабер салкынлыгы ничек үтеп кергән? Марина тиз сизеп алды: Мәрвиянең кәефе кырылган иде. Мондый чакта кешене ялгыз калдырудан да яхшысы юк. Марина, ашыгып, җыена башлады.

— Китмә! Калдырма берүземне! — Мәрвиянең бу тавышыннан стеналар калтыранган төсле тоелды. — Кил яныма!

Зөһрә кайткалаганчы, Мәрвия эчен бушатып өлгергән иде инде. Аның ул чактаниләр кичергәнен Маринадан башкалар сизми калды. Зөһрә, тиктормас тел, бу хәлләрнең берсен дә белми иде шул. Белсә, һич кирәкмәгәндә, Бәхти турында шундый саксыз сүзне куертып та тормаган булыр иде.

Ярый әле, Мәрвиянең бу үпкәсе озакка сузылмады. Икенче көнне иртән алар бергәләшеп эшкә киттеләр. Станокларын да икесе бер вакытта тоташтырдылар.

Гадәти көн иде бу. Тик бераздан, каршында күзләре атылып чыгарга җитешкән Мәрвия апасын күреп, Зөһрә тагын каушап төште. «Шул Мәрвияме соң бу? Бөтен кою заводы яшьләренә үрнәк итеп

телгә алына торган, калып коючы кызларның комсоргы Мәрвия шушымы?»

Ул кулларын болгый-болгый кемнедер тирги иде.

— Күпме вакытымны әрәм иттем? Җен ачуларымны чыгарды!..— Тезеп торып китте, сабырлыгың җитсә тыңла, анысы булмаса, якын килмә. — Каныма тоз салды, тиремә сыеша алмый башладым. Тегеләй дә итәм, болай да җай эзлим — юк! Булмаса булмас икән!

Тагын бераз шулай кызса, һичшиксез, елап ук җибәрәчәк иде ул. Хәлне бу дәрәҗәгә үк китереп җиткермәс өчен, әле хикмәтнең нәрсәдә икәнен дә белмәгән килеш, Зөһрә:

— Ә син төкер аңа, Мәрвия апа! — диде.

Мәрвия «шып» туктады. Кысык күзләр түгәрәкләнеп киткән кебек булды. Аның тынычланып калуыннан файдаланып, Зөһрә үз сорауларын яудыра башлады.

— Нәрсәгә дип шул кадәр кыздың соң әле син, Мәрвия апа, баш ярылып күз чыкмагандыр бит?

— Әйтеп торам ич: тегеләй дә итәм, болай да — юк! Станогым киреләде. Инструкциясен яттан беләм, әллә кемнәргә ярдәм итеп, җайлашып йөргәнем бар... Юк, әнә, туктады да калды. Әллә ничә салырлык изменә әрәм иттем, башта киптерми интектерде, инде бөтенләй туктады.

Чыннан да, сәер хәл иде бу. Станоклар күп эшне автомат рәвештә башкара. Коючының бурычы әзер калыпларны конвейерга алып куеп, машинага күз-колак булудан гына гыйбарәт. Бер җаена төшенгәч, бу «Сахара дөяләре» бик күндәм эш атларына әйләнделәр. Мәрвия әлегә кадәр мактап бетерә алмый иде аларны. Хәзер әнә үзе үк чарасыз калган. Калыпчыларның остазыннан саналган Мәрвия үзе дә тыңлата алмаган станокны Зөһрә генә нишләтсен? Ул Мәрвиягә ярдәм итәргә әзер булуын аңлатыр өчен генә:

— Әйдә соң, бергәләп карап карыйк! — диде. — Мин генә әллә нишли алмам инде, Мәрвия апа, мастерга әйтеп, ремонтникны чакырырга кирәк!

— Ә-әй! Алардан да эш чыкмады шул: мастеры, үзе урынына мине калдырып, завком утырышына китте. Ремонтник — әнә! — Мәрвия агрегатның аргы ягына ымлады. — Сәгать буе азаплана, станок тавышы чыгара алганы юк.

Ремонт ясарга тиешле егет үзе әллә кая, станок артында иде. Зөһрәгә аның лакированный туфли кигән аяклары күренде дә яман авыр итеп мышнавы ишетелде. Бу күренешләр дә Мәрвиянең чыгырдан чыгуын аклый иде.

— Нишлик соң, Мәрвия апа?

— Эшләсәң, син эшли аласың инде аны, сеңелем. — Мәрвия хәйләкәр елмаеп куйды. — Син бу станокларны ясап китергән оешма вәкилләрен беләсеңме? Американнарны? Кайда утырганнарын күргәнең бармы?

— Ба-ар, Мәрвия апа, беркөнне шул бүлмә ишеге төбендә юри басып тордым, сөйләшкәннәрен ишетәсем килде.

— Аңлашыламы?

— Аңлашыла-а! Алар бит, кызык, бер-берсенә «мистер» дип эндәшәләр, «р»ны ишеттермичә генә әйтәләр.

— Ә син миңа бу участокны проектлаучы оешма вәкилен беләсеңме?

— Юк.

— Бүлмәнең иң түрендә утыра, исеме мистер Майкл. Башында гел ишел каска була аның, кабинетта утырганда да салмый, әллә түшәм төшәр дип курка. — Мәрвия бер солдатын разведкага җибәрергә әзерләгән командирны хәтерләтә иде. — Миңа шул мистер Майкл янына

кер син! Иң түрдә, уң кул яктагы өстәлдә. Кер дә әйт: мистер, диген, один «Суттер», диген, никуда не годится, диген. Әйдә әле, күз сал, диген.

Зөһрә инде Мәрвиянең сүзләрен ишетми, эчтән генә инглиз сүзләре чүпли, мөмкин кадәр гади генә итеп сорау бирү ысулларын эзли иде. Кызның тынып калуын Мәрвия, үзенчә, куркуга исәпләде.

— Их, син! — дип үчекләргә тотынды. — Инглиз теленә керәм дип, әтәчләнеп йөргән буласың тагын!

Зөһрә куркырга уйламаган икән.

— Ну, комсорг, андый-мондый халыкара скандал чыгарсам, җавабын бирергә әзер тор! — диде дә ялтыравык стеналардан цех уртасына торгызып куелган кабинетлар ягына китте.

Бер-икене атлагач, Мәрвиягә кычкырды.

— Тел өйрәнә алмас идең син, бер мәртәбә әйттем бит инде, «Суттер» түгел, «Сатә» дип укыла ул. Минем «Сатә»гә күз-колак бул!

Коридордан барганда, Зөһрәне төрле шикләр биләп алды. «Ярамыйдыр. Дәүләт белән дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләргә зыян китерүең бар. Телләре дә бөтенләй башкадыр әле?..» Үзенең инглизчә сөйләшеп карау теләге бик көчле иде, шуңа күрә әлеге шикләргә каршы торырлык дәлилләр дә эзләп таба барды. «Нигә, мин начар ният белән йөрмим бит! Кеше — кеше инде ул. Әнә егетләр белән футбол матчлары оештырып йөриләр бит әле. Безнең егетләр командасы җиңсә дә, ачуланышмадылар»...

Күңелне иң җилкендергәне — үзен сынап карау теләге барыбер җиңде. Кулларының ишекне ачып җибәргәнен сизми дә калды Зөһрә. Бүлмәгә кергәч, ул эчке бер сиземләү белән тоеп өлгерде: әгәр үзенә кирәкне хәзер үк, үҗәтләнеп әйтеп салмаса, башны аска иеп чыгып китүдән башка чара калмаячак. «Без әлеге сәгатьләрдә бу мәсьәлә буенча берәүне дә кабул итмибез!», «Бусы безнең вазифага керми!», «Безгә моның өчен түләнми!» кебек мең төрле сәбәп белән чит ил агае аны «эһ» тә итмичә кире чыгарып җибәрә ала. Баш тартырлык урын калдырмаска иде!

Зөһрә, Мәрвия өйрәткәнчә, бүлмәнең түренә, башына каска киеп утыручы ак йөзле агай янына барып басты. Һәр сүзен, китап битеннән укыганча, аермачык итеп, инглизләрчә, «т» авазын телне аңкауга терәп, дырылдаттырып, сүз азагында килгән «р» авазын «йота-йота» сөйли башлады. Сәламенә җавап бирүләрен дә көтмәде:

— Мистер Майкл, вууд йоу пэс ту де туул-рум фо э минит! Э мәшин из аут оф оодә! Йоу һелп из несисри. (Мистер Майкл, бер генә минутка безнең цехка керә алмассыз микән? Бер станок киреләнә. Сезнең ярдәм кирәк.)

Американ утә күренердәй сыек зәңгәр күзләрен Зөһрәдән ала алмый торды. Ни генә болай гаҗәпләндерде икән аны? Зөһрә: «Аңлата алмадым, күрәсең», — дип, пошына да башлаган иде инде. Агай, тавышына соклану төсмере кушып:

— Вәт э йоу? (Кем соң син?) — дип куймасынмы!

— Э воке — Зөһрә Алмаева. (Эшче мин — Зөһрә Алмаева).

— Дю йоу спиик иңлиш? (Инглизчә сөйләшә беләсеңме?)

— Ес, ай дю! (Әйе, беләм.) — Зөһрә елмаеп җибәрде, тыела алмыйча, шатлыгына чыдаша алмыйча елмайды. Моны инглиз инженер да сизде. Ул да ачылып китте.

Зөһрә Мәрвиянең станогы тынып калуга хәзер мең рәхмәтләр укый, аның бу хакта бөтен дөньяга ура кычкырасы килә. «Бу американ агай белән, шул киң цехны бию залына әйләндереп, пар килеп вальс биергә иде! Белә Зөһрә: чит илдә хәзер вальсны бик биемиләр бугай. Риза, ул бүген, агайча, бөгелә-сыгыла кыланырга да риза. Зөһрәнең биюләргә мөнәсәбәтен беләсегез килсә, аныңча, иң әйбәте — Айлы Яр авылы

көенә тыпырдау! Тик бүген ул әлләниләр кыланырга да әзер: твист, вуги-вуги, хула-хоп... Чөнки бүген Зөһрә үзен җиңүче итеп тоя. Җиңүчеләр исә мондый вак нәрсәләргә әһәмият биреп тормый. Җиңү кешене горур итә.

Шул көннән башлап, Зөһрә өчен кою заводы тагын бер яңа мәгънә алды. Эштә станогына сөенеп туя алмый, тулай торакка кайтыр юлга чыкса, «Новый город — Литейный» маршрутлы трамвайга утыргач, күңелен аңлатып бирә алмастай горурлык били. Күңел тулы яхшылык. Кемгә караса да елмая ул. Трамвайда үзеннән аз гына олырак яшьтә кеше күренсә, сикереп торып урын бирергә әзер. Өлкәннәр юк дәрәҗәсендә. Йөкле яшь аналар күп. Аларга һәркем тарафыннан хөрмәт һәм ихтирам монда.

Зөһрәнең өзлексез сөйләшәсе, көләсе, шаярасы килә бүген. Эш көне тәмам, ә караңгы төшкәнче күпме вакыт бар әле! Көн озайганнан-озая бара, матурлана, җылына, җанны тәмам шаштыра инде!

Шактый ара узгач кына, Зөһрә үзе утырган вагонда ук Мәрвиянең дә кайтып килүен күрде. Заводта чакта: «Бүген бергә кайтып булмас, мин комитетка керәм әле», — дигән иде, үзе шул ук трамвайга өлгергән. Зөһрә, ашыгып килеп, аның янына басты.

— «Пятачок»ка чыгабызмы бүген, Мәрвия апа?

— Минем белән генә биергә булсаң, чыгам.

— Синең белән генә, Мәрвия апа! Без икәү биербез, Бәхти абый гармун уйнар!..

Кызлар килгәндә, мәйданда «пыр» килеп танцевать итәләр иде инде. Баянда, чыннан да, Бәхти уйный. Зөһрә туп-туры аның янына үтте. Мәрвия читтәрәк калды. Бу хәлгә Зөһрә үзенчә бәя бирде. Мәрвия апа дөрес эшли дип уйлады ул. Кайсы татар кызының, яраткан егетен күргәч, атылып-бәрелеп, аңа сарылганы бар? Иөрәгенә генә буйсынса, бик барыр иде дә, башкалардан ким сарылмас та иде, борыннан килгән гадәт җибәрми. Әйбәт гадәтме бу, начармы — кем белсен?! Ни буласы булган, ул кадәресен бүгенге яшьләргә кадәр ата-баба хәл итеп куйган, шуны канына сеңдергән: яратам, дип, ир-егет алдында туарылма, тешеңнең агын күрсәтмә! Яратуы хак булса, нишләргә кирәген егет үзе белер. Син — кыз, алдыңны-артыңны карап йөр, хисләреңне тезгендә тот, бәхетең сәгате сукканны көтәргә өйрән! Кызларны яшьсез елата, сусыз батыра, суыксыз өшетә, утсыз көйдерә торган бу гадәткә Мәрвиянең буйсынырга теләмәгәнен, Бәхтигә: «Син кирәк миңа!» дип таләп куйганын Зөһрә белми иде. Мәрвиянең хәзер дә Бәхтидән читтә торуын ул бик урынлы, гадәтчә дип санады.

Мәрвиянең күзенә исә ак-кара күренми. Алдында — бары Бәхти генә, колаклары фәкать баяннан Бәхти бармаклары басып чыгарган авазларны гына ишетә. Ник шунда җирнең асты-өскә килми — Мәрвиянең хәзер анда кайгысы юк. Ул бер генә нәрсәне белә: монда, бер-ике генә адым ераклыкта Бәхти бар, Бәхти баян уйный. Бу баяннан таралган көй башка берәү дә белмәгән, бары Мәрвиягә генә аңлаешлы мең төрле вәгъдәләр бирә. Өметсез — шайтан, диләр, бәлки әле Бәхти бүген аларны озата кайтыр, Мәрвияне үз янында калырга чакырыр да: «Минеке бул!» — дигән үтенечен белдерер.

Кыз күз кырые белән генә егетне күзли. Әнә Зөһрә аның янына барып та җитте. Гөлдер-гөлдер сөйләшә дә башладылар. Зөһрә, мөгаен: «Без килдек, Бәхти абый, — дигәндер. — Мәрвия апа да монда!» Хәзер егет күзләре белән Мәрвияне эзләп табар. Күз карашлары очрашыр...

Әй, дөнья! Ник соң син үз кешеләреңнең теләкләрен шулай сансызлыйсың?! Нигә вакыт-вакыт аларның көткәненә капма-каршы нәрсәләр китереп чыгарасың, ник кешедән: «Тумавым яхшырак булган икән!» — дигән мескенлек сыгып чыгарасың?!

— Исәнмесез-саумысыз, Бәхти абый! — диде Зөһрә. — Без килдек, яле, без ярата торган көйне уйнале!

Башка чакта, Зөһрәне күреп алгач, Бәхти уенын «шып» туктата, кыз белән иркенләп сөйләшергә тотына торган иде. Майдандагылар теләсә нишләсен — Бәхти Мәрвияләр бүлмәсе турында хәл-әхвәл сорашмыйча баяныннан ялгыш бер аваз да чыгармый. Шул арада янга Мәрвия дә килеп баса. Сәламләшәләр. Сүзсез генә. Карашып кына. Аннары Бәхти Мәрвия яраткан «Яшьлегем» вальсын сузып җибәрә. Егет уйный, Зөһрә белән Мәрвия туйганчы бииләр. Мәйданны бер урап чыккач, Мәрвия тагын да кыюлана төшә, җырның сүзләрен дә әйтә-әйтә әйләнә.

...Әгәр, иркәм, ай шикелле
Булалсам иде мин дә,
Алдыңа туктар идем лә
Айрылмас идем бер дә!

Шушы кичәләрдә Зөһрә үзен Бәхти белән Мәрвиянең элемтәчесе итеп тоя иде. Тик бүген, бу ни галәмәт — Бәхти уенын һаман туктатмый, уйный да уйный. Сәламне да башын кагып кына кабул итте, йөзен кире якка ук борып куйды. Һаман бер көй биючеләрне ялыктыргач, мәйдан уртасында кеше калмагач кына, ул беразга туктап торды. Шунда: «Табибәне күрмәдеңме?» — дип сорады.

Зөһрә үзен ут белән су арасында калгандай хис итте. Ул бер Бәхтинең кире якка борылган тузгак башына, бер шактый еракта басып калган Мәрвиягә карады. Аны үз янына чакырып кул да изәгән иде, Мәрвия ашыкмады.

Инде өченче биюне башладылар. Зөһрә һәр бию артыннан «Яшьлегем»не көтте. Бер-бер артлы бөтенләй кызыксыз көйләр яңгыраган иде, яңасы барыннан да яманрак килеп чыкты. Үзара сөйләшкәндә, Мәрвия гел: «Мин аны яратмыйм!» — дип телгә ала торган «Барыня» көе иде бу. Бусы — бер хәл. Калганы тагын да шаккаткычрак булды: әлеге үзе өнәп бетермәгән көйгә, «пятачок»ның баянчыга каршы ягыннан, туфли үкчәсе белән асфальт «идәннән» очкыннар чәчрәтә-чәчрәтә, Мәрвия килеп чыкты. Ул аның, эре-эре атлатып, әйләнеп узулары, ул аның, баянчы каршына килеп җиткәч, теттереп «Чәчетка» сиптерүләре — мәйдандагы халык «аһ» итте.

Мәрвия шактый вакыт ялгызы гына биегәч, аны хуплау, куәтләү йөзеннән, бию мәйданына Зөһрә дә кыяр-кыймас кына аяк басты. Боларның парлап тыпырдавы башкаларга үрнәк күрсәтте, икенче якта да биергә тотындылар, өченчеләр, дүртенчеләр кушылды. Ниһаять, үзләренең игътибардан читтәрәк калуларын искәреп, Мәрвия Зөһрәгә:

— Әйдә ычкындык! — диде дә мәйданның иң караңгы читенә атылды.

Зөһрә аның адымына көчкә иярә иде.

— Кая чабасың шул кадәр?

— Йөрәгемә чыдаша алмыйм!

Мәрвиядән мондый сүзләрне сирәк ишетәсең, кичерешләре турында тел тибрәтергә дә яратмый. Менә хәзер, Мәрвиядән нидер ишетергә өметләнгәч тә, Зөһрә кырт кисеп сорау бирергә батырчылык итмәде. Күңел сизенүен сизенә: Мәрвиянең җене сөймәгән көйгә сиптерүе дә, соңыннан караңгылыкка уктай кереп чумуы да, инде менә чатыр чабып өйгә ашыгуы да тикмәгә түгел, бу — Бәхтигә булган мәхәббәт әкәмәтләре.

Зөһрә Мәрвиянең беләгенә сарылды. Юл буе сүзсез атладылар. Зөһрә, эчтән генә, Мәрвиянең чишелеп китүен, Бәхти белән ике араларындагы мөнәсәбәтне тәфсилләбрәк сөйләвен көтте. Ник дисәң, кыз күңеле үзенә дә шул көннәр якынлашуын тоя. Ничек буласын гына белми: кем яндырыр аның йөрәген, кай тарафтан килеп чыгар ул егет? Болары әлегә билгесез. Җан гына талпына, очына, эзләнә.

Бүлмәгә кергәч, юл буе ишетергә теләп тә ишетә алмаган сүзләрне сөйләтергә ниятләп, Зөһрә:

— И, бәхетле дә син, Мәрвия апа, әэме? — диде.

Мәрвиягә шул сүз генә җитмәгән икән. Ул, гөрселдәп, караватына ауды.

— Бала шул син, бала! Бәхет белән бәхетсезлекне генә дә аера белмисең.

Зөһрә шатланды: менә хәзер ул үз бәхетенең нәрсәдә икәнен аңлатып бирәчәк, көткәнне сөйләп китәчәк.

— Беләм! — Зөһрә, шаянланып, үчекләргә тотынды. — Син шундый итеп биедең, шул кадәр көйгә китереп бастың, бәхетле икәнеңә ерәүнен дә шиге калмады!

Мәрвия ятагына капланган җирдән кинәт күтәрелде. Чәчләре тузгыган, кешелеккә кия торган иң матур күлмәге таушалып та өлгергән, карашлары билгесез ераклыкка юнәлгән.

— Бәхеттән генә бииләрмени, бала?

— Бәхеттән бииләр, җырлыйлар, ә бәхетсезлектән елыйлар.

— Бии-бии елап та була ул, сеңелкәем. Менә мин бүген, җаныма урын таба алмый, сагышымны кая куярга белми, аптыраганнан биедем. Елау иде ул, елау иде! — Ул тагын караватына капланды. Мендәрләр, юрганнар аша аның үзәк өзгеч тоныклык сулкылдавы ишетелә башлады.

Аны юатырдай сүз таба алмасын тоеп, Зөһрә коридорга чыкты. Нигә комачауларга? Еласын. Бушансын кеше. Шаһитларның кирәге юк.

Ары сугылды, бире кагылды Зөһрә, туктатырлык җай таба алмый йөрде. Кызыл почмактагылар телевизор карый, әллә ничә серияле фильмның азагын күрсәтәләр. Зөһрә аның баштагыларын карамаган иде, монысын гына күрүдән мәгънә юк.

«Кызлар клубы»на челтәр бәйләргә өйрәнүчеләр тулган. Зөһрә бу түгәрәккә язылмаган иде, хәзер генә кушылып китеп булмый. Киләсе ел башыннан ук йөрер инде: бәйләргә дә, тегәргә дә ярата ул. Монда бит барысына да нечкәләп өйрәтәләр. Түгәрәк җитәкчесенең: «Сулга биш күз чалдыгызмы? Ярый. Хәзер — уңга!» — дип аңлатуы ишетелеп калды. Зөһрә ишекне ябып куйды.

Табибәләр ишеген шакыганда, Зөһрә аның өйдәлегенә өмет тә итмәгән иде. Җавап-фәлән ишетелмәгәч, ул тотканы тартып та карады. Ишек ачылып китте. Бүлмә ян-якты. Табибә өйдә берүзе.

— Йокламыйсыңмы әле, Табибә апа? Берәр партия шахмат уйныйбызмы?

Зөһрә Табибә янына еш керә. Монда рәхәт аңа. Табибәнең үз күрүен, туган итүен тоя. Яңа шигырьләрен дә ул хәзер беренче булып Зөһрәгә укый. Кайчак алар эштән кайтышлый трамвайда очрашалар. Табибә һаман ТЭЦ төзелешендә, кою заводы ягында эшли. Трамвай вагонында чакта өсләренә карасаң, талчыгулары да сизелә: берсе кою станогы янында көн уздырган, икенчесе яңа гына гына кран кабинасыннан төшкән. Башта сүз дә ялганмый. Сәламне дә ым белән генә бирешәләр. Бераз баргач, Табибә кинәт ачылып китә. Сумкасыннан таушалып беткән куен дәфтәре чыгара.

— Яңа шигырь яздым. Төш вакытында гына күчереп куйдым әле, менә укып кара! — ди.

Трамвай бара да бара. Яңа шәһәр турысына җитә. Җир астын уеп ясалган араны кичә, кызлар аны сизмиләр дә: сүз — шигырь, китаплар, киләчәк өметләр турында.

Бүлмәләрдә әллә ни еш очрашып булмый, Зөһрә — сменалы эштә. Бер-береңбелән өйдә очрашу тагын да рәхәтрәк. Табибә хәзер дә, иң кадерле туганын күргәндәй, Зөһрәне күрүгә, китап-дәфтәрләрен читкә

этте. Шахмат тезделәр. Табибә ак һәм кара пешкаларны кулына алып, артына яшерде.

— Кайсы?

— Мин сораганда, син гел сул кулдагысын аласың, аннары отасың. Мин дә сулдагысын сорыйм әле!

— Сул кул — йөрәк ягы бит ул, җаныемдыр ла! Мин аны шуңа күрә генә яратам. Мат куюга бер катышы да юк. Мат куюда йөрәк түгел, баш кирәк!

— Йөрәк ягы булса, ни? — Зөһрә уенны башлап та җибәрде.

— Йөрәк — мәхәббәт учагы!

Кызлар, телләренә ни туры килсә, шуны такылдый-такылдый, уенга бирелделәр. Берсе йөрешен ясап куя да өзелгән сүзне дәвам итә, икенчесе уйлый, яңа йөрешкә юл эзли, тозак кора.

— Мин күлмәклек алып кайттым әле бүген, әнә, тумбочкада!

— Шаһ сиңа! — Зөһрә, тактаның Табибә ягындагы өслегендә җайлы бер юл тапкан булып, фил белән бер пешканы сугып алды. Корольгә куркыныч белдерде. Аннан урыныннан ук торып китеп, Табибәнең күлмәклеген карый башлады:

— Аб-бау, Табибә апа, бигрәк матур, гел челтәр генә, гипюр диләрме әле? Үзе ап-пак, кер күтәрмәс инде? Бусы эчлегемени? Ак атлас.

— «Шаһ» биргән буласың, ашыйм бит мин синең бу слонынны! Ачуланма, җаныемдыр ла! — Табибә Зөһрәнең уйламый ясалган йөрешен үзенә зур файда беләнябып куйды. — Ефәк җептән бәйләнгән гипюр ул, җаныемдыр ла! Ак, ап-пак! Миңа нәкъ шундые кирәк иде. Кер күтәрә торган күлмәкләрдән туйган. Кер тидерергә ярамый торганын эзләдем.

— Мин йөрдем, Табибә апа. — Зөһрә сүзне тагын күлмәклеккә китереп ялгады. — Моны кайда гына киеп булыр икән соң?

Зөһрәгә мода җене кагылмаган әле. Башта уку белән бик мавыкты, аннан яңа эшкә күнекте. Менә хәзер генә толымнарын сүтеп, чәч очларын бөтеркәләндереп йөри башлады әле.

— Бу пешканы ат белән алабыз, короленә шаһ, икенче йөрештән ферзең оча! — Табибә ат белән йөреш ясаган кулын югары күтәрде.— Ә бу ак челтәр күлмәкне, җаныемдыр ла, Табибә апаң туйда киячәк! Белдеңме? Әйтсәм әйтим инде: без Бәхти абыең белән загска гариза бирдек, тиздән — туй!

Зөһрә җиңелде. Уен башында ук ферзеннән колак каккан шахматчы ничек җиңсен инде? Тик монысы гына аны гарьләндермәде. Табибә ни сөйли диген син, Табибә?! Зөһрәнең күзләре мат алудан түгел, яңа хәбәрдән шар булды. Табибә исә туй хәбәренең тулай торактагы кызларга, бигрәк тә Мәрвия бүлмәсендә яшәүче Зөһрәгә ничек тәэсир итәсен белеп тора.

— Менә шулай, җаныемдыр ла!

Ул ишек ягына күчеп басты. Шактый озак сүзсез торды. Зөһрә аның килешле итеп кистерелгән кыска чәченә, түгәрәк йөзенә, бөтен бүлмәне шатлык белән тутырган нурлы күзләренә сокланып карады.

Табибә күкрәк тирәнлегенән чыккан басынкы, йомшак тавыш белән шигырь сөйли башлады:

...Дәрья таптым, яңа дәрья ачтым:
Киңлекләре чиксез, үзе тирән, төпсез!
Кайда соң ул? Кайсы кыйтгада?
Беркем белми! Табалмыйсыз минсез!

Кыз, шигыренең һәр сүзенә аерым басым ясап, эчке мәгънәләр сала-сала, ашыкмыйча гына укый. Сүзе саен тавышы ныгый бара, ятлаганлыгы гел сизелми, онытмаммы, алда ялгышмаммы, дип, һич шикләнми. Шигырь юллары аңа гүя күктән иңә. Тора-бара тавышка кисәтү, дөнья

белән бәхәскә керү, кешеләрне сынашка чакыру сыман яңгыраш өстәлде.

Сусызлыктан сусаганнар ялварсыннар,
Дөнья коргаксысын, ташлар ярылсыннар.
Барыбер әйтмим, бирмим, дәрья — үземнеке!
Үзем таптым, миңа булсын, миңа гына!

Тулы дәрья синә нигә, димсез? —
Олы хәсрәт, тынычсызлык — ул нәрсәгә?
Үз өлешем: минем хәсрәт, минем бәхет,
Кайгым белән шатлык янәшә!..

Зөһрәнең япь-яшь башы бу хәлләрнең барын да сыйдыра алмый, кызның япь-яшь йөрәге бу кичерешләрнең барын да кабул итми. Киләчәген уйлый башласа, күз алдына ни китереп бастырырга белми: бу Чаллы, бу КамАЗ хәлләренең бүгенгесе генә шулай акыл ирешмәс, колач ицләмәс, җан җилкендергеч булыр дисеңме?

Зөһрә, коридорга чыккач, яңа гына ишеткәннәреннән бераз айныр өчен, караңгырак якка китеп, тын гына басып торды. «Табибә күңеленә яңа шигырь китергән вакыйга Мәрвияне авыруга сабыштырды. Кайчанга кадәр барыр бу буталчыклар, кайчан тын гына яши башларлар соң? Хәер, тып-тын яшәүнең ни кызыгы бардыр дип беләсең?!.»

... Яз килде. Шәһәрдә кышкы аяусыз суыклар шаукымыннан яшелләгән дә үзгәртми котылган наратларның хуш исе аңкый. Таңнарда кешеләрнең йөзен сыйпап-назлап, Кама ягыннан дымлы, йомшак җил исүчән. Беренче җылы яңгырдан соң урамнар сафланып, чүп-чарлардан арынып калды. Туң хәлендә өнсез яткан җир дә җылынды, киң күкрәге белән иркен сулыш ала башлады кебек.

Язгы һава, язгы җилләр, язгы сулар кызлар күңеленә өр-яңа җыр булып күчте. Һәрберсенекенә. Аерым-аерым. Төрледән-төрле җыр булып...

Зөһрә китап кибетеннән бер кочак инглиз китаплары алып кайтты, тәрәзә төбендә бармак төртерлек тә урын калдырмады. Заводның техник-информация бүлегенә инглиз теле белүче лаборантка кирәк, ди. Мәрвия, кадрлар бүлегенә кереп, Зөһрә кандидатурасын күрсәтеп чыккан. Өйрәтеп тә куйды:

— Үзеңне чакырып алып сөйләшсәләр, икеләнеп торма! — диде. — Булдырам диген. Өйрәнерсең. Бераздан укырга да җибәрәчәкләр, читилләргә командировкаларга да йөртәчәкләр.

Кызлар әле бүген генә Матрена түтинең бүлмәдәшен котларга бала табу йортына бардылар. Тәвәккәл хатын игез бала тапкан, игез кыз. Ул хатын больницадан соң монда кайтмый инде, яңа өйләнешүчеләр йортыннан үзенә квартира биргәннәр.

Матрена түти белән Степан дәдәй һаман никах яңартып туймыйлар. Авызлары — авызда. Кайчан кермә, өстәлләрендә — самавар, чүти-чүти килеп чәй эчәләр. Шатлыклары эчкә сыймый.

Мәрвиянең баскан җирен ут алды. Шул хәлендә дә кеше язмышын кайгыртып йөрергә көч каян ала икән! Кем белә, бәлки кеше кайгысы артыннан йөргәндә, үзенеке бераз онытылып торадыр. Ялгыз башың уфтанырга калсаң, очына чыгып җитәрлекмени?

Марина Украинага ялга китәргә җыена. Кызлар шаярталар: «Миңлеәхмәтеңне дә алып кайт!» — диләр. Егетнең күзенә ак-кара күренер чакмы соң? Соңгы сынау язы, диплом язы аның. Марина юлга ялгыз гына чыга.

Табибә шау чәчәкле ап-ак челтәрдән күлмәк тегә. Тиздән — туй!

## Рөстәм Мингалимов

### Кышкы шигырь

Узган гомер —
Искән җил, дип
Әйтәсе килми әле.
Җилләр исә, җилләр иссә,
Җанымда кырык җәем.
Йөрәкне шулар җылыта,
Көч бирә уйларыма.
...Уйланырга чыктым әле
Иделем буйларына.
Илкәемнең ак кырында
Ак юллар салып уздым.
Күкләргә колачым җәйдем,
Карларга кулым суздым.
Тауларга басып кычкырдым,
Шатлыгым яңгырады.
Яңгыраган шатлыгымны
Илемә калдырамын.

1977

### Без җырлаган көйләр

Идел-илдән еракларда йөрдек,
Дөньяларны гизеп тойды йөрәк:
Безнең якты күңел киңлекләре
Зур дөньядан киңрәк.
    Ул киңлектә бер кала бар —
    Узганнар уты — Казан.
    Ул гөрләгән бәйрәмнәрнең
    Мәңгелек йорты — Казан.

Мәйданнарга чыгып сынатмадык,
Һаваларга ашып шуны белдек:
Безнең күңелләрнең биеклеге
Йолдызлардан биек.
    Ул биектә бер кала бар —
    Безнең чор уты — Казан.
    Ул гөрләгән бәйрәмнәрнең
    Мәңгелек йорты — Казан.

Яман исем калдырмадык артта,
Киткән чакта кайтып Идел-илгә.
Гел чайкалыр еллар хәтерендә
Без җырлаган көйләр.
Ул көйләрдә бер кала бар —
Киләчәк уты — Казан.
Ул гөрләгән бәйрәмнәрнең
Мәңгелек йорты — Казан.

1976

## Әйт, бабакай

Арыдым бүген,
Никтер, бабай, арыдым.
Синең янда бер ял итеп алырмын.

Бу юлларда мине болай ни куды?!
Күтәрелгән күк тузанны җил куды.

Бу күкләрдә мине болай ни куды?!
Төркем-төркем болытларны җил куды.

Бу дөньяда мине болай ни куды?!
Өзелеп төшкән яфракларны җил куды.

...Кеше җаны — җил түгелдер бит инде,
Өметләре җил түгелдер бит инде!?
Җил түгел дип әйт, бабакай,
Әйт инде?

1977

## Барып күрдек

Барып күрдек берәүне,
Югарыда — урыны...
Шулай өстә булуның
Ләззәтен дә беләдер.

Елмайса да көн сыман,
Карашы кар, сүзе кар:
Тау өстенә урнашкан
Кар буласы киләдер.

Тау өстендә кар булыр,
Кар — кар булса, бар булыр,
Эреп калса юк булыр —
Ул моны да беләдер.

Күпме карлар эрегән,
Түбән таба йөгергән —
Бу гел тауда һәм гел ак
Күренәсе киләдер.

1977

Ак касә күк мөлдерәмә
Көнем килде бүген дә...
Өстендә чүбе әйләнә,
Бардыр тагы төбендә.
Бу ошамас та кемгәдер,
Ә кемгәдер бик ошар.
Шәраб түгел, сөтле чәй бу —
Ярыйсы ясаганнар!
Агулы булса да хәтта,
Мин моны эчәр идем.
Өлешемә тигән бу көнне
Исән-сау кичәр идем.
Йөрәгем шушы көннәргә
Әзерләнгән, өйрәнгән.
Чынлык мәңге үзгәрәк ул
Хыялдагы көннәрдән.
Мин чынлыгы туган якның,
Ил күзе булып күрәм.
Тәкәббер еллар түренә
Таләбем куеп керәм.
Сорама таләбең ни дип,
Бер шуны гына кара:
Апалар, өйләр, кызлары,
Чәйләре — матурлана.

1977

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ТУЙ БАЛДАГЫ

хикәя

Калку-калку кыялар, биек тау-таш араларыннан бәреләсугыла мәтәлеп аккан чишмә... Шушы сурәт, шушы күренеш бала чактан ук Фирүзәне үзенә тартты. Кайларда гына йөреп кайтмасын, ул шунда ашыкты, килгән саен, сихерләнеп калган берәүдәй, калку кыяларга, биек-биек тауга, чылтырап аккан чишмәгә таң калып карап торды. Фирүзәнең ихтыяр көчен җуеп кыя араларыннан чылтыр-чылтыр ага да ага шул чишмә. Фирүзә чишмә моңын сәгатьләр буе тыңлый ала. Чишмә моңы аның күңелен сабый чагына, яшьлегенә алып китә...

Бүген ул яшьлек хатирәләре белән тулган тау-кыялар һәм Таң чишмәсе белән саубуллашырга дип килде. Иртәгә ул ире Дамир янына — Әлмәткә китә. Фирүзә кыя араларыннан салынган сукмак буйлап югарыга, чишмә башына таба кузгалды. Кайчан гына шушы җиргә аяк басмасын, ничәмә-ничә тапкыр гына чишмә типкән очка шушы сукмактан менмәсен, Фирүзәнең күңелен һәрчак ике хис биләде: әлеге хозурлыкка соклану һәм бераз гына курку хисе. Башын күтәреп каравы була, йөрәге әллә нишләп китә: дәү-дәү ташлар менә-менә түбән тәгәрәп китәрләр сыман, шул ук вакытта колактан чишмә җыры китми, әллә шуңа инде, кыяларга, алар арасыннан, кечкенә салават күперләре ясап, сикерә-мәтәлә аккан көмеш сулы чишмәгә Фирүзә күңелендә тиңсез соклану хисе уяна, тиктомалга, иләсләнер дәрәҗәгә җитеп, җырлап җибәрәсе килә.

Әйе, мәшһүр табигать, оста сурәтче буларак, нәфис куллары белән бөек рәссамнар кебек гүзәл һәм мәһабәт картиналар иҗат иткән. Бирегә килгәч, Фирүзәне һәрчак экиятләрдә генә була торган сихри көч әсир итә. Тау битендәге дәү-дәү кыялар, йоклап яткан батыр уянгандай, бермәл кузгалып, хәрәкәтләнеп куярлар шикелле. Ул гынамы соң: күп яттык инде дип, түбән тәгәрәрләр, юлларындагы агачларны, куакларны сыта-изә, җимерә-вата тау битенә утырган өйләргә хәтле төшеп җитәрләр кебек. Әмма чал тарих шаһитлары — тау битендәге дәү-дәү кыялар, ташлар мең ел ничек ятсалар, шулай ята бирәләр; тау итәгенә урнашкан өйләрдә кешеләр яши, балалар үсә, аларның балаларының балалары туа тора, га-

сырлар уза, ә кыялар, җансыз шаһит буларак, шуларны күзәтәләр дә күзәтәләр. Кайчак Фирүзәгә шушы кыя-ташлар — тауның биттендәге җыерчыклар, ә түбәсендәге кылганнар — аның чал чәчләре, чишмәләре — күз яшьләре кебек тоела башлый.

Фирүзә һаман югарыга үрмәләде. Аның тизрәк чишмә башына җитәсе килде. Сусап килгән чаклары да булды аның Таң чишмәсе янына, эчәсе килмәгән чаклары да, әмма беркайда да Таң чишмәсенең суыннан да татлы суны эчкәне булмады. Һәм булмас тадыр. Ул гына да түгел, Таң чишмәсе аның истәлекләр белән тулы яшьлеге. Мәктәп елларындагы җан дусты Камил белән дә еш кына шунда менә торганнар иде. Әле дә булса хәтерендә: үбештеләр дә тәүге тапкыр егет белән шунда, бер-берсеннән оялышып чишмәгә төбәлделәр. Чишмә алардан көлде, суым эчегез, шуннан йөрәгегезгә талгынлык килер, диде.

Нигә әле бу Камил тиктомалга искә төшеп тора. Ниемә кирәк ул шахтер егет Фирүзәгә. Ул инде Дамирга кияүгә чыкты, бармагында туй балдагы, Дамир кидерткән алтын балдак.

Кыялар кубәя, тау текәләнә, Фирүзә һаман өскәрәк тартыла. Менә ул чишмә, Таң чишмәсе, Фирүзә горур төстә тау итәге буйлап сузылып яткан туган авылына карый. Аннары чишмә янындагы зур ташның берсенә аякларын салындырып утыра да янә тирә-юньгә сокланып карап тора. И-и, рәхәт тә соң шунда утырып авылны күзәтү. Тау итәгенә, зәңгәр тасма булып, инеш сузылып яткан. Фирүзә саубуллашырга менгән Таң чишмәсе дә шул инешкә коя. Инеш аша агач күпер салганнар, ара-тирә басмалар күренә. Күперне чыгуга, уң якта, Фирүзәләрнең өе. Ишегалдында ак яулыгын чөеп бәйләгән әнисе йөри. Фирүзәнең әнисенә кычкырасы килә. Китә бит инде кызы, китә бит. Дамиры янына, Әлмәткә китә.

Дамир больницада врач булып эшли. Фирүзә дә шунда эшләячәк. Дамир инде аңа урын да хәстәрләп куйган. Кичә телеграммасы килде. Бер сүз белән: «Фирүзә, көтәм!» — дигән. Фирүзәнең күзе кулындагы балдакка төшә. Менә ул аларның йөрәкләрен бәйләгән алтын балдак. Йөзек кояш нурында уйнаклап ала. Фирүзә ирексездән елмаеп куя. Балдакка караган саен күз алдына Дамир килә. Фирүзә таш өстенә менеп баса, кулларын күтәрә, аның очар кошлар сыман җилпенәсе килә.

— Менә күр, күр, Дамир, Фирүзәңне, яныңа бүген үк очып китәргә әзер. Күр, Дамир!..

Шунда гына аның күзе таш өстендә торган кечкенә кәрзингә төште. Күрче, ул бит Дамирга җиләк тә җыярмын дигән иде. Ә үзе Камил белән тәүге тапкыр үбешүе турында уйланып саташа.

Камил, Камил... Хезмәттән кайтуга егет Казанга, Фирүзә яшәгән медицина институтының тулай торагына килде. Бүлмәдәш кызлар шау-гөр иттеләр — кияү егете, йөргәнең, диделәр. Әйе дип тә әйтмәде Фирүзә, юк та димәде, егетне театрга дип алып чыгып китте дә гел юк итте. Фирүзәнең кулын сорарга килгән иде солдаттан кайткан егет. Әле өченче курста гына укыган Фирүзә аңа кырт кисте:

— Юк! Кирәкмәс, Камил, дуслар гына булып калыйк...

Үпкәләде дип әйтмәс иде егетне Фирүзә, әмма Камил тулай торакка кире кайтмады. Китеп барды. Хәзер әнә Себердә шахтер булып эшли, күмер кисә һәм бәйрәм саен Фирүзәгә котлау открыткалары сала. Фирүзә котлаганда котлый сабакташын, котламаганда — юк. Егет моңа ачуланмый да, хурланмый да, күрәсең, һаман җибәрүе җибәрү открыткаларны. Хәзер инде җибәрмәс. Фирүзә дә җавап бирмәс. Соңгы котлавында Фирүзә аңа: «Камил, мин кияүгә чыктым», — дип язды.

Фирүзә тау уйдыгындагы каенлыкка юнәлде. Камилне искә төшерүгә, аңа моңсу булып китте, яшьлектәге беренче мәхәббәте бит. Каеннар да, Фирүзәнең серен уртаклашкан шикелле, моңсуланып калганнар: чәчләре иңнәренә таралып төшкән, башларын түбән игәннәр, нигәдер алар да сагышка бирелгән сыман иде.

Аланга җитүгә, Фирүзә җиргә тезләнде. Шунда ук аңа бер тәлгәш кызарып пешкән җир җиләге башын каккалап сәлам бирде. Менә кая икән ул җиләк уйдыгы. Фирүзә, дөньясын онытып, җиләк җыя башлады. Тик җиләкләр кәрзингә генә төшмәде. Ниһаять, исенә килде. «Җитте сиңа, тыя бел нәфесеңне», — дип тиргәде ул үзен, әмма тамак күңел теләгәннән өстенрәк булып чыкты. Кәрзин бер читтә утырып калды. Үлән арасыннан дымлы, татлы хуш ис килә, актарган саен, менә ул мин дигән сыман, тәлгәш-тәлгәш җиләк килеп чыга. Башын күтәреп өскә карады: күз алдында һаман җиләкләр йөгерешә, әйтерсең йолдызлар. Чалкан төшеп үләнгә ятты, күзләрен йомды. Шунда сусау тойды. Юк инде, башта җиләк җыярга. Кәрзинен алып килде, күз ачып йомганчы әллә ни хәтле җиләк җыйды. Дамиры шаккатсын әле. Менә сиңа, Дамир, үзем аунап үскән аланнан җиләк җыеп килдем, дияр.

Билләре катты. Кәрзине тулды. Торды да Фирүзә чишмәгә юнәлде.

Таң чишмәсе... Кем кушты икән аңа шул исемне? Таңны беренче каршы алгангамы шундый исем биргәннәр үзенә? Чишмә янында көмеш тәңкәләр биешә. Су өстендә кояш нурлары уйный. Чишмә чыккан төштә һәрчак кошлар була. Әнә уткойрык таштан-ташка йөгереп йөри. Кызылтүш очып китеп бара. Фирүзә кәрзинен бер читкәрәк куйды да чишмә чылтырап торган төшкә килде. Чишмә суы кыя таш араларына мәтәлеп төшеп китә. Тик тибеп чыккан төштә генә түгәрәк кул көзгесе хәтле тын урын бар. Суга каравы булды, Фирүзә үзен гүя көзгедә күрде, үз-үзенә елмайды. Йөзеген салып, таш өстенә куйды. Куш учына тутырып су алды. Учындагы суда көмеш тәңкәләр биеште. Тешне камаштырырдай салкын иде чишмә суы. Фирүзә уч-уч чишмә суын эчте. Аннары күтәрелеп күккә карады. Зәңгәр киңлектә, адашкан аккош кебек, ак болыт йөзә. Фирүзә кулларын күтәрде, ак болытка иптәш булып очып китәсе килде. Баскан урнында бөтерелеп алды. Шунда нидер зыңлап китте. Тиң-тиң-тиң. Башта ул моңа игътибар итмәде. Күккә ашкан иде, җиргә төшә алмый торды. Ләкин икенче мәлдә: «Балдак!» дигән уй зиһенен телеп үтте. Күзе таш өстенә төште — алтын балдак юк иде. Аркасына гүя салкын су койдылар. Фирүзә калтырап китте. Түбән карады. Кыялар, уентыклар аша, кая сикереп, кая ташлар арасына керә-югала чишмә ага, балдак шул юлдан түбән очкан. Түбән! Фирүзә чишмә буйлап төшә башлады, һәр уентыкка игътибар итте. Текә җиргә житкәч, туктап калды, башы әйләнеп китте, аста куркыныч текә упкын иде. Юк! Монда ук килеп җитмәгәндер. Фирүзә һәр таш арасын яңа җентекләп карап чыкты, тәгәрәп китү юнәлешләрен чамалады, янә-янә эзләде, әмма балдак табылмады да табылмады. Чишмә янына килеп утырды, бергә килүен, балдагын салып таш өстенә куюын, су эчүен, ике кулын күтәреп күккә каравын күз алдына китерде. Яңадан эзли башлады. Таш араларын актара-актара тырнаклары каерылды, бармаклары канады, тамак төбеннән каты төер китмәде, күзләре әчетте... Кояш кич якка авыша башлады. Фирүзә инде унынчы мәртәбәдер йөзек тәгәрәр җирдән яңа баштан эзләргә кереште. Тик балдакны барыбер таба алмады.

Күз яшьләрен тыюдан гаҗиз калып, нәүмизләнеп өйгә таба атлаганда Казанның үзәк ЗАГС бинасында алтын балдакны бармагына

кидергән Дамирны йөзенче тапкыр дияргә була күз алдына китерде. Юк, бу һич тә мөмкин хәл түгел, ничек инде иң кадерле кешесе бүләк иткән алтын балдакны югалтырга тиеш ул! Бу хәл Фирүзәнең башына сыймады. Ләкин буласы булган инде. Иртәгә ул Әлмәткә Дамир янына китә. Ә туй балдагын Таң чишмәсе йотты.

Фирүзә өйләренә ашыкты, һич югы, кайгысын әнисе белән уртаклашасы килде. Ул әле әнисенә ни дип әйтәсен дә белми иде, бу хәбәрне ишеткәч, әнисенең ни әйтүен дә күз алдына китерә алмый иде хәтта, мәгәр бер нәрсәне ачык белә: әнисе аны юатыр, күңелендәге төерне эретер, киңәш бирер, берәр әмәлен табар. Гомер буена мәктәптә техничка булып эшләгән әнисе аны җиде ел буена институтта укытты. Фирүзә Ленин стипендиясенә укыды, акчаны җитәрлек ала иде, әмма кайчан, кемгә җиткәне бар ул акчаның. Кияүгә чыгам дигәч, әнисе аңа балдак алырсың дип тагын йөз сум акча салган иде. Әй куанган иде Фирүзә шул акчаны алгач, бу бит ана кешенең ризалык билгесе иде.

Әнисе ут алган, өстәл янында бәйләм бәйләп утыра. Фирүзә акрын гына керде, кәрзинкәсен өстәлгә китереп куйды. Әнисе кәрзинкәгә үрелеп карады.

— Ярыйсы җыйгансың, кинәнер инде Дамирың,— диде. Тагын бәйләменә керeште.— Чәй әзер, кызым.

— Юк, инәкәй,— дип кулларын кая куярга белми, борсаланып алды Фирүзә.— Эчмим. Арыдым.

— Ни булды, аю кудымы әллә үзеңне?

— Инәкәй, мин балдагым югалттым...

Әнисе бәйләмен бер читкә куйды, кызына текәлебрәк карады, кул-бармакларына күз төшереп алды.

— Берәрсе талап-фәлән алып китмәгәндер бит?

— Юк, инәкәй, чишмә янына туктаган идем. Салып таш өстенә куйдым. Беләсеңме, теге сул кулдагы шома ташны... Кояш баеганчы эзләдем.

Фирүзәнең күзләре яшь белән тулды.

— Балдак баш түгел, балам, кайгырып кире кайтарып булмас. Насыйп булмагандыр...

— Инәкәй, аны миңа Дамир алып биргән иде бит. Туй балдагы. Ничек мин аның каршына балдаксыз барыйм. Ни уйлар ул, ни әйтер?..

— Әй бала, бала. Яманга гына була күрмәсен инде, ходаем. Күршеләрдән әҗәткә акча алып булса да...

Фирүзә әнисенең алдына тезләнде, итәк очына башын төртте, елап җибәрде.

...Балдакны алырга әнисе белән икәүләп бардылар, бик озак сайладылар. Әнисе түгел, Фирүзә сайлады. Алтын балдак югалганына охшаган булса да, Фирүзә кат-кат әнисенә дәште.

— Менә шундый киңлектәге, саргылт төстә иде. Шулай бит?.. Ә акчасын, инәкәй, мин сиңа беренче зарплатадан ук салырмын. Дамир ике ставкага диярлек эшли, мин бер ярымга эшләргә исәп.

— Ярый, кызым, хәерлегә юрыйк, — диде әнисе, магазиннан кайтканда. — Күңеле изгедә булса, иншалла, әйбәт кеше булыр. Чишмә суын болгатып булмаган кебек, саф күңелле кешене дә алдап булмый. Мин ышанам сиңа, балам, начар кеше сайламагансыңдыр...

...Дамир янына китәргә капкадан чыккач, Фирүзә, теләсә-теләмәсә дә Таң чишмәсе янына күз ташлап алды. Күксел-кара болыт тау битенә шәлен салган, болыт күләгәсе чишмә ягына таба шуыша. Озата чыккан әнисе Фирүзәнең Таң чишмәсе ягына карап торуын абайлап:

— Куй, балам, изгегә юрыйк, исән-имин барып җит. Җай табып, кияү белән әйберләрең алып китәргә кайтыгыз. Их, бала, атаң булмагангамы санга сукмадың, кияүне күрмәдем дә, чыктың да куйдың, — дип соңгы чиктә булса да рәнҗеп алды ана.

«Атаң булмаганга», — дип уйланды Фирүзә. Моңа кадәр бу турыда ул уйламады диярлек. Әйе шул. Кая аның әтисе? Әмма сабый чагындагы бер хәл еш кына исенә төшкәли. Урам буйлап югары очка баралар иде, әнисе ни сәбәпледер Фирүзәне алгарак этеп җибәрде. «Әнә, әтиең килә, йөгер каршына!» — диде. Фирүзә әтисенә каршы йөгерде. Аның башында төлке бүрек, аягында унтылар, өстендә аю тиресеннән теккән тун иде. Башка нәрсәсен хәтерләми Фирүзә, ә менә тун чабуы хәтергә нык сеңеп калган. Йомшак иде чабу, Фирүзәнең битен рәхәт итеп кытыклап алды. Ләкин аны атакай белергә дә теләмәде. «И-и, сабый. Мин синең атаң түгел, — диде.— Ялгыштың бит, ялгыштың!» Фирүзә, кире борылып, әнисенә таба йөгерде һәм анасының пальто итәгенә капланып, елап җибәрде. Бераздан башын күтәреп караса, әнисенең күзләре яшь белән мөлдерәп тулган, үзе керфек какмый китеп баручы ир-аткага карап тора. Шул хәлдән соң сабый чакта да, үсеп балигъ булгач та Фирүзә: «Инәкәй, минем әткәй кая?» — дип бер генә тапкыр да сорамады. Әмма әнисенең яшь тулы күзләре белән китеп барган ир-затка карап торуларын мәңге-мәңге онытасы юк.

Фирүзә бармагындагы алтын балдакка бакты, елмайды, әнисенең иңнәрен кочып, аркасыннан сөйде.

— Инәкәй, син аны яратырсың. Ул шундый әйбәт, шундый әйбәт кеше...

— Кеше күңеле — карурман, бала. Танышуыгызга ай тулыр-тулмас кияүгә чыгуыңа ризалыгым бирдем дә, бирмәдем дә дип уйла. Сыный-сыный сынала кеше. Бәхетле була күрегез, бар теләгем шул. Әйдә инде, автобуска соңга калырсың. Юлчының юлда булуы хәерле. Киләсе атнага алып кайтырсың үзен...

— Әйе, әйе, инәкәй!

... Соңгы тапкыр туган авылына карап алды Фирүзә. Ни хикмәттер, Казанга медицина институтына укырга киткәндә дә шулай моңсу булган иде аңа, инде укып бетереп врач булгач та туып-үскән өйдән чыгып китүләре моңсурак.

Казан больницаларының берсендә практика узганда Дамирны очратуы, аңа кияүгә чыгуы, башкалага белемен күтәрергә килгән Дамирның үз шәһәренә кайтып китүе, Фирүзәнең аның янына барырга чыгуы куанычлы хәл булса да, барыбер моңсу иде аңа. Ә бит Дамиры аны көтә. Өзелеп, зарыгып көтә. Телеграммасы килде. Фирүзә дә аңа иртәгә юлга чыгам дип телеграмма сукты.

Автобуска утыргач, Фирүзә сумкасын, киндер букчасын аяк янынарак куйды да, йокымсырап, күзләрен йомды. Тигез асфальт юлдан тәгәрәгән автобус тибрәнүенә оеп уйланып барды.

Хыялсыз кеше — канатсыз кош. Хыял ул кешенең юанычы, куанычы, ышанычы, хәтта мактанычы. Фирүзәнең хыялы врач булу иде, ул аңа иреште, аннары ул кияүгә чыгу турында уйлана башлады. Танышлары арасында күңеленә ошаган, килешкән егетләр булмадылар түгел, булдылар, әмма Фирүзә ашыкмады, кемнедер көтте. «Ул», аңа очрарга тиеш, «гыйшык алласы» Фирүзәне үз тиңе белән кавыштырыр, нәкъ менә хыялында йөрткән кеше очрар аңа, очрамый калмас, дип өметләнеп йөрде Фирүзә. Һәм әлләә инде «гыйшык алласы» зарын ишетте, аңа Дамирны җибәрде.

Дамир башкаланың 6 нчы больницасында белемен арттыра, ә Фирүзә интернатура уза. Ул аны башта коридорда күрде. Авырулар үтеп-сүтеп йөри, гадәти хәл, Фирүзә җиденче палатага юнәл-

де, анда авыр хәлдә бер ир-ат ята иде. Йөрәк чире, инфаркт. Фирүзәгә каршы берәү килә. Ярый, килә бирсен, азмы больница коридорында килеп саручылар. Ләкин күз дигәнең ботак тишеге түгел шул. Синең күзең мизгел эчендә күргән кешеңә бәя бирә, сыный, һәрхәлдә, кеше турында, һич югы, азмы-күпме белергә тели. Мәгәр ни кызыксынса да, Фирүзә түгел, ә ул аны туктатты.

— Җиденче палатада сезнең авыруны әллә? Минем исемем Дамир, — дип, ул Фирүзәне баштан ук шаккатырды. — Кызык авыру, сирәк очрый торган. Сез биредә күптәнме?.. Гафу, коллега, исәнмесез!..

Нәкъ менә баштан әйтәсе сүзен иң соңыннан әйтүе белән Фирүзәне көлергә мәҗбүр итте ул.

— Исәнмесез. Минем авыру булса нишләр идегез?.. — Фирүзә кулларын халат кесәсенә тыкты, кинаяләп көлемсерәде.

— Карагыз әле, ни. Бирегез әле ул авыруны миңа? Шеф риза, мин аңа хәлне аңлаттым инде. Әйтәм бит, минем өчен гаять кызык авыру ул.

Фирүзә аңа төбәлебрәк карады. Күзләре әллә күк, әллә яшел шунда. Киң кашлы, ияк уртасында чокыр, җәлпәгрәк, шул ук вакытта чөенкерәк борынлы, шуңамы, башын күтәребрәк йөри кебек. Чәчкәле күлмәккә кара галстук бәйләгән, галстугы бер якка кыйшаебрак тора. Фирүзәнең галстукны төзәтеп куясы килеп китте.

— Юк инде, мин ул авыруны үзем карыйм.

— Беләсезме нәрсә, кичә аның янына хатыны килде, ул китеп бераз торуга, сөяркәсе килеп керде. Аны күрүгә бичара авыруның битләре алсуланып китте... Тәк-тә, коллега. Мәхәббәт ул дәвалау көченә ия нәрсә. Менә шунысы белән кызыклы да ул чирле миңа. Шуларны искә алганда...

Фирүзә китә башлады, Дамир да, барган юлын онытып, кире борылды, аның белән янәшә атлап китте.

— Сезне авыруның сөяркәсеме, әллә чирле үземе кызыксындыра?

— Икесе дә. Миндәй буйдак кешегә мәхәббәт турында сөйләүнең нинди гөнаһы булсын ди, тәк-тә.

Башта ул Фирүзәгә бик беркатлы күренде. Барасы җирен җуеп аның белән атлап китүе дә, гомумән, үз-үзен тотышы да, кара көдрә чәче дә ошамады Фирүзәгә. Үтә кызыксынучан, Фирүзәне күрүе булды, бер адым аңардан калмады, аның шәүләсенә әверелде диярсең. Иң сәере шул булды: ул килмәгән чакларда Фирүзә аны юксынмады. Моңа кадәр таныш егетләрен кайчак исенә төшергәли, хәтта юксынып куйгалый иде. Әйтик, шул ук Камилне юк-юк та исенә төшереп куя бит. Ә бу әллә бар, әллә юк шунда. Мәгәр Дамир үзе әрсез булды. Иртән иртүк тулай торакка килеп, Фирүзәнең чыгуын көтеп алды, кич озата килде. Ә бер ял көнне ниндидер концертка чакырды. Зур спорт сараенда барган бу концертка Фирүзә үзе дә бик барырга теләгән иде, Дамир билетлар алып килгәч, шундук ризалашты.

Концерты концерт инде. Артистлар алар киләләр дә җырлап-биеп күңелгә рәхәт оеткысы салып китеп баралар, ә менә Фирүзә әллә нишләде шул концерттан соң. Дамирны юксына башлады. Шәүлә дә шәүлә, ул да шәүлә. Җепкә таккан диярсең үзен, Фирүзә кая, ул — шунда. Җитмәсә, үч иткәндәй, кич җиттеме, кая булса чакыра, һич югы, бүлмәгә кереп утыра. Гел янда инде югыйсәң. Ә менә килми, күренми башладымы, әллә нигә күңел юксынып куйгалый.

— Фирүзә, әйдә театрга. Премьера бүген.

Фирүзә бара. Ә ул егет дигәнең телгә гаять шома. Күп укуы бер хәл, шактый дөнья да күргән икән үзе. Институтны бетерүенә дүрт-биш ел узган, белемен күтәрү курсларын тәмамлагач үз шәһәренә кайтып китәргә тиеш, хәтта... дөрес, монысын кыймый гына:

— Фирүзә, әйдә безнең больницага эшкә, — диде.

Фирүзә көлде. Чөнки аның кай якларга китәсе күптән билгеле. Институт тәмамлаган һәр студентка бирелгәсе направление аңа да бирелгән иде инде. Алай ансат кына итеп теләгән җиренә китеп бара алмый иде шул инде Фирүзә. Ләкин Дамир аңа:

— Чык миңа кияүгә, Фирүзә, тәк-тә,— дип куйды.

Бу театрдан кайтышлый Ленин бакчасында булды. Икесе эскәмиядә утыралар. Иңнәре-иңгә дә тимәгән, хәтта үбешеп тә караганнары юк иде әле, әмма шул кеше: «Кияүгә чык миңа», — дип утырсын инде. Ни дип җавап бирсен Фирүзә моңа каршы?

— Кияүгә чыксаң, сине минем янга җибәрми хәлләре юк, тәктә,— диде Дамир кайнарланып.— Мин сиңа әйбәт ир булырмын, Фирүзә. Ике бүлмәле квартирам бар. Берүзем яшим. Без бит икебез дә врачлар. Ә мәхәббәт, килер ул мәхәббәт, Фирүзә, сиңа да. Миңа килде инде ул.

Фирүзә Дамирның күзләренә карый. Ләкин ярым караңгыда һичнинди үзгәреш күрми. «Ә бит хак әйтә. Кайчан да булса ул да кияүгә чыгарга тиештер бит инде», — дип уйлана ул. Дөресен әйтергә кирәк, сабакташ Камилдән башка моңа кадәр аның кулын сораучы берәү дә булмады әле. Бу бик җитди нәрсә дип йөри иде Фирүзә, баксаң, бик гади икән бит. Риза буласы да, ЗАГСка гариза язасы. Бер айдан туй һәм алар ир белән хатын. Шаяртмыймы бу Дамир?

Фирүзәнең күңелендә әллә ниткән шикләр «мәш» килсә дә, Дамирның: «Чык миңа кияүгә», — дигән сүзе йөрәгенә уелып кереп утырды. Шул көнне алар тулай торак подъездында беренче тапкыр үбештеләр.

Гариза биргәч, Фирүзә йөрәгендә нindидер гүзәл гөлнең чәчәк атуын тойды. Бу куанычлы хәл иде. Энисеннән ризалык сорап язды. Ни әйтсен ана кеше, ризалыгын белдереп йөз сум акча салды. Кызына бит инде егерме биш тулып бара иде, вакыт инде дип уйлавы булгандыр.

Туйдан соң өч көн гостиницада яшәделәр. Барысы да заманча булды. Дамир квартира ачкычын хатынына биреп, үз шәһәренә кайтып китте. Фирүзәнең ялы бар иде әле, ул әнисе янына Актауга юл тотты. Вәгъдәләштеләр: ун көннән Фирүзә аның янына килә. Ул арада Дамир аңа эш урыны әзерләп куя.

*
* *

Фирүзә кулындагы адрес язылган кәгазьгә минут саен күз төшереп алды. Автобустан төшкәннән соң аны алып киткән такси өч катлы өйләр тезелеп киткән Гоголь урамына борылды. Чаттан өченче өй дигән иде Дамир. Унсигезенче йорт. Әнә ул. Икенче кат, балконы да бар, диде. Чынлап та. Әнә, балконы да. Фирүзә шоферга акча биргәндә кулларының калтыравын тойды. Шофер аңа шикләнеп карады.

— Гафу итегез. Дулкынланудан бу.

— Их, хатыннар! — диде шофер һәм, Фирүзә төшүгә, моторын үкертеп китеп барды.

Сумкасыннан Дамир биреп калдырган ачкычны чыгарды. «Мин эштә чакта килсәң, менә, ач та кер», — дигән иде яшь ир. Йөрәге ашкына, аңа карап, куллары калтырана. Фирүзә ишекне ачты. Керде. Ачык балкон тәрәзәсеннән җил сулышы кагылды, шапылдап балкон ишеге ябылды.

— Дамир!..

«Эштәдер. Бик әйбәт. Бераз җыештырынырмын». Фирүзә, сумкасын ишек янында калдырып, бүлмәләрне йөреп чыкты. Түр як бүлмәдә телевизор, диван кисәге, ике урындык. Йокы бүлмәсендә тар гына агач караватат. Почмакта әле сүтеп җыелмаган софа тора.

«Хәзерләнгән, көткән», — дип уйлады Фирүзә, кухня ягына кереп чыкты, ванна бүлмәсенә күз салды.

Беренче эш итеп Фирүзә идәннәрне юды, кухнядагы савыт-сабаларны рәткә китерде. Гаҗәбе шул иде: бүлмәләр бер дә гел ир-ат кына яшәгәнгә охшамаган. Чисталык, пөхтәлек, һәр нәрсә үз урнында.

Кичкә таба ул аш пешерде. Дамирны көтте. Дамир сәгать бишләрдә кайтты. Ул кухня ягында, кечкенә алъяпкыч бәйләп, нидер пешеренеп йөргән Фирүзәне күрде дә, атылып аның янына килде, яшь хатынны кулына ук күтәреп алды.

— Дамир, Дамир, нишләвең бу. Егасың ич, егасың, җүләрем...

— Фирүзә, Фирүзә, синме бу, әйт әле, синме?! Мин көттем сине, Фирүзә, сагынып көттем. — Кулыннан төшерде, урындыкка утырды. — Ә син молодец. Өйгә уют керткәнсең. Беләсеңме, кайчак кайтып керәсе килми башлый шунда. Бүген канатлар үстеме үзәмә, ашыга-кабалана кайттым. Тәк-тә.

Фирүзә аш бүлде.

— Иртәгә шимбә, хуҗалык кибетенә чыгып керербез. Рәтле савыт-сабаң юк икән.

— Керербез, — Дамир өстәл янына утырды. — Аш. Токмач ашы. У-у, телең йотмалы. Мин дә хатынлы булдым, тәк-тә, Фирүзәкәй.

Кара көдрә чәчләренә биш бармагын батырып, Дамир бер тын уйга чумып утырды, ул арада Фирүзә чәй табыны әзерләде.

— Софа алгансың икән, — диде Фирүзә.

— Алдым. Син килүгә. Хәзер чәй эчәбез дә урнаштырырбыз... Йомшак күренә болай.

Чәй эчкәч, софаны җыйдылар. Җыеп бетергәч, Дамир софага чалкай төште, селкенеп карады.

— Их-ма! Кил әле, кил яныма, Фирүзә...

Фирүзә кыяр-кыймас кына софага утырды. Ул Дамирдан ояла иде әле.

Кич белән йокларга яткач, Фирүзә иреннән сорап куйды:

— Мине эшкә кая урнаштырырга исәбең?

— Сөйләшенгән. Поликлиникада приемда утырырсың.

— Кайчаннан?

— Хет дүшәмбедән.

— Ә нигә сузып торырга, дүшәмбедән үк керешәм.

— Миңа калса, бер-ике атна өйдә тора аласың әле. Вакытың бар, тәк-тә. Арттан кумыйлар.

— Юк инде, Дамир. Дүшәмбе дигәч дүшәмбе, сиңа иярәм дә барам...

— Ихтыярың. Эшли күр. Ике кулдан акча ала башларбыз. Мебель юнәтәсебез бар...

*
* *

Баш врач шул көнне үк Фирүзәне эштә калдырды. Көннең икенче яртысында аның янына Дамир кереп чыкты. Фирүзә карап утырган авыру карчык, ир-затның ак халаттан булса да, бүлмәгә какмый-шакымый килеп керүен ошатмады булса кирәк, Дамир чыгып киткәч, төксә генә:

— Йөри шунда! — дип, ыслап алды. Фирүзә аңа: «Ул минем ирем», — дип тә карады. Алай да карчык тынычланмады.

— Иргә ышанма, Иделгә таянма, бала.

— Әбекәй, сездә кан басымы авыруы. Сезгә аз гына да борчылырга ярамый, — диде Фирүзә, тавышын күтәрә төшеп. Әлмәткә килә-килүгә шәхси тормышына тыкшынучыларны яратмавын сиздерүе иде.

— Йә, йә, кызым. Үзең кара. Ил тереге — ир, җир тереге — хатын, үзең беләсеңдер.

Башка бер кәлимә сүз катмаса да, Фирүзәнең күңеленә әллә нит-кән шом салып чыгып китте карчык. Бу халәттән ул эштән кайткач та тынычлана алмады.

Ашап-эчеп, телевизор карап урынга яткач, Фирүзә Дамирдан сорап куйды:

— Дамир, син нигә миңа үз тормышың турында бер дә сөйләмисең?

— Ни сөйлим соң? — Дамир кулларын баш астына куеп, чалкан әйләнеп ятты.

Бүлмә стенасына урамнан узып торган машиналарның фара утлары төшә, башта ул стена буйлап үрмәли, аннары Дамирның йөзен яктырта һәм почмакка кереп поса.

—Ә син сөйлә, Дамир. Арабыздан җил дә узмасын..

— Җил дә. Ярый. Калада әйткән идем инде үзеңә. Авылда үстем. Укыдым. Институт тәмамладым. Менә бирегә, Әлмәткә, эшкә җибәрделәр. Бер елдан шушы квартираны алдым. Әни белән тора идек... Узган ел ул кинәт кенә дөнья куйды. Менә Казанга килгәч, сине очраттым. Тормышым минем шуннан гыйбарәт булыр, Фирүзәкәй, тәк-тә.

— Әйт әле, Дамир, син миңа кадәр берәүне дә яратмадыңмы?

Дамир, терсәгенә таянып, торгандай итте, нигәдер башын чайкап куйды.

— Ә син үзең берәүне дә яратмадыңмы? Сиңа егерме бишь яшь, ә үлеп гашыйк булыр еллар унҗиде яшьтә башлана түгелме? Миңа калса, кайберәүләргә ул иртәрәк тә килә.

— Ачуланма, Дамир. Яратканга гына әйтүем...

— Йокла. Соңгы чиктә галиҗәнабләре врач Дамир Хуҗиев сиңа өйләнгән икән, димәк, синнән дә гүзәл затны тапмаган булып чыга, тәк-тә. Хәтерем ялгышмаса, син үзең дә егетләр белән очраштыргаладым дип сөйләгән идең түгелме?..

— Мин сине чынлап та яратам, Дамир. Яраттым.

— Яратсаң, йокла. Иртә кичтән хәерлерәк.— Дамир, үрелеп, Фирүзәнең маңгаеннан, күзләреннән, иреннән үбеп алды.— Тыныч йоккы, татлы төш сиңа, тәк-тә.

...Икенче көнне эштә аның янына күрше бүлмәдәге күз врачы керде.

— Безгә ашка рәхим итегез. Буфет бар-барын да, өйдән өчпочмаклар алып килгән идем...

Рәтләп танышып өлгермәсәләр дә, әбәт вакыты җиткәч, Фирүзә күрше бүлмәгә керде. Түр яктагы буш бүлмәдә чәй эчеп утырган хатыннар, сүз куешкандай, берсе артыннан берсе торып, аңа урын бирә

башладылар. Ак яулык бәйләгән сестра гына, башын түбән игән килеш, утыра бирде.

Фирүзә бирегә килмәс борын ук коллектив ничек кабул итәр дип курыккан иде, эш көненең икенчесендә үк чәйгә дәшкәч, аның күңеле булып китте.

— Быел гына бетердегезме?

— Әйе.

Коллегалары гүя сорау алалар иде. Фирүзә җавап бирә торды. Барысы да сорашты. Тик бер сестра гына сөмсере коелып утыра бирде.

— Дәүҗан, нишләдең син бүген, балтаң суга төшкән күк утырасың? — дип сорады күз врачы шунда.

Сестра анда да дәшмәде, өстәлгә төбәлгән килеш тын калды.

Кич якта алар Дамир белән бергә эштән кайтырга чыктылар. Фирүзәнең кәефе күтәренке иде. Ул ирен култыклап алды. Ни генә булмасын, ул ирдәге хатын һәм Дамир аңа ошый, юк, ул аны ярата хәтта. Сагынды бит? Сагынды. Димәк, ярата ул аны, я-ра-та!

— Дамир, әйдә киләсе атнага әни янына кайтып киләбез. Кайтабыз дип ышандырдым. Киявең алып кайтам дидем.

— Ярый, барырбыз, Фирүзә. Тик тыңла әле башта. Ашыкмыйк, ишетәсеңме, ашыктырма мине, Фирүзә. Барысына да өлгерербез, тәк-тә...

Иренең бу сүзләренә Фирүзәнең кәефе кырылды, Дамир аңардан нидер яшерә сыман тоелды. Тик ни? Урамның уң ягыннан да, сул як тротуардан да кешеләр агыла. Фирүзә Дамирның кәефен бозарга теләмәде. Шулай да күңеленнән борчу китмәде. Нигә аның кәефе юк? Ни булды аңа? Нигә Фирүзәнең шатлыгын уртаклашмый?..

Өйгә кайтып җиткәндә генә алар каршына бер малай йөгереп чыкты.

— Әтием!

Бала йөгереп килде дә Дамирның аякларын кочаклады. Фирүзәнең тыны кысылды. Дамир көлде.

— Ялгышты сабый, — диде Дамир. — Бар, бар, әтиең башка синең, малай. — Дамир малайны җиңелчә генә читкә этәрде. — Ялгыштың дим, тәк-тә...

Малайның күзләрендә яшь елтырады, ул ни әйтергә белми бермәл аптырап торды, аннары үртәлеп:

— Кит! — диде.

Фирүзә Дамирның күзләрен эзләде, сорыйсы килде.

— Бер анекдот бар, — дип көлемсерәде Дамир. — Французлар урамда бер ялгыз малай күрдеңме — һич югы, башыннан сыйпап үт, карт-корыны күрдеңме — аз булса да хәер бир, диләр икән.

— Нигә?

— Малае — улың булуы бар, карты — әтиең. Ха-ха-ха!..

Фирүзәгә мәзәк ошады, ул да көлде. Тик бу көлүдән соң күңелдәге авырсу тойгы тагы да авырая гына төште.

— Дамир!

— Җитмәсме, Фирүзә. Сорашма. Шикләнмә миннән, ишетәсеңме, беркайчан да шикләнмә. Син минем хатыным, мин — синең ирең. Шул җитмәгәнме?!

— Җиткән.

— Тәк-тә.

«Минем мәхәббәтем диңгез кебек, ярларына сыймас дәрәҗәдә, — дип уйланды Фирүзә. — Ә ул миннән нидер яшерә. Ни? Кем ул малай? Нигә ул аңа әтием дип килеп сарылды?»

Йөрәгенә ук булып кадалды бу шик Фирүзәнең, ул ни кылырга белми, тәнозын күз йоммый ятты. Дамир йоклый. Әле кичә генә ул аңа шул тиклем якын иде, бүген нигәдер ят тоела. Аңа үзенең сабый

чагы, йөгереп барып: «Әтием!» дип берәүнең тун чабуына ябышуы күз алдына килә, янә күңеле айкала Фирүзәнең.

Иртән ул Дамирга сер бирмәскә тырышты. Күзләре кызарган иде, ир-ат хатынына карап-карап торды да:

— Ни булды сиңа? Әллә чынлап та кичәге хәлгә ышана калдыңмы? — диде.

— Әллә нигә башым авыртып тора, — дип алдады Фирүзә. Ул иренә туры карарга оялды, күзләрен читкә алды.

Эшкә баргач та ул тынычлана алмады. Авыруларны кабул итү алдыннан аның янына күз врачы керде.

— Дамир Галимович җирдән йөрми кебек миңа, түбәсе күккә тигән. Кичә Дәүҗан алдында сорарга яхшысынмадым, Дамир белән элегрәк таныш идегезме, әле ул Казанга баргач кына таныштыгызмы?

— Танышуыбызга ике ай да булмады әле.

— Алай... Бу ир-атка мин шаккатам. Эзләнәләр-эзләнәләр, сайланалар-сайланалар. Тиң тиңен эзли шул...

— Нигә алай дисез?

— Дамир Галимовичны әйтәм. Сездәй хатын табуына шат берүк. Кемнедер бәхетле итә бу ир-ат, кемнедер бәхетсез итә. Сер тубаллары прямо...

Авыруларны кабул итсә итте Фирүзә, итмәсә юк. «Нигә ул алай диде? Кеме бар Дамирның?» Эш сәгатьләрен үткәрә алмый иза чикте Фирүзә. Тизрәк беләсе, нидер тизрәк ачыклыйсы килде. Бүген ул Дамирның да керүен көтмәде. Өс киемнәрен калдырган бүлмәгә ашыкты, халатын салып, урамга атлады. Миен бертуктаусыз кичә очраган малайның сүзе бораулады.

Күз алдына малайның мөлдерәп яшь белән тулган күзләре килә, аптырап, гаҗәпләнеп калуы, нәүмизләнеп, балаларга гына хас үртәлү белән үпкәләве, йөгереп түгел, ә тәпен-тәпен артка чигә-чигә китеп баруы; малайның куе-кара чәче, Дамирныкыдай, бер-берсеннән качарга җыенгандай, читкәрәк урнашкан күзләре... Фирүзә ашыкты. Менә ул шунда очрады. Я бала бакчадан кайтып килә иде, я бу тирәдә, әнә шул өйдә яши...

Фирүзә тротуардан ишегалдына борылды, ләкин киң ишегалдында андый бала-чага күренмәде. Балалар өчен ясалган ком әрҗәсе тирәсендә ике яшьлек кызчык йөри, аның кулында кечкенә көрәк, әрҗә янындагы эскәмиядә бер карчык утыра. Фирүзә шунда юнәлде. Ләкин, карчыкка җитәрәк, кире борылды, урамга чыкты.

«Нигә йөрим соң әле мин болай? Ул мине ярата, шул җитмиме әллә миңа?» — дип уйлады ул, өй стенасына сөялгән килеш, тирәюньне күзәтә башлады. Кичә малайны очраткан вакыт җитмәгән иде әле. Бакчадан кайтып барышы булган булса, ун минутлардан малай биредә булырга тиеш. Ярый әле, аны бу шәһәрдә берәү дә белми. Үтүче-сүтүчеләр гүя аны күрмиләр дә. «Әллә соң барысына төкереп, кайтып, аш хәстәрләп торыргамы?.. Юк, мин аның кем булуын белергә тиеш. Мине тәүге тапкыр алдаган икән, димәк, ул гомергә алдаячак. Аның хатыны, баласы булса?!»

Бу уеннан Фирүзәнең коты алынды, сулышы кысылды.

Чатта бер төркем бала-чага күренде. Фирүзә ике өй арасына узды, багана артынарак басты. «Әнә ул кичәге малай. Дамирныкы кебек, чәчләре чем-кара. Күрче, йөреше дә гел аныкы». Фирүзә, йөрәге кага башлавын тоеп, тротуарга чыкты, малайга каршы китте.

— Исәнме, малыш!

Малай бер мәлгә туктады, сирпелеп Фирүзәгә карады, бер дә исе китмичә шундук китә дә башлады.

— Исемең ничек синең?

— Гали.

— Гали кәҗәне ашата, кәҗә сакалын селкетә: Галигә рәхмәт әйтә, — дип сөйләп китте Фирүзә. — Мин синең әниеңне беләм. Сердәшләр без. Алып барасыңмы үзегезгә мине?

— Әнием минем эштә. Ул сәгать биштә генә кайта.

— Ә сез кая торасыз?

— Менә безнең йорт.

«Бер квартал аша гына яшәгәннәр. Юк, өйләнмәгән булгандыр, өйләнеп аерылышкан булсалар... Киткән-киткән, ераккарак китәр иде». Шулай дип уйлауга, Фирүзәгә чәк кенә булса да тынычлану килде. Биш туларга ярты сәгать бар иде әле. «Дамир эштән кайтыр, мине эзләр», — дип куркынды Фирүзә, ә үзе малай белән янәшә атлый бирде.

— Ә синең ачкычың бармы соң?

Малай кара тасма белән муенына таккан ачкычны чыгарып күрсәтте.

— Сез Шалтыданмы әллә?

— Юк, Актаудан.

— Шалтыда минем әбием бар...

Өченче катка күтәрелгәндә Фирүзә шулай йөрүенә үкенү тойды, хәтта борылып китеп барасы килде. Мәгәр малайга ияреп кенә менде. Гали ишекне үзе ачты, зурларга хас тәвәккәллек белән коридорга узды.

— Хәзер мультик була. Карыйсызмы? — малай Фирүзәнең аягына күз салды. — Тик туфлиегызны салыгыз. Әнием келәмдә аяк киеме белән йөрергә кушмый.

Фирүзә балага ияреп йөрүенә үз-үзен тиргәде, орышты. Тик барыбер әйләнеп чыгып китә алмады. Әллә нәрсә тотты үзен. Туфлиен салды, түр якка узды. Бер бүлмәле квартира. Идәндә яшел синтетик келәм, почмакта «Рекорд» телевизоры. Малай аңа урындык китереп бирде, барып телевизорны тоташтырды.

— Сиңа ничә яшь инде, Гали?

Малай биш бармагын тырпайтып күрсәтте.

— Бер, ике, өч, дүрт, биш, — диде малай, һәр бармагын аерып күрсәтә-күрсәтә.

— Зурсың инде, дәүсең дим.

Малай дәүлеген исбат итәргә теләпме, телевизор ручкаларынборгаларга кереште. Аннары Гали Фирүзәгә кара тышлы альбом китереп бирде.

— Менә рәхмәт. Мин альбом карый торам.

Беренче бит. Фирүзәнең йөрәге ашкынып тибә башлады. Бу бит күз врачы янында утыручы медсестра Дәүҗан. Димәк?.. Юк-юк. Мөмкин түгел бу!.. Ә ник, нигә алай булмасын, ди... Менә ни өчен дәшми-тынмый, башын игән килеш утырган икән ул! Менә монда кыз чагы, медицина училищесы студенткасы. Фирүзә, алтын эзләгән кешедәй, тизрәк битләрне актарды. Менә ул Дамир. Озын чәчле, янәшәсендә Дәүҗан...

Фирүзәнең күз аллары караңгыланып китте. Альбомның соңгы битенә кадәр Дамир фотолары. Димәк, ул өйләнгән булган, аның баласы бар.

Фирүзә, тез буыннары калтыравын тоеп, торып басты.

— Гали, рәхмәт сиңа, мин китим инде, соңрак килермен, яме...

Малай мультфильм белән шул тиклем мавыккан иде, әйләнеп тә карамады.

«Нинди хурлык, нинди түбәнлек! Ни өчен?.. Ни гаебем бар минем?.. Нигә алай иттең, Дамир» — дип үртәлде Фирүзә, өйгә таба атлаганда.

Мизгел эчендә кичә генә якын, ямьле тоелган шәһәр шыксызланып калган сыман булды, кешеләре, өйләре, тротуар буена утыртылган тупыллар үзгәрде, бөтенләй башка төс алды. Фирүзәнең йөрәге күкрәк читлегеннән бәреп чыгардай булып типте. «Нишләргә, нишләргә?!»

Ярый әле, Дамир кайтып җитмәгән иде, Фирүзә, йодрыкларын тешли-тешли, ярсынып, бүлмәдән-бүлмәгә йөренде. Әнисе ни әйтер, ни күзләре белән күренер әнисенә!

Колак төбендә әнисенең сүзләре яңгырады. «Юньлегә генә булсын инде, балам». Юньлегә генә... Менә ул язмыш.. Фирүзә йөзекне салды, әйтерсең балдак телгә килде, ни эшләргә кирәген әйтеп бирер кебек иде. «Нигә ул мине алдады, нигә ул баласы, хатыны булуы турында әйтмәде?»

Ул ашыга-кабалана сумкасына әйберләрен тутырырга керешге һәм, ачкычны өстәлгә куеп, подъезд ягыннан ишекне япты.

Ул килеп кергәндә, Гали кино карап утыра иде инде.

— Кем бар анда? — дип, кухня ягыннан Галинең әнисе килеп чыкты, аннан әллә ишекнең ачык калуына аптырап, әллә көтелмәгән кунакны күрүдән баскан җирендә катты да калды.

— Сез?!

— Мин, Дәүҗан... Дәүҗан, зинһар әүвәл мине тыңлагыз. Бер сорау, нибарысы бер сорау сезгә... Бала анықымы?..

Дәүҗан күзләрен түбән төшерде, бер тын кулындагы тастымалны бөтәрләп торды.

— Без аның белән язылышмаган идек. Үзе никтер теләмәде...

Фирүзәгә кисәк җиңел, бик-бик җиңел булып китте. Бер тапкыр ул, бала чакта, су буена, болынга төшкән иде. Чәчәкләр арасында йөри торгач, бер күбәләккә тап булды. Ул шундый матур иде ки, Фирүзә күбәләкне тотарга итте. Ә күбәләк очынды да очынды. Гүя Фирүзә белән юри уйный иде. Фирүзә аның артыннан йөгерде, һәм шунда кинәт аңа да канатлар үсеп чыккан кебек булды. Ул күккә күтәрелде, очып китте. Җиңел-җиңел булып киткән иде аңа шул вакыт. Бу хәлдән соң ул еш кына төсле төшләр күрде, кошлар кебек биектә-биектә очып йөрде.

— Менә бу йөзек, бу алтын балдак, Дәүҗан, анықы. Аны миңа Дамир алып биргән иде. — Фирүзә ни әйтергә белми аптырап калган хатынга балдакны сузды. — Алыгыз, ал. Сезнеке ул. Мин китәм. Бөтенләй китәм. Мин аны бүтән күрергә теләмим...

Дәүҗан балдакка үрелмәде, тораташтай басып тора бирде. Фирүзә аның янына килде, балдакны хатынның учына салды.

— Алыгыз. Зинһар, рәнҗемәгез миңа...

*
* *

Автобус түбән тәгәри, кояш баеп бара, ә көнчыгыш ягыннан, кояшны озатырга дипме, ай калкып килә. Ул шундый мул, түгәрәк һәм ак ки, үрелеп кагыласы, тотып карыйсы килә. Ә бераздан кояш баеп, ай тагы да көмешләнә, купшылана төшәр, йолдызлар кабынып, тик ул вакытта инде Фирүзә бу шәһәрдән еракта, бик еракта булыр. Ай нуры Таң чишмәсенә дә төшәр, Фирүзәнең кайтуын әйтер, шул хәбәргә чишмә тагы да дәртләнеброк чылтырар, саф күңелне болгатып булмый, кайгырма, Фирүзә, дияр.

# ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕННӘН

*Арчада яшь иҗат көчләренең зона конференциясе булып узган иде. Казаннан, Арча, Биектау, Балтач һәм Саба районнарыннан килгән яшь язучылар, шагыйрьләр һәм драматурглар иҗатын тикшергән тәҗрибәле әдипләр аларга бик күп файдалы киңәшләр бирделәр. Шагыйрьләрдән Шамил Маннапов һәм Нәҗип Мадьяров СССР Язучылар союзына тәкъдим ителде. Роза Хәлиуллина шигырьләре аерым китап итеп бастырырга лаек табылды.*

*Журналның бу санында әсәрләре конференциядә тикшерелгән яшь шагыйрьләрнең шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

## Шамил Маннапов

●

Күпләр чакыра мине үзенә генә.

Күкләр чакыра:
— Бул үземә генә...
Җил чакыра:
— Бул үземә генә...
Сил чакыра:
— Бул үземә генә...
Җир чакыра:
— Бул үземә генә!..
Ә мин барысын бердәй сөям менә.
Барысына да бердәй үлеп гашыйк,
Барысын да карыйсы иде татып.
Ләкин беләм:
Килер бер көн картлык,
Барысына да өлгералмам артык.
Калырмындыр тик берсендә генә:
Җилдә генә,
Яки силдә генә,
Күктә генә,
Яки Җирдә генә...

Кайсында да ярый,
Булсын бары
Туган илдә, Туган илдә генә.

## Җиһан дәрьясында

Ни кузгата җиде төннең уртасында,
Күз шар ачык,
                    әллә ниләр уйландыра.
Гомеремдә дә ишетмәгән нинди өннәр
Тыңландыра,
                моңландыра,
                                шомландыра?
И-и, бу җиһан...
«Юктырсың ла, алла, диеп,
Әгәр булсаң, мин-бәндәңне аңла», диеп,
Әйтүчеләр беркатлылар булып тоела.
Патшаларга, түрәләргә кадәр хәтта
Тавышың барып җиталмәгән бер заманда
Кая инде, сине алла кадәр алла
Ишетсен дә, теләгеңне суксын санга?!
Адәми зат никадәрле көчле, димә,
Ишталмыйсың кайчак якын кешеңне дә...
Әле менә эштән арып кайтканнан соң,
Ял итәргә ятканнан соң
Кем уйлары дулкын булып кагыла миңа?
Җавап таба алмыйм шуңа.
Җиде төннең уртасында күңелемә
Әшкәрүче, нинди зат син? —
Җавап юк, тын...
Шул дәшмәве белән җавап бирәдер ул,
Бәлки минем ерактагы якын дустым:
«Кешеләрне, җан дусларны сүзсез аңла,
Шатлыгына, кайгысына бергә чыда».
Иксез-чиксез дәрья сыман бу җиһанда
Кыя булып нәни генә йөрәк тора...

●

Әй, бу дөнья, усаллыкта ашып китә...
Бала чактан сине үзенә гашыйк итә.

Соңра ямьсез якларын да ача башлый,
Ул да булмый, синнән никтер кача башлый.

Картайганың күреп, күңеле бизә бара,
Аның күзе яшьрәкләрдә, сабыйларда.

Бу дивана минем арттан чапмасын дип,
Аякларның хәлен ала таяк биреп.

Гүзәллегем күрмәс булсын дипме әллә,
Күзләреңә ябып куя тонык пәрдә.

Ләкин күпме китермәсен хәсрәт-кайгы,
Инде кеше ташлый алмый бу дөньяны.

Хәтерли ул бала чагын, яшь чакларын,
Шулар, ахры, саклый сөю учакларын.

Әҗәл алып киткәндә дә,
Күңеле тулып
Китә кеше, мәхәббәткә тугры булып.

## Соңгы бураннар

Очасыз, кар күбәләкләр,
Шаярышып туйганчы.
Уйнап калыйк, дисез, бугай
Җиргә төшеп кунганчы.

Җиргә яткач, ак керфекләр
Дымсуланган шикелле,
Инде уйнап булмас, диеп,
Моңсуланган шикелле.

Энҗе чәчәкләре булып,
Төшәсез яланнарга.
Кар кызына әверелеп,
Карыйсыз малайларга.

Әле төштә дә аларны
Төрерсез бураннарга.
Ә аннары гомер буе
Очарсыз хыялларда...

## Урманнан кайтканда сөйләшү

— Тирән елга суы кайда, әти?
— Кипкән, улым, кипкән.
— Болан сазлыгының боланнары?
— Киткән, улым, киткән.
— Имәнсәрнең имәннәре ник юк?
— Күптән киселеп беткән.
— Исемнәре ничек калган икән?
— Үзе югалтканны кеше кабат
Тапсын өчен, иркәм...

## Ә мин ашкынам...

Кешеләр оча ерак Галәмгә —
Җире турында күп белү өчен.
Җирне ерактан күп күрү өчен,
Җирдә ал гөлләр үстерү өчен.

Кеше омтыла кеше янына —
Үзе турында күп белү өчен,
Үзен бер читтән күзәтү өчен,
Күңел гөлләрен ишәйтү өчен.

Ә мин ашкынам синең яныңа —
Барсы турында күп белү өчен.
Галәмне, Җирне, кешеләрне, сине
Яратуымны сиздерү өчен.

●

Кайсы мәлдә, кайчан җимерелгән
Кешеләрнең ышаныч кәгъбәсе?
Әй, кайтарып шушы кәгъбәләрне
Төзәтәсе иде, төзәтәсе.

Яхшылыктан яхшылыклар шыта,
Усаллыктан туа усаллык.
Заманалар әйбәтләнгән саен
Кешеләрдә арта уйчанлык...

Тыныч торыйк! —
Дигән изге теләк
Җитсен өчен һәрбер адәмгә,
Җирдән торып, кат-кат әйтә кеше,
Күтәрелеп әйтә, галәмнән.

Ышанычны аны җимерү җиңел,
Төзү генә кыен яңартып.
Дипломатлар куллар кысышканда
Ракеталар тора сагаеп...

Кайсы мәлдә, кайчан җимерелгән
Кешеләрнең ышаныч кәгъбәсе? —
Әй, кайтарып шушы ышанычны,
Төзәтәсе иде, төзәтәсе.

## Роза Хәлиуллина

### Җирәннең ал гөле

Илләрдә батырлар — дан икән,
Билләрдә ярсу бар чак икән.
Еллардан мәңгегә онтылмас
Беренче сөюне ал икән.

Һәркемдә сагынулар бар икән.
Хәтердә туган җир, яр икән.
Юлларда сагынудан сусаткан
Илаһи көч туган як икән...

Таш кына юл. Сукмак — бормалы,
Камышлы күл, дәрья, гөлләре...
Камыш бил — сылу яр Асылъяр,
Егетнең тиңсез ут дигәне.

Яр итеп, гөл итеп, бер итеп
Сайлаган тиңкәе үз микән —
Сылуга берсе йөз батырның
Сүз кушкан. Кадерле сүз микән?

Илләрдә — батырга дан юлы.
Билләрдә — ярсулар аелы...
Сөюнең көчлесе, керсезе,
Тиңсезе — җирәннең ал гөле.

## Ана назы

Җылы кулда
Яңа туган
Алсу бала.
Әнкәсенең
Яратуы
Кучкән аңа.

Әнкәсе ал
Биләүләрен
Били-сутә.
Җан җылысы
Белән җылытып
Сулар кертә:

— Ал булгырым,
Гөл булгырым,
Зур булгырым.
Үсеп җитеп,
Чыгып китеп
Юл йөргерем.

Нур булгырым,
Үз булгырым,
Зур булгырым.
Туган илгә
Тугрылыклы
Ул булгырым...

Олы җиргә
Яше-карты
Бер баладай.
Кайнар июль...
Агар Идел
Бормалана;

— Су кер,— дия,—
Бәләкәем,
Су кер, балам...
Яшен-картын
Шулай назлый
Зур җир-Ана.

— Яшь булгырым,
Шат булгырым,
Зур булгырым.
Ак булгырым,
Пакь булгырым,—
Болгар улым!

## Адәм баласы бу

Бу кадәрле котырып исәрлек дип,
Җилгә кемнәр биргән исәрлек дип,
Купме кирәк безнең яшь бәгырьгә,
Исәр җил дә аны кисәр бер дип,

Ваемланган юлчы идек ул чак.
Адымнарны барды еллар үлчәп.
Газиз җанын кочкан көчсез кочак
Михнәтләргә тәмам җуйды хисап.

Адәм җаны эт җаныдай диләр,
Эт түзгәнгә адәм түзәмедер.
Курми булмый, киселмәсә гомер,
Мең киселә бәгырь, өзәргә — бер...

Ә без очтык табып алтын канат,
Канат эзләп тоттык каты җавап.
Кыеклыктан өркеп яшәү газап,
Газапларны җиңә яшәү — сәләт.

Башта бит без курка идек «җил» дип,
Алар тора бүген башын иеп.
Алар тездән генә, ә без биек
Давылларның башын йөрдек сөеп.

## Ярат

Күзең зәңгәр түгел димә,
Кара күземә карап.
Зәңгәр күзгә тормаммыни,
Кара күземне ярат.

Тиң итмичә йөрмә мине,
Йөрмә кимнәргә санап.
Ятимәлектән кимсенгән
Зая гомеремне ярат.

Әйтмә бәхет тапмассың дип,
Хәсрәтең бар дип, газап...
Миннән бәхет күпсенмә син,
Хәсрәтле килеш ярат.

Матурларны йөрмә эзләп,
Бөтенесенә ярап.
Минем ямьсез көннәремне
Үзең матурлап ярат.

Кимчелекләрем булса да,
Сөюең белән тарат.
Әле мин бер гүзәл булам —
Син бары ярат, ярат.

●

Аклар, пакьлар хөкем итсен,
Хаклык өчен аклык шарт.
Йөземә кара ягарга
Тырыштылар ничә кат.

Җирдән хаклык эзләп үттем,
Серле дә соң шул йомгак.
Кайбер хаклык исбатлана
Вакыт үткәч мең еллап.

Горурлыгым, үткен телем
Күп чак сәбәп ялага —
Бер рәнҗүем үтмәс борын
Икенчесе ялгана.
Еш абынам ялага.

Хаклык дигән серле йомгак
Тәгәрәде каяле?
Аны җуйсам, аклар, пакьлар
Хөкем итсен әвәле.

## Шик

Озын юлга
Китте инде.
Я сагынып,
Я сагынмас...

Кире кайтып
Иңнәремә
Я сарылыр,
Я сарылмас.

Шигем белән
Күңелемә
Ялгыз кереп
Бикләнимме?
Күңел белән
Күкрәк пәрдәм
Читлегемдә
Чикләнимме?

Дус-дошманга
Чәчмәс идем
Бу өметсез
Көткәнемне.

Юка кәгазь,
Сиңа йөклим
Таудай серем-
Йөкләремне.

Озын юлга
Китте инде.
Я борылыр,
Я борылмас.
Кире кайтып
Туфрагыма
Я орыныр,
Я орынмас...

●

Берәүләр ут,
Берәүләр су,
Ут та кәчле,
Сулар да.

Тик шулай да
Ут башына
Сулар тиеш
Сугарга.

## Нил Габбасов

●

Төн — караңгы, төн — кара.
Күктә бер йолдыз яна.
Кем, аны маяк итеп,
Юл таба?
Кем, аны өмет итеп,
Юана?
Кем, аны символ итеп,
Уйлана?
Кем, аны алла итеп,
Инана?
. . . . . . . . . .
Ул йолдыз сезне
Маяк та, өмет тә, символ да, алла да итми.
Ул сезне бар дип тә, юк дип тә исе китми...

### Хыял

Салкын җилләр,
        җилли-җилли, җәйне җирли...
Күңел боек...
Карлы яңгыр
        ява коеп,
күңел читен ала кыеп.
Ай-һай, кыен,
        ай-һай, читен шундый чакта.
Тик хыялым,
        күз яшь аша,
— Кояш, яшә!

Күңлем, ташкын булып ашкын!—
Диеп дәшә.
Аргамагы
өмет белән ул янәшә.
Гүя миңа
әллә кайда адашкан бер бәхетемне
ак томаннар арасыннан ул яршә...
Ул янәшә...
дәшә!..

●

Гомер сукмагымнан акрын гына
Йолдызларга карап барганда,
Уйлый идем: кайда минем йолдыз?
Туктап эзли идем арганда.
Табалмагач,
Әллә юк микән, дип,
Хафаландым бик күп таңнарда.
Булса да ул, диеп,
Сүнәр-сүнмәс...
Калтырыйдыр... әллә кайларда...

Күз карашың, бер ягымлы сүзең
Җилкәләрдән алып ташлады
Еллар буе шөбһәм өскә өйгән
Авыр йөктән зур-зур ташларны.

Һәр атылган йолдыз,
Сагыш ташы булып,
Иңнәремә килеп төшкәндә,
Минем йолдыз исән! Исән! — диеп,
Мин кабатлыйм хәзер төштә дә!

●

Сөйгән һәм сөелгән идем аз-аз гына,
Мәхәббәт булмаган, булган аваз гына...

Әйтә алмыйм, мәхәббәттә мин йөздем, дип,
Эчеп бетерә алыр идем диңгезен тик.

Бер хатирә яши ләкин күңелемдә:
Сусаганнан алҗып, ярга якынлаштым
Һәм иелдем шул мәхәббәт диңгезенә,
Тик иренне тидергәнче, диңгез... качты.

●

Очар кошлар китә көздә,
Кайта язда сагынып.
Үлсә читтә, хәбәр кайтмый
Илгә канат кагынып.

Яз да китә, көз дә кайта
Кешеләрнең кайсысы.
Үлсә читтә, илгә кайта
Сәламе һәм кайгысы.

●

Бар да бетәр, очар-китәр күгелҗем төтен кебек,
Бар да бүтән: килер, көтәр дөньяны, безнең кебек.

Кабатланыр яратулар, йөрәкләр янар көеп,
Сагышларны таратырлар өздереп җырлап, биеп.

Кемнәргәдер яңа җырлар сокланып багышланыр,
Җыр язганнар китә барыр, сыкранып җырлар калыр.

Яфраклар да коелырлар саргаеп, көзләр җиткәч,
Яшьлекнеме сагынмассың, билләрне еллар бөккәч?!

Хатирәләр булып кайтыр кайгысыз бала чаклар.
Өзгәләрләр үзәкләрне без киткәч калачаклар.

Аларга да килеп җитәр, көттермәс андый чак та.
Исләренә шунда төшәр, сөйләрләр безнең хакта.

Арада тик томан ятар үткесез пәрдә кебек.
Шул томаннан күренерләр күпләр тавышсыз көлеп.

Яңгырап куяр колакта инде югалган аваз.
Сискәнерсең: тирә-якта тып-тын, хәтта күк аяз...

Болар — алда. Ник соң борчый күңелне сагыш, телеп?
Бөреләр дә моңая шул, көзләрдән кышка кереп.

Мөлдериләр ботакларда тезелеп күзләр кебек.
Яфраклар бит коелалар җан биреп — булмый түзеп!

...Мөлдерәгән бөре сыман мин тормыш ботагында.
Нинди давыл яный аңа салкын җилле яңгырда?

Белмиме ул язларның да кышны җиңеп киләсен,
Яшел яфрак кочагында назлы чәчәк көләсен?!

...Ышанам да, ышанмыйм да язым бер киләчәк, дип,
Мин — яфракның кочагында наз бөркер ул чәчәк, дип.

●

Эчпошыргыч соры болытлар
Каплап алган күкне тоташтан.
Мин сорадым чибәр туташтан:
Бу болытлар кемнең кайгылары?
Әйтте туташ: алар — тик су пары.

Шунда күкне басты моңсулык,
Сибәләде яңгыр тоташтан.
Мин сорадым чибәр туташтан:
Кемнең күз яшьләре ява күктән?
Әйтте туташ: су бу, мәгълүм күптән!

# Фәнил Мәүлетов

## Кичке якта

Игеннәр — яшелле-сарылы,
Аксыллы-зәңгәрле — күкләрем.
Тәнемә башаклар сарылды,
Кулларым сыйпады күпләрен.

Башаклар иелгән туклыктан,
Баш ию түбәнлек түгел ич.
Тәкәббер масаю юклыктан,
Алдымда илаһи күренеш.

Гадилек бөркелгән басулар
Гел алга, еракка узачак.
Артыгы бернәрсә кирәкми,
Бер кимлек бар ямьне бозачак.

Офыклар оялып кызарган:
Кояшка баерга иртә күк,
Кешене кызарту өчен дә
Бер башак югалту җитә күк.

## Көз бизәкләре

Җир яфраклар ябынганда,
Һич тыныч атлый алмыйча,
Кыштыр-кыштыр бер кыз йөри,
Ялгыз йөрүләремени?
Каз канатын кагынганда,
Җирдә сары яфраклар
Тәгәриләр, чабышалар,
Шул каз бәбиләремени.

Җиргә томан сарылган да,
Тырпаешкан ботакларга
Эләгә күрмим, дигәндәй,
Әкрен генә йөзеп бара.
Үткән җәйне сагынганда —
Кабатланмас вакытларны,
Кем күңеле тыныч кала:
Вакыт һаман ага, ага...

Тар сукмаклар салынганда
Ботка булган җир өстенә —
Тезелешеп йөрүләрне
Көз, ахрысы, килештерә.
Күкне болыт каплаганда,
Якты кояш сыман булып,
Балкый миләш тәлгәшләре
Тирә-юньне сокландырып.

## Нәни бөртек

Энҗеләрдәй кар каплаган эскертләргә
Тракторлар килеп туктый шаулый-шаулый.
Эскерт кинәт кузгала да китеп бара,
Мондый хәлне җәнлек-кошлар аңлый алмый.

Кайта эскерт — кайта соңгы көзге байлык,
Ничә тапкыр урар иде чаналы ат!
Бар булуда, югалуда тизлек хәзер
Күкне телгән җәйге яшен чамалырак.

Салам кайта, ә басуда ялгыз карга
Кунар өчен урын эзләп көн уздырыр.
Өнсез калган куяннарның тәпиләре
Ирексездән бакча карын пыр туздырыр.

Салам кайта, җилләр арттан этеп карый,
Тик кая ул — җитә алмый үксеп кала.
Нәкъ шул чакны мең саламнар арасыннан
Сиздермичә җиргә бөртек төшеп кала.

Авылга, юк, кайтып йөрми нәни бөртек:
Кышлар үтсен, яңгыр гына тамчыласын...
Карны тишеп, тоеп иртә күкрәүләрне,
Белә бит ул тиздән язны каршыласын.

## «ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

**Шамил Бикчурин**

# РЕКОМЕНДАЦИЯ

хикәя

Кук-кү, кук-кү!

Күкеле звонок тавышына килеп ишекне ачса, коридорда мескен генә кыяфәттә Сәет басып тора.

— Ә, син икәнсең, — диде Габдерәхим абзый, игътибарсыз гына.— Әйдә, уз тизрәк, өйне суытасың.

Керергә кыймыйча, кергәч тә ни эшләргә белми һаман бусагада таптанып торучы бу егет Габдерәхим өчен кадерле кунак түгел иде. Алар бер бораулау идарәсендә эшлиләр, вахта машиналарын көткәндә автовокзалда һәр иртәне диярлек йөзгә-йөз, күзгә-күз очрашып торалар.

Элегрәк еш килеп йөрсә дә, соңгы айларда бу йортта Сәетнең эзе суынган иде.

«Әһә, яңадан кыз янына иләшмәкче булып йөри, — дип уйлап алды хуҗа, егетне түргә кыстаган булып.— Ай-һай, кискән икмәк кире ябышыр микән?»

Үзенә булган карашны Сәет тә сизмәде түгел, сизде. Элек булса, ишек ачарга барысыннан алда Мәрзия үзе килеп җитәр иде, Сәетнең җиңеннән тотып, шыпырт кына үз бүлмәсенә тартып кертер иде. Анасы да күреп алыр: «Нихәл, Сәетҗан? Әниең исән-имин генәме, нишләп бу араларда күренми?» — итенгәләп, хәйләкәр генә кухняга үткән булыр иде. Бүген егетне сәламнәр өчен ник берсе өеннән башын чыгарып карасын!

Кыен, бик тә кыен булып китте Сәеткә. Хәзер, шушы минутта ук моннан чыгып йөгерәсе килде. Тик, йөзеңне ертып килгәч, теләсәң-теләмәсәң дә каласың икән.

Кыстаучы булмаса да, Сәет өс-башын чишенде, аяк киемнәрен салды һәм хуҗага ияреп залга керде.

Утырыштылар. Бер-берсенә карашып алдылар. Алай да сүз башлаучы булмады.

Сәет өчен иң читене дә менә шулай су капкандай шым утыру иде. Телсез кебек. Гаепле, җинаять кылган кеше кебек.

Билгеле, кызын ташлаганга дәшми Габдерәхим абзый. Соң, дөньяда егет белән кыз арасында ни булмас? Аннан бит әле гаеп Сәеттә түгел, Мәрзиянең үзендә. Әтисенә сөйләп, аңлатып булмый бит инде...

Габдерәхим абзый шырпы-тәмәкеләре белән бергә көл савытын күтәреп килде, мыскыл иткәндәй, өстәлгә Сәет алдына куйды. Тартмаганын белә торып:

— Төтәтеп җибәр, — диде.

Монысы инде хуҗаның: «Йомышыңны сөйли башла», — дип әйтүе иде.

Бар иде заманнар: Мәрзия өйдә булмаса, аны көтеп шушы бүлмәдә утыра иде Сәет. Габдерәхим абзый ул вакытта болай кырт та мырт кыланмый иде. Тәмәке кабызып диванга менеп утырыр иде дә: «Яшь чак, кесә тулы борчак», — дип, үзе белән булган мәзәк хәлне сөйләп китәр, я булмаса сугышта күргәннәрен хикәяли башлар иде. Ә бүген, ата казың күкәй саламы? дигәндәй, мә сиңа: «төтәтеп җибәр», имеш.

Ике арадагы бу киеренкелек озак барырга тиеш түгел, егеткә булган дәгъваларын я тегесе туп-туры әйтеп бирергә, я булмаса монысы чыгып китәргә тиеш иде.

Ахырда Сәет, салкын су эчкәндәй сулышын эчкә йотып:

— Мин сезгә, Габдерәхим абзый, бик зур гозер белән килдем бит әле, — диде.

— Йә?

Һәм Габдерәхим абзый мизгел эчендә: «Кызны сорарга килгән бу», — дип уйлап алды.

— Үзегез беләсез, Габдерәхим абзый, мин сезнең кул астында елдан артык эшләгән кеше. Ничек эшләгәнемне дә яхшы хәтерлисездер... Хәзер сездән киткәч тә бирешергә исәп юк...

— Әлбәттә, әлбәттә, — диде хуҗа, татлы уйларга чумып. Ләкин үзе әйткәнне үзе ишетмәде. «Болай кызның вакыты җиткән җитүгә дә, чак кына иртә түгел микән? Мәрзиянең кичен укып техникум бетерәсе бар бит әле», — дип борчылып алды.

Аннан Габдерәхим үзен кадерле кода сыйфатында Сәетләрнең әтиләрендә итеп күз алдына китерде, аннан сакаллы бабай рәвешендә оныклары белән әүмәкләшеп алды, аннан...

Ул ләззәтле хыялларыннан айныганда егет әле һаман нәрсәдер сөйли, ә монысы, аны җөпләп, тоташ баш кагып утыра икән.

— Мин бу турыда партоешма секретаре Селиванов белән дә киңәшкән идем, — дип дәвам итте Сәет, — ул да минем ниятне хуп күрде. Бу мәсьәләдә сездән дә кулай кеше булмас, — диде...

Шушы урында өйләнүгә дә, кыз сорауга да һич катнашы булмаган нәрсә сизенеп, Габдерәхим егетне бүлдерде:

— Тукта әле, ачыграк сөйлә! Яратмыйм авыз эченнән ботка пешергән кешеләрне!

— Партиягә керү хакында әйтәм. Селиванов та минем ниятне хуплады...

Шунда гына эшнең нәрсәгә терәлгәнен аңлады Габдерәхим — Сәет аңардан рекомендация сорарга килгән иде.

— Башта ук шулай дип әйтәләр аны! — дип шелтәләргә кереште хуҗа. — Әллә кайдан, ындыр артыннан уратып йөрисең!

Юк, егет җебеп торган өчен түгел, үзенең татлы хыялларыннан мәхрүм калганы өчен ачулана иде ул чынлыкта. Дөрес инде: «Уллы кеше губернатор, кызлы кеше башын кашып ятыр»...

Күңеле кырылган хуҗа папирос кабызды, аны бер-ике суыргач, үз хәленә кайткандай булды.

— Рекомендацияне тагын кемнәр бирә? — дип кызыксынды.

— Беләсез инде, устав буенча ВЛКСМ членына берсен комсомол бирергә тиеш, калганнарын...

— Тиеш дип сөйләмә! Миңа әллә кемнәр әллә нәрсәләр тиеш! Турысын әйт, комсомолың бирәме?

— Комсомол бирде.

— Коммунистлардан тагын кем бирде?

— Дядя Вася язам диде. Теге, мастерскойдагы слесарь.

— Хуп! Аңа мин ышанам, ул начарларга тавыш бирмәс!

Габдерәхим абзый торып китте дә, тәмәкесен төтәтә-төтәтә, идән буйлап йөренә башлады. Ул партоешма секретаренең Сәеткә әйткән сүзләре белән хушланган иде.

— Димәк, Селиванов, миннән дә кулай кеше юк, дип әйтте инде? Туп-туры шулай дидеме?

— Туп-туры.

— Алайса, Сәет энем, килештек. Мин сине артың белән мичкә керсәң дә таныйм. Монысы үзара гына... Сине яхшы беләм дип әйтүем. Ярый, иртәгә язып куярмын...

Сүз тәмам икәнне белдереп, Габдерәхим абзый тәмәкесен көл савытына китереп кадады.

Сәет чыгып китү белән үк язарга утырмакчы иде Габдерәхим, ләкин көтмәгәндә өенә егет килүдән һәм үтә җаваплы эш йөкләнүдән вәсвәсәләнгән күңеле тиз генә басыла алмады. Моңа кадәр карт коммунист Габдерәхим Моратовның бер генә кешегә дә рекомендация язганы булмады һәм мондый йомыш белән мөрәҗәгать иткәннәре дә юк иде.

— Рекомендация, рекомендация... — дип кабатлый-кабатлый, ишекле-түрле йөрде, тәрәзә каршына килеп шау-шулы урамга карап торды. — Димәк, парторг мине үзе тәкъдим иткән... — дип куанды ул эченнән, — Селиванов кемнең кем икәнен яхшы белә шул. Ярый, бирәбез аны, ул рекомендация дигән нәрсәне. Нигә бирмәскә, Сәет лаеклы егет.

Сәет буровойга моннан дүрт-биш еллар элек техник училище бетереп килгән иде. Эшкә кулы йогып тора иде егетнең. Иренмәде, кушканны гына көтмәде. Башта Габдерәхим бригадасында буровой эшчесе иде, аннан верховой булып вышка башына үрмәләде. Бераздан, син күр дә мин күр, бурильщик дәрәҗәсенә күтәрелеп мастерның уң кулы булып куйды.

Шулай шәп кенә эшләп ятканда солдатка алып җибәрделәр үзен. Бик тә кызганган иде аны Габдерәхим. Сәет кебекләрне юлдан табып булмый бит...

Армиядән кайткач инде Габдерәхим Моратов бригадасына Сәет тәтемәде. Егетне берьеллык курсларга җибәрделәр дә мастер итеп кайтардылар. Хәзер кем белән диген, гомерен нефтьтә үткәргән Габдерәхим абзыйсы белән ярышып ята, каһәр. Зирәк, зиһенле малай...

Чокына торгач, аның гаепләрен дә казып чыгарды Габдерәхим. Кимчелекләре дә байтак икән егетнең. Түземсез. Каядыр ашкына, ашыга, кабалана. Зур нәчәл буласы килә дип әйтергәме, күтәрелергә, үрмәләргә, менәргә ашыга. Иң аянычы — кеше сүзенә колак салмый, үзенчә эшләргә тырыша. Кире, үзсүзле, үҗәт. Әйтергә кирәк булыр бу турыда җыелышта...

Габдерәхим кинәт, зур ачыш ясагандай, иренен тешләп тынсыз калды.

— Мәрзия белән аралары бозылу да шул үҗәтлегеннән түгел микән? Бик мөмкин. Юкса Мәрзияне егетләр яратмаслыкмыни?

Габдерәхимне рәнҗү, хәтер калу кебегрәк яман тойгылар биләп алды һәм ул тойгылары ачы камыр сыман күпергәннән-күперә барды. Моңа кадәр һәр җирдә: җыелыш-киңәшмәләрдә булмасын, тәмәке тартканда яки үзара гәпләшеп утырганда булмасын, Сәетне башкаларга үрнәк итеп куярга яраткан Габдерәхим абзыебыз минут эчендә егетнең әллә никадәр гөнаһларын эзләп тапты.

«Узган ел көзме әле, әйе, көз, октябрь аенда унтугызынчы буровойда авария ясаган иде. Җиде йөз метр тирәнлектә борауны сындырып калдырды. Дөрес, комиссия инструментта завод гаебен тапты, ә мастер ни караган? Нигә инструментны алдан тикшермәгән?

Аннан соң буровойда тәртип, чисталык мәсьәләсе. Шапшак тота эш урынын мастер. Китерелгән торбалар, агач материаллары кайсы кайда аунап ята, инструментлар пычрак. Әйтсәң яратмый, үпкәли. Җыештырырга вакыт юк, янәсе, аңа себерүче булып йөрергә түгел, борауларга кирәк. Метрлар куа мастер.

Янә дә килеп, Сәетнең үз-үзен тотышы. Үзенә ата булырлык өлкән яшьтәге эшчене, бораулаучы Мәхмүтовны яман сүзләр белән тиргәп ташлаган. «Эшләрдән түгел, пенсия өчен генә селкенеп йөрисең»! — дип җикеренгән. Дөрес, Мәхмүтовны да якламый Габдерәхим. Эленке-салынкы, көн узсынга гына йөри. Аңа хәзер буровойда авыр. Тик, ни өчен инде картны шулай рәнҗетергә?

Саный китсәң, ямьсез гадәтләре шактый икән Сәетнең.

Үзенең фикерен кызы Мәрзиядән дә җөпләтәсе килә иде Габдерәхимнең. Ни әйтсәң дә, Сәет белән ничә айлар башка-баш терәп, кулга-кул тотынып йөрделәр. Егетнең чатакларын, әлбәттә, ул күбрәк белә. Җитмәсә, комсомолда икесе бер оешмада торалар...

Габдерәхим бүлмәгә кызын дәшеп кертте.

— Сәеткә рекомендация биргәндә син җыелышта бар идеңме?

— Бар идем. Ә нәрсә, әти?

— Ничегрәк соң, тәкъдим ителдеме? Каршы килүчеләр булмадымы?

— Бик хуплап тавыш бирделәр.

— Син дә кул күтәрдеңме?

— Әйе. Ул иң яхшы мастерларның берсе ич. Җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Кичен техникумда да укый.

— Ә кеше буларак? — Монысы инде Габдерәхимнең иң кирәкле, кызын төп башына утырта торган соравы иде. Хәзер инде Мәрзия тайпыла алмас, егете турында да, араларында булган низагның сәбәпләре турында да яшермичә туп-туры сөйләп бирер, дип көткән иде әти кеше. Ләкин алай килеп чыкмады.

— Ул начар егет түгел, әти, — диде дә кырт борылып чыгып китте Мәрзия. Сизенде картның тел төбен. «Аңламассың бу яшьләрне, — дип кулын селтәде Габдерәхим, — төшенмәссең. Бер карасаң, тәрәзә төбендә яшертен генә балавыз сыгып утыра, икенче карасаң, «начар егет түгел»... Рекомендация ул, туган, сәяси мәсьәлә генә түгел, шәхси мәсьәлә дә! Габдерәхим теләсә кемнең авызын капларлык үткен сүз тапканына куанды. — Рекомендация бирүне ордым-бәрдем кәгазь язып ату гына дип аңламасын әле ул! Партиягә тәкъдим иткән кешесе өчен коммунист гомер буе җаваплы!»

Менә шушы сүзләрне ул Сәетнең үзенә әйтәчәк. Йөзенә бәреп әйтәчәк...

Тукта, болар бит Габдерәхим сүзләре түгел. Аларны бит кайчандыр рота командиры әйткән иде...

Габдерәхим абзый күңеле белән ерак сугыш елларына китеп, Курск дугасында бергә көрәшеп йөргән өлкән лейтенант Муратовны исенә төшерде.

Русчаны начар сукалагангамы, әй, сөенгән иде Габдерәхим аның ротасына эләккәнгә! Күпме фронтларда булып, ниһаять, татар командирына юлыкты, янәсе. Үз кеше, тегенди-мондый кыен хәл килеп чыга калса, кыерсытырга бирмәс әле, дигән тәмле өмет тә яши иде әчтә. Аннан, ерак җирләрдә милләттәшең белән бер тәмәке төреп, үзеңчә сайрашып алулары да ни тора бит!

Шулай дип уйлап, татарча эндәшеп караган иде Габдерәхим, теге акаеп карады да, «как, как?» дип, тик какылдап тора. «Йа ходаем, кечкенә генә түрә булып алган да, исемен үзгәртеп, үз телен онытканга салышкан!» — дип уйлады солдат.

Ә командир, чыннан да, рус, тумышы белән Себернеке булып чыкты. Михаил Матвеевич Муратов. Фамилияләр туры килү аны да гаҗәпләндергән икән. Габдерәхимнеке Моратов, тегенеке Муратов. Ә русчада икесенең дә Муратов. Соңыннан «Адаш» дип эндәшә башлады командир.

Адашлар байтак бергә булдылар фронтта. Бүгенгедәй күз алдында: кыю, кызу канлы кеше иде. Бәреп тә егар, тартып та торгызыр.

Бер көнне, алгы позициягә керәбез дип торганда, Габдерәхим килә дә Муратов янына:

— Адаш, минем бу сугышка керер алдыннан синең кебек коммунист буласым килә, — ди.

— Син, Адаш, партиядә түгелмени? — дигән була Муратов. Бергә күпме хезмәт итеп, әйтерсең бүген генә белгән.

— Так точно, иптәш өлкән лейтенант, партиядә түгел, — дип җавап бирә Габдерәхим, үрә катып.

— Ничек сиңа оят түгел, Муратов! «Адаш» аталасың, җитмәсә! — дип башын селкеп тора командир: — Үзең Дан ордены кавалеры, тәҗрибәле сугышчы, ике тапкыр яраланган кеше, ә үзең шушы көнгә кадәр беспартийный! Моны ничек аңларга?

— Моңынчы мин, миннән нинди коммунист инде, дип оялып йөрдем, иптәш өлкән лейтенант? Минем гыйлем ягын үзегез беләсез бит инде...

— Наданга сабышасың! Дивана булып кыланасың!

Тәмәке кабызгач, командир бераз уйлап тора да әйтә:

— Син болай да коммунист инде, Адаш, — ди. — Йә, әйт, кай җиреӊ коммунист түгел? Синең исәптә хәзер дошманның дүрт дөмектерелгән танкысы бар! Калганнарын әйтеп тә тормыйм!

— Ә рекомендацияне кем бирә? — дип, кисәк кенә сорап куймасынмы шунда Габдерәхим.

Командир елмаерга мәҗбүр булды.

— Рекомендация? Кара син аны: «рекомендация!» Бәлки сиңа зиннәтле утырыш заллары, кызыл комач җәелгән өстәлләр дә кирәктер? Фронт диләр моны, туган! Фронт, аңлыйсыңмы?!

Рекомендация мәсьәләсендә тикмәгә генә сүз кузгатмады солдат. Бу турыда кемнәрдәндер сугышка кадәр үк ишеткәне бар иде аның. Имеш, партиягә керергә теләүчеләргә рекомендацияне утнысуны кичкән, Чапай, Буденный дивизияләрендә сугышкан, я булма-

са Кышкы сарайны штурмлауда катнашкан зур стажлы өч коммунист бирергә тиеш.

— Рекомендация дисең инде, алайса, — дип, Габдерәхимнең җилкәсенә кулын салды бераздан командир. — Ярый, килештек, яз гаризаңны. Рекомендацияне бүген сугыштан чыккач үзем бирәм! — Һәм, приказ биргәндәй, солдаты каршында «смирно» басып, кырыс кына кисәтте. — Тик шуны бел: рекомендация биргән кешесе өчен коммунист гомер буе җаваплы! Тикшереп торырмын, кара аны!

Габдерәхим гариза язды, тик алдагы һөҗүмгә партия билеты алып керә алмады. Өлгермәделәр. Билетны соңыннан, сугыштан чыккач бирделәр. Тик ул тантананы өлкән лейтенант Муратовка гына күрергә насыйп булмады. Батырларча һәлак булды командир...

Габдерәхим командирын бүгенгә кадәр оныта алмый. Исән килеш түгел, ни өчендер үлгән килеш күз алдына килә ул. Терелә, окобыннан торып утыра да: «Син бит, Адаш, минем янәшәмдә генә сугыштың, нигә инде шунда минем өскә килгән «Тигр»га кырыйдан граната тондырмадың? Мин, бәлки, исән калган булыр идем»,— ди.

Күрде ул танкны Габдерәхим, граната ыргытырга да мөмкинлеге бар иде кебек, ләкин үзенә таба килгән «Тигр» белән бик мавыккан иде шул. Әллә таптап китәр дип шүрләдеме икән? Хәзер, күпме еллардан соң, төгаен генә әйтүе кыен. Андый мәхшәр вакытында төрлесе булгандыр...

Сугыштан соңгы елларда да күңелдән китмәде Муратов. Ул чакта азык ягы бик кысан булды. Нефтьчеләргә паек белән бераз он бирәләр иде. Ул онны буровойга алып барып, умач уып ашыйлар иде бораулаучылар. Габдерәхимнең егет чагы, киенәсе-ясанасы килә. Бер айны үзенә тиешле онны сатып костюм алган иде, күп тә үтми, хәле бетеп, башы әйләнеп буровойда егылды...

Аларын да, башкаларын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә Муратовка Габдерәхим. Хәтта үзенең белеме, тәҗрибәсе җитмәү аркасында буровойда аварияләр ясаганына кадәр яшерми.

Әллә кайда, еракта ишетелер-ишетелмәс булып кына Муратовның карлыккан тавышы ишетелә: «Син белем җитми дисең, Адаш, мөмкинлегең барда укырга кирәк иде. Сине бит курсларга да, техникумга да җибәрмәкче булганнар, ә син: «Карт көнемдә китап күтәреп йөрисем юк әле», — дип бармагансың. Нинди карт инде ул утыз яшьтә?»

Габдерәхим шул елларда укырга китмәвенә бик тә үкенә, ләкин соң. Менә ярышып карар иде ул аннан Сәет белән, көч сынашып карар иде!

Соңгы елларда Габдерәхим командиры белән төннәрен яки ялгыз калгач кына түгел, хәтта көндезләрен, буровойда эшләгәндә дә сөйләшеп йөргәли башлады.

Мондый сәер хәл Сәет килеп рекомендация сорап киткәннән соң бигрәк тә ешайды. Сәеткә рекомендация бирергә ул бөтенләй каршы да түгел, ләкин һаман нидер кулны тота.

Инде Габдерәхим абзый Сәет белән очрашырга да читенсенә башлады. Эшкә барганда вокзалга кермичә, машиналар артына посып тәмәке тартып тора. Ә егет, үч иткәндәй, гел очрап тора, һәркөнне диярлек көтелмәгән урыннан каршыга килеп чыга. Тик рекомендация турында ләм-мим. Хәл-әхвәлне сорашыр, буровойдагы эшләр белән кызыксыныр, әмма язу кирәклеген кузгатмас.

Габдерәхим генә:

— Бу араларда вакыт кысан, скважинаны үзләштерү чоры, үзең беләсең, тегесе кирәк, бусы җитми, — итенгәләп, Сәет янын-нан тизрәк ычкыну ягын карый.

Башына зур бәла төшкән кебек уйланып, борчылып бер атна-лар йөрде Габдерәхим. Ахырда язарга дигән карарга килде.

Иртәгесен автовокзалга килгәндә газетага пөхтә итеп төрелгән рекомендация Габдерәхимнең кулында иде инде. Ул аны төн уты-рып, юлын-юлга, хәрефен-хәрефкә китерергә тырышып, матурлап язды. Мондый зур эштә ашыгырга, кабаланырга ярамый. Рекомен-дация биргән кешесенә рәнҗерлек булмасын егет...

Сәетне эзләп вокзалга керсә, ни күрсен: партоешма секретаре Селиванов тактага белдерү ябыштырып тора. Көн тәртибендә: Сә-етне КПСС членлыгына кандидат итеп алу мәсьәләсе.

Габдерәхим, ни әйтергә белми аптырап, кулындагы язуларын Селивановка сузды.

— Мин аңа рекомендация китергән идем...

— Ул алды инде, — диде секретарь, һаман үзенең белдерүе бе-лән булыша биреп.

— Ничек алды? Кем бирде?

— Шулай. Бирделәр. — Аннан кисәк кенә борылды да: — Бү-ген җыелышка килергә онытмассың бит, Габдерәхим Муратыч? — дип сорады.

Җыелышта Сәетне яклап берсүзсез кул күтәрде Габдерәхим.

# ОЛЫ МӘХӘББӘТ, ЯКТЫ МОҢ ҖЫРЧЫСЫ

Чыңгыз Айтматовка 50 яшь... Гаҗәбрәк тә, сәеррәк тә...

Гаҗәп, чөнки әсәрләре белән инде күптәннән бирле дөньякүләм дан казанган мәшһүр язучы, халыкара масштабтагы җәмәгать эшлеклесе, Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое Чыңгыз Айтматов өчен бу сан аз кебек.

Сәеррәк, чөнки күп милләтле, күп тармаклы совет әдәбиятына ялкынлы яшьлек тематикасы, саф мәхәббәт, дәртле моң белән килеп кергән һәм күңелләребез түрендә урын яулап алган сердәшебез, фикердәшебезне олыгайган ир агасы итеп күз алдына китерүе читенрәк. Әгәр аның «Беренче мөгаллим», «Гүзәлем Әсәл» повестьларында кеше яисә җәмгыять яшьлеге үзәктә торуын, ә «Бәхил бул, Гөлсары», «Анам кыры» әсәрләрендә катлаулы тормыш мәсьәләләре яшьләрчә дәртлелек, яшьләрчә ялкын белән яктыртылуын исәпкә алсак, әлеге сәер хис тагы да көчәя төшә.

«Ак пароход»та исә әдип тормышка, дөресрәге, бу кырыс тормышның «мәңгелек көрәш мәйданында» барган гүзәллек һәм явызлык бәрелешенә саф күңелле нарасый бала күзлегеннән карап хөкем чыгара.

Дөнья проблемаларына бала күзе белән карау... Искә «Җәмилә» повесте, андагы хикәяче Сәетнең мәхәббәт һәм тормыш хакындагы кичерешләре, хөкемнәре килеп төшә. Очраклымы бу? Бер уйласаң, мәхәббәт «четерекләре», матди тормыш тудырган әхлакый конфликтлар хакында тәҗрибәле ир-егет яисә акыл чарлап хикмәт туплаган аксакал гаделрәк тә, дөресрәк тә хөкем чыгарыр иде сыман. Ләкин Айтматов хаким итеп ир агаларын түгел, ә сабый балаларны сайлый. Чөнки бу — тормышка нарасыйлар күзе белән карау — иҗаты яшьлек мәхәббәте кебек саф, тормышны да саф итеп күрергә теләгән, үзара мөнәсәбәтләрдә башкалардан да сафлык таләп иткән әдипнең иҗади үзенчәлеге.

Гомумән, Чыңгыз Айтматов әсәрләрен аерым-аерым укыганда да, аның иҗатына тулаем бер караш ташлаганда да күз алдына таштан-ташка сикереп ага торган чиста сулы тау елгалары килә. Күз яшедәй мөлдерәмә суын учларыңа алып карасаң, уч төпләреңнең һәр җөе, һәр күзәнәге тагы да ачыграк күренә... Эчеп җибәрдең исә күңелләрдәге дәрт-хәсрәт ялкыннарына шифалы яңгыр яугандай була...

Язучының беренче әһәмиятле, автор иҗатында төгәл бер этапны тәшкил иткән «Җәмилә» повесте беренче мәртәбә русча тәрҗемәдә басылып чыкты. Шуннан, Луи Арагон каләме аша узып, французча басылды; бер-бер артлы тагы күп телләргә күчерелде. Фикер алышуга төрле халыклар, төрле илләр вәкилләре катнашу нәтиҗәсендә, «Җәмилә»нең чын әһәмияте икърар ителде.

Яки «Ак пароход» мисалын алыйк. Бу әсәр тирәсендә барган чын иҗади бәхәсләргә кемнәр генә катнашмады да, фикер алышулар нинди генә телдә яңгырамады! Һәм шунысы характерлы, кыргыз язучысының кыргыз тормышына багышланган әсәрләре хакында сүз барган чакта, фикер үзәгендә бер милли культура күренеше яисә бер милли әдипнең табышы яки югалтулары түгел, бәлки барыбыз өчен уртак мәсьәләләр торды. Чыннан да, Җәмилә — Данияр һәм Җәмилә — Сәет мәхәббәтләре хакында укыган вакытта без үзебезнең саф тәүге мәхәббәт яисә чын сөю хисләребезне яңарттык. Тулганай ананың уй-хисләре, шатлык-хәсрәтләре белән уртаклашканда күз алларыбызда мәрхәмәтле әбиләребезнең, газиз аналарыбызның моңлы йөзләре балкыды. «Ак пароход»тагы малай фаҗигасен дә үз хәсрәтебез кебек якыннан кичердек, аның язмышына битараф кала алмадык. Бүген дә битараф түгелбез!..

Шулай итеп, Чыңгыз Айтматов безнең өчен кабатланмас кыргыз язучысы сыйфатында да кадерле; әсәрләрендә барчабыз өчен гомум мәсьәләләрне күтәрүе белән барыбызга уртак әдип.

Чыңгыз иҗатында актив кулланылган әдәби чараларның берсе — ул язучының өледән-әле фольклорга, бигрәк тә миф һәм риваятьләргә — халык күңелендәге якты моңнарга мөрәҗәгать итүе (моның яңа үрнәкләрен аның «Диңгез яры буйлап йөгерүче Ала эт» әсәрендә дә күрәбез). Халык иҗаты материаллары, әлбәттә, сурәтләнә торган тормышны колоритлы, халык рухын исә калкурак рәвештә гәүдәләндерүгә дә ярдәм итә. Бу җәһәттән дә фольклорның профессиональ әдәбиятта тоткан урыны кечкенә түгел. Әмма Айтматов өчен халык иҗаты мотивлары төрле катлаулы мәсьәләләрне пространство киңлегендә дә, вакыт колачында да карарга хезмәт итә. Фольклор материалы аның өчен милли орнамент — бизәк кенә түгел. Чөнки, автор инануынча, фольклорда, мифта «кешелек рухының тәүге яратылыш поэзиясе, аның ирлеге һәм өметләре гәүдәләнә». Мифлар, риваятьләр борынгы кешеләрнең аңнарын, дөньяны танып-белүләрен генә чагылдырмый, бәлки «халык хәсрәтенең, халык газабының канлы елъязмасы булып та хезмәт итә». Шуңа күрә бүгенге әсәрләрдә сурәтләнә торган халыкның язмышын, рухын, хәзерге халәтен, омтылышларын аның узганыннан, шул чордан калган истәлекләреннән башка аңлавы мөмкин түгел. «Әгәр без Гомерны аңлый алмасак... — ди язучы бер бәхәс уңае белән, — населлэребез дә безне аңламаячак». Димәк, узган белән бүгенгелек һәм киләчәк янәшә, хәтта бергә яши. Менә шушы таләпнең органик рәвештә тормышка ашырылуы Чыңгыз Айтматов әсәрләренең заманча рухын, бүгенгелек көчен, хәтта аларның гел киләчәккә омтылган булуларын тәэмин итә дә инде!

Язучының тарихка, халык иҗатына, шул серле дөнья аша халык рухына юл эзләвенә бер мисал рәвешендә «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» исемле әсәрен күрсәтергә мөмкин. Дөрес, ул әле төгәл басылып чыкмаган. Ләкин аның инде кыргызча басылып чыккан, хәзер татар укучылары игътибарына тәкъдим ителә торган өлешеннән дә (ике өзектән) Чыңгыз Айтматовның нинди мәсьәләләр күтәреп, аларны ничегрәк хәл кылырга омтылуын аңлавы читен түгел.

Әсәрдә сүз XVII гасырда кыргыз халкы башына ишелеп төшкән зур бәла-казалар: канлы җоңгар яулап алулары, явыз килмешәкләргә каршы атка атланган ил уллары, аларга көч биргән халык җырлары — дастаннар һәм, ниһаять, дастанчылар хакында бара.

Ләкин әдип мәсьәләне хәл кылганда вакыйгалар бара торган тар конкрет даирә белән генә чикләнми. Бер төбәктә барган хәлләрне бәяләр өчен ул очар кошлар биеклегенә менә, алай гына түгел, бәлки күчмә кошлар белән бергә илләр гизеп, тасвирлау объектларына зур биеклектән дә, киң пространстводан да карый.

Дөрес, кеше һәм күктәге «ирекле кош» мотивы, яки җирдәге кешенең күктәге очар кошка карап уйланулары төрле халыклар авыз иҗатында да, профессиональ әдәбиятларда да еш очрый. Уңышлы үрнәкләрнең берсе сыйфатында Расул Гамзатов сүзләренә язылган торналар хакындагы мәгълүм җырны атарга мөмкин. Кеше күктәге кошка карап фәлсәфи фикер йөртә, үзенең тормыштагы, көрәш мәйданындагы урынын билгели. Әмма Чыңгызда мәсьәлә икенчерәк, хәтта беркадәр көтелмәгән планда карала: әдип үзе кош булып күккә менә, укучыларга да күктә канат кагып, каты җилдә «канат кайрап очуны» тойдыра. Язучы гына түгел, укучы да җирдә барган вакыйгаларга шул биеклектән торып бәя бирә...

Мотивны автор кыргыз халык иҗатындагы мәгълүм сюжеттан алган. Ләкин ул аны, кем әйтмешли, «түкми-чәчми генә» күчерми, бәлки профессиональ сәнгать югарылыгына күтәреп эшкәртә, яңа рух, бөтенләй икенче эстетик юнәлеш бирә. Бер карасаң, борынгы мотив, иске чаралар монда. Икенче яктан баксаң, гаҗәеп нечкә яңарту да бар. Мәсәлән, «яхшы-яманы бергә укмашкан, шул кадәре зур хәятны кочагына сыйдыручы әлеге җир дигәнең шушымы?» Бу сорауның Әфлатуннар, Локманнар чорындагы хакимнәр тарафыннан да әйтелгән булуы бик мөмкин. «Иксез-чиксез галәмдә япа-ялгыз торучы, адашкан дөя бутасы (баласы) шикелле бүзәреп кенә күренүче шул нәрсәме?» — җир шарына карата, ерактан торып, мондый образлы тасвирлауны очар кошлар биеклегенә менгән язучы түгел, бәлки космик очышлар чоры рәссамы бирә ала. Кечкенә генә детальләрдә дә чал тарих хикмәте белән өр-яңа бүгенгелек янәшә яши...

Гомумән, Айтматов фольклор материаллары белән иҗади, кыю гамәл итә. Аңар фольклорның детальләре түгел, рухы, эчке җегәре, үзе әйтмешли, халыкның ирләрчә горурлыгын һәм өметләрен гәүдәләндергән асыл төше әһәмиятле. Шуңа күрә аерым детальләр Чыңгызда танымаслык булып үзгәрә. Мәсәлән, чынбарлыкта ана маралда (янсә боланда) мөгез булмый. Ә менә «Ак пароход»та «кыргыз анасын» гәүдәләндергән марал исә тармак-тармак мөгезле. Нәтиҗәдә мифологик сер белән өртелгән кабатланмас сурәт туа, мотивның сәнгатьчән ышандыру көче исә тагын да көчәя төшә. Мондый кыю алымнар «Әйләнеп кошлар кайтканчы...» әсәрендә дә нык сизелә...

Ләкин бигүк алга узып китмик әле, чөнки автор әсәр өстендә эшләвен дәвам итә. Димәк, аның бу катлаулы тарихи полотносын без бөтенләй күтмәгән, күз алдына да китерә алмаган чаралар белән баетып, ихтималы уйга да килмәгән нәтиҗәләр белән тәмамлавы бик мөмкин. Шуңа күрә юбиляр хакындагы бу сүзне аның адресына юнәлтелгән бихисап күп изге теләкләр һәм чикләнмәгән яңа зур өметләр белән тәмамлыйсы килә.

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ.**

## Чыңгыз Айтматов

# ӘЙЛӘНЕП КОШЛАР КАЙТКАНЧЫ...

Хәсрәтләрең үз өстемә алаем,
Юл караем, сабыр итче, ата йорт...

Алыкол.

Табигатьнең кодрәте инде — ниндидер бер хәбәр килгән төсле, билгеләнгән көне, тиешле сәгате җиткәч, канатлылар күч булып, башка якларга очып китәләр. Һичкайчан үзгәрми торган бер гадәт, гаҗәеп тотнаклы бер канун бу...

Кыш буе Эссе Күлгә сыенып җан саклаган казлар, үрдәкләр менә хәзер — яз башлангач — ерак якларга, төньяк тарафларына китәргә җыеналар. Күлне тирәли кысрыклаган тауларның ышык җирләрендә дә, ачык түшләрендә дә калын кар, күгелҗем боз катлаулары һаман кимемичә ята бирүләренә карамастан, теге биек-биек кыяларда ачы җилләр сызгырып, караңгы чырайлы салкын болытлар хөкем сөрсәләр дә, бүген яисә иртәгә ерак-ерак юлга чыгасыларын сизеп, кошлар бергә җыелалар, өер-өер булып төркемләнәләр, кыйгак-кыйгак итеп сөйләшәләр, аңлашалар. Бер ишеләре тау итәге буйлап, икенчеләре күл өстен иңләп очалар, ярышалар — шулай ыгы-зыгы килеп канат чыныктыралар, ерак юлга әзерләнәләр.

Аккошларның кыйгаклаулары да «бүген-иртәгә, бүген-иртәгә» дигән сыман язның тонык, җилектергеч саф һавасында әллә ничек серле, дәртле яңгырыйлар.

— «Бүген-иртәгә, бүген-иртәгә!»

Бүген яисә иртәгә, насыйп булса, күктә зур сәяхәт башланачак...

Тау сыртларындагы карларның җуела барулары кошлар өчен яз сәфәре башлануга тагы бер ишарә. Ләкин күк буйлап биек-биектә никадәр очсалар да, кунасы урыннары бары бер җир генә бит. Алда — катлы-катлы булып күккә таба сырышкан таулар арасында — Буом капкасы, аннан ары, төньякта, Тугызком — киң Талчөй үзәне. Анда кар тәмам җуелып бетеп, җир яшәрә башлаган инде. Аннан соң иксез-чиксез киң, иркен сахралар. Менә шундагы эреле-ваклы язгы күлләр күчмә кошлар өчен әзрәк туктап тамак ялгап алырга да, хәл җыеп китәргә дә иң җайлы, гел әзер урыннар. Моннан соң Сырдәрья буйлап очып, Арал диңгезендә бер туктап көч җыячаклар, аннары тагы көне-төне очаоча, сагындырган олуг Идел дәрьясына җитәчәкләр. Хәйран Идел, күктәге йолдызларның агымы сыман, аның башы кайда да, төене белән очы кайда?! Кошлар килеп җиткәнче бу хан-дәрьяның үзәне бозлы ташкыннардан арчылачак. Һәм ул аларны киң, иркен-имин кочагын ачып, җылы каршылаячак. Иделгә койган елгаларның санын кем белә? Ярлары буйлап никадәре киң болыннар, тын тугайлар, калын камышлы сазлавык, мөлдер сулы инешләр... Суы да мул, ризыгы да мул...

Күз ачып йомганчы якты җәй узып, яшь бәбкәләр дә үсеп җитеп, аларның канатлары катып өлгерәләр. Яңа үрчемнәрен ияртеп, кошлар

салкыннар төшү белән тагы Эссе Күлгә кайталар. Сагынып, зар-интизар булып кайталар. Сагынмаган кая! Салкын кышка исе дә китмичә җәйрәп ята торган тау диңгезе — тыңмас Эссе Күлне табигать гүяки бары шуның өчен — авыр кыш уздырып нәсел сакларга кошлар килеп сыенсын өчен генә яраткан сыман. Кырыкка төрләнеп ажгыра торган кышкы бураннарда аның тын култыкларында ышыкланып, көн ачылып, һава тынуга кымырҗып кына ятучы суның өстен каплап, киң көтүлекләрдә утлап йөрүче терлекләр сыман иркендә, иминлектә яши бит бу кошлар! Бу мәрхәмәтле күлнең хикмәте дә әйтеп бетергесез — бөтен җир-суларның барсы да бозга әйләнеп, шәфкатьсез салкын ташка әверелгән чакларда да ул күгелҗем дулкыннарын биетә-биетә нурланып, сихри төсләр белән төрләнеп, тыныч кына ята бирә бит!

...Шулай, тагы бер кышны баштан кичереп, каз-үрдәкләр ерак юлга китәргә җыеналар. Көзен үрчеп, күбәеп, янә кире кайтырлар алар. Кышны уздыргач тагы еракка китәрләр... Дөнья дигәнең менә шул гел бөтерелеп тора торган хәрәкәттән гыйбарәт икән ләбаса... Хәят та бит менә шундый тынгысыз хәрәкәттән тора, бер-бер артлы алмашып, бихисап күп көннәр уза, туктаусыз уза. Шул исәпсез көннәрнең берсе. Тарих төшенчәсе белән унҗиденче гасыр. Адәм өчен гомернең бер мизгеле. Кошлар өчен язгы сәфәр алды...

Күл бүген ял иткән сыман изрәп кенә тып-тын ята. Кымырҗып, беленер-беленмәс тирбәлгән вак дулкыннар өстендә әллә нинди серле чаткылар чәчрәтеп, кояш нурлары биешә. Күлнең башы да, ахыры да бик ерак; әйләнә-тирә буш, тын; ниндидер эш белән шөгыльләнгән кешеләр дә, утлап йөрүче терлекләр дә күренми. Бөтен тирәне текә таулар сырып алган, уртада — су, өстә — күк. Һичнәрсәгә исе китмәгән, бөтенесеннән хәбәрсез яткан ваемсыз дөнья; тыныч, имин дөнья. Бары вакыт-вакыт очып узган каз-үрдәкләр генә күзгә чалынып кала, бары шуларның гына өзек-өзек тавышлары яңгырый.

Баядан бирле яр өстендәге куаклыкта киселгән коры-сарыларны үгезгә төяп мәш килгән тире чабаталы, кайры тунлы ике яшүсмер малай бу ваемсыз тыныч дөньяны менә хәзер генә күргән, аның хозурын бары шушы мәлдә генә тоя башлаган шикелле әйләнә-тирәгә карап сокланып торалар.

Йөк төялгән үгезләрен торган җирендә үк калдырып, су буена, нәкъ сары комлыкка килеп бастылар. Күлнең күңел тойгыларын оетырлык серле тынлыгына исләре китеп, шулай озак-озак сүзсез тордылар.

— Балтаң кайда? — диде олырагы, үзе биленә кыстырылган балтаны капшап куйды.

Икенчесе, олысына охшаган коңгыр чырайлы юантык малай, буы чыгып торган тирле бүреген салып, «ә-әнә, тегендә», дигәндәй үгез тарафына ишарәләп күрсәтте.

— Югалтасы булма, кара... — диде абыйсы эре генә, учын күз өстеннән алмаган килеш. — Күл бүген кояш кебек ялтырый...

Малайлар тагы беравык шулай тын тордылар, аннары тубык тиңентен ком кичеп, үгезләре калган төшкә таба юнәлделәр. Нәкъ баш очларыннан һава сызгыртып казлар төркеме очып узды. Озын муеннары төз сузылган, канатлары җилпенгән саен һава киселеп-киселеп киткән сыман була; түбәннән очканга коңгыр түшләре, ак бөерләре, кып-кызыл тәпиләре бик ачык күренә. «Әй-әй!» — диеп, малайлар да куллары болгый-болгый, куып җитәр төсле җилкенеп, казлар очып барган тарафка йөгерделәр. Кечерәге, томырылып чапкан килеш, иске бүреген башыннан йолып алып, казлар артыннан күккә чөеп җибәрде. Җитмәде, әлбәттә. Шулай да ул бик сөенде. Үзенең башы карбыз кебек түптүгәрәк, күзләре елтырап яна; шабыр тиргә баткан, ком ерып йөгерүдән тыны кысылган.

— Иләман, — диде еш-еш сулап янәшә килүче абыйсы, — синең дә шундый канатларың булса, нишләр идең соң?

— Минме? Мин... — очып барган кошларга төбәлеп караган Иләман җавап бирә алмады.— Ә үзең?.. Син үзең нишләр идең соң?

— Ә мин әкияттәге алтын лачын шикелле томырылып очып, Кара шәһәрдәге ханның кызы Айганышны алып качар идем.

— Ва-ай әкәмәт... — энесе мыскыллап көлергә дә, гаҗәпләнеп сокланырга да белмәде, черт иттереп төкереп куйды.— Ул нәрсәгә хаҗәт соң?..

— Ханның кызын алсаң, җүләр, үзең дә хан буласың бит! — дип, абыйсы эре кыяфәт белән аңлатма бирде.

Иләман сүзнең асылына барыбер төшенмәде:

— Булмасам, ни булган ди!.. Әгәр минем канатым булса иде, мин... — малай маңгай тирен сөртеп алды, — хәзер үк Талчөйгә очып барып, Куйчыман абыема ияреп, уйратлар белән сугышыр идем.

— Кара моны, сугышам дигән була бит тагы! — дип, олы малай аны үчекләргә тотынды. — Абый юлга чыккан чакта җиңгәмнән биш тапкыр уздырып елап, аның артыннан кем йөгерде соң? Тукта дигән сүзгә колак салмыйча, хатыннардан арттырып үксүче син түгелме соң?! Сугышыр идем, имеш!..

— Бер мин генә еладыммы әллә? — Иләман кызарып, бүртенеп чыкты.— Әтием дә елады... Ә башкалар еламадылармыни?! Куйчыман абыем үзе дә елап җибәрде!!

— Аны син елаттың, синең елавыңа карап, түзә алмыйча елады ул!

Иләман җавап бирмәде, бәхәстә җиңелгән кеше төсле түбән карады.

— Әгәр син булмасаң... — дип, Торман олы агалары Куйчыманны акларга теләгән сыман тагы бер кабатлап куйды. Шулай да, энесенең мескен кыяфәтен күреп, әлеге хатын-калач зар елап, ир-егетләрне сугышка озаткан шомлы көннәрне исенә төшереп, үзе дә юашланып калды, авыр итеп көрсенде.— Мин дә сугышка барырга теләгән идем, тик яшең җитмәгән әле дип әйттеләр...

— Әйдә, кайтыйк инде...

Абыйсы эзләреннән басып атлый-атлый юантык малай күңел түрендәге уен әйтеп куйды:

— Әнә, әтием сөйли бит, борынгы заманнарда безнең ише малайлар да яуга каршы сугышка барганнар дип...

— Ул бит борынгы заманда, — Торман үкенүле кыяфәт белән көрсенде.

— Ә безнең борынгылардан нәрсәбез ким соң?

— Әтәчләнмә әле, җенемне чыгарып!..

— Җен синдә генәме әллә?!

Ике малай тагы бер-берсенә акаеп карап тора башлады:

— Бар әйдә алайса! Чап Талчөйгә карап — уйратлар сине генә көтеп торалар ди, бергә-бер сугышырлык батырлары килмәгән дип!..

— Барырмын да! — дип, Иләман да тиз генә бирешергә җыенмады.

Утын төялгән үгезне берсе җитәкләп, икенчесе арттан әйдәп, ике малай юлга төштеләр — тау култыгындагы кышлак-авылларына таба юнәлделәр. Төшке кояштан эри башлаган карлы юлдан үгез тая-тая көчкә генә атлый иде. Бер кадәре вакыт үгез артыннан тын гына барган Иләман тагы телгә килде:

— Торман, — диде ул, абыйсына ишетелерлек итеп, — сөңге тотып сугышырга ярамасак та, Талчөйгә олау маллары илтә алыр идек бит, әйеме?

— Нинди олау маллары тагы?!

— Дөяләрне әйтәм! Яуга китүчеләр өчен азык төялгән дөяләрне...

— Ул дөяләр үзеңне чәйнәп ташласалар?..

— Чәйнәми торсыннар әле!

— Ике чәйнәрләр дә бер генә йотарлар...
— Йотмый торсыннар әле!
— Әллә синнән куркыр дисеңме? Синең төшеңә Манас керүен алар кайдан белсен ди!

Ачуы дөрләгән уттай кабынган Иләман, тез тиңентен кар кичә-кичә, абына-сөртенә йөгереп, абыйсы алдына чыкты да, тегенең якасына ябышып, зәһәрле пышылдады:

— Әгәр тагы да сиңа серемне әйтәсе булсам, кадалып китим, йәме?!

Энесенең җиңелгән чакта да йодрыклашып алырга күп сорамый торган гадәтен яхшы белгән Торман бу юлы артык карышмауны хәерле тапты:

— Ярар, бетте, бетте, шаярдым гына бит, җүләр... — дип, елмаерга ашыкты. — Сереңне ят кешегә әйтмим ләбаса... Карале, ул төшеңне абыйның үзенә сөйләп, аңардан юратып карарга кирәкмәс микән? Моңлының хәлен зарлы гына белә диләр бит, бәлки мәгънәсен әйтер...

— Әллә куркыр дисеңме мине? Сөйләрмен! Кайтыр юлына каршы чыгып, төшемне бәйнә-бәйнә сөйләп юратырмын, менә күрерсең, онытма, йәме!

— Тәңре боерса диген, тиле, насыйбы булып, исән-имин күрешсәк диген, — дип, Торман тәҗрибәле картлар шикелле, үрчәләнгән энесенең сүзләрен бүлдерде.

— Әйе, боерса... — диде Иләман эчтән генә пышылдап.

Аталары Сәңербайның һәр вакытта «тәңре боерса», «насыйп булса» диюләренең буш сүз түгеллеген, тормышта аларның үз урыны барлыгын менә хәзер генә аңлаган, ләкин шулай соң аңлауларыннан бераз курыккан төсле, малайлар эчтән генә аптырашып, астыртын гына шомланып, өнсез-тынсыз бардылар. Әйе, бары насыйбы булып, исән-имин күрешсәләр генә. Әгәр башкача килеп чыкса?..

Күк үгезне җитәкләгән малайлар шулай өнсез-тынсыз атладылар. Әлеге сүзләрнең чын мәгънәләренә алар тәмам төшенеп җитмәделәр, әлбәттә. Мәгәр нәкъ менә шушы мизгелдә, күк үгезгә утын төяп барган чакта, алда әллә кайларда әллә нинди язмышлар булуын, кешеләрдән өстен әллә нинди көчләр ярдәме белән шул язмышлар төрлечә хәл кылынуын сизеп, тоеп, үзләренчә юрап, өмет итеп, шомланып, төеннәре чишелмәс уйларга төренеп бардылар алар...

Моннан дүрт көн элек Аксолтан-кашка[1] җитәкчелек иткән Күл буе кабиләләренең чирү-яраннары, бер зур «кул» булып[2], Буом тарафына юнәлгәннәр иде. Рәт-рәт булып тезелгән хисапсыз күп кораллы җайдаклардан соң йөк төялгән атлар, дөяләр кәрванын каулап кушчылар төркеме дә юлга чыкты. Иләманның «олау маллары» дигән сүзе менә шулар хакында иде. Торман һәм Иләманның олы агалары Куйчыман, авылдагы тагы башка ир-егетләр шул көнне атка атланып, зар инрәп елаучы хатын-кызлар, дога укый-укый гөрләп фатихалар бирүче олылар белән саубуллаша-саубуллаша, иләсләнеп аяк астында буталучы малай-шалайлар төркемен беркадәр ара үз артларыннан ияртеп, хәтәр юлга чыкканнар иде. Әйтелеп бетмәгән изге теләкләр, бирелеп өлгермәгән ихлас фатихалары булган ак сакаллы картлар да шактый җиргә хәтле ияреп бардылар, күңелдәгеләрнең бөтенесен дә бәйнә-бәйнә әйтә алмаулары өчен үкенеп бетә алмадылар; тояклар белән җир уеп ат биетә-биетә, хәтәр сәфәргә чыккан чирүләр артыннан куып җитә алмаулары өчен әрнеделәр, калган теләк-фатихаларын, акыл-киңәшләрен арттан баручы йөк кәрванындагыларга аманәт итеп тапшырдылар...

Йөк кәрваннарындагы кешеләрнең күпчелеге исә моңарчы үзендә куй көтеп йөрүче буйчанрак малайлар, әле өлгереп җитмәгән яшь егет-

[1] Кашка — берничә кабиләнең башында торган өлкән би.
[2] Кул — борынгы төркиләрдә зур чирү берләшмәсе, армия.

ләр яки сакаллары агара башлаган картрак ирләрдән гыйбарәт иде. Башка вакытларда аксакаллар аларга исәнме-саумыдан артыкны әйтеп тә тормаслар иде, ләкин бүген менә шулар да әллә ничек батыр, солтанатлы булып күренделәр. Хәтта шуларның атлары, дөяләре дә ничектер күңелгә бик якын тоелдылар — аларның маңгайларыннан сыйпадылар, муеннарыннан кочтылар:

— Исән барып, исән кайтыгыз, малкайлар, аякларыгыз җиңел булып, ак юл белән сөенечле җиңү хәбәрләрен алып кайтыгыз! — дип, күз яшьләре аша ялвардылар.

Менә шуннан бирле яуга китүчеләрдән бернинди хәбәр юк. Бүген бишенче көн инде. Нәкъ шул көнне үк, ягъни Күл буендагылар яуга атлаган көнне, Атбашы ягыннан алып, Кучкар-Ата белән Җомагол кыргызлары да Шамшы үткеле аркылы Талчөйгә таба сәфәр чыккан дигән хәбәр ирешә. Ул тарафларда оешкан чирү кулына, имештер, Саяк-Чирекләрнең баш бие Бурҗук-кашка үзе җитәкчелек итә икән. Талчөйдәге Чуңбагыш, Күкугъыл, Сарыбаш дигән зур кабиләләр дә хәрәкәткә килгәннәр. Аларның баш бие мәшһүр Субатай-кашка.

Ил өстенә үрмәләп килүче уйрат-җоңгарларны кыргыз җиренә кертмичә, баштан ук маңгайларына сугып, чигереп ташларга кирәк дигән фикерне менә шул Субатай-кашка әйткән икән. Ил-йорт өстенә бәла-каза килә, бергә җыелыйк, кыргызлар, көчне бер кулга туплап, бердәм булыйк дип, халыкка оран салучы да шул икән. Субатай-кашканың Ширбәк, Асылбәк исемле менә дигән ике баһадир улы бар диләр, чирү кулларына шулар баш, имеш. Ерак таластагылар каршы таудан тиз генә ашып килә алсалар, шул Субатай-кашкага кушылачаклар икән. Тагы әллә ни хәтле имеш сүзләр...

Бөтен уйратлар бергә җыелганлыктан, җоңгарларның чирүләре исәпсез-сансыз икән диләр. Яулап алган, буйсындырып торган җирләренең дә иге-чиге юк, имеш: Алтай-Хангайлардан башлап, юлдагы барлык илләрне, бөтен халыкларны көч белән үзләренә буйсындырганнар, баш имәгәннәрен канлы кылычтан кичереп, кырып-җуеп ташлаганнар, җирләрен, мал-милекләрен басып калганнар. Шулай кырып, себереп, йотып, мәрхәмәтсез ут шикелле юлда очраганның барысын да ялмап, көчәйгәннән көчәеп, коточкыч янгын төсле ябырылып килә диләр ул җоңгарларны. Башлыклары Элә буендагы өләт кабиләсеннән чыккан Бока-нуйон, аның улы Миргән-хунтайшы дигән кансызлар, тагы әллә никадәре зайсаннар икән. Көмеш акча суга диләр, әгәр берәүнең кулында кытай акчасы күрсәләр, шунда ук ул кешенең башын чабып өзәләр, имеш...

Менә алар хәзер казакъларның, кыргызларның җирләрен яулап алырга җыеналар икән. Узган елы уйратларның гомум корылтаенда казакъ-кыргызларның җирләрен әлеге өләт улусына бүлеп биргәннәр ди. Димәк, бу җирләрнең барсы да олуг Җоңгар дәүләтенең бер өлеше булырга тиеш икән... Әнә казакъларны ничек пыр туздырып кырып ташладылар... Каршы торырлык көчләре калмагач, илбасарлар белән очрашудан баш тартып йөриләр ди ул казакъларны. Ярый әле, аларның җирләре киң... Хәзер нәүбәт кыргызларга җиткән икән. Әле Бока-нуйонның узынган улы Миргән-хунтайшы, имеш, «шул кызы талак бурутларның[1] ташларын талкан итеп, ирен — кол, хатынын — көң[2] кылмасам, атым үчсен!» — дип әйтә икән ди.

Шулай имеш-мимешләрнең чиге юк... Хәер, эшкә ярарлык ирләрне яуга озатып, авылда калган карт-коры, хатын-калач, бала-чаганың авызыннан мондый имеш-мимешләрдән башка нәрсә чыксын тагы?!

---

[1] Бурут — кыргызларның калмыкча исеме.
[2] Көң — кол хатын-кыз (кәнизәк).

Котлары алынып курыккан халыкның ятса да, торса да уйлаганнары гел шулар, көткәннәре исә Талчөйдән бер хәбәр иде. Тик Күл буена шылт итеп бер нәрсә дә ишетелмәде. Бүген бишенче көн инде. Ни булды, ни булачак, — беркем бернәрсә белми. Уйратлар кайда? Кыргызлар нишлиләр? Очраштылармы, юкмы?.. «Я тәңрем, үзең кулла! Ата-бабаның әрвахы, үзең мәдәт бир!» — дип, өрәкләре очкан кешеләр юл күзәтәләр, берәр җайдак-мазар күренмәсме дип, ерак-еракка төбәләләр, сөенче сораган тавыш яңгыравыннан өметләнеп, колакларын тегәләр; тукта, яман хәбәр килеп, ил өстен елау-сыктау капламагае дип, шомланып калалар, шунда ук уй тезгенен яхшы якка таба тарталар; ләкин җиңелеп калуның ихтимал икәнлеген искәреп, ил өстенә киләчәк бәла-казаларның күләмен чамалап, коелып төшәләр. Авыр уйлар җилкәдән басып, йөрәкләр сызлый, нигә соң һаман хәбәр юк дип, күңелләр шомлана. Берәүләре шулай хәвефләнәләр, куркалар, уй-хәсрәтнең очына җитә алмыйча газаплананалар; икенчеләре исә, болай соңгарулары бәлки хәерлегәдер, яулар бер-берсен күзәтеп, ихтимал, сугыш башламаганнардыр әле дип, юанып, үзара юатышып йөриләр...

*

* *

Әлеге икс яшүсмер Күл буенда кышлый торган Бузуй ыруының Туры Айгыр дигән авылыннан иде. Аларның әтиләре Сәңербай кирәгәче[1] әүвәл бик ачык чырайлы, көр күңелле җор кеше иде, тик соңгы елларда йөрәк чиренә сабышты, шуңа күрә хәзер бердә сау, бердә сырхау булып, нурсыз чырай белән эленеп-салынып көчкә генә йөри. Шулай да, һөнәрле үлмәс дигәндәй, ил эчендә абруен югалтмыйча, ятдошманга сер бирмичә, үз көнен үзе күреп, үз өенә үзе баш булып килә әле. Үзеңнән көч киткәч, әгәр җүнле булсалар, эшеңне балаларың дәвам итәләр. Сәңербай кирәгәченең уллары да өметле генә башлап җибәргәннәр: яшьтән үк барысының кулы эшкә күнегеп үсте, шуңа күрә хәзер ипле бармаклары агачка ябышып кына тора. Шулай булуы табигый да, чөнки боларның ата-бабадан кала килгән кәсепләре агаччылык, ягъни агачтан кирәгә, уык,ияр, утыргыч, аннан калса ыңгырчак, савыт-саба кебек каты-корылар чабып ясау иде. Хәзер дә шул кәсепләре белән көн күрәләр (шунлыктан Сәңербайның исеменә «кирәгәче» дигән койрык тагылып калган).

Бер иске тирмә — махсус остаханәләре. Ил күчкән чакта сәңербайнынылар да, үгезләренә төрле агачлар, озынлы-кыскалы кискәләр белән балта-пычкы кебек әсбапларын төяп, күчкә ияреләр иде. Хәтта тегермән ташы кадәре дәү махсус ташны да дөягә төяп алалар. Сөйләүләренә караганда, яшь чагында Сәңербай кирәгә, уык бөгәр өчен кирәкле әлеге зур ташны бер үзе генә күтәреп, чүгеп яткан дөя өстенә ялгызы сала торган булган, имеш.

Иртәдән кичкә хәтле кулыннан кечкенә балтасы төшмәс. Башкалар ат менеп ил гизгән чакта да, туй-тумалакта күңел ачып, бәйрәм-җыенда сәйран итеп йөргәндә дә кирәгәче башы эштән чыкмас. Кайчандыр берәү аңар: «Сәкә, ходай каргаган төсле балта-пычкыларыңнан аерылмыйсың, аларны кочаклап та ятасың бугай», — дигән икән. Моңа каршы Сәңербай: «Нишлисең, эш бетми бит», — дип җавап биргән. Теге дә чигенергә теләмәгән: «Эшли бирсәң эш бетмәс ул, хуп диеп, башыңны үзең иеп торгач, камыт киертүче күп булыр, үз убалың үзеңә, оста!» — дип әйткән. Шунда Сәңербай: «Әгәр миңа эш чыкмый калса, илгә дә яхшы булмас...» — дип, табышмак белән җавап биргән. Бу нәрсәсе та-

[1] Кирәгәче — тирмәнең агач каркасларын ясый торган оста (кирәгә — киез өйнең агач рәшәткәле стена өлеше, уык — гөмбәз өлеше каркаслары; тирмәнең иң түбәсенә, ягъни төнлегә бар гөмбәз очына «чаңрак» дип әйтәләр).

гы дип, тыңлап утыручылар гаҗәпкә калганнар. Ләкин кайсыдыр бер авылның олы аксакалы, моның хакында ишеткәч, баш кагып: «Әйе, кирәгәче бик дөрес, хикмәтле сүзләр әйткән», — дип, аның фикерен җөпләгән икән. Һәрхәлдә, шушы тирәләрнең барсында Сәңербай ясаган тирмәдә тормаучы бер кеше дә юк диярлек. Дүрт канат кирәгәдән җыелган кечкенә генә куыштан алып, унике, ундүрт канаттан торган, чаңрагына күтәрелеп караган чакта түбәтәең җиргә төшәрлек биек, нәкъ акбашлы таулардай дәү, мәһабәт тирмәләргә кадәр, хәтта кунак өе, ашханә, кияү тирмәсе шикелле махсусларына хәтле — барысы да аның кулыннан чыккан.

Сәңербай кирәгәче менә шундый кеше. Каты кышта авыр йөк астында ябыгып какчаланган алып бәдәнле ата дөя шикелле, кул-аяклары озын, буе биек, баһадир гәүдәле кеше ул. Һәр бармагы буынтык-буынтыклы камышны хәтерләтә. Гомер буе балтасын селти-селти алга таба иелеп утырудан аркасы бөкрәя башлаган. Елдан-ел шул бөкресе зурайганнан-зурая бара. Моны күргән саен хатыны Киртулгауның, ирен кызганудан, йөрәге әрни; аның әле күптән түгел генә сөлектәй сылу, имәндәй таза бәдәнле егет булуын искә төшерә; кешегә ишеттереп әйтмәсә дә, эчтән генә: «И-и бу гомер дигән хәйран нәрсә, күз ачып йомганчы узып та киткән бит!» — дип, көрсенеп куя. Шулай да аның белән уртак уздырган тормышы өчен үкенми ул — картаймас кеше буламыни... Чыннан да, Сәңербайдан тапкан — теге барган җирләрендә котлы урынга ия булып, итәк-чабуы киңәйгән ике кызын исәпкә алмаганда да — менә дигән өч егете ни тора! Аларның олысы Куйчыман иржитеп, кеше рәтенә басты, хатын алды; төпчеге Иләман да күзгә күренеп үсеп килә. Боларның барсы да ана өчен сөенеч кенә, әлбәттә. Егетләр таза-сәламәт, көчле рухлы булып, үз акыллары белән үсәләр. Бигрәк тә Куйчыман атасына охшаган, җиңгәләре аңар «торна егет» дип исем куштылар. Нәкъ атасының егет чагын хәтерләтә: шундый ук дәү гәүдә, сурайган озын буй... Хәер, «сураю» дигәннең дә бер вакыйгасы бар әле. Узган җәйдә шушы авыллар арасында йөрүче бер шалдыр-шолдыр акын булмышы, кымызга исереп утырган чакта, Куйчыманны мактап, ике-өч авыз җыр җырлагач, Киртулгау карчык аңар бер бәрән биреп җибәргән иде. Әлеге җырчы кисәгенең әйткәннәре түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде:

Һай бу егет зурайган,
Буе үсеп сурайган,
Үзе торна аталган,—
Белдегезме, җиңгәләр!
Ул басса — җир калтырый,
Ияр чапса — ялтырый,
Ә кирәгә — шалтырый;
Сәңербайлар ясаган
Тирмә күккә терәлгән,—
Чаңрагына карасаң,
Түбәңдәге түбәтәй
Җиргә төшеп китәчәк!
Илләр гизеп йөрдем мин,
Күп осталар күрдем мин,
Осталыгы ягыннан
Сәңербайга кем җитә?!
Аның улы Куйчыман,
Балтасы шәп көйләнгән;
Тагы да бер һөнәргә
Бу Куйчыман өйрәнгән:

Атадан калган «Манас»ны
Гөрелдәтеп сөйләргә.
«Манас» әйткән чагында
Гөрләп сулар аккандай,
Көче ташый күкрәктә,—
Үзе ерак чапкандай.
Даны китте ян-якка —
Бөтен кыргыз иленә,
Япь-яшь кенә бер егет
Бөтен илгә беленә!
Тайәкәсе[1] Ирәгол,
Манасчының зуры ул;
Шуны яхшы белегез:
Сулы җирдән су чыгар,—
Авызлык чәйнәп чапса ат,
Бәйгедә алга шул чыгар.
Ташып чыккан чагында
Көч атасын танырмы?
Зур манасчы Куйчыман
Безне телгә алырмы?..

[1] Тайәкә — ана яктан ир кардәш.

Без генә түгел, Сәкә,
Үзегез уйлап карагыз,
Манасчы дигән һөнәргә
Ия булды балагыз.
«Манас» әйтер Куйчыман —
Башына бәхет кунган;
Мактамаган кеше юк,—
Даны дөньяга тулган!
Улларының һәрберсе
Берәр һөнәр иясе,
Исән булсын улларың,
Сәкә, сездә үкенеч юк,—
Тагы нәрсә диясе?!
Олы улың Куйчыман,
Уртанчысы ир Торман,
Иң кечесе Иләман,
Анысы да, карасаң,
Ыңгырчак чаба һаман.
Әй Иләман, Иләман,
Син иржитеп барасың,
Базык гәүдә, житү буй,—
Ананда бер баласың.

Әй Иләман, Иләман,
Иркәлидер гел атаң.
Сиңа халык сокланыр,
Килеп житсә бер заман!
Бәхет булса ходайдан
Куйчыманнан калышмас,
Сәкә, синең бу шаян;
Аның да даны чыгар,
Халыктан алкыш явар!
Киртулгау анай, гел телим,
Имин булсын дип шулар!!

Ана күңеле башкача икән: өйдәгеләр «әйдә, әйдә, әйт шуны!» дип шаркылдап көлешеп, күпертелгән мактау сүзләрен шунда ук оныткан булсалар, Киртулгау карчык әлеге такмакларны зур мәгънәле сүзләр кебек кабул кылды — атка атланып китәргә җыенган әлеге җырчы сыман нәмәстәнең алдына ияргә бер бәрән салып бирде: «Авызыңа бал да май, кадерлем, әйткәннәрең килсен!» — дип, сөенечле каударланып йөрде.

Берәүнең сүзне иләк иләгәндәй сиптереп, арзанлы такмаклар такылдавы өчен шул хәтле итенгән әнисен Куйчыман мыскылларга тотынды:

— И-и, әни, эч сереңне дә яшерә белмисең бит ичмасам...

— Балам, нинди сер ул тагы? — дип, Киртулгау карчык аптырап калды.

— Берәү «манасчы» дип керәле-чыгалы мактый башлауга ук бөтенләй сүтелеп төштең бит!

— И-и, кит әле моннан! Ни әйтә дип торам тагы... — Киртулгау карчык чыраен сытты. — Син үзеңне уйлыйсың икән, ә мин әлеге сарыбаш шаяным өчен сөендем: эшкә ярап, күзгә күренә башлаган бит. Ничек әле, ыңгырчак чаба дип әйтәме?.. Сезгә ни, картайган чагымда мине шул төпчегем багачак әле, — дип, Киртулгау һәрбер карт ана сөйли торган сүзләрне, бары шуларга хас уй-теләкләрне кабатлады.

Ул шулай әйтте әйтүен, ләкин чынлыкта исә аның күңелен йомшартып җибәргән нәрсә башка иде — ул Куйчыманның халык тарафыннан чын манасчы сыйфатында кабул кылынуы, шулай итеп, улының аякка нык басып, илгә кирәкле, аның ихтыяҗын үтәргә яраклы зур кеше дәрәҗәсенә ирешүе иде. Бер вакытта да ачып-ярып әйтмәсә дә, күз тиюдән куркып, уй-хыялын яшереп тотса да, ананың ходадан теләгәне бер нәрсә — улы өчен абруй, чын хөрмәт китерерлек игелекле һөнәр иде. Кирәгәченең улына түрәлек дәрәҗәсе, билек шөһрәте сатып алырлык зур байлык каян килсен — ни табып, нәрсәгә ирешсә дә, барсы бер үзеннән, үзенең көче, үзенең һөнәреннән генә булачак.

Карты да шулай уйлады. Куйчыманның бала чактан ук узган-киткән вакыйгалар белән кызыксынып, төрле шәҗәрә-риваятьләр, әңгәмә-хикәятләргә күңел биреп, картлар авызыннан чыккан һәр хикмәтле сүзгә,· гыйбрәтле хәбәргә колак тегеп йөрүен абайлаган ата аның кулын эш белән артык богауламады. Аңардан менәр өчен ат та, кием-салым да кызганмады, бәлки үзе аны халык күп җыела торган туй-мәҗлескә, җыен-бәйрәмнәргә җибәрә торды: «Яле, балам, бер әйләнеп кайт әле, илдә ниләр бар икән, нәрсәләр сөйләнә, ишетеп-белеп кайт». Соңрак, көннәрнең берсендә, яшүсмер Куйчыман, башта каушап-тотлыгып, ан-

нары кызып-мавыгып, Манас хәлләрен сөйли башлагач, ата белән ул арасында бер кечкенә аңлашу булып алды. Остаханәдә гадәттәге эш белән шөгыльләнеп утырган чакта, Сәңербай очлап бетергән уыкны читкә ыргытып, улына карады:

— Кичә кичен энеләреңә Манас хәлләрен әйтүеңне мин дә тыңлап яттым... Нәрсә, үзеңнән чыгарып әйтәсеңме, әллә олылардан ишеткәнеңне кабатлыйсыңмы?

— Әйе, атай, ишеткәннәремне... Бик күп әйтәләр бит аны.

— Шулай шул. Төш күрмәгәндерсең бит?

— Юк, атай, төш күрмәдем...

— Алай икән... Төш күренә диләр иде гадәттә. Хәер, үзеңә кара, тик оятлы гына була күрмә.

— Нәрсә, әллә сиңа ошамыймы?

— Нигә ошамасын ди, булдыр гына... Тик, улым, «Манас» бит ул бик олы нәрсә, әйтәсең икән, бөтен күңелеңне биреп, җиренә җиткереп әйт, уйнап-нитеп кенә йөрисе булма диюем.

— Чын күңелдән әйтәм... Аның турында уйласам гына да йөрәгем әллә нишли. Ирәгол тайәкәмдәй «Манас»ны төгәл белүчеләр күземә әүлия булып күренәләр. Шулардай буласым килә. Тик куркам...

— Алайса син ашыкма. Манасчы булырга бил баглыйсың икән, һәр ишеткәнеңне хәтереңә салып, күңелеңә тукып бар, насыйбы булса, бер дә гаҗәп түгел, тайәкәң Ирәгол бит... Ул да картаеп килә инде, элек дәрья да бер, Ирәгол да бер иде...

Сәңербай тынып калды, аннары кинәт айнып киткән төсле кулына уык өчен әзерләнгән озын колгаларның берсен алды, күнекмеш хәрәкәтләр белән селтәнеп-селтәнеп, аның нечкә башын дүрт кырлы итеп очлады һәм икенче якка ташлады. Яңа колганың очын чаба-чаба, мыек астыннан елмаеп куйды.

— Синең тайәкәң минем кайнагам бит, улым, әгәр кулыңнан килеп, шуннан үчемне бер алып бирсәң... их, хәйран! — дип көлеп җибәрде һәм, сакалын сыйпый-сыйпый шаркылдап, артык түзә алмаган кешедәй ишеккә таба юнәлде.

Болай көлүнең сәбәбе бар иде. Кайчандыр, Киртулгауның алмадай пешеп өлгергән, кызларның гөле булып утырган чагында, аның бөтен тирә-юньгә мәшһүр манасчы агасы Ирәгол белән масаеп, хәттән тыш кәперәйгән туганнары: «Әллә нинди сурайган агач юнучыга биреп җибәрәсе кызыбыз юк!» — дип, Сәңербайны байтак кимсеткән көннәр дә бар иде. Дөрес, ул вакыйгалар күптәннән тарихка күчте инде, ярлы кияү бәхеткә ирешеп, үз аякларына басты, элеге рәнҗүләр дә бөтенләйгә диярлек онытылып өлгерде. Ләкин ул вакытта Сәңербайга гаять авыр булган иде: кызның туганнары берниндн әман-сәламгә җавап бирмичә, нәсел-нәсәбе кем соң аның, дип, төксәешеп, егетең ятим нәмәстә икән лабаса, дип, ыржаешып, кызыбызны менә дигән җиргә бирербез әле, дип, кәпәрешеп, ары тайпылып, бире түнеп, бер дә игә килмичә газапладылар. Бары Киртулгауның: «Шул остадан башка беркемгә дә барасым юк!» — дип, кырт кистереп, биз кебек күгәреп утырып алуын күргәч, аның күңелен кыя алмыйча аптырап, үз убалың үзеңә алайса, ябынуга җитмәсәң дә, ямаулыкка ярарсың әле дип, уңга карап көлә-көлә, сулга карап елый-елый кызны бирергә мәҗбүр булганнар иде... Их, хәйран дөнья, шуннан бирле күпме гомер узган?!.

Хәер, Куйчыманның зур манасчы сыйфатында телгә кереп, җырда да җырлана башлавы бер ата өчен түгел, бәлки кайчандыр туганнарның сүзен таптап, иң хөрмәтле агасы Ирәголның да иркенә буйсынмыйча ярлыга ябышып чыккан Киртулгау өчен дә йөз аклыгы, шунысы белән тирән мәгънәле, гаять мөһим бер вакыйга иде.

Дөрес, Куйчыман яшь — барасы юлы озак, житәсе жире ерак; картлар әйтмешли, «яшьнең эше дә яшь, алдында гел кыя таш». Элгәрге акыл ияләре бу олы юл хакында мәгънәле сүзләр әйтеп калдырганнар:

Өзәңге тибеп ат менмәк
Ир-егетнең эшедер,
Гөрләтеп «Манас» әйтмәк
Зур егетнең эшедер.
Барыр юлы чиксез юл,
Абынырлык хәтәр мул,
Арттырмыйча, киметмичә
Әйтү Алып эшедер.
Баштан ахырга житкән —
Чын батырның көчедер!

Ата белән бала арасындагы әлеге аңлашудан соң тагы ике-өч ел узды. Көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән шөгыльләнеп йөрсә дә, егетнең күңелендә гел серле дөнья булды. Бер көнне ул төш күрде, төшендә Манас белән очрашты... Бары шуннан соң гына Сәңербай бу балада, чыннан да, өмет бар икән, шулай да бер сынатып карарга кирәк дип, аны кайнагасы Ирәголга алып барды, Хикмәт иясе Ирәгол әлек Куйчыманны якын кардәше — кадерле жияне[1] сыйфатында яратып, аңар бераз өмет тә баглап йөргән булса, бу юлы эшкә бик зур житдилек белән тотынды: «Манас» әйтү уен эш түгел, кияү, аның базары бик зур, туры кереп, кыек китеп йөрмәсен, оят булыр; озак сынарга, иренмичә күзәтергә кирәк, шуңа күрә жиянемне монда калдырып кит, кирәгәләреңне исә син үзең генә дә ясый торырсың әле», — диде.

Шулай итеп, карт тайәкәсе егеткә фатихасын биреп, аны үз янына кабул кылды. Куйчыман чын-чынлап атка атланды, тезген-чылбырын остазы кебегрәк тартып, камчысын да тайәкәсе белән бергә селтәп, чал манасчының сыңары сыман, мең дә бер тармаклы олы «Манас» юлына төште.

Шул көннән алып Куйчыман һәр кышын (жәйләрен исә атасына эштә булыша иде) тайәкәсе Ирәголга ияреп йөри торган булды, ул барган жиргә барды, ул кайтканда бергә кайтты, аның «Манас» әйтүен тыңлады, һәр ишеткәнен күңеленә тукыды һәм, бәйгегә әзерләнгән яшь ат кебек, атаклы толпар янында «буын чыныктырды»; беркадәре вакыттан соң үзе дә гөрелдәтә-гөрелдәтә җәмәгать алдында Манас вакыйгаларын сөйли башлады. Шул хәлдә көн артыннан көн уза торды.

Әмма Куйчыманның чын манасчы булып өлгерүе бары узган көзне генә беленде. Ә ул көзне әлеге чал Ирәгол, әлеге зур Ирәгол, Манас-Манас дип оран салып та тавышы карлыкмаган, теле һич тә көрлекмәгән мәшһүр Ирәгол бәйгеләр чапкан олы юл белән дөньядан үтте!

Төрле төштән жыелган халык Ирәголның изге сөякләрен тау өстендәге мазарга илтеп куеп, инде ат чаптыра-чаптыра елап, мәрхүмнең авылына кайтырга җыенган чакта, жайдаклар алдына дөнья куйган олы картның сөекле жияне Куйчыман узып чыкты һәм, ай-вай салып акырып, үкси-үкси үкереп, ат муенын кочаклап яткан килеш, авылга беренче булып килеп житте. Егетнең бу югалтуны барсыннан да авыр кичерүен белүче кешеләр аның култыгыннан тотып аттан төшерделәр, билennән кочып, өйгә алып керделәр. Менә шул чак Куйчыман, таякка таянып торып, олы остазыннан аерылу хәсрәтен жырга салды, үкенечен белдереп, арманын әйтте:

Әрвахы изге тайәкәм,
Син идең минем олы атам, —
Бер имчәктән сөт имгән
Кыз туганың үз анам,—
Инде сине кайдан күрермен!?
Мескен, хәйран тайәкәм,
Манас-Манас ди идең,
Бөтен кыргыз язмышын

[1] Ж и я н — кияүгә озатылган кыздан туган кардәш.

Хөкем кылган би идең;
Җилдә ялын тараган,
Тоягын ташка кайраган
Толпар кебек бер идең,—
Инде сине кайдан күрермен!?
Мескен, хәйран тайәкәм,
Киттең безнең арадан...
Әйткән сүзең хак икән:
Барып яткан урының
Кире кайтмас як икән,—
Инде сине кайдан күрермен!?
Мескен, хәйран тайәкәм,
Манас иде бар дөньяң;
Сайратып тел былбылын,
Айгырлар да кичә алмас
Дәрьялардай ургыдың!..
Аерылырмын дип синнән
Уйламады угылың,—
Инде сине кайдан күрермен!?
Мескен, хәйран тайәкәм,
Күрегендә останың
Әллә җиле беттеме?
Зур манасчы һөнәрен
Үзең белән бергә алып,
Кайтмас юлга киттенме?!.

Күзең уттай ялтырап,
Тау селкетеп акырдың,
Чәчеп ялкын авыздан,
Манас рухын чакырдың...
Мескен, хәйран тайәкәм,
Сүз кәрванын башлаган
Хикмәтле бер җан идең,
Фани дипме дөньяны
Безне болай ташладың? —
Инде сине кайдан күрермен!?
Мескен, хәйран тайәкәм,
Карлы, биек тауларның
Иң биеге бер булыр,
Манасчылар эчендә
Берсе олы ир булыр...
Даның калды, үзең юк,
Кая барыйм? Юлым юк!..
Өзәңгем бассам өзелә,
Хәсрәттән билем бөгелә;
Барлык кыргыз йортына
Башлык Айкүл урнына,
Манас рухын чакырып,
Ирәголдай ажгырып,
Кайсы Алып баш булыр?!..

Ирәголдай аксакалыннан аерылып хәсрәтләнгән халыкны зар елата-елата иңрәп, Куйчыман олы остазы белән шулай саубуллашты.

Шул көнне үк, Ирәголның рухына багышланган нәзер мәҗлесеннән соң, аксакаллар-карасакаллар бергә җыелып, Куйчыманга үз теләкләрен әйттеләр: «Үз гомеребездә Ирәголдай зур манасчыны бүтән күрмәдек. Арабызда исән йөргән чакта аның кадеренә җиттек микән, юк микән, моны бер ходай үзе генә белер... Ул безгә, баксак, истәлек итеп сине калдырган икән, Куйчыман җиян. Әрвахы изге Ирәголның урыны бушап калуын сиздермичә, аның һөнәрен үстереп, йоласын дәвам итеп, «Манас»ны моннан соң үзең әйтерсең инде. Безнең ихтыярыбыз да, теләгебез дә, киләчәк өчен өметебез дә менә шул», — дип, бөтен халык исеменнән егеткә фатиха бирделәр.

Шул ук төнне Куйчыман гүр иясе булган Ирәголга атап «Манас»ны әйтте, баһадир Манасның бу вафасыз дөнья белән саубуллашу хәлләре турында җырлады. Моң-зар эчкә шул кадәре җыелган икән, аны тыңлап утырган кешеләр бер мәлне сулышлары туктагандай тынып калып, бер ара иңрәгән манасчының аһәңенә ияреп сулкылдый-сулкылдый елап, җырга тагы моң куштылар, күз яшенә тоз өстәделәр; егет исә таң атканчы серле вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр хакында дастаннар дәрьясын агызды.

Хәйран Манас, ул да үткән икән дөньядан! Күзе йомылыр чакта соңгы дәрманын җыеп, калучыларга дәрт биргән:

Абыкә, Бакай, елама!
Ахирәт таба юл тотам,
Елаудан җаным кыйнала!..
Әҗәле җиткән үләчәк;
Яраткан таңрем боергач,
Бәндәгә шулдыр күрәчәк!

Тыңлап утыручылар көндәлек эшләрен, зарури шөгыльләрен оныттылар; төпсез тирән хыялларга, серле-шомлы уйларга баттылар, «и-и, вафасыз дөнья!» дип, күңелләре әрнеп сызып, хәсрәт ялкыны өреп көрсенделәр.

Ихтимал, бу мизгелдә һәрберсенең күңелендә иң нечкә тойгылары уянып, һәрберсе үзенең кабатланмас бер шәхес икәнен тоеп, бу якты дөньяның һәртөрле яхшылыгына сөенеп, начарлыгы өчен көенеп, адәм булып яшәүләреннән таң калып, әллә кайчан узган-беткән вакыйгаларны бер кадәре тирән итеп тагы бер кат кичерә алулары өчен яратучы тәңреләренә ургылган хисләре белән мең дә бер тапкыр алкыш әйткәннәрдер?.. Әйе, кешелекнең бер төп сыйфаты аның узган өчен хәзергедәй итеп кайгыра алуында, шул узганның суыгыннан туңып, эссесеннән пешә белүендә; «аңа минем ни катнашым бар» дип, йөзен читкә чөермичә, аны үз җилкәсенә алып, хәзерге хәсрәт-шатлыгы кебек бөтен йөген үз иңендә йөртә алуында.

Шулай булмаган тәкъдирдә кеше кеше булырмы, ата — бала, ил — йорт була алыр идеме соң?!.

Манасның вафаты хакындагы хикәят тә әйтелеп бетте, таң да сызылып атты. Төннең яртысы авышуга күпереп торган йомшак кар ява башлаган иде. Соңгарып килгән көзнең тәүге кары. Уйга баткан төсле салмак сибәли-сибәли җай төшеп, җиргә җылысын бирергә теләгәндәй йомшак түшәлеп, ул кар иртәнге якта да явып торды. Кар шулай һаман ява бирсә дә, соргылтланып бүзәргән күктән кояшның күренер-күренмәс күзе сизелер-сизелмәс нурларын сирпи; бөтен дөнья тып-тын, дымсу; таулар-ташлар, күл буенда анда-монда сибелеп утырган озын-озын төтенле авыл-тирмәләр, утлаудан туктап, көрпә карга аркаларын түшәп торучы мал-туарлар — җир өстендәгенең барсы да әлеге күпереп-ишелеп яуган җепшек кардан тирләгән төсле изрәп, йокымсырагандай тынып калган.

Үз кардәшләре белән кайту юлына чыккан Куйчыман, атының тезгенен тарта-тарта, арттарак калып барды. Ни өчендер аның бүген ялгыз каласы килә иде. Узган көннән бирле хөкем сөргән ыгы-зыгы, шау-шудан, шулай ук керфек элмичә төн ката «Манас» әйтүдән аның башы гүли, колаклары шаулый. Хәтта менә бу сөттәй ак, мамыктай йомшак тынлыкта да аның колак төбендә нидер туктаусыз гөжләп торгандай итә, вакыт-вакыт еракта ярсып аккан дәрьяның гөрелтесе ишетелгәндәй була.

Күл өсте томанга төренгән, ишелеп-тузгып яуган кардан теге яктагы, бу тарафтагы тауларның бары тонык шәүләләре генә абайлана.

Бу бер гаҗәеп, ап-ак булып түшәлгән серле тынлык иде.

Йомшак кардан атның атлавы да сизелми; алга узып киткән җайдакларның шау-шуы, дистәләгән тоякларның дөбер-шатыры колакка бер чагыла, бер тынып кала.

Куйчыман атының башын Күлгә таба борды. Һәм, су янына җиткәч, җиргә төште. Нигә болай эшләвен үзе дә белми иде. Ләкин менә шунда гына, бары шул урында гына, томанлы күлнең салмак сулышын тыңлап торган килеш, ул бер әчеле-төчеле нәрсәнең тәмен татыгандай, үзенең иң бәхетле, шул ук вакытта иң бәхетсез кеше икәнлеген аңлады. Никадәре манасчылар узган дөньядан, нихәтлесе хәзер дә яши, киләчәктә дә алар күп булачак, әмма һәрберсенең бер үзенә генә хас юлы бар, һәрберсе җаваплылыкны үзенчә аңлый; оят-хурлык, вөҗдан-намус та һәрберсендә төрлечә — үзгәчә, хосусый, алып торырлык, өләшеп йөрерлек түгел.

Ә инде бу «Манас» дигән дөньяның башы кайда да, очы кайда? Андагы катлаулы вакыйгалар, аларның үрелеп үсүләре, төрле чорлар, ул заманнан бу заманга күчүләр, атадан балага кала килә торган

серле тарих, иксез-чиксез җыр, моң дигәнең бер гаҗәеп кара урман түгелме соң? Менә шуларның барсын да йодрыктай гына башка ничек сыйдырырга, диңгез кадәре хәтсез бу нәрсәне түкми-чәчми тәгәл саклап, өстәвенә йөрәк каның белән сугарып, кешеләргә, ил-йортка ничек җиткерергә кирәк? Шушы таудай дәү әманәтнең җаваплылыгы никадәр? Газабы-хәсрәте нихәтле? Шул ук вакытта ләззәте, рәхәте азмы соң аның?!.. Нинди чиксез хыял киңлеге, никадәре уйланулар — кеше башына сирәк куна торган олы бәхет түгелме соң боларның барсы да!?

«Манас» дигән гаҗәеп дастанның никадәре олы булуын ачык сизеп, шуңа күрә җаваплылыктан имәнеп, бер үк вакытта үзенә язмыш тарафыннан шундый хәзинә тапшырылуның иксез-чиксез бәхет икәнлеген аңлап, Куйчыман, капланып ат ялын кочаклаган килеш, сагындырган анасына сыенган яшь баладай тавышланып елап җибәрде. Үксеп-үксеп елды. Күз яшьләренә аралашкан кар эреп, бөтен бите-йөзе тәмам чыланганчы елады. Ярларына бәрелә-бәрелә Эссе Күлнең уфтануы кебек бик озак сулкылдап елады ул. Ниһаять, ташыган хисләрен яшь белән мул итеп сугаргач, бераз тынычланды, күңеле иркенәеп калды. Моннан соң үзенең бар гомере, уй-фикере, бөтен тәне, кайнар каны — барсы да «Манас» әйтүгә багышланачагын ул бик ачык тойды. Әгәр, башкача килеп чыгып, тәкъдирнең шушы әманәтенә турылыклы була алмаса, бервакытта да үзен чын кеше рәтендә ихтирам кыла алмаячагын аңлады.

Ул шулай уйга батып торганда, сибәләгән карны аралап, яр буеннан очкан бер төркем үрдәк якындагы тын култыкка килеп төште. Шунда ук алар бакылдый-бакылдый су чәчрәтеп, куыша-куыша чумып китеп, шауларга, уйнарга тотындылар.

«Кошлар да кайтып җиткән икән!» — диде Куйчыман пышылдап. Куанычлы елмаеп куйды. Өркетеп җибәрмәс өчен шыпырт кына атына атланып, әкертен китеп барды.

Әкрен генә кар явудан туктады; әкрен генә кояш күзе ачылды...

Бер-бер артлы көннәр узып, Ирәголнең кырыгына нәзер ашы биргән чакта Куйчыман тагы халык алдында «Манас»ны әйтте. Кышкы чиллә мизгеле иде. Куйчыманның кызу «урак өсте» дә нәкъ шунда килде — илһамланды, очынды, очты, күкләргә ашты!.. Тик күңелне китәргән нәрсәләр дә булды. Нәкъ шул нәзер җыенында ил эченә уйратлар турындагы имеш-мимеш сүзләр таралды — казакълар тарафыннан уйратлар көч туплап, зур яуга әзерләнәләр, дигән шомлы хәбәр килде.

Кайберәүләр әллә чын бу, әллә ялган дип, ул хәбәрне шик астына алсалар да, тәҗрибәле аксакаллар замананың бозыла баруын, илдән иминлек китеп, киләчәктә әллә нинди хәлләрнең булуы бик ихтимал икәнлеген әйттеләр.

Шулай килеп чыкты да: яз башында ук үз ише егетләр белән бергә яуга дип атка атланып, Куйчыман сугыш мәйданына юнәлде.

Ил-йорт калды. Күл калды. Биш айлык йөге белән сөекле хатыны яшь Алмаш калды...

*
* *

...Таңга каршы Сәңербай кергәнче, нуры сүнеп, тоныкланып калган күзләрен көчкә генә ачып, хырылдап чыккан хәлсез тавыш белән нәрсәдер әйткәндәй итте. Кичен Иләман елый-елый йөгереп барып чакырып китергән, хәзер сырхау янында утырган куй көтүче карт хәл өстендә яткан мескенгә таба иелеп:

— Кирәгәчем, кадерлем, нәрсә әйттең соң?.. И-и, пигамбәр кебек булган асыл затым!.. Йә, нәрсә әйтергә теләдең соң? Әйт инде, әйт сүзеңне!.. Бәхиллегеңне бир... — дигән иде, Сәнербай кирәгәче бер тартышып алып, тагы нәрсәдер әйткән кебек булды. Аның әллә кайлардан, бик ерактан ишетелгән төсле хәлсез, зәгыйфь чыккан тавышы куйчы картның колагына чак-чак кына килеп җитте.

— Тал... Чө-өй... — дигән сүзне көчкә генә аера алган куйчы карт сискәнеп китте:

— Талчөй дип әйтә! — дип, күзләре акаеп, тыны буылып калды. Аннары бу сүзнең хәзер нинди мәгънәгә ия икәнлеген аңгарып алып, ачы тавыш белән кычкыра-кычкыра сөйләп, елап җибәрде:

— Талчөйдән хәбәр юк әле, оста! И-и, әттәгенәсе, и-и, бу коргыры заманасы!.. Хәбәр юк, оста, әле хәбәр юк!.. Ничек итеп ялган әйтим, бу хәлеңдә сиңа ничек ялганлый алам соң?! — дип, мескен куйчы карт, баядан бирле истән аерылып, калтырап елап утырган Иләманны кочаклап алып, эч-бөерләрен селкетә-селкетә үкси башлады.

Тышка качып чыккан Иләман яңадан өйгә керә алмады. Әле атып җитмәгән таңның иләс-миләс яктысында елый-елый, үзеннән-үзе качарга теләгәндәй үкси-үкси, үзән буйлап түбәнгә карап йөгерде.

Озак йөгерде ул, бары Күл буена җиткәч кенә туктады. Күлдә дулкыннар биешә; су өсте әкрен генә яктырып, җанланып килә икән. Исен-акылын җыя алмыйча торган Иләманның колагына элек бер дә ишетмәгән-белмәгән һава хәрәкәтенең өне чалынды. Башын югары чөеп күккә караган иде, анда исәпсез-хисапсыз күп кошларның Күл өстендә әйләнеп йөрүләрен, кисәк-кисәк болытлардай төркем-төркем булып, өер-өерләргә бүленүләрен күрде. Алар ерак сәфәргә чыгарга әзерләнеп өлгергәннәр икән. Барган саен кубәеп, барган саен күл өстеннән тиз-тиз әйләнеп, тавыш-өннәрен дә көчәйтә-көчәйтә, алар гел югарыга күтәреләләр иде. Бер ара, Күлнең теге ягына таба авыштылар да, шунда бер-бер артлы рәт-рәт булып тезелешеп, көтелмәгән кискен тизлек белән Буом тарафына очып китә башладылар.

Аларны куып җитәрдәй булып омтылган Иләман елый-елый кычкырды:

— Әтием үлде! Әй-әй, еракка киткән каз-үрдәкләр, әтием үлде! Абыема әйтә барыгыз! Абыема хәбәр итегез! Әтием үлде! Үлде, үлде, үлде...

Буом сыртыннан ургылып торган каты җил, нәкъ каршыдан исеп, кошларның канат-койрыкларын каерды, килгән якларына таба куып, кире сөрде. Чигенергә, яңадан Күл буена кайтырга мәҗбүр булган кошлар янә өер-өергә төркемләнеп, рәт-рәт булып тезелеп, тагы очып юнәлделәр.

Таң алдындагы тауларның кап-кара тирән үзәннәре өстендә ажгырган җил, биектәге болытларны каулап, түбәндәге томаннарны да буташтырып, кошларга Буом аркылы очып узарга юл бирмәде. Өшеткеч салкын һавада бер-бер артлы аралашып яуган кар, яңгыр, боз, төн төсле кап-кара болытлар кошларның юлларына киртә кордылар. Шулай да, ничә мәртәбәләр кире борылырга мәҗбүр ителгән, ничә мәртәбәләр тагы сәфәргә тәвәккәл кылып, яңадан очкан, һәр омтылганнары саен югарырак, биеккәрәк күтәрелгән, хәтта болытларның да өсләренә менгән, нишләтсәләр дә, ниятләреннән кайтмыйча, гел алга ашкынган кошлар, ниһаять, Буом аркылы очып уздылар һәм, кояш чыгар алдыннан Талчөй үзәненә таба ашыгып, канат кактылар.

Кояш калкып чыгып, тәмам яктырган иксез-чиксез киң Талчөй үзәненә җитә язганнар иде. Нинди иркен, нинди рәхәт киңлекләр бу!

Менә алар кырыс табигатьле тау үткеленнән узып, рәтләрен тагы бер кат төзәтеп алып, кыйгак-кыйгак кычкыра-кычкыра биек-биектә очып баралар. Аларның асларында борылып-борылып аккан Чөй

елгасы. Шул елга буйлап оча торгач, алар җәйрәп җәелгән киң, иркен-имин бер төшкә җитәчәкләр — шунда беразга туктап ял итәчәкләр, талган канатларына көч җыячаклар, аннары тагы сәфәрләрен дәвам кылачаклар.

Шулай биек-биектә ашкынып оча-оча, күчмә кошлар төш мизгелендә Чөй дәрьясының әлеге җәелеп-җәйрәп ята торган кин агымына якынлаштылар. Шул төшкә җиткәч, түбәнгә таба иелеп очып, җиргә кунарга җыена башладылар. Ләкин бу юлы аларга анда кунып ял итәргә, хәл җыярга насыйп булмаган икән...

Нәкъ шул җирдә, Чөй дәрьясының көзгедәй иркен-имин ялтырап, тын гына агып яткан җирендә каты сугыш бара иде. Атлысы атта, җәяүлесе җирдә килеш кычкырышып, акырышып, үкерешеп, ажгырышып, бер-берсе өстенә ябырылган ничәмә-ничә мең чирү, төркем-төркем булып, үзара бәрелешәләр; төркемнәрнең берсе ары китеп, икенчесе бире килә, ләкин, тагы бер бөтерелеп алып, янә бер-берсе өстенә ташланалар; бераүләре качалар, икенчеләре аларны куа китәләр, тагы укмашалар, тагы аяусыз тукмашалар, төркем-төркем булып, янә бүленеп чыгалар; бер мизгелгә өстенлек ала башлаганнары кычкыра-кычкыра дошманнарын эзәрлекли, җиңелүчеләре исә пыр тузып качарга тотына, әмма шунда ук каршы яклар тагы буталырга тотыналар, янә кизәнә-кизәнә бер-берсе өстенә ташланалар, кисешәләр — башы-ахыры булмаган ыгы-зыгы, гарасат, очы-кырые күренмәгән киң мәйдан... Шулай Чөй дәрьясының агымын кан, киң мәйданлы үзәнен исә кешеләрнең, атларның үләксәләре белән тутырып, аяусыз каты сугыш бара иде.

Күктән түбәнгә төшә башлаган кошлар, кинәт өркеп китеп, кире күтәрелделәр, югары үрләп качтылар, бер тирәдә әйләнеп оча башладылар, куркуларыннан колакларны тондырып кычкыра-кычкыра, кая туктарга, инде нишләргә белмичә аптырап, бик озак шаулап йөрделәр алар; аннары бу җирләрдән барыбер игелек күрмәячәкләренә ышангандай, канатларын селтәп-селтәп, моң-зар белән тулы тавышларын яңгыратып, ерак-еракларга очып киттеләр...

И-и, кадерле күчмә кошларым, еракка очып, ерак китегез... Туктамыйча юлларыгызны дәвам итегез... Сез әйләнеп кайтканчы менә бу канлы сугышның ахыры ничек бетәсен кем белсен, сез әйләнеп кайтканчы кеме исән, кеме үле буласын, сез әйләнеп кайтканчы кемнен көне көн булып, кемнең язмышы, кемнең гомере ничек очланасын кем белсен...

Газиз күчмә кошларым, күкне иңләп гизгән канатлыларым, еракка очып китегез сез — адәм баласының күргән көне менә шундый инде... Ни чара бар, калдырыгыз аларны шул килеш! Бүксәләре тулып туюдан авырайган журыларның[1] канатларын селкеп-селкеп тә оча алмый утыра торган бер җире менә шушында булыр инде...

* * *

И-и, дөнья!.. Күчмә кошларга кушылып мин дә очып барамын. Канатларымны җилдә киереп, күп кошларның арасында сәфәргә чыктым; күп юллар уздым.

Биек-биек күктә кыйгаклашып өн салып, рәт-рәт булып тезелеп, тәртип саклап, канатларны селти-селти очып барабыз. Юлыбыз ерак, юлыбыз кыен юл.

---

[1] Журы — үләксә белән туена торган зур кара кош.

Каршыдан сызгырып искән кара җил ургылып аккан елга сыман гүелди. Күкнең бу төшендә кыштагы төсле каты салкын. Тын кысыла. Шул боздай салкын, боздай күгелҗем һавада выж-выж иткән канатлар бер калыпта тигез җилпенәләр.

Канатларны җәеп, канатны канатларга терәп, агылып очып барабыз. Аста торып югары карауччыларга кошларның һавада шулай очып барулары иркен киңлекләрдә ваемсыз гына йөзеп йөрүләре сыман тоелыр.

Һәрбер камиллеккә җиткән һөнәр читтән карап торучыга шулай гап-гади булып тоела ул.

Чынлыкта исә бу үлмәү өчен җан талашкан хәрәкәт, чынлыкта исә бу яшәү өчен барган тынгысыз көрәш, тынгысыз талпыну... Каршыдан ажгырып исеп күкрәккә бәрелүче кара җил көчәйгән саен муеннар сөңгедәй булып алга сузылып, аяклар юнып алгандай бөер йоннарына сыланып, эчләр аркага ябышып, күзләребез көзгедәй чәчрәп, судан да сыек күктә, иге-чиге юк күктә, туктар җире юк күктә, уктай очып, канат кагып барабыз, канат кайрап барабыз...

Бердә болыт очраса, бердә — тыныч киңлекләр, бердә — ярсыган буран...

Төннәрен дә тыныш юк, җан-җанварларның барсы да рәхәт-рәхәт йокыга талган чакта да без:

Карангыда юл салып,
Хәсрәткә баткан күктә,
Гүрдәй кап-кара күктә,
Йолдызлы биек күктә,
Якты ай йөзгән күктә,
Тынмаенча ашыгып,
Канат селтәп барабыз,
Канат кагып барабыз.
Көн алмашып төн була,
Төн алмашып көн була,
Очып китеп барабыз,
Очып китеп барабыз.

Гел югары үрләп, гел биеккә ашкан саен Җир шәүләсе дә ерагаеп, гел кечерәя бара, әйләнә-тирәсен күгелҗем бушлык чолгап, чиге-кырые беленми кала; әле былтыр гына бишектә яткан йомры җилкәле яшь баланың башы шикелле, түп-түгәрәк нәрсә икән ул Җир дигәнең. Гаҗәп, яхшы-яманы бергә укмашкан шул кадәр зур хаятны кочагына сыйдыручы әлеге Җир дигәнең шушымы? Шул нәфис, шул тупас бер нәрсәме? Иксез-чиксез галәмдә япа-ялгыз торучы, адашкан дөя бутасы шикелле бүзәреп кенә күренүче шул нәрсәме? Җир дигәнең шушымыни?!

Җир дигәнең шул булса,
Сакла, хода, саклачы
Соңы начар эшләрдән,
Дип барамын эчемнән;
Сакла, хода, саклачы
Канлы, салкын сиилләрдән,
Дип барамын эчемнән;
Сакла, хода, саклачы
Сүндерелмәс утлардан,
Дип барамын эчемнән.
Канатымны каккалап,
Күздән яшем тамганчы,
Сакла, хода, сакла дип,

Очып
        китеп
                барам мин.
Очып
        китеп
                барам мин,
Очып
        китеп
                барам мин...
Күздән яшем тамгалап,
Сакла, хода, сакла дип,
Елап
        очып
                барам мин,
Елап
        очып
                барам мин.
Елап
        очып
                барам мин!..

Иңрәгән өннәрем шулай гел яңгырап, аннары ишетелер-ишетелмәс сузылып, күчмә кошлар өере белән бергә ераклаганнан-ераклап, игечигенә күз җитмәс күктә шомырт бөртекләре кадәре кечерәеп, аннары тары хәтле генә калып...

Тып... тын...

**Кыргызчадан М. ГОСМАНОВ тәрҗемәсе.**

# А. С. ПУШКИННАН ЯҢА ТӘРҖЕМӘЛӘР

## Һәйкәл

Кеше кулы ясый алмас һәйкәл куйдым үземә,
Үлән басмас аңа салган халык сукмагын.
Патша баганасыннан да ашып менде күгенә
Иелмәүчән горур башы, — тиңе юк аның.

Юк, мин үлмәм бөтенләйгә, — лирасында җаным,
Тәнем туфракка дүнгәч тә яшәр гомергә —
Айлы күк астында калыр мәңге минем даным,
Хәтта тик бер генә шагыйрь калса да җирдә.

Шаным китәр җәелеп бөек Рус дәүләте буйлап,
Исемем йөрер кабатланып барлык телләрдә,
Атар мине горур славян, кыргый тунгус олылап,
Киң далалар дусты калмык, тагын финнәр дә.

Халык мине озак ядлар — аның йөрәгендә
Яхшы хисләр уяттым мин лирамда уйнап,
Җырладым мин замананың авыр көннәрендә
Изелгәннәр хакын яклап, ирекне зурлап.

Буйсын тәңрең кушканнарга, шигъриятем минем,
Курыкма син рәнҗеткәннән, таләп итмә дан,
Һич китмәсен исең мактау, хурлауларга синең,
Бәхәсләшмә — ерак бул син әрсез-ахмактан.

1836

●

Мәгъдән базларында — Себердә
Түземлекне горур саклагыз сез,
Юкка чыкмас кыен хезмәтегез,
Бөек уйлар сүнмәс сөргендә.

Өмет сезгә куәт, рух бирер,
Бәхетсезлек белән ул бер туган,
Алып чыгар сезне караңгыдан,
Зарыгып көткән гаҗәп көн килер:

Зиндан ишекләре аркылы
Сөю, дуслык барып җитәр сезгә,
Җиткән кебек ерак өнегезгә
Азат тавышым — җырым ялкыны.

Өзелеп төшәр авыр богаулар,
Бар зинданнар хәрабәгә калыр,
Ирек сезне көләч каршы алыр,
Тагын кылыч бирер туганнар.

1827

## Вакх җыры

Шат өннәр ник тынып калдылар?
Яңгыра, гыйш-гашрәт җырлары!
Яшәсен нәзакәт кызлары
Һәм безне сөйгән яшь хатыннар!
Җамнарны тутырып алыгыз!
Төбендә чыңласын,
Шәрабка чылансын,
Кадерле балдаклар салыгыз!
Алыйк та җамнарны, күтәрик без бергә!
Яшәсен шигърият һәм акыл гомергә!
Син, изге кояш, ян!
Бу шәмдәл калтырап яктырган урнында
Сүрелгән төсле таң алдыннан,
Акылның үлемсез кояшы нурында
Ясалма хикмәт тә сүрелә — була фаш.
Югалсын җәһаләт, мең яшә таң-кояш!

1825

●

Хыяллардан тәмам җаным бизде,
Күңелдә юк хәзер теләк тә,
Тик газаплар гына борчый мине,
Җан бушлыгы салып йөрәккә.

Явыз язмыш давылы харап итте
Таҗга үргән чәчкә-гөлемне,
Мин хәсрәтле, ялгыз көтәм инде
Килерме дип соңгы көнемне.

Кышкы җилләр тавышы шулай кайчак
Килә сыкрап көзге салкында,
Соңга калган япа-ялгыз яфрак
Ботагында тетри — талпына!..

1821

## Карт

Мин элекке алчак түгел инде
Бик күпләрне үзенә караткан:
Матур язым, җәем үтеп китте
Мәңгелеккә, кайтмас кабаттан.

Амур, Амур[1], яшьлектәге аллам!
Хезмәтеңдә бөктем билемне;
Аһ, яңадан әгәр туа калсам,
Алай гына бөгелер идемме!

1814

## Шигырь чыгаручы үлеменә эпиграмма

Җәннәт күрмәс мәрхүм Клит җаны:
Гөнаһларның кылды зурларын,
Оныт, тәңрем, яманлыгын аның,
Ил оныткан кебек җырларын!

1814

## Воронцовка

Ярым милорд, ярым сәүдәгәр,
Ярым хаким, ярым — җаһилдер,
Ярым — кабих, өмет бар мәгәр,
Бөтенләй дә кабих булыр бер.

1824

**НУРИ АРСЛАНОВ** тәрҗемәләре.

[1] Амур — борынгы рим мифологиясендә мәхәббәт алласы.

# ОЧЕРКЛАР

## ЕГЕРМЕ АЛТЫНЫҢ БЕРСЕ

Егерме алты Баку комиссары... Аларның инглиз интервентлары һәм эсерлар тарафыннан ерткычларча үтерелүенә быел 60 ел тулды... Менә инде күпме еллар буе алар Баку шәһәренең егерме алты комиссар исеме белән аталган үзәк мәйданында һәйкәл булып яшиләр. Ел саен 20 сентябрьдә иртән бирегә эшчеләр, хезмәткәрләр, укучылар килә. Кулларында чәчәк бәйләмнәре. Солдатлар почетлы караулга баса. Композитор Кара Караев язган матәм моңы сызыла. Җыелып сөйләүләр булмый бу көнне. Баку хезмәт ияләре төркем-төркем булып киләләр дә комиссарларга сүзсез генә баш ияләр...

Алар егерме алтау иде, егерме алты комиссар... Төрле милләт уллары, төрле һөнәр кешеләре, коммунистлар, партиясезләр... Иң яше егерме икедә булып, иң олысы кырык бишне дә тутырмаган иде.

Комиссарларның туган җирләре — Баку, Тифлис, Рига, Кишинев, Рязань, Батуми, Елизаветополь (хәзерге Кировабад) шәһәрләре, Казан, Владимир, Тамбов, Смоленск, Могилев губерналарындагы авыллар.

...Егерме алты комиссарның берсе — Иван Яковлевич Габишев — безнең якташыбыз. Ул Казан губернасы, Лаеш өязе, Панова авылында 1888 елның 30 январенда (яңа стиль белән 12 февральдә) крестьян Яков Николаевич Габишев белән Анна Васильевна (кыз фамилиясе Гурьянова) гаиләсендә дөньяга килгән. Туганнарының әйтүенә караганда, Ваня кечкенәдән үк җитез хәрәкәтле, шук күңелле булган, абыйсы Федор белән Мишә буйларында йөрергә яраткан, йомшак чирәмгә ятып тургай сайрауларын тыңлау аның өчен иң ләззәтле минутлар булган. Зурайгач та җырларга, музыка тыңларга һәм гитарада уйнарга һәвәс булып калган.

Панова крестьяннары алпавыт А. Юшков изүеннән җәфа чигеп яшәгән, түзәрлекләре калмаганнары бәхет эзләп күмер, нефть чыккан якларга, шәһәрләргә юл тоткан. Габишевлар гаиләсе дә шундый язмышка дучар булган. Каты авырудан соң, өч баласын калдырып, әниләре Анна Васильевна дөнья белән хушлашкач, гаилә Казанга күченеп, әтиләре Крестовниковлар заводына (хәзерге Мулланур Вахитов исемендәге химия комбинатына) эшкә кергән.

Укырга бик омтылса да, Ваняның моңа мөмкинлекләре булмаган. Аңа Казанның төрле заводларында эшләргә туры килгән. Архивта аның 1911—1912 нче елларда Крестовниковлар заводында эшләү чорына караган кайбер мәгълүматлар сакланган. Ул заводның механика бүлегенә 1911 елның 5 июлендә алынган һәм 1912 елның сентябрь аена кадәр шунда эшләгән. Көнлек хезмәт хакы 90 тиен булган. Аңа шулай ук хәрчәүнәдән азык-төлек алу кнәгәсе бирелгән. Иван Габишев Крестовниковлар заводында егерме-егерме бишәр ел бил бөккән Мөхәммәт Шәрипов, Нигъмәтҗан Сафиуллин, Гыйззәт-

дин Шаһиәхмәтов, Сабирҗан Ибәтуллин, Габделгали Саттаров һәм башка бик күпләрнең авыр хезмәтләрен, аларның өметсез киләчәген күреп яшәгән. Аның абыйсы Федор да шул ук механика бүлегендә эшләгән.

Мәгълүм ки, Крестовниковлар заводы Казанда пролетариатның көрәш үзәкләреннән берсе була. РСДРП (б)ның Казан Комитеты биредә зур эш алып барган. 1912 елның 18 мартында комитет, 15 данә большевистик «Звезда» газетасын тарату турында карар кабул итеп, шул унбиш данәнең берсен Крестовниковлар заводы эшчеләре өчен билгеләгән. Ә 22 мартта ук инде «Звезда» газетасының 18 саны Крестовниковлар заводы эшчеләре тарафыннан кулдан-кулга күчереп укыла[1]. Нәкъ менә шул 1912 елда Иван Яковлевич большевиклар партиясе сафына баса.

Ул һәр вакыт ничек тә булса белем алырга омтылып яши, врач булырга хыяллана. Казан университеты студентлары аны медицина факультетына укырга керергә әзерлиләр, аңа рус теленнән, математика һәм физикадан, латин һәм немец телләреннән дәресләр бирәләр. Ул анатомия театрына йөри, операцияләрне күзәтә. Иван татар телен яхшы белә һәм татар эшче яшьләре белән аралашып яши, алар арасында аның дуслары күп була. Габишевлар үзләре дә чыгышлары ягыннан татарлар[2].

Патша самодержавиесенең эзәрлекләвеннән качып, Иван Яковлевич хатыны Евдокия Семеновна һәм кызы Галя белән 1914 елда Бакуга күчә. Биредә алар Баилово районында яшиләр, И. Я. Габишев судно-лар ремонтлау мастерскоена эшкә керә[3]. Бакуда да ул революцион эшен дәвам иттерә. Партия кушуы буенча аңа Челекен утравында яшәргә һәм нефть промыселларе эшчеләре арасында революцион эш алып барырга туры килә. Биредә 1912—1914 нче елларда РСДРП(б)-ның партия группасы җитәкчесе булып И. Я. Габишевның дусты, 26 комиссарның берсе Иван Тимофеевич Фиолетов эшли. 1913 елның 16 октябрендә Ашхабад «җинаятьчеләрне» эзләү пункты мөдире: «Челекен утравындагы нефть промыселларе эшчеләре арасында үзләренең революцион үткәннәре аркасында властьлардан яшеренеп ятучы кешеләр бар»[4], — дип яза. Шул ук пункт мөдире 1914 елның 29 июнендә Төркестан Хәрби округ штабына язган хатында Казандагы политик яктан ышанычсыз кешеләр белән Хәрби округ солдатлары арасында элемтә барлыгын да хәбәр итә[5].

Челекен утравында Россиянең Казан, Сембер, Пенза һәм башка губерналарыннан бик күп эшчеләр, шул исәптән татарлар да, эшләгән[6]. Күренә ки, партиянең биредә И. Я. Габишевны җибәрүе очраклы булмаган.

---

[1] Татарстан Үзәк Дәүләт архивы, 199 ф., 225 ис., 199 эш, 30—32 битләр.

[2] И. Я. Габишевның кызы Галина Ивановна Черняеваның (ул Мәскәүдә яши) 1977 елның 4 сентябрендә миңа язган хатында мондый юллар бар: «Әниемнән мин, ни өчен безнең фамилиябез татарча һәм мине ни өчен татарка дип йөртәләр? дип сорадым. Шунда мин күптән булган хәл турында ишеттем. Безнең бабаларыбыз татарлар булган. Берзаман аларның барсын да Кабан күленә куып төшергәннәр дә чукындырганнар. Патшага шулай кирәк булган» (Хат авторда саклана.)

И. Я. Габишевның сеңелесе А. Я. Нариманбекова (Бакуда яши) болай ди: «Әтием Яков Габишевның гармун моңына кушылып безгә, балаларга, татар җырларын җырлавын яхшы хәтерлим. Әтием Ваняның татарча әйбәт белүен, татар халык көйләрен яратуын күп мәртәбәләр әйткәне бар».

[3] КПСС ҮК каршындагы марксизм-ленинизм институтының Әзербәйҗан партия архивы, 303 ф., 1 ис., 71 эш, 1 бит.

[4] Төркмәнстан Үзәк Дәүләт архивы, И-1 ф., 2 ис., 15918 эш, 129 бит.

[5] Үзәк Дәүләт Хәрби архивы, 1396 ф., 3 ис., 651 эш, 39 бит.

[6] Биредә бигрәк тә Буа өязеннән эшчеләр күп булган. Мәсәлән, «Люборөд» товариществосындагы 90 эшченең 34 е бу өяздән, шуларның 25 се Әйтуган авылыннан булган. Ә «Бр. Нобель товариществосы»ндагы 95 эшченең 26 сы Буа өязе татарлары булган.

И. Я. Габишевка Красноводск, Ашхабад шәһәрләрендә дә эш алып барырга туры килә. Әле Бакуда вакытта ук ул, Казанда алган белеменә таянып, фельдшерлар курсын тәмамлый. Ашхабадта хәрби госпитальдә фельдшер булып эшли һәм солдатлар арасында империалистик сугышка каршы агитация алып бара.



*И. Габишев гаиләсе белән.*

Февраль буржуаз-демократик революциясеннән соң ул яңадан Бакуда. Биредә И. Я. Габишев В. И. Ленинның якын көрәштәше Степан Шаумян җитәкчелегендә эшли.

Бакуда 1917 елның ноябрендә власть тулысынча Советлар кулына күчә. Ул Закавказьеда контрреволюцион көчләргә, шул исәптән буржуаз - милләтчеләргә, каршы көрәш үзәгенә әверелә. 1917 елның 14 (27) ноябрендә Баку шәһәренең Порт районы Эшче һәм солдат депутатлар Советы комитетына 5 меньшевик, 2 сул эсер һәм 2 большевик (Чикарев һәм Габишев) кертелә. Большевиклар сан ягыннан азчылыкны тәшкил итсәләр дә, район комитеты председателе итеп И. Я. Габишев сайлана[1]. Аны шулай ук Баку Эшче һәм солдат депутатлары Советы Башкарма комитетына кандидат итеп тә сайлыйлар.

1917 ел ахырында шул Совет И. Габишевка Кызыл гвардия оештыру эшен тапшыра. Озакламый Бакуның барлык районнарында Кызыл гвардия отрядлары барлыкка килә. 1918 елның февраль аена кызылгвардиячеләр саны 6 меңгә җитә. Ә 1918 ел башында Кызыл Армия төзү турында В. И. Ленин имзасы белән декрет басылып чыккач, Иван Яковлевич бар куәткә Кызыл Армия частьләрен оештыру эшенә керешә. Ул район штаблары эшенә зур игътибар бирә, районнарга хәрби инструкторлар билгели, хәрби частьләрне корал һәм башка кирәк-яраклар белән тәэмин итүдә инициатива һәм тапкырлык күрсәтеп эшли.

Г. Корганов, Б. Шеболдаев, И. Малыгин, Ф. Солнцев һәм башкалар белән бергә, И. Габишев Баку предприятиеләрендә, эшче районнарда, нефть промыселларында чыгышлар ясап, Кызыл Армия төзү зарурлыгын аңлата. 1918 елның май ае ахырына Баку Советы карамагында 18 мең кешедән торган 19 батальон төзелгән була.

[1] С. Беленький, А. Манвелов. Революция 1917 г. в Азербайджане. (Хроника событий) Баку, 1927, 207 бит.

1918 елның апрель аенда Закавказьеда Баку коммунасы оеша. С. Г. Шаумян җитәкчелегендәге Халык Комиссарлары Советы барлыкка килә. Ул барлык банкларны, нефть промыселларын, сәүдә флотын хуҗаларыннан тартып ала, 1918 елның 2 июнь декреты белән барлык җирләрнең крестьяннарга түләүсез бирелүен игълан итә.

В. И. Ленин Баку коммунасының эшен зур игътибар белән күзәтеп бара. Яшь Совет Россиясенең хәле авыр булуга карамастан, Совет хөкүмәте Баку Халык Комиссарлары Советына туганнарча ярдәм кулы суза, аның экономикасын ныгыту өчен дистәләрчә мең сум акча җибәрә. В. И. Ленин 1918 елның 14 маенда Степан Шаумянга: «Без сезнең нык һәм кыю политика үткәрүегезгә бик шатбыз, — дип яза. — Бу политиканы, һичсүзсез, хәзерге бик кыен обстановка таләп итә торган сак дипломатия белән бергә куша белегез, — һәм без җиңәрбез»[1].

Баку коммунистлары Совет Россиясенең авыр хәлдә булуын һәм кыен шартларда эчке һәм тышкы дошманнарга каршы сугыш алып баруын яхшы аңлыйлар. Баку хезмәт ияләре Совет Россиясен ягулык белән тәэмин итүне үз бурычлары итеп саныйлар, берничә ай эчендә Россия социалистик республикасына 80 миллион поттан артык нефть озаталар.

Империалистик державалар, әлбәттә, Баку коммунасының бу эшләре белән килешә алмадылар. Баку нефте аларның үзләренә кирәк иде. Ул вакытта Баку нефть промыселлары дөнья күләмендәге барлык нефтьнең 15 процентын бирә иде. Америка Кушма Штатларының «Нью-Йорк таймс» газетасы 1918 елның 14 июлендә: «Союзникларның беренче чираттагы бурычы — Кавказның иң әһәмиятле нефть районнарын кулга алу», — дип язды. Ә инглиз экономик журналларының берсе: «Нефть мәсьәләсендә Бакуның тиңнәре юк, Баку — дөньяның бөек нефть үзәге. Әгәр дә нефть король булса, Баку аның тәхете», — дип өстәде[2].

1918 елның язында Баку коммунасына җитди куркыныч туа. Немец һәм төрек гаскәрләре Бакуга һөҗүм башлыйлар. Алар белән бердәм хәрәкәт иткән имам Гоцинский җитәкчелегендәге Дагыстан контрреволюцион бандасы революцион Бакуны төньяктан Совет Россиясеннән аера.

Баку нефтенә инглиз интервентлары да кул сузалар. Нәкъ менә шушы киеренке вакытта революция дошманнары Баку коммунасын эчке яктан таркатуга керештеләр. Меньшевиклар, эсерлар һәм дашнаклар (әрмән буржуаз милләтчеләре оешмасы), шәһәрне төрек-герман гаскәрләре талавыннан коткару өчен инглизләрне чакырырга кирәк дип, большевикларга каршы чыгалар, төрле яла ягалар, азык-төлек җитмәүне аларга сылтыйлар. 1918 елның 25 июлендә Баку Советында күпчелек тавыш белән инглизләрне чакыру турында карар кабул ителүгә ирешәләр. Шул шартларда да большевиклар шәһәрне төрек-немец басып алучыларыннан саклауны дәвам иттерәләр.

И. Я. Габишев Баку өчен алгы сызыкта торып сугыша, бригада комиссары буларак, шәхси батырлыгы белән кызылармеецларга үрнәк күрсәтә. «Г. Корганов, Б. Шеболдаев, А. Микоян, Г. Петров, И. Малыгин, И. Габишев, Ф. Солнцев, Э. Берг һәр вакытта да фронтта иделәр; С. Шаумян, П. Джапаридзе, М. Азизбеков һәм башка җитәкче иптәшләр берничә тапкыр алгы позицияләрдә булдылар», — дип яза Л. С. Шаумян[3].

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 35 том, 299 бит.
[2] Л. Шаумян. Двадцать шесть Бакинских комиссаров. Мәскәү, 1968, 4 бит.
[3] Л. Шаумян. Двадцать шесть Бакинских комиссаров. Мәскәү, 1968, 13 бит.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәтенең күренекле эшлеклеләреннән берсе Анастас Иванович Микоян үзенең истәлекләрендә, Бакуны дошманнан саклауда комиссарлар Ганин һәм Габишев белән бергә киңәшеп эш иттек, фронтны ныгыту өчен бергәләп чаралар күрдек, дип искә ала. Бакуны төрекләргә бирү максаты белән сатлык җаннар, корал белән янап, комиссарлар Микоян, Габишев, Ганинга ак флаг күтәрергә тәкъдим иткәч, алар моны катгый төстә кире кагалар, андый хурлыкка барганчы, пуля астына керүе хәерлерәк дип белдерәләр[1].

Иван Яковлевич Габишевның шәхси батырлыгы турында 19 нчы батальон командиры Г. Попов та искә ала.

Төрек-немец гаскәрләренең Бакуга һөҗүмен туктату өчен, 19 нчы батальонга Аджикабул-Кюрдамир тимер юл линиясен, күперләрне һәм Кура елгасының сул як ярындагы водокачканы саклау бурычы куела. Дошманның һөҗүме туктатыла, ләкин, көтелмәгәндә, капитан Русский, подполковник Арутюнов әмере буенча батальон командиры Попов кулга алына. Алар Поповны юк итәргә, төрек һәм герман гаскәрләренә юл ачарга булалар. Бу җинаять турында шунда ук С. Шаумянга хәбәр ителә һәм ул комиссар Габишевка Поповны кичекмәстән азат итәргә боера. И. Габишевның тәвәккәллеге белән командир Г. Попов азат ителә[2].

Шулай да меньшевикларның, эсерларның, буржуаз милләтчеләрнең хыянәте нәтиҗәсендә Баку вакытлыча дошман кулында кала. Хәрби боҗра эчендәге Совет Россиясе ул вакытта Баку коммунарларына тиешле ярдәм күрсәтергә өлгерә алмый. Баку коммунасы вакытлыча яшәүдән туктый.

1918 елның 4 августында Бакуга инглиз гаскәрләре керә. 14 августта большевиклар, үз көчләрен саклап калу максаты белән, Әстерханга күченергә омтылып карыйлар. Ләкин пароходлар кире Бакуга кайтарыла, барлык партия, совет һәм хәрби җитәкчеләр, шул исәптән И. Я. Габишев та, кулга алына һәм төрмәгә ябыла. А. И. Микоян җитәкчелегендәге берничә партия работнигы гына иректә кала.

Тиздән инглизләрне шәһәрдән төрекләр куып чыгара. Төрекләр Бакуга кергәндә А. И. Микоян кулга алынган иптәшләрен азат итүгә ирешкән була һәм 15 нче сентябрьгә каршы төндә алар, «Төрекмән» пароходына утырып, Әстерханга юл алалар. Пароходтагы инглиз һәм дашнак офицерлары, эсерлар ярдәмендә, капитанны Әстерханга бару урынына Красноводск шәһәренә курс тотарга мәҗбүр итәләр.

Красноводскида инглиз интервентлары һәм аларның ялчылары — эсерлар революцион Баку җитәкчеләреннән 35 кешене кулга алалар һәм төрмәгә ыргыталар. Дошманнар Баку Советының җитәкчеләреннән Шаумян, Джапаридзе, Азизбеков, Фиолетов, Коргановны гына белә торган була. Кызганычка каршы, тентү вакытында Корганов кесәсеннән 25 фамилия язылган исемлек табыла. Әле Бакуда Баилово төрмәсендә утырган вакытта ук, камерада староста буларак, ул ирektән китерелгән азыкны менә шушы табылган исемлек буенча бүлә торган булган. Иван Яковлевич Габишев фамилиясе бу исемлектә теркәлгән була. Ә большевик С. Кондалаки, Хәрби революцион комитет члены Э. Гигоян, А. И. Микоян һәм башкаларны бәхетле язмыш кына үлемнән коткарып кала: аларның фамилияләре исемлектә булмый. Инглизләр 26 нчы кеше итеп Баку комиссарларын эвакуацияләүдә ярдәм иткән кавалерия отряды командиры Т. Әми-

[1] «Юность», № 1, 1968, 71 бит, Б. Бибинейшвили. Ахча-Куймская трагедия. Тифлис, 1935, 148—149 битләр.

[2] Г. Попов. Железный полк имени «26». Баку, 1927, 12, 14 битләр.

ровны алалар. Инглиз генералы В. Маллесон: «Большевиклар үле килеш кенә куркынычсыз», дип уйлый һәм палачлык вазифасын инглиз капитаны Реджинальд Тиг-Джонсон һәм вакытлы «Каспий арты хөкүмәте» башкарма комитеты председателе эсер Ф. Фунтиковка тапшыра.

Коммунистларны көчле сак астында Красноводскидан Ашхабад ягына алып китәләр һәм 1918 елның 20 сентябрендә Ахча-Куйма һәм Перевал станцияләре арасында бернинди судсыз вәхшиләрчә үтерәләр.

Алар егерме алтау иде, егерме алты Баку комиссары: С. Шаумян, П. Джапаридзе, М. Азизбеков, И. Фиолетов, Я. Зевин, И. Малыгин, Г. Корганов, М. Вәзиров, Г. Петров һәм башка каһарманнар белән бер сафта безнең якташыбыз, Казан егете Иван Яковлевич Габишев... Комиссарларны җәзалау — гражданнар сугышының иң фаҗигале сәхифәләренең берсе ул.

В. И. Ленинны Баку комиссарларының язмышы бик борчый.

1918 елның 14 ноябрендә В. И. Ленин Әстерханнан кайгылы хәбәр ала. «Телеграмманы укыгач, — дип искә ала элекке Совнарком эшчесе Э. Вовшина, — Владимир Ильичның йөзе кинәт үзгәрде, карап киткәндәй булды: минем аны беркайчан да мондый кайгылы хәлдә күргәнем юк иде»[1].

1920 елның апрелендә Әзербайҗанда Совет власте торгызылгач, геройларның мәете Бакуга күчерелә һәм олылап күмелә.

Баку комиссарлары төрле милләт уллары иде. Серго Орджоникидзе шул хакта уйланып: «Степан, Алеша, Мишадиның туганнар каберлеге әрмәнне, грузинны, татарны, еврейны аермаган кебек, Баку пролетариаты милли ызгыш-талашны белми», — диде[2].

Каһарманнар бездә онытылмый... Баку комиссарлары мәйданында Мәңгелек ут яна. Бакуда, Красноводскида аларга багышланган музейлар бар. Урамнар, теплоходлар, мәктәпләр, пионер дружиналарына аларның исеме кушылган. Ашхабад — Красноводск юлында 26 комиссар исемендәге разъезд бар. Бирелә зур нигезгә куелган дүрткырлы биек һәйкәл өстендәге алтын йолдыз еракта ук күренеп тора, аларны хәтерләтә, аларга кул күтәргәннәргә карата нәфрәт уята.

Казан... Бик күп каһарманнарның тормышы безнең шәһәр белән бәйле. Шәһәрдә яңа төзелә торган урамнарның берсенә «Комиссар Габишев» исеме бирелде. Аның белән янәшә легендар Рихард Зорге, чех Юлиус Фучик, Бөек Ватан сугышы герое Гани Сафиуллин урамнары.

Мулланур Вахитов исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан химия комбинаты да үзенең революцион һәм хезмәт традицияләренә турылыклы. Агалы-энеле Георгий һәм Константин Петряевлар хөрмәтенә куелган истәлек тактасы шуңа бер мисал. Эшче Петряевлар дәһшәтле 1917 елда заводта Кызыл гвардия отряды оештыралар. 1918 елда ак гвардиячеләр белән ак чехларга каршы көрәштә алар батырларча һәлак булалар. Халкыбызның бөек улы, В. И. Ленин көрәштәше Мулланур Вахитов та завод белән нык элемтәдә торган. Ул бирелә революцион эш алып барган. Мулланур Вахитовны да 1918 елда дошманнар һәлак итте.

1978 елның февралендә Иван Яковлевич Габишевның тууына 90 ел тулган көндә комбинатта митинг булды. Истәлек тактасы ачу

---

[1] «Известия», 11 август, 1976 ел.
[2] С. Орджоникидзе. Статьи и речи. I том. М., 1956, 244 бит.

тантанасына комиссарның кызы Г. И. Черняева, сеңелесе А. Я. Нариманбекова да килгәннәр иде. Чыгып сөйләүчеләр бер-берсен алыштырып кына торды. Социалистик Хезмәт Герое Г. Сәлимҗанов та сүз алды. «Унынчы бишьеллыкны срогыннан элек үтәү өчен, — диде ул, — бригадалар арасында социалистик ярыш бара. Һәр бригада үз исемлегенә бездә эшләгән комиссар Габишевны почетлы эшче итеп кертте һәм аның өчен эшләргә вәгъдә бирде. Ярышларда җиңеп чыккан бригадага Иван Яковлевич Габишев исеме биреләчәк». Бу сүзләр алкышларга күмелде.

Митингта шагыйрь Мөхәммәт Садри да чыгыш ясады. Ул үзенең хезмәт юлын 1928 елда И. Я. Габишев эшләгән цехта башлап җибәргән, хезмәт чыныгуын шунда алган. Мөхәммәт ага Садри Баку комиссарына багышланган шигырен укыды:

Вахитовны — Ленин комиссарын
Үтергәннәр август таңында,
Изге каны Идел суы белән
Агып китеп, Каспий янында
Чүлдән аккан 26 батыр
Каны белән бергә кушылган.
Баку белән Казан туганлашкан.
Кан-кардәше булган шушыннан.

Алар егерме алтау иде, егерме алты комиссар. Моннан 60 ел элек алар изге көрәштә һәлак булдылар. Үзенең азатлыгы, бәхете хакына каһарманлык күрсәткән улларын совет халкы онытмый, онытмаячак!

**Марат МӨЛЕКОВ.**

# ПОЛКТАШЫБЫЗ МУСА ҖӘЛИЛ

*Отставкадагы полковник Ислам Хәйбуллович Хәбиб үзе хезмәт иткән 2 нче Удар армия буенча полкташларының сугышчан юлын өйрәнеп, «Любань операциясе батырлары» дигән очерк язды. Очерк шушы армия ветераннарының советы тарафыннан әзерләнгән китапта урын алачак.*

*Мәгълүм булганча, Любань операциясендә Муса Җәлил катнашкан. Шушы очерктан аңа бәйләнешле бер өзекне укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

Өлкән политрук М. М. Җәлилов ул чакта 2 нче Удар армиянең «Отвага» газетасы редакциясендә эшли иде. Аңарчы монда күренекле совет шагыйре Эдуард Багрицкийның улы Всеволод Багрицкий эшләде. Кышын ул һәлак булгач, аның эш урыны бераз буш торды, ә аннары 2 нче Удар армиянең политбүлеге бу эшкә Мәскәүдән җибәрелгән Муса Мостафовичны билгеләде. Ул хәбәрче булып эшләде. «Аның очерклары һәм мәкаләләре Ватан хакына батырлыкларга рухландыралар иде», — дип яза маршал Н. А. Мерецков.

Фронтка килүенең беренче көннәрендә үк әлеге политбүлек резервында исәпләнгән Муса Мостафович алгы сызыкка омтыла — һөҗүм итүче 2 нче Удар армия сугышчылары арасына җибәрүләрен үтенә.

Баштарак аны аерым задание белән җибәрәләр. Заданиене үтәгәч, ул Малая Вишерага кайта. Март азагы булуга карамастан, кыш әле бирешми: көннәр салкын тора. Хәрби заданиене үтәве турында хәбәр иткәч, Җәлил фатирына кайта һәм хатлар язарга утыра.

Кызы Чулпанга җибәреләсе хатына ул болай дип яза: «...Мин яңа гына сугыштан үз квартирама кайттым. Анда ун көнләп булдым. Без фашистларны кыйнадык. Алар артларына да әйләнеп карый алмыйлар, качалар. Безнең туплар аларны снарядлар белән сыйлый, һәм, монда бик каты салкын кыш булуга карамастан, аларга кайнар...»

*Без барабыз алга,*
*Безнең юлда*
*Ватык туплар, сынган мылтыклар,*
*Кокардалы яшел каска ята.*
*Үлек тәне тосле тутыккан.*

Җәлилнең ул көннәрдә язылган «Өлешеңә чыккан көмешең» шигыре шулай башлана. Әсәрдә илбасар фашистларның фаҗигале күрәчәге сурәтләнә. Ул менә нинди юллар белән тәмамлана:

*Шулай, фашист, безгә килсәң дә син*
*Өмит итеп илнең җимешен,*
*Бер колач җир белән агач тәре —*
*Өлешеңә чыккан көмешең.*

2 нче Удар армия сугышчыларының батырлыклары белән рухланып, Җәлил бик күп патриотик шигырьләр иҗат иткән. Алар хәзер совет поэзиясенең алтын фондына керде.

«Отвага» газетасы хәбәрчесе сыйфатында Муса Җәлил безнең армиянең байтак подразделениеләрендә һәм частьларында булган, сугышчылар, командирлар белән очрашкан. Мондый очрашуларның берсен 327 нче дивизиянең 1100 нче укчы полкының элекке командиры, отставкадагы майор И. К. Сульдин хәтерли.

...1942 елның апреле. Язның юмарт кояшы җирне киптереп һәм җылытып өлгергән. Агачлар инде яшеллеккә күмелеп килгән, болыннарны тәүге чәчәкләр бизәгән, үләннәр буйга тартылган чак.

Төнге һөҗүмнән соң, полк алдына куелган бурычны үтәү хакына фидакарьлек үрнәкләре күрсәткән сугышчылары белән канәгатьләнү һәм горурлану хисләре кичергән майор Сульдин, полк штабына тиешле күрсәтмәләрен бирә дә, яшел үлән өстенә плащ-палаткасын җәеп, уйларына чума. Аның яңа тәэсирләрен куен дәфтәренә теркисе бар.

Урман өстеннән кояш күтәрелеп килә. Аның нурлары агач төпләрен алтынга манган. Иртәнге тынлыкны берәм-сәрәм генә ишетелгән шартлаулар, пулемет тыкылдаулары бозып куйгалый. Төнге бәрелештән соң һәр ике як үз-үзен тәртипкә китерү белән мәшгуль.

Бераздан майор Сульдин, үзенә таба якынлашкан адымнарны ишетеп, яткан җиреннән күтәрелә.

— Исәнмесез, иптәш командир! — дип сәламли аны әлеге хәрби кеше.

Иван Кузьмич алдында бер кулына командир сумкасы тоткан төз гәүдәле офицер басып тора. Иртәнге чык белән юылган кирза итекләре аның байтак юл үткәнен әйтеп тора. Ябыккан йөзендә елмаеп торган зур күзләре, елмаюлы карашы, арыган кыяфәте аны үз иттерә.

— Исәнмесез!— дип, утырган килеш сәламне ала майор Сульдин.

— Мин армия газетасы «Отвага» хәбәрчесе өлкән политрук Җәлилов булам, — дип таныштыра ул үзен. — Төнге бәрелештә батырлык күрсәткән сугышчыларыгыз белән сөйләшмәкче идем, — ди. Ул майорның дәфтәр тотып уйланып ятуын килешли үк күргән икән, сорап куя:

— Ни белән мәшгуль сез, иптәш командир?

— Хикәя язмакчы идем дә, тик булдырып булмый әле, — ди Сульдин. Ул әдәби күнегүләр ясарга ярата икән һәм менә сугыш тынып торган шундый минутларда көндәлек алып бара, киләчәктә язучы булып китәргә хыяллана икән.

— Хикәяне сез хәзер яза алмаячаксыз, — ди корреспондент, Сульдинның өстенә салкын су сипкәндәй итеп.

— Нигә?

— Төн буе сез нәрсә эшләдегез, иптәш майор?

— Һөҗүм иттек...

— Шулай шул менә, димәк, сезгә бу минутта хикәя язарга түгел, бәлки ял итәргә кирәк, — ди Муса.

«Ул чакта, әлбәттә, мин бу очрашуның шундый истәлекле булачагын белмәдем. Бездә башка хәбәрчеләр дә булгалады. Еллар үткәч кенә, Җәлилнең шул чорда төшкән рәсемен күргәч кенә мин аны хәтергә төшердем...» — дип сөйләде Иван Кузмич Сульдин.

Мин И. К. Сульдинны Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәрендә күреп сөйләштем.

**Альберт Яхин**

# «ПУЛЯ ТИЗЛЕГЕНӘ ИЯЛӘШКӘН КАЛӘМ»

Шәхеснең зурлыгы, башкарган эшләренең күплеге һәм төрлелеге белән Шамил Усманов хәтта талантлы шәхесләргә бай егерменче-утызынчы елларда да аерылып, калкып тора. Бу язучы һәм комиссар турында матбугатта мәгълүмат күп бирелде инде. Ләкин Усманов шундый мәһабәт күпкырлы талант: аның турында кай яктан гына килеп сөйләсәң дә, искә алынырга тиешле һәм, әгәр әйтми узсаң, образ бөтенлеге ким була торган берәр сыйфаты барыбер күздән төшеп кала.

Ш. Усманов турында язганда аның гаять кызыклы һәм гыйбрәтле тормышы вакыйгаларын телгә аласы килә. Аларның һәркайсы турында озаклап, сокланып сөйләргә мөмкин. Аның бай иҗат мирасы бар. Шактый әсәрләре татар совет әдәбиятында үз жанрының беренче үрнәкләре булдылар. Бу әсәрләрне җентекләп анализлау, татар совет әдәбияты тарихында аларның тоткан урыннарын билгеләү кирәкле эш булыр иде. Ләкин юбилей уңае белән язылган кыска мәкалә кызыклы тормыш вакыйгаларын да, әсәрләргә күпьяклы анализны да сыйдыра алмый. Шуның өчен, аларга кирәк урында гына тукталып, Шамил Усмановның тотрыклы һәм үзенчәлекле бер сыйфаты турында сөйләү белән чикләнергә тиеш булабыз.

Усмановка «пуля тизлегенә ияләшкән каләм» дигән метафорик билгеләмәне Гадел Кутуй бирә («Кызыл Татарстан», 1925 ел, 178 сан). Бу билгеләмәгә язучының хәрби биографиясе дә, иҗатының кайбер бик мөһим сыйфатлары да кергән. Фикерен ачыклап, билгеләмәсенең эчтәлеген ача төшеп, Гадел Кутуй болай яза:

«Аңарда сүзләр, җөмләләр бер-бер артлы тезеләләр дә узышалар, ашыгалар. Аларның тизлегендә гаскәрилек бар. Сугышны тасвир иткән юлларыннан пуля, порох исләре аңкып тора». Бирелә сүз «Кызыл байрак астында» әсәре турында бара, әмма Г. Кутуй Усманов иҗатына гомумән хас булган үзенчәлекне әйтеп биргән һәм «Шамил Усмановта ораторлык (хатиплык) стиле бар»лыгын күрсәткән.

Зирәк әдәбиятчы Гадел Кутуй шул вакытта ук язучы иҗатын автор шәхесе, ул язган әсәр һәм укучы белән бәйләп карарга омтыла. Шамил Усманов — хәрби кеше. Утны-суны кичкән дәрәҗәле комиссар. Ул менә дигән агитатор, оратор. Аны, генерал чинындагы егерме ике яшьлек егетне, ишетмәгән кеше юк. Комиссарның чыгышларын яратып тыңлыйлар, митингларда аны көтеп алалар.

1920 елның 24 мартында Казанда үткәрелгән митинг турында, мәсәлән, «Кызыл Армия» газетасы мондый хәбәр бирә: «Иптәш Усманов кафедрага чыкканда татар ярлыларының юлбашчылары тарафыннан каты алкыш белән каршы алынды. Бары да аякларына бастылар». (30 март, 286 сан.) Ул басып каршы алырлык абруйлы кеше булган.

Бригада комиссары буларак аңарга яңа гына кулына мылтык алган меңнәрчә эшче-крестьян егетләрен Кызыл Армиянең ышанычлы көрәшчеләре итеп тәрбияләү вазифасы йөкләнә. Оештыру сәләте, ораторлык таланты аңарга бу гаять дәрәҗәдә җаваплы эшне башкарып чыгуда ярдәм итә.

Бригада фронтка китәр алдыннан язган мәкаләсендә комиссар үзе үк: «Хәзерге көндә безнең дә йөзне агартырлык полкларыбыз бар»,— дип ышанып яза. («Кызыл Армия» газетасы, 1919 ел, 7 ноябрь саны.) Шуннан соң легендар Икенче Татар бригадасы гражданнар сугышы фронтларында авыр, ләкин данлыклы сугышчан юл үтә. Академик И. П. Трайнин, башлыча шул бригаданы күздә тотып, болай дип язган:

«Татарлар Көнчыгыш халыклары арасында Октябрь байрагын кулларына тотып, югары күтәрүчеләрнең иң беренчеләреннән булдылар. Алар бу байракны, артта калган милләтләр йөрәгенә революция уты сала-сала, Идел ярларыннан алып Бохарага, Иран чикләренә кадәр илттеләр... Татар сугышчылары үзләренең революцион бурычларын тулысы белән аңлый иделәр». (И. П. Трайнин. СССР һәм милли проблема. Мәскәү, 1924 ел.)

«Революцион бурычларын аңлап», гражданнар сугышының соңгы көненә кадәр көрәшкән Татар бригадасының якты нуры аның беренче комиссары, рухи тәрбиячесе Шамил Усмановка да төшә.

Гадәттә, бу еллардагы язучылар турында, ул революцияне икеләнүсез кабул итте, дип матур сүз әйтәләр. Шамил Усманов — күпләр кабул иткән революциянең уртасында кайнаган көрәшче. Документларда беренче мәртәбә аның исеме Акчуриннар, Дебердеевлар фабрикаларында большевиклар оештырган партия комитетының өч җитәкчесе арасында теркәлгән. Сызрань Дәүләт архивында сакланган документларның икенчесе аның унҗиденче елда ук Совдеп председателе итеп сайлануын хәбәр итә. Ул ялкынлы большевик булып калкып чыга һәм гомеренең соңгы көненә кадәр шундый булып кала да.

Данлы гражданнар сугышы еллары артта кала. Усманов исә көн дә диярлек митингларда чыгыш ясый, газета-журналларга мәкаләләр яза, «Кызыл Армия» газетасы һәм «Тамашачы» журналының баш редакторы була. Башка шартларда, башка чаралар белән пропагандистлык эшен дәвам итә.

Мәшһүр комиссар төннәрен утырып детекторлы радиоалгычлар ясый, аларны сораган бер кешегә өләшеп йөри. Радио һәвәскәрләре түгәрәге оештыра, үзе үк шунда җитәкчелек итә. Радиоалгыч ясарга өйрәтеп дәреслекләр яза. Аның авыл кешеләренә Мәскәүне һәм Казанны көн дә тыңлатасы килә. Детекторлы алгыч белән генә канәгатьләнмичә, Казанда радиостанция төзү эшенә җиң сызганып тотына. Эфирга беренче булып татарча сүзне әйтүче дә ул була.

Язучы татар сәнгатенә аеруча зур игътибар бирә. Үзе пьесалар язу өстенә ул талантлы артистларны илнең төрле почмакларыннан чакыртып, труппалар төзүгә гаять күп көч куя. Театр сәхнәсе җыйган тамашачыларга гына риза булмыйча, уенны шәһәр мәйданнарына, урамнарга чыгара. Революция темасына үзе үк язаган әсәрен йөзләгән артистлар катнашлыгында Казан урамнарында куя. «Красная Татария» газетасы шуннан соң, бу мәһабәт спектакльне биш меңнән артык кеше карады, дип хәбәр итә. (1924 ел, 18 июнь, 36 сан.)

Эсперанто телен өйрәнеп, ул Октябрь азат иткән халыкларның яңа тормышы турында Польша, Венгрия, Чехословакия, хәтта Кытай газеталарында мәкаләләр бастыра («Совет әдәбияты» журналы, 1936 ел, 4 сан).

Замандашлары Ш. Усманов хакында: бик тә чәчелә торган иде, ул тотынмаган, башлап йөрмәгән һәм башкаларны да артыннан ияртмәгән өлкә калмагандыр, дип искә алалар. «Теләсә нинди өлкә» дигәннәрне барысын бергә җыеп карасак, аларның халыкка революция тудырган яңа идеяләрне җиткерү чараларына кайтып калуын күрәбез. Максатын тормышка ашыруда аруны-талуны белмәгән Шамил Усманов. Ул гомере буена халык белән тыгыз бәйләнеш юлларын эзли, мөмкин кадәр зуррак аудитория будырырга тырыша.

Югарыда искә алынган мәкаләдә ул: «Мин язучылыкны үземә һөнәр, кәсеп итеп алган профессионал түгел. Язучылык ярдәмчел хезмәтем генә. Моның сәбәбе... җан-

лы хезмәткә бәйләнеп, аңардан аерыла алмаудан килә», — дип яза. Аның әдәби эшчәнлеге: пьесалары, повестьлары һәм хикәяләре дә, үзе әйткәнчә, мөһим «җанлы эшенең ярдәмчел кисәге», бер тармагы иде.

«Миңа әле егерме түгыз тулмаган, ә... карт язучы саналам», — дип яза Усманов әлеге исемсез мәкаләсендә. Шунда ук ул беренче пьессасы «Канлы көннәрдә»не унтугызынчы елның башында бер кич эчендә язып ташлавы турында әйтә. Шул ук елны аның икенче мәшһүр пьесасы — «Беренче адым» куела. Бу әсәрләрен Ш. Усманов башта — полк, аннары бригада комиссары вазифаларын үтәгәндә иҗат итә. Фронтта сугышчы татар гаскәрләренә, көрәш юлына чыгарга тиешле авыл һәм шәһәр яшьләренә революциянең асылын аңлатучы пьессалар ипи кебек һәм ашыгыч рәвештә кирәк булганга шулай «пуля тизлегендә» яза ул.

Әлеге пьесалар сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан безнең бүгенге таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә үк түгел кебек тоела. Ләкин үз вакытында алар бик тә популяр булганнар. Шамил Усманов аларны, меңнәрчә мәртәбә сәхнәдә уйналдылар, дип искә ала. Ә Фәтхи Бурнаш «Татар театр әдәбияты» исемле мәкаләсендә: «Канлы көннәрдә» белән «Беренче адым» сугыш дәверендә эшче-крестьян гаммасы арасында зур бер дикъкать белән каралып, сөелеп, Россиянең төрле почмакларында сәхнәдән төшми килде», — дип яза. («Безнең юл» журналы, 1922 ел, 1 сан.)

Комиссар -язучы үз алдына көн кадагына сугарлык, шул көнгә файда китерерлек әсәрләр тудыруны максат итеп куя. һәм ул мавыктыргыч булган, кирәк булган, әһәмияттен хәзер күз алдына да китерүе кыен булган зур эш башкара.

Соңрак үзенең даими идеясенең эчтәлеген язучы болай ачыклаячак: «Пролетариат революциясендә катнашкан һәрбер язучының әсәре үз кул көче белән көн күрүчеләрнең дәртләрен, тойгыларын, уйларын сыйнфый көрәш әләме тирәсенә оештырырга тиеш». («Кызыл Татарстан газетасы. «Татар әдәбияты турында деспут». 1924 ел 110 сан.)

Шуннан соңгы елларда Шамил Усманов тагын ике пьеса язачак, бик күп хикәяләр повестьлар иҗат итәчәк, ләкин үзенең сайлаган темасын тугрылыклы булып калачак. Пуля тизлегенә иярләшкән каләм һаман бер ноктага бәрәчәк.

Усманов бөтен дөнья революциясенең тиздән җиңәчәгенә чын күңелдән инанган кеше. Аның өчен бу җиңү шул кадәр бәхәссез һәм табигый ки, ул җир шарындагы барлык халыклар өчен төзеләчәк социализм турында хыяллана, шуңа әзерләнә. Социализм — матур күңелле кешеләр җәмгыяте. Ул җиңүче сыйнфның тыныч төзелеш чорындагы көрәше белән төзелә. «Сыйнфый көрәш әләме» язучы өчен яңа тормышны төзүче көрәшчеләр сафын да белдерә. Киләчәк заман кешесе нинди ул? Шамил Усманов аны «Памирдан радио» повестенда күрсәтә. Техника һәм культура гаять дәрәҗәдә үскән бу җәмгыятьтә кешенең матурлыгы барыбер аның көрәшчелек дәрәҗәсе белән билгеләнә, ди язучы. Ә көрәшче, аның аңлавынча, беренче чиратта — нык рухлы, тайпылуның ни икәнлеген дә белми торган, гражданнар сугышының утын-суын кичкән кеше. Комиссар киләчәкне сурәтләгәндә дә гражданнар сугышы сынавы үлчәмен кертә. Киләчәк заман кешеләренең матурлыгын да дәһшәтле елларда үзе күргән нык рухлы кешеләр өлгесеннән ала.

Шуңа күрә аның темасы даими булып кала. Гражданнар сугышы каһарманнары үрнәге Усмановның соңгы әсәрләрендә дә тәрбия үрнәге булып саклана.

Ул гражданнар сугышы һәм фабрика эшчеләре турында язган. Тагын бер даимилеге: гаскәриләр арасыннан да, эшчеләр арасыннан да горур кешеләрне, үз бәяләрен белә торганнарны сайлый. Ләкин аның геройлары горурлыкларын төрлечә күрсәтәләр. Алар шәхес буларак гап-гади, әмма бик төрле, үзенчәлекле кешеләр. «Ачылган йозак» хикәясендә Фәхри кулыннан башкалар булдыра алмаган эшләр килүе белән горурлана. Аның шул осталыгы белән мактанасы да килә. Теләсә нинди серле сейф йозакларын ача алуын күрсәтү — аның өчен бәхет тә, мактаныч та. Ләкин шикләнеп кырын карый башласалар, ул үз бәясен белә, бәхеттәннән дә, шатлыгыннан да баш тартырга әзер тора.

Үзен рәнҗетүчеләргә әлегә үпкәли генә ала Фәхри. Киреләнеп сораганнарын үтәмәскә генә булдыра ала. «Әптери агай хикәяте»ндәге эшчеләр дә үзләрен рәнҗе-

түчеләргә форсаты чыккач кына тиешенчә җавап бирәләр. Ләкин Фәхри дә, «Әптери агай...»дагы эшчеләр дә рухлары белән коллар түгел инде. Араларына «Беренче адым»дагы революционер Камил кебек егетләр килү белән аның артыннан барырга әзер торалар.

Язучы кешенең кешелек горурлыгын гаять югары бәяли. Өметле кешеләрне ул горурлыгы булганнар арасыннан көтә. Яңа юлга андый кешеләр беренчеләрдән булып аяк басалар, характерларындагы кимчелекләрдән арынып, язучы өчен идеал булган ышанычлы көрәшчеләргә әвереләләр.

Кимчелекләрдән арыну мотивы Ш. Усманов әсәрләрендәге рухи куәтнең, тойгы, хис куертуның нигезе булып хезмәт итә. Төрле кешеләр, төрле характерлар көрәшчеләр сафына да төрле юллар белән киләләр. Үсү, арыну күренеше шуңа күрә төрле киеренкелектәге хис, тойгы тудыра. «Легион юлы»нда ул күпчелек очракта драма белән, я юмор белән тәмамлый, ә менә «Гает корбаны» хикәясендә трагедия югарылыгына күтәрелә.

Хәйрүш карт татар батальонына үз теләге белән килгән. Капчыгында комганы, фикерләү рәвеше, дингә мөкиббән китүе белән күеп куйган патриархаль авыл крестьяны ул. Сугышка китүче иптәшләрен Хәйрүш догалар укып озата, аларны намаз укырга үгетли, гает көнне тезелеп мәчеткә барырга өнди. Иптәшләре баш тарткач, ялгызы гына китә. Хәйрүшнең кимчелеге дә яхшылык өчен хезмәт итә кебек. Картның иске гадәтләргә буйсынуы да аның рухи көчен ачу өчен файдаланыла. Мулла аны акларга тотып биргәч, карт солдат дингә бөтенләй башкача карый башлый. Ләкин бик зур корбан — тормышы исәбенә була аның искелектән арынуы.

«Бар әсәрем нинди дә булса тормыш вакыйгасы нигезендә язылды», — ди Усманов бер мәкаләсендә. Ә вакыйгаларга бай була әдипнең тормышы. Аларның күбесенең үзәгендә ул үзе тора. Ләкин без аның һичбер әсәрендә үзе турында кинаялэп кенә булса да әйткән сүзне күрә алмабыз. Бөтен тормышын «пуля тизлегенә» җайлаштырган бу кеше тормышта да, иҗатында да чиктән тыш тыйнак булган. Ул татар совет әдәбиятына яңа темалар, яңа алымнар белән килеп керә. Заманында аңарга ияреп язучылар да күп була. Ләкин язучы буларак ул үзен бервакытта да аз гына да күтәрми. Ул гомере буена яңалыкка соклана, ләкин күп кенә иске традицияләрнең дә үз заманы өчен файдалы булуын онытмый. Егерменче еллардагы «искелеккә» каршы көрәш шаукымында Габдулла Тукайларны, Фатих Әмирханнарны икеләнүсез яклап чыга, алардан өйрәнергә чакыра. Әдәпле, тыйнак, көчле шәхес булган Шамил Усманов, шуңа күрә ясалма рәвештә үз-үзен күтәрү хакында уйлап та карамаган. Ул оратор, пропагандист булган һәм бу кешенең хезмәтен, иҗатын, шәхесен популярлаштыру нәкъ менә пропаганда максатында гаять әһәмиятле булыр иде. Соңгы вакытта журнал битләрендә барган поэзия турында сөйләшүнең авторлары арасында татар совет әдәбиятының безгә изге булган традицияләрен кире кагучылар да юк түгел. Усманов кебек тарихи шәхесләр аларга үзләре турында уйлау өчен бик гыйбрәтле үрнәк була ала.

Шамил Усмановның иҗаты кызыклы һәм әһәмиятле. Аның әсәрләреннән дары исе аңкып тора икән, ул дары исе аңкып торган кул белән язылганга шулай. Аның уңай геройларында ясалмалык юк икән, алар ихлас күңелле, чын мәгънәсендә уңай язучы тарафыннан язылганга шулай. Автор, син үзең кем? Әсәрләреңдә сөйләгән идеяләреңә үзең җавап бирәсеңме? Бу сорау сүз уңаеннан гына куелган сорау түгел. Татар әдәбиятының күренекле әдипләре горурланып, сокланып туймаслык шәхесләр булганнар. Бу хакыйкатьне кабатлап тору һич тә зыян итмәс иде.

Хәзер әдәби әсәрләрне әдип — әсәр — укучы системасында өйрәнү мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Бу системаның бер яссылыгы — әхлак мәсьәләсе. Нәкъ менә шул яссылыкта Шамил Усманов әсәрләре бай мәгънә алалар, өстәмә эмоциональ буяулар белән төсмерләнәләр.

Миләүшә Маннурова

# ШАМИЛ УСМАНОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗМ ИДЕЯЛӘРЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Шамил Усманов үзенчәлекле язучы булып шаулы революция елларында үсеп чыкты. Кискен каршылыклар, героик драматик вакыйгалар белән характерлы бөек чор аның биографиясенә дә, шәхси характеры һәм дөньяга карашына да тирән эз салды, әсәрләренең эчтәлеген һәм үзенчәлеген билгеләде.

Шамил Усманов 1898 елның 26 декабрендә Саратов губернасында авыл укытучысы семьясында туган. 16 яшеннән ул Актүбәдә слесарь булып эшли башлый. Аннан соң Сызраньда Акчуриннарның туку фабрикасына керә, революцион хәрәкәткә тартыла. 1917 елның мартыннан алып ул партия сафларында. Октябрь революциясе вакытында булачак язучы, партиянең актив һәм ышанычлы солдаты буларак, РСДРПның Сызрань комитетына сайлана.

1918 елның гыйнварында партия Ш. Усмановка, Сызраньдагы фронттан кайткан солдатлар һәм эшчеләрне туплап, отряд оештырырга куша. Шул отряд белән ул Оренбург фронтына китә, Кызыл Армия комиссарының сугышчан юлы шулай башлана. 1918 елда татарлар, руслар һәм Австрия, Германия хәрби әсирләреннән торган «III Интернационал легионы», комиссар Шамил Усманов җитәкчелегендә, Оренбургны азат итү өчен барган сугышларда катнаша.

1919 елда Ш. Усманов — Беренче татар бригадасының комиссары. «Революциянең кызыл байрагын Волга ярларыннан Персия чикләренә кадәр илтеп җиткергән бригада бу»,— дип язган алар турында академик И. П. Трайнин.

Бераздан Шамил Усманов Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге начальнигы итеп, ә автономияле Татарстан республикасы төзелгән чорда Ревком секретаре итеп билгеләнә. 1927 елда дивизия комиссары дәрәҗәсендә язучы Кызыл Армия сафларыннан демобилизацияләнә һәм гомерен иҗат эшенә багышлый.

Әсәрләренең төп геройлары итеп ул тормышның төбеннән күтәрелгән, халык арасыннан чыккан революционерларны һәм көрәш юлына баскан миллионлаган гади кешеләрне ала. Шул ук вакытта автор большевистик аңлылык белән стихиячелек, революцион дисциплина белән башбаштаклык, ачык бер максаты булган пролетариатның оешканлыгы белән бунтарьлык ирege арасында да көрәш баруын яктырта. Мәсәлән, «Гает корбаны» исемле хикәясендә Хәйрүш солдатның революцион дисциплинаны бозуы, дини ышанулардан арына алмавы аны һәлакәткә китерүе күрсәтелә.

...Әдәбият һәм сәнгатьтә бер дә искерми торган темалар бар: дөнья сугышлары, крестьян кузгалышлары, давыллы революция көрәшләре... Халыкның зурлыгы, рухи көче һәм күркәм сыйфатлары нәкъ менә шундый олы кузгалышлар вакытында аеруча тулы һәм калку чагыла. Давыллы чор каһарманнар тудыра, үзенчәлекле характерлы, колоритлы шәхесләр тәрбияли. Тарихның зур борылыш ноктaларына тукталып, дөньякүләм әһәмияткә ия вакыйгалар фонында халык массаларының үтә каршылыклы һәм гыйбрәтле язмышын сурәтләүгә багышланган сәнгать әсәрләре: пьесалар, роман-повестьлар совет әдәбиятында байтак.

Октябрь революциясеннән соң совет әдәбияты төп тема итеп революция һәм гражданнар сугышы вакыйгаларын алды, тарихта революцион массаларның роле, аларның сыйнфый аңы формалашу һәм үсү мәсьәләләре яңа әдәбиятның эчтәлегенә әверелде.

Бу темалар татар язучыларының да игътибарыннан читтә калмадылар, билгеле: чөнки сүз Россиядәге һәр милләт өчен әһәмиятле һәм дөньякүләм мөһим булган иҗтимагый, тарихи вакыйгалар турында бара иде.

1920—1930 нчы елларда язылган иң яхшы китапларда революциянең тарту көче, тормышның давыллы каршылыклары аша халыкның революциягә килүе дөрес,

ышандырырлык итеп тасвирлана. Менә шундый әсәрләрдә инде интернационализм темасы көчле яңгырады, интернациональ геройлар сурәтләнде. Чөнки революцион көрәш барышында халыклар арасындагы дуслык ныгый, гомуми ирек өчен барган көрәшкә барлык милләт кешеләре кушыла. Бу елларда басылган китаплар изелгән, җәберләнгән милләтләргә революциянең тәэсирен күрсәтүче тәүге әсәрләр булдылар.

Ш. Усмановның беренче әсәрләре гражданнар сугышы вакытында язылганнар. Аларда яңа чор кешесенең портреты, революциядә катнашкан киң массаларның гомуми образы, аларның интернационализм рухында тәрбияләнүе сурәтләнә. Язучының «Канлы көннәрдә», «Беренче адым» дигән пьесалары фронттагы татар театры сәхнәләрендә куела һәм меңләгән гади тамашачыларның игътибарын яулап ала. Камил кебек революция көрәшләре эчендә чыныккан кеше образы биредә үзәктә тора. Аның аерым сыйфатлары халык массаларының көрәше фонында күрсәтелә. «Канлы көннәрдә» пьесасында, татар революционерлары белән беррәттән, рус революционерлары Соловьев, Гладилов образлары бирелгән. Алар халыклар арасындагы бердәмлек идеяләрен яклап: «Немец, латыш, рус эшчеләре — барыбыз да кызыл байрак астына тупланып, алга атлыйк, туганнар!» — дип чакыралар.

1920 елдан башлап Ш. Усманов хикәяләр, повестьлар яза башлый. Гражданнар сугышының каһарманлык, фидакарьлек таләп иткән, драматик кичерешләргә бай вакыйгаларын сурәтли. Изүче сыйныфларны юк итү һәм яшь Совет дәүләтенең эчке һәм тышкы дошманнарын тар-мар китерү өчен барган дәһшәтле, рәхимсез көрәшне чагылдыра.

Язучының «Таң» дигән повесте тарихи-революцион жанрга карый дисәк, ялгышмабыз. Биредә рус һәм татар эшчеләренең революциягә кадәрге авыр тормышы сурәтләнә. Язучы эшчеләрнең көнкүрешен барлык каршылыклары белән күрсәтә. Бер яктан — тоташ әчкечелек, сугышулар, рухи ярлылык. Шул ук вакытта изелгән, кимсетелгән бу кешеләр гаделлек эзли, шуңа омтыла. Әүвәл зәгыйфь кенә сиземләнгән бу омтылыш әкренләп үсә, эшчеләр үзләренең җәмгыятьтәге, тормыштагы рольләрен аңлау дәрәҗәсенә күтәреләләр. Әсәрдәге Сөләйман образы мисалында язучы шушы процессны күрсәтә. Башта стихияле рәвештә генә каршылык күрсәткән бу кеше, тормышта күпне күргәннән соң, көнбатыштан килгән алдынгы эшчеләр белән аралашкач, революцион хәрәкәткә катнашып китә.

Канлы империалистик сугышка каршы аңлы рәвештә бергәләп чыгу төрле милләт кешеләре арасында дуслыкның ныгуына китерә. Мәсәлән, поляк хатын-кызы Марианна ярдәмендә Сөләйман тормышта дөрес юл таба, большевиклар белән таныша. Төрле милләт вәкилләре булган Сөләйман һәм Марианна — хикәядә тигез хокуклы геройлар, авторның идея-художество фикерен ачуда икесе дә бик мөһим образлар.

Ш. Усмановның «Тиң түгелләр» һәм «Эшче кызы Нина» исемле хикәяләрендә татар һәм рус эшчеләре арасындагы дуслык, бердәмлек тормыштагыча реаль күренеш һәм вакыйгалар аша чагыла. «Таң» хикәясендә тасвирланган тормыш күренешләре «Эшче кызы Нина» хикәясе өчен көнкүреш фоны булып тора кебек. Бу караңгы фонда рус кызы белән татар егетенең мәхәббәте бигрәк тә якты нур булып балкый. Милли һәм дини чикләүләр кешеләрнең чын хисләре өчен киртә була алмыйлар икән. Төрле милләт кешеләре арасындагы рухи дуслык биредә кыю һәм ачык итеп сурәтләнә. Хикәядәге идея бик мөһим һәм актуаль булуын автор үзе дә яхшы аңлаган: геройларына — Нина һәм Газизгә — югары әхлакый сыйфатлар һәм милли горурлык хисе биргән. Биредә язучының фикере ачык: бары үз халкын олылаган кеше генә чын интернационалист була ала һәм икенче милләт кешеләрен дә хөрмәт итә белә.

Язучы үз геройларының бай эчке дөньясын бик оста һәм нәзакәтле итеп ачып бирә, уйлары, эшләре аша аларның хисләрен, кичерешләрен гәүдәләндерә. Төрле милләт кешеләре арасында дошманлык тәрбияләүче диннең реакцион асылын фаш итә.

Ш. Усмановның бу хикәясе татар совет әдәбиятында халыклар арасындагы бәйләнешләрны, дуслыкны шулай конкрет һәм кыю итеп чагылдырган беренче әсәрләрдән иде. Авторның үз геройларына мөнәсәбәте ничек сиземләнә дигәндә, шул: аның хикәяләрендә кайсы да булса бер милләт вәкилен романтик идеаллаштыру юк.

Татар совет әдәбияты үскән һәм язучының эш тәҗрибәсе киңәйгән саен интернационализм, халыклар арасындагы дуслык, фикер бердәмлеге мәсьәләләре аның

әсәрләрендә тагын да тирәнрәк чагыла, ә соңга таба бу тема инде бигрәк тә зур урын ала.

Талантлы әдип Г. Ибраһимов кебек үк, Ш. Усманов та рус һәм татар халкының дуслыгын тормыштагыча тасвирлый, рус революционерларын татарларның дуслары, көрәштәш иптәшләре итеп таный.

Гражданнар сугышы елларында фронтларда төрле милләт кешеләре арасында туган дуслыкны яктырту әдәбиятта интернационализм пафосы тууга китерә. Бу еллардагы татар әдәбиятының герое — төрле милләт кешеләреннән оешкан һәм кулга-кул тотынып көрәшкә күтәрелгән халык массалары ул. Моңа мисал итеп Ш. Усмановның «Ай чыкканчы», «Митинг» дигән хикәяләрен күрсәтергә мөмкин.

Интернационализм идеяләре «Памирдан радио» исемле маҗаралы-фантастик повестьта да көчле яңгырый. Әсәрнең романтик герое Җаббар хәтта ерак илләрдәге изелгән халыкларны азат итү өчен көрәшеп йөри, гомуми эш өчен ул үз бәхетен корбан итәргә әзер.

1922 елдан 1934 елга кадәр Ш. Усманов «Легион юлы» исемле дилогия өстендә эшли. Әсәр чын тормыш фактларына нигезләнгән эпопея итеп планлаштырыла.

1929 елда, «Кызылармеец» газетасының 14 нче номерында, автор бу әсәренә «Хикәяне башлау алдыннан берничә сүз» язган. Анда ул болай ди:

«Кызыл Армия тарихчысы бөек көрәш китабын язганда, Актүбә фронтының истәлекләренә туктап, тиешле урын бирер. Ә мин, укучылар каршында ул көрәшнең аерым күренешләрен җанландырырга, 18 нче елда Тургай далаларын буйга-аркылыга кисеп үткән мадьяр-татар легионының батыр көрәшчеләрен искә төшерергә теләп, шушы хикәямне яздым».

Әсәрнең төп герое — төрле телләрдә сөйләшүче сугышчылар массасы. Бу коллектив бер җыелма образ булып күз алдына баса. Аның үзенең психологиясе, рухи дөньясы бар. Авыр походларда, көрәш эчендә революцион массаның корыч ихтыяры үсү — массаларның көндәлек каһарманлыгын тасвирлау — хикәяләүнең эчке этәргеч көче булып тора. Бу коллективның гади кешеләре, геройлык турында уйламыйча, зур батырлыклар эшлиләр. Пулеметчы Сәет, разведчик Григорий — шундый кешеләр. Язучы катлаулы чорда дәһшәтле каршылыклар бәрелешенең аерым кешеләр язмышына зур тәэсир итүен күрсәтә.

Әсәр тарихи-революцион жанрга якын тора дияргә була. Г. Халит аның турында: «Егерменче елларның дәвамында языла килеп, утызынчы еллар башында тәмамланган бу әсәрнең фактик җирлегендә төрле милләт вәкилләрен бер бөтен революцион коллективка әйләндергән көрәш — азатлык дошманнарына каршы сугышларда үткән героик походы ята. Ул походтан чорның драматизмы, тарихи мәгънәсе, политик пафосы һәм гуманистик рухы бөркеп тора.

Тарихның киеренке, катлаулы шартларында революцион массаның корыч ихтыяры формалашу — «Легион юлы»ның үзәк эстетик сызыгы»,— дип яза [1].

Әйтелгәнчә, Ш. Усманов үзенең бу хезмәтен озак еллар эшкәртә һәм бу әсәр татар әдәбиятында күренекле бер урын ала. Интернационализм темасын яктырткан һәм бу мәсьәләне киң планда караган иң яхшы әсәрләрнең берсе санала ул.

Рус, татар, венгр, чех милләте вәкилләренең характерларын Ш. Усманов тормыштагыча тәгәл итеп бирә. Автор бу кешеләрнең һәркайсын яратып, сокланып күзәтә, бер-ике сүз белән булса да аларның милли үзенчәлекләрен билгели. Иң әһәмиятлесе исә шул: бу кешеләрне берләштергән изге интернационализм хисләре аларның төп сыйфаты икәнен исбат итә. Совет хөкүмәте игълан иткән теләктәшлек идеясе беренче империалистик сугыш әсирләренең йөрәкләрендә тирән эз калдыра. Пролетар интернационализм хакына, рус революциясенең казанышларын саклап калу хакына бу кешеләрнең күбесе хәтта гомерләрен дә корбан итәләр.

Шулай итеп, әсәрнең төп темасы — интернациональ бердәмлек, уртак идея белән рухланган немец, венгр, чех, рус, татарларның легион эчендә коллективка берләшүе. Шушы фактган чыгып фикер йөрткәндә, татар әдәбиятында бу ягыннан Ш. Усманов повесте белән чагыштырырлык әсәр юк бугай.

Бу елларда, гадәттә, бүтән милләт кешесе образлары татар язучылары әсәрләре-

[1] Халит Г. Яңа герой ничек туды. «Герой, стиль, осталык» дигән җыентыктан. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1972, 20 бит.

нә очраклы рәвештә генә кертелә иде. Ш. Усманов өчен исә башка милләт кешеләренең характерын бирү зур бер әсәрнең төп темасы булып тора.

Әсәрдә халыклар арасындагы дуслык тормышның иң изге, иң кыйммәтле бер ягы итеп күрсәтелгән. Автор, марксизм-ленинизм өйрәтмәләренә таянып, сыйнфый көрәш барышында, тормышны тамырыннан үзгәртеп корганда интернациональ дуслык барлыкка килүен сәнгатьчә аңлатып бирә алган. Геройларындагы гомумхалык, интернационализм идеяләрен коммунистик идеаллар белән бәйләгән.

Заман сулышын тою, бердәм көрәштә барлыкка килгән дуслыкны үз әсәрләрендә яктырту, Совет хөкүмәтенә хөрмәт белдерү — Ш. Усмановка гына түгел, кайбер чит ил язучылары әсәрләренә дә хас сыйфатлар. Россиядәге революция бу илләрдәге хезмәт ияләре өчен юаныч, киләчәк көннәрнең үрнәге булып саналган. Мәсәлән, Венгрия әдәбиятында революциядә катнашкан рус кешесе образын бирү хәсрәт, бәла-каза китергән сугышка карата халыкның ачуын аңлату өчен файдаланылган. Фронтларда туган һәм ныгыган теләктәшлекнең солдат шинельләре кигән венгр һәм русларны якынайтуы турында Ж. Мориц 1917 елны үзенең «Йошка Шаму Киш» исемле хикәясендә язып чыккан. Дюла Юхас исә «Русский» исемле хикәясендә тыныч хезмәтеннән аерып, көчләп фронтка куылган рус крестьянынын поэтик образын иҗат итә. Сугышта, венгр халкы кебек үк, җәбер күргән рус халкын якын итү һәм бөтен дөнья халыклары өчен тынычлык теләү аның бик күп әсәрләрендә очрый.

Чит ил язучылары үз геройларының Россиядә булулары, сугышларда катнашулары турында, гадәттә, әсәрләрендә әйтеп кенә үтәләр. Ш. Усманов исә үзенең дилогиясендә бу геройларның Кызыл Армия отрядларында ничек сугышып йөргәннәрен күрсәтә. Аның китабында күп милләтле хезмәт ияләре массаларының Совет республикасы өчен батырларча көрәшүе турында җентекләп сөйләнә.

Бу мәсьәләдә Ш. Усмановның иҗади карашлары күренекле язучылар А. Серафимович, Д. Фурманов, Г. Ибраһимов, Вс. Иванов үстергән совет әдәбияты традицияләренә килеп тоташа. Алар да бит Совет республикасы өчен барган көрәштә массаларның интернациональ бердәмлеге туу темасын эшкәрткән язучылар.

Безнең илдәге күп милләтле әдәбиятта да, чит ил әдәбиятында да (атап әйткәндә: венгр, чех, румын әдәбиятында) рус кешеләре, рус революционерлары образлары бик еш очрый. Андый әсәрләрдә русларның характерындагы интернационализм, башка милләтләргә карата дуслык, иптәшлек мөнәсәбәтләре күзәтелә. Милли революцион кадрлар әзерләүдә аларның ярдәме һәм җитәкчелек роле ачыклана.

Ш. Усманов әсәрләрендә тормышны сәнгатьчә үзләштерү тулылыгы сизелеп тора. Тормышны шулай аңлау аның әсәрләрен үз вакыты өчен эстетик бер ачыш итте, аңа татар әдәбияты тарихында лаеклы урын тәэмин итте.

## Шамил Усманов

# БЕРЕНЧЕ АДЫМ

*Мәгълүм булуынча, Шамил Усманов — Татарстан радиосын оештырган һәм татар телендә беренче тапшыруларны юлга салган кешеләрнең берсе. Биредә без аның шул эшчәнлеге хакында егерменче еллар ахырында язылган үз истәлекләрен урнаштырабыз. Истәлекләр рус теленнән тәрҗемәдә кыскартып басыла.*
***РЕДАКЦИЯ***

Залда утырган барлык делегатлар минем чыгышны аеруча киеренке бер игътибар белән тыңлады. Мин трибунадан төшкәндә бөтен зал тып-тын утыра иде. Бик уңайсыз булып китте. Чөнки мин чыгышыма карата башка мөнәсәбәт көткән, делегатларның теләктәшлек күрсәтәчәкләренә ышанган идем. Ләкин күтәрелгән мәсьәлә аларның күпчелеге өчен көтелмәгән яңалык булып чыкты. Үз урыныма табан атлаганда өзек-өзек сүзләр, фикерләр колагыма чалынды.

— Мәсьәләдән читкә китте бу.

— Сүз бирмәскә кирәк иде.

— Монда без эшлекле мәсьәләләр тикшерәбез, ә ул радио-радио дип баш катыра.

Делегатлар арасындагы ул төркемнең фикерен Минзәлә партоешмасыннан килгән иптәш Мөслимов бәян кылды.

— Без иң гади мәсьәләләрне крестьяннарга аңлатып җиткерә алмыйча баш ватабыз, ә Усманов биредә безгә үзенең радиосы хакында сөйли.

Һәм делегатларның бер өлешен дәррау көлдереп, аннары болай дип өстәде:

— Крестьян агайга радиодан түгел, җиз торбадан туп-туры колагына кычкырсаң да, начар ишетә әле ул!

Ләкин конференциядә мин әйткән идеяләргә теге яки бу рәвештә теләктәшлеген белдергән кешеләр дә аз түгел иде.

— Зарар юк, иптәш, күңелеңне төшермә. Кыю һәм яңа идеяләр тиз генә юл ярып китә алмый алар.

Ә республика газетасы редакторы иптәш Рубинштейн исә:

— Шушы темага мәкалә яз әле. Мин аны бастырып чыгарачакмын,— диде.

Һәм, күп тә үтмәде, «Известия Татцик» газетасының беренче битендә минем мәкалә дөнья күрде[1].

Дөресен әйткәндә, радио белән мавыгуым бала чагымнан ук килә. Оренбургта һөнәр училищесында укыган елларда чын һәвәскәрләрчә электротехника белән өвәрә килдем. Николаев шәһәрендә чыга торган «Электричество и жизнь» журналын да алдыра идем. Бу өлкәдә минем иң югары казанышым — шушы журналда бирелгән сызымга карап, «ике звоноктан торган чыбыксыз телеграф» төзү булды.

Егерме икенче елның язында безнең хәрби частебыз Кушка каласында лагерьда тора иде. Һәм шунда мин куәтле радиотапшыру станциясе эше белән танышу мөмкинлеге алдым. Аңлаешсыз морзе сигналларын тыңлап, колакка кигән килеш сәгатьләр буе утыра торган идем. Радиостанция хезмәткәрләре әйтүенчә, соңгы вакытларда эфирда җанлы сөйләмне ишетергә, хәтта музыка тыңларга мөмкин икән. Әмма алар бик сирәк яңгырый, чагыштырмача кыска дулкында — 500 метрдан 1200 метргача гына диапазонда бирелә, диделәр. Ә радиотелеграф биш меңнән алып егерме биш мең метрлы дулкында эшли. Аппарат янында шулай утыра торгач, ниһаять, көннәрдән бер көнне минем үземә дә трубкада җанлы кеше тавышын ишетергә туры килде. Бу тавыш иясе, мөгаен, моннан бик күп мең чакрымнарда торадыр диган уй күңелне җилкендереп җибәрде.

Егерме икенче елның җәй ахырында Казанга кайттым.

Монда иң беренче күзгә ташланган нәрсә — Казан радиостанциясенең алтмыш метр биеклектәге галәмәт зур мачталары булды. Җай чыгу белән үк мин станциягә килеп, андагы хезмәткәрләрдән рация һәм радиолаборатория начальнигы инженер Александр Тихонович Углов, аның иң якын хезмәттәше Анатолий Васильевич Ликарев, радиобатальон комиссары иптәш Константинов белән таныштым һәм шуннан бирле радиостанциягә бик еш килеп йөри башладым. А. Т. Углов үзе төзегән радиотапшыргычка сынау үткәрә иде. Тапшыргычының куәте кечкенә булуга да карамастан, станцияне илнең иң ерак төбәкләрендә һәм хәтта Европа шәһәрләрендә дә ишетәләр, шул хакта телеграмма-квитанцияләр җибәрәләр иде. Шундыйрак сынау эшләрендә катнашасым килеп, мин А. Т. Угловтан контроль өчен радиоалгыч сорап торырга булдым. Чамасыз катлаулы процедуралар — төрле резолюция салдыру, анкеталар тутыру, дәүләт серләрен читкә таратмаска вәгъдә иткән катгый ант язулары бирү һәм җиде данәдә наряд кәгазьләре тутырулардан соң мин, ниһаять, хәрби максатлар өчен файдаланыла торган детекторлы радиоалгыч алуга ирештем.

Бүгенге нәфис ЭЧЭСлар белән чагыштырганда, ул аппаратның тышкы күренеше, әлбәттә, әллә ни мактанырлык түгел иде. Ярты метр биеклектәге калын панельдә галәмәт зур конденсатор һәм аның май салынган изоляциясе, әллә күпме контакт чы-

[1] Кара: «Известия», ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм ВКП(б) өлкә комитеты органы, 1922 ел, 25 сентябрь саны.

быклары һәм спираль рәвешендәге кереш-тоташтыргычлары шактый ук сәер тәэсир калдыралар иде.

Тантаналы бер кыяфәт белән мин шушы радиоалгычны күтәреп өйгә алып кайттым. Шунда ук өй түбәсенә антенна куя башладым. Тулай торакта безнең белән яшәүчеләр (иске Горшечный урамындагы беренче номерлы Советлар йорты) астан минем мәтавыкланганны күзәтеп торалар. Сөйләшкән сүзләре дә ишетелгәләп китә:

— Яшеннән саклагыч җайланма ясыймы әллә?

— Юләрләнгәндер ул, юкса шушындый җилдә өй түбәсендә йөрмәс иде.

— Күгәрчен асрарга урын сайлый булса кирәк.

Антеннаны аннан-моннан беркетеп, җиргә төштем дә үз бүлмәмә керешли, барлык кеше алдында хәзер радиотелефон тапшыруын күрсәтәчәгемне әйттем. Бәхетемә каршы, нәкъ шул минутта тапшыру башланган иде һәм миңа эфирда кеше сөйләгән тавышларны тоту авыр булмады. Шатлыгым эчемә сыймый иде, җыелган кешеләрнең барысына берничә генә секунд булса да тыңларга биреп, аларны радионың чын нәрсә булуына ышандырдым. Ә аннары тапшыруның кабул ителүе хакында әйтергә дип лабораториягә чаптым.

Эфир ул елларда чагыштырмача тыныч иде. Коләкса кигән килеш «эфир буйлап сәяхәт итү» ул елларда чүлдә йөрүне хәтерләтә иде. Бик сирәк кенә әллә кайлардан аңлаешсыз сигнал ишетелеп куя, ә кеше сөйләвен, гомумән, әллә нидә бер ишетергә мөмкин. Германия, Франциядәге берничә станция, ә безнең илдә бары тик Мәскәү һәм үзебезнең Казан радиостанциясе эксперимент тәртибендә эфирга чыккалый иде. Шул вакытларда Казан радиолабораториясе якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә Мәскәүдән бирелә торган тапшыруларны кабул итә башлады. Радиолаборатория янында баганага арзан граммофон торбасына охшаган калай рупор беркетеп куелган. Тавышы ярыйсы ук чиста чыга, тик бераз зыңгылдавы гына бар иде.

Мәскәү концертларын тыңларга багана янына күп кенә халык җыела. Ул тапшыруларны тыңлый-тыңлый, минем күңелдә радионы, киң колачлы тапшырулар оештырып, практик максатларда файдалану теләге өлгереп җитте. Бу уйларымны радиостанция хезмәткәрләре белән уртаклашып, тормышка ашарлык булуына инанганнан соң, бу хакта VI өлкә партия конференциясендә чыгыш ясарга булдым.

Партконференциядәге әлеге чыгыш, радиофикация турында газетадагы мәкалә Казан хезмәткәрләренең киң даирәсендә зур кызыксыну уятты. Һәм без шушы хәлдән файдаланып калырга, алга табан яңа адымнар ясарга дигән карарга килдек.

Мин Татарстан республикасы Халык Комиссарлары Советына Татарстанда радиофикация үткәрү турында язма тәкъдим белән кердем. Ул язу Госплан комиссиясенә җибәрелде. Берничә киңәшмәдән соң, Госплан «сынаулар үткәрү өчен кирәкле булган чыгымнарны ачыклау», «үтәчәк информация күләмен билгеләү», «чыбыклы телеграфны бушату хисабына күпме табыш алырга мөмкин булачагын» исәпләү өчен җитмеш мең сум күләмендә акча бүләргә карар итте.

Госпланның шушы утырышында Идел-Кама элемтә идарәсе вәкиле ип. Игошкин да катнашты. Ул, аеруча нык басым ясап, «чыбыксыз телеграф тарафдарлары аның чыбыклы телеграфка караганда арзанрак, шул ук вакытта ике тапкыр табышлырак икәнлеген исбат итә алган тәкъдирдә генә бу эшнең максатка ярашлы» булачагын белдерде. Ә инде тиешле инстанцияләр Госпланның бу зирәк карарын үзләренчә аңладылар һәм әлеге сумманы җибәрү мәсьәләсен шундый шартларга китереп бәйләделәр ки, аларны алганчы ук егерме икенче елгы совзнаклар үз бәясен югалтырга өлгерде.

Егерме икенче елның Октябрь көннәре алдыннан Мәскәү радиостанциясе бәйрәм тапшырулары программасын игълан итте. Без, шуннан файдаланып, партия һәм совет активын радио белән якыннанрак таныштырып калырга булдык. Радиобатальон сугышчылары көче белән ашыгыч рәвештә радиостанциядән Комклуб бинасына элемтә линиясе сузылды. Булачак радиоконцерт хакында алдан ук хәбәр итеп куйдык. Гаҗәпкә каршы, халык әллә ни күп җыелмаган иде. Күп кенә җаваплы хезмәткәрләр, «уңайсыз хәлдә калу»дан куркып, килмәделәр. «Газетага язып, сөйләнеп йөрү бер нәрсә, эшләп күрсәтү бөтенләй икенче нәрсә. Берни дә чыкмас», янәсе.

Концерт башланырга сәгать-сәгать ярым калды дигәндә, чыбык сузу эшен тәгәлләделәр. Радиостанциядән линияне сынау башланды. Сәхнәгә куелган калай рупордан: «Алло, даем пробу, даем пробу, бер, ике, өч, дүрт» дигән тавыш яңгырады. Монысы гаҗәп нәрсә түгел иде әле — тавыш чыбыклар буйлап килә иде. Менә, ниһаять, «Тыңлагыз, Мәскәүне бирәбез» дигән сүзләр яңгырады. Рупорда җиңелчә генә ысылдаган, чыелдаган тавышлар ишетелеп китте һәм кинәт бик ачык тавыш белән кемдер:

— Алло-алло! Алло! Мәскәү сөйли, тапшыру Сокольникидагы радиостанциядән бара...— диде.

Залда киеренке тынлык урнашты.

— Радио тыңлаучы иптәшләр! Артистлар килеп җитмәгәнлектән, концертыбызны бераз гына кичектерергә туры килә. Мәскәү хезмәт ияләренең Октябрь демонстрациясе вакытында урам хәрәкәте тукталып тору сәбәпле, артистлар студиягә соңгарып киләләр. Концертны ун-унбиш минуттан башлап җибәрәчәкбез...

Рупор тынып калды. Залда исә кызуланып фикер алышу, гөрләшү китте. Димәк, чыннан да, Мәскәү тапшыруы икән... Ниһаять, гомердә беренче тапкыр радио тыңлыйбыз...

Биш минут үттеме-юкмы, рупорга янә җан керде һәм шунда ук концерт та башланды. Хәтерем ялгышмаса, ил күләмендә беренче радиоконцерт иде бу.

Икенче тапкыр мин Казанга 1927 елның җәендә кайттым. Шушы вакыт эчендә радио бөтен илгә таралып өлгергән иде. Ташкент, Махачкала, Саратов, Нижний Новгород, Харьков һәм башка шәһәрләрдә радиотапшыру станцияләре эшли. Совет радио һәвәскәрләре хәрәкәте дә көннән-көн киңрәк җәелә бара.

Казан исә тып-тын. Арча кырындагы алтмыш метрлы мачталар һәм антенналар да бер эшсез утыра. Ә өй түбәләрендә, кораб мачталарын хәтерләтеп, антенналар күтәрелгән. Аларны детекторлы радиоалгычлар аша Мәскәү тапшыруларын тыңлау өчен корганнар. Лампалы алгычлар ул чагында бик сирәк нәрсә, ә ерак станцияләрне детекторга кабул итү өчен биек антенна корырга кирәк иде.

Казанда радионың торышы белән танышкач, мин ВКП(б) өлкә комитеты секретаре иптәш Хатаевич янына киттем. Сүземне тыңлаганнан соң ул:

— Бу юнәлештә без чаралар күрдек инде, — диде. — Совнарком Почта халык комиссариаты белән сөйләшүләр алып бара. Ике елдан соң безнең үз радиостанциябез булачак.

— Ике ел ул бик озак вакыт, иптәш Хатаевич, — дидем мин. — Казанда радиотапшырулар станциясе эшли башларга тиеш иде инде. Ә аның булмавы һәр адымда сизелә. Бирегә «Радио дуслары җәмгыяте» эшли. Ләкин ул җәмгыятьтә яхшы радиоалгычлары булган һәвәскәрләр генә тора. Һәвәскәрләр хәрәкәте Мәскәүне тыңлау максаты белән оешкан һәм җирле радиостанция төзү белән кызыксынмый. Милли составы ягыннан анда туксан биш процент рус кешеләре. Авыл җирендә, бигрәк тә татар авылларында, радио хакында берни дә белмиләр. Берничә карамастан, станция төзү эшен башларга һәм бу эшне бик кызу алып барырга кирәк.

Иптәш Хатаевич бу фикерләр белән килеште һәм Октябрь бәйрәменә әзерлек комиссиясендә тиешле тәкъдимнәр белән чыгыш ясарга киңәш итте.

Октябрьның X еллыгын үткәрүгә әзерлек эшләрен җитәкләүче дәүләт комиссиясенең көн тәртибенә, башка чаралар белән беррәттән, «радиотапшырулар станциясенә нигез салу» турындагы пункт өстәлде. Мин исә моңа төзәтмә кертүне кирәк санадым. Мондый тәкъдимгә Халык Комиссарлары Советы Председателе урынбасары иптәш Эглит каршы төште.

— Бу мөмкин эш түгел, — диде ул. — Без элемтә идарәсе белән күптән инде ике киловаттлы станция төзү турында сөйләшүләр алып барабыз. Бу эшкә, компетентлы кешеләрнең әйтүенчә, кимендә ике ел вакыт һәм өч йөз мең сум акча кирәк булачак. Ә Октябрь комиссиясе исә егерме-егерме биш, бик күп дигәндә, утыз мең сум акча гына бүлә ала.

— Почта халык комиссариаты мәгълүматлары нык күпертелгән, — дидем мин. — Бер киловаттлы радиостанция төзү өчен өч ай вакыт җитә. Һәм моңа кырык биш-илле мең сумнан артык кирәк тә түгел. Элеккеге радиобатальонның әзер антенна җи-

һазлары булуын исәпләгәндә, бу сумманы утыз-утыз биш меңгә кадәр киметергә мөмкин. Шул чак Идел-Кама элемтә идарәсе вәкиле иптәш Хренов сүз алды.

— Бу — чеп-чи хыял. Безнең ведомство ул эшкә бик житди тестә алыначак һәм станциянең күп еллар буена өзлексез эшләвен тәэмин итәчәк. Бер киловаттлы станцияне өч ай эчендә төзү мөмкин хәл булса да (мин үзем исә моңа ышанмыйм), без аның белән көлкегә генә калачакбыз. Ул илле чакрымнан да ишетелмәячәк. Хәтта Казанның үзендә дә андый станция кычкырып сөйләү урынына пышылдап кына утырачак.

Иптәш Хреновның бу сүзләре комиссиянең кайбер членнарын шиккә калдырса да, күпчелек башкача фикер йөртте.

— Без нәрсә югалтабыз соң? — диде Эглит.— Усмановка Мәскәүдәге тиешле оешмалар белән бәйләнешкә керү өчен вәкаләт бирик. Әгәр станцияне Октябрь бәйрәме көннәрендә өлгертергә һәм акчаны да азрак тотарга мөмкин икән, тәвәккәлләргә ярыйдыр дип уйлыйм.

Шул ук көнне тиешле кәгазьләрне алып, мин Мәскәүгә юл тоттым. РККА Хәрбитехник идарәсе начальнигы Казандагы элекке радиобазаның антенна корылмасын бушлай файдалануга ризалыгын бирде. «Радиотапшырулар җәмгыяте»ндә дә, бераз уйлашканнан соң, безгә ярдәм итәргә булдылар һәм Ленинград шәһәренең Песочная урамындагы 1,2 киловаттлы радиостанцияне Казанга күчерергә карар иттеләр.

Без Мәскәүдән әлеге җәмгыять вәкиле инженер иптәш Алексеев белән бергә кайттык һәм туп-туры Октябрь комиссиясе утырышына килеп эләктек. «Радиотапшырулар җәмгыяте» вәкиле станцияне төзү срогы һәм моның өчен таләп ителә торган акча суммасы хакында минем фикерләрне раслаганнан соң, комиссия радиостанцияне Октябрь көннәренә төзеп өлгертү турында тиешле карар кабул итте.

Гаять ашыгыч рәвештә төзелеш эшләре башланды. Иң элек станция өчен бина табарга кирәк иде. Ә радиолаборатория бинасы элемтә идарәсе карамагында булып, иптәш Хренов анда үзен тулысынча хуҗа итеп сизә иде. Ул катгый рәвештә бинаны бушатудан баш тартты. Мәсьәлә хәл ителгәнче, бик күп вакыт бушка китте.

Ул вакытта мин Татарстан тамаша предприятиеләре идарәсе директоры булып эшли идем. Станцияне төзү Татарстан хөкүмәте тарафыннан миңа йөкләтелгән булганга күрә, мин төзелешне тизләтү өчен идарәнең күптән җайга салынган техник аппаратыннан һәм шулай ук акча һәм матди ресурсларыннан да киң файдаландым.

Станция бинасын чистарту һәм ремонт ясау, электр чыбыкларын үткәрү, электр тогы белән тәэмин итү, җиһазларны кору, студия өчен урын сайлау, тапшырулар программасын төзү, йөзләрчә башка эреле-ваклы эшләр белән иртә таңнан төнгәчә мәш киләбез. Вакыт бик тиз һәм сизелми үтә. Ноябрьның беренче көннәрендә, ягъни Октябрь тантанасына өч-дүрт көн калганда, станциягә Октябрь объектларының әзерлеген тикшерү буенча дәүләт комиссиясе килде. Комиссия членнары төзелеш барышы хакында фикерләрен бик ачык белдерделәр.

— Эш өзелгән. Октябрьга өлгермәячәк, — диделәр алар, бик катгый рәвештә.

Октябрьга әзерлек комиссиясенең 3 ноябрьда үткән утырышында алар үзләре башкарган эш хакында хисап бирделәр.

— Радиостанция Октябрь көннәренә өлгермәячәк. Шушы фактны теркәп, комиссияне алдаган, Октябрьга әзерлек чараларын өзгән өчен уполномоченныйга шелтә белдерергә тәкъдим итәм.

Ләкин мин төзелешнең техник персоналы биргән сүзгә нык ышана идем. һәм моңа комиссияне дә ышандырдым.

— Көндез дә, төннәрен дә эшләрбез, әмма станцияне вакытында тапшырырбыз.

4 һәм 5 ноябрьда монтаж эшләре тәүлек буе тукталмады. Радиостанция начальнигы иптәш Житковский, радиотехник иптәш Мишкин, методист иптәш Михайлов, линия монтеры иптәш Зәбиров һәм инженер иптәш Алексеев көндез дә, төнлә дә алсыз-ялсыз эшләделәр.

6 ноябрь көне. Сәгать биштә станция янындагы кече студия җиһазланып бетте, микрофон куелды. Менә, ниһаять, «Эфирга чыгабыз» дигән сигнал да бирелә. «Башларга мөмкин!»

— Алло, Казан сөйли! Октябрьның X еллыгы исемендәге яңа гына туган Казан радиостанциясе үзенең тыңлаучыларын пролетариатның Бөек бәйрәме белән тәб-

рикли. Ничек ишетүегез хакында телефоннан хәбәр итегез... Тапшыруны татар һәм рус телләрендә алып барабыз...

Бер минут үтмәде, телефоннан шалтыраттылар. Трубканы алдым.

— Радиостанцияме?

— Әйе, тыңлыйбыз.

— Хренов шалтырата.

— Исәнмесез, иптәш Хренов. Сезнең беренче булып шалтыратуыгызга без бик шат. Безнең тапшыруны ишеткәнсездер, аның сыйфаты, тонының чисталыгы хакында әбруйлы фикерегезне әйтерсез дип өметләнәбез.

— Ммм... Тапшыру ярыйсы гына. Аз гына хырылдый. Бүген шуннан башка тапшыру булмаячакмы?

— Тагын берничә сынау үткәреп карыйбыз әле. Әнә Алексеев иптәш хырылдауны бетереп булыр, тавыш сыйфаты да шактый яхшырыр дип ышандыра.

— Һм... Ә сез ул тапшыруларыгызны иртәгәге көнгә калдырып торсагыз икән. Без монда Мәскәүдән концерт тыңлап утырабыз. Туп-туры Зур театрдан бирәләр. Ә шул чакта менә тагын сез комачаулык итәсез.

Хреновтан соң тагын берничә кеше шалтырата. Аларның барысы да бер үк мәсьәлә — тапшыруны кайчан туктатуыбыз белән кызыксына иде. Ләкин бераздан телефонда дулкынланган-шатланган тавыш ишетелде.

— Иптәшләр! Без Заречьедәге эшчеләр клубында барыбыз бергә Мәскәүдән концерт тыңлап утыра идек. Көтмәгәндә сезнең тавышны ишеттек тә бик шатландык. Үз станциябез телгә килде дигән сүз бит бу! Безнең арабызда берничә татар эшчесе дә бар. Алар барысы да сезгә тәбрик сәламнәре җиткерүемне үтенделәр. Клубта телефон эшләмәгәнлектән, күрше бинага йөгердем, шуннан шалтыратуым. Эшләгез, башлаган эшегезне кыю рәвештә дәвам иттерегез, иптәшләр! Без, Заречье эшчеләре, сезгә һәрчак булышырга әзер.

Башкарган эшебез, соңгы вакыттагы йокысыз үткәргән төннәребез өчен безгә бүләк иде бу.

Станцияне кору эшләре белән беррәттән зур радиостудияне җиһазландыру дәвам иттерелде. Ул студия Татар академия театры бинасы фойесына урнашкан иде. Студияне җиһазлау эшләре, тавыш изоляциясе, сигнализация чаралары — барысы да кыска вакыт эчендә ашыгыч тәстә башкарылды.

Бигрәк тә татар халкы арасында радиотапшыруларга зур мохтаҗлык булуын исәпкә алып, без радиостанция эшен җайга салу чорында бирелә торган льготалы айлардан баш тарттык һәм кичектергесез рәвештә тапшырулар оештырырга керештек. Бу вакытта кулыбызда алдан ук төзеп куелган һәм расланган тапшырулар программасы бар иде инде.

Программаны үтәп бару җиңел булмады. Радиостудиядә нибарысы ике-өч кеше бар. Тәҗрибә җитенкерәми. Микрофон дисциплинасы да әледән-әле бозыла. Докладчылар һәм лекторлар тапшыруга еш кына унбиш-егерме минут соңлап киләләр. Шуннан соң ачу һәм нәфрәт белән үзләрен микрофонга җибәрүне таләп итәләр. «Минем докладны өзәргә хакыгыз юк. Мин, күп булса, бары чирек сәгатькә генә соңга калдым!»

Шулай да Казан радиостанциясе даими радиотапшыруларны башлап җибәрде. Мәскәү, Ленинград, Харьков шәһәрләрендәге куәтле радиостанцияләр белән беррәттән Казан радиостанциясе дә эфирга үз дулкыннарын юллады.

— Алло, тыңлагыз, Татарстан радиосы — Казан сөйли. Октябрьның X еллыгы исемендәге радиостанция аша Казан сөйли.

Тапшыруны ике телдә игълан итәләр.

Радиотыңлаучылар күңелендә матур хисләр кабынды.

Станциягә Ташкенттан, Себер шәһәрләреннән h. б. төбәкләрдән тапшыруларны ишетүләрен хәбәр иткән хатлар, телеграммалар яуды.

# ШИГЪРИЯТ ШӘХЕСТӘН БАШЛАНА...

*Шагыйрь белән тәнкыйтьче диалогы*

**— Шигырь — күңел чәчәге генә булса,**
**. . . . . . . . . . .**
**Чәчәк өчен җирдә беркемне дә**
**Беркайчан да үтергәнне тарих белми...**

**РЕНАТ ХАРИС.**

**— Шигърият — кеше күңеленең иң хозур, иң ирекле, иң кешелекле һәм иң матур яшәеше ул...**

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

**(Әңгәмәдә катнашучыларның элегрәк язылган әсәрләреннән.)**

**М. Вәлиев.** Үсеш, алга таба хәрәкәт һәр вакыт яңа проблемалар, хәл итәсе конкрет мәсьәләләр, алар турында уйланулар тудыра. Поэзия турында барган сөйләшүне барыбыз да бертавыштан кирәкле һәм вакытлы дип саныйбыз икән — бу да, минемчә, иң беренче чиратта, әнә шул хәл белән — татар совет поэзиясенең тагын да үсүе, яңа биеклекләр яулавы белән аңлатыла. Шушы биеклеккә, бүгенге дәрәҗәгә күтәрелгән шигърият әйтерсең үзенең кайда, ничек торуын белергә тели һәм, шулай ук, алдагы үрләрне барлап, күзаллап карау нияте белән уйлана...

**Р. Харис.** Әлбәттә, поэзия алдында торган мәсьәләләр гаять күп һәм алар — бик зурлар, җитдиләр. Аларның берникадәрен үзебез өчен ачыклау, көчләребезне барлау, фронтыбызның йомшаграк урыннарын билгеләп табу һәм аларга уртак игътибарыбызны юнәлтү вакыты да җиткән иде инде. Ләкин мене сөйләшүебезне башлап җибәргән мәкаләне «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе» дип исемләү (гәрчә монда куштырнаклар кулланылса да һәм «яки» сүзе аша ул күренешне гражданлык белән бәйләргә тырышу булса да) безнең поэзиябез үсүе өчен иң мөһим булган нәрсәләрне, аның иң авырткан җирләрен, үзәк мәсьәләләрен эченә алырдай юнәлеш бирде микән? Бирсдә, аңлаешлылык мәсьәләсендә, ситуация бик ачык бит: чын шигырь икән, ул аңлаешсыз була алмый. Аңлаешсыз икән — димәк, ул шигырь булып җитмәгән дигән сүз. «Шагыйрь» кешенең, димәк, таланты, осталыгы, тырышлыгы җитмәгән дигән сүз... Ә гражданлык мәсьәләсе минә — үтә мөһим һәм поэзия үсешенең генераль юнәлешен билгеләүче мәсьәлә. Тик шундый олы проблеманы поэзия алдында реаль кыенлык булып тормаган аңлаешсызлык күренеше белән бәйләү бераз гаҗәбрәк тоела...

**М. Вәлиев.** Бу мәсьәләдә мин дә сезнең белән килешкәнгә һәм башка авторлар да җитди генә фикерләр әйткәнгә күрә, ул хакта сүзне артык озынга сузып тормыйк. Ә куелган проблеманың үзенә — гражданлык мәсьәләсенә якынрак килик. Бер кара-

ганда коры социаль яки чиста фәлсәфи категория кебек тоелган бу төшенчә бүген нигә безнең поэзия өчен үтә мөһим булып тора соң?

**Р. Харис.** Чөнки чын, тирән мәгънәсендәге гражданлык ул — олы шагыйрь шәхесенең асылы, үзәге белән бер диярлек, һәрхәлдә, аңа бик якын төшенчә, шуңа тәңгәл килердәй мәгънә. Чын гражданлык төшенчәсе ул һәр вакыт — саф, эчкерсез күңелле, олы йөрәкле булу, тормышны һәм, гомумән, дөньяны бар тулылыгына якын күзаллау, үзеңнең андагы реаль урыныңны, миссияңне ачык аңлау һәм шул миссияне тормышка ашыру өчен ихлас көрәшү дигән сүз. Шушындый ук бөек вазифа шигърият өстенә дә йөкләнмимени?! Чын шагыйрьдән халык һәр чорда шул сыйфатларны ук таләп итмимени? Соңгы вакытта еш кына ишетелә торган «поэзия бирешә башлады» дигән сүзләрнең төбендә кешеләр, укучылар күңеленең әнә шундый зур рухи ихтыяҗы ятмыйммыни?!

**М. Вәлиев.** Әйе, мондый таләп хәтта бүген бер поэзиягә генә дә карамый бугай. Ул башка жанрлар — повесть, хикәя, драма әсәрләре өчен дә — гомумән, әдәбият өчен бик әһәмиятле һәм зарури сыйфатка әйләнде шикелле. Тормышның һәм, аерым алганда, рухи тормышның яңа катламнарга тирәнәюе, кешеләрнең гомум культура дәрәҗәләре нык үсү әдәбиятка булган таләпләрне хәзер бик күтәрде. Әдәбияттан укучылар үз күңелләренең иң кадерле почмагында ятканны, аның иң түрендәге, иң изге һәм олы, мөкатдәс нәрсәләрне әйтүен өмет итәләр. һәм халыкның әнә шул эчке өмете, күңел көткәне—әдәбиятка бердәнбер һәм ышанычлы стимул, иртәгесе үсешенә ышанычлы ориентир. Әйткәнемчә, бу, гомумән, әдәбият өчен. Ә менә поэзияне аерыбрак алсак, аның үзе алдында гына торган, бары тик аныкы гына булган бурычлары бармы соң? һәм, гомумән: бүгенге тормыш өчен, безнең заман кешеләре өчен поэзия — нәрсә ул? Шигърият бүгенге яшәештә нинди
рәк урын тота?

**Р. Харис.** Әйе... Мин үз фикеремне дәвам итим әле. Әдәби жанрларның һәм сәнгатьнең дә тамыры бер үк — шигърияттелек, тормышның, яшәешнең матурлыгын ачу, шул ачышны кешеләр белән уртаклашу...

**М. Вәлиев.** Ә минемчә, поэзия ул — кеше яшәешенең җанлы мизгелләре (басым ясап әйтим: аның һәр мизгеленең) мәгънәсен, матурлыгын, олылыгын ачу һәм шул юл белән кешенең, тормышның бөеклеген, зурлыгын ачу.

**Р. Харис.** Әйе... Мин үз фикеремне дәвам итим әле. Әдәби жанрларның һәм сәнгать төрләренең тамыры бер, уртак дигән идем. Әнә шушы уртаклык аларның җәмгыятьтәге функциясенең дә берникадәр охшашлыгын билгели. Мәсәлән, кешегә акыл, киңәш бирү, нинди дә булса кичерешкә дучар итү, шул халәт аша фикер үткәрү — әдәбият-сәнгатьнең уртак нигезе ул. Ә поэзиягә килгәндә, ул, минемчә, барыннан да элек — кешенең әңгәмәдәше. Ләкин бик сизгер һәм нечкә күңелле, укымышлы, аңлы, тәҗрибәле, югары культуралы әңгәмәдәш.

**М. Вәлиев.** Әле менә үзебезнең фикер сөреше турында уйлап алдым: поэзияне безнең югарыдагыча билгеләвебез, аны шулай аңлатуыбыз — ул үзе үк гражданлык принципларының поэзия торышы белән килеп тоташуы дигән сүз бит. Соңгы вакытта поэзиядә гражданлык турында уйлана башлау ул, күрәсең, поэзиянең җитдилеге, чынлыгы, ихласлыгы турында уйлану нәтиҗәседер, шул уйларның көчәйгән авазыдыр ул. Тик бу уйлану, үткәннәрдән аермалы буларак, инде хәзер икенче вакыт яссылыгында — җитмешенче еллар ахыры (әз генә ераккарак карасак, инде егерменче гасыр ахыры да җитеп килгәнен күрербез) яссылыгында бара. Шуңа күрә безнең гражданлык хакындагы таләпләребез нәкъ менә үзебезнең чор вакыйгалары җирлегеннән, үз чорыбыз яшәешеннән туалар. Алар — җитмешенче елларда яшәүче реаль кешеләрнең реаль күңел таләпләре...

**Р. Харис.** Поэзия турында сүз барганда «җитмешенче еллар» дип бүлеп, аерып куюга мин үзем шикләнебрәк карыйм. Чөнки әллә ничә гасыр элек иҗат ителгән «Илиада»ның һаман яратып укылганын беләм. Аны укып, борынгы заман философиясен, тарихын, культурасын өйрәнеп булганлыгын беләм.

**М. Вәлиев.** Шулай, шигърият үзе мәңгелек, мәңге шиңмәс сихри гөл кебек. Ул кеше күңеленнән шытып чыга, үсә. Ә кеше күңеле — кайчан да кеше күңеле инде ул. Ләкин... Ләкин бит әле кешенең конкрет яшәеше — басып торган җирлеге, көн күргән туфрагы, үтә реаль каршылыклар белән тулы бердәнбер һәм бик конкрет гомере бар. Ул гомернең эчтәлеге дә шактый конкрет һәм күпмедер еллар эчендә, «рамка-

сы»на сыя кебек. Менә шул ноктадан торып, минем үз чорыбызны күздән кичерәсем килә. Ышануымча, һәр заман тормышының үзенчәлекле психологиясе, җаны булган кебек, безнең чорыбызның да үз җаны — үзенә генә хас иң газиз кичерешләре, хисләре, уй-фикерләре, тынгы бирмәс сораулары яши торган, дулкынланып торучы үз сферасы бар. Әнә шул сфера заманның рухи эчтәлеген, аның дөнья үсешендәге урынын, мәгънәсен билгели кебек. Конкрет алып карaганда: инде менә җитмешенче еллар узып бара. Ә ул елларның җаны, яшәеше безнең поэзиядә ничектер канәгатьләнү алырлык дәрәҗәдә ачылып, тасвирланып җитмәде кебек. Һәрхәлдә, алтмышынчы елларның рухи яшәеше шикелле үк ачылмады. Сез моның белән килешәсезме?

**Р. Харис.** Юк. Минемчә, һәр заманның җанын кешеләр алдында торган проблемалар, мәсьәләләр, хәл ителәсе эшләр һәм кешеләрнең әнә шуларны тормышка ашыруда ирешкән рухи һәм матди казанышлары билгели. Шул проблемалар һәм казанышлар, әлбәттә, һичшиксез шагыйрьләр иҗатына да тәэсир итә, йогынты ясый. Аларга багышланган, я булмаса шагыйрьнең аларга мөнәсәбәтен белдергән шигырьләр, поэмалар барлыкка килә. Бу, минемчә, заман рухының тышкы чагылышы. Ләкин әле моннан башка заман рухының эчке чагылышы да бар. Ул — шагыйрьләр иҗатының сыйфаты. Шигырьнең сыйфат дәрәҗәсенә карап, теге яки бу әдәбият тарафыннан заман җанының ни дәрәҗәдә аңланганын шәйләп була... Әмма заманның җаны, аның эчтәлеге дигән сүзне, минемчә, артык примитивлаштырудан, аны бик схематик күзаллаудан сакланырга кирәк безгә. Югыйсә еш кына шундый хәлләр килеп чыга: нигездә дөрес һәм бик вакытлы куелган таләпләр бездә, җиңел карашка очрап, бөтенләй икенче төрле яңгырап китәләр. Мәсәлән, төрле темалар турында акланмаган сүз куерту еш кына шактый схематик, әдәбиятның һәм поэзиянең үзенчәлеген искә алмый торган таләпләр куюга китергәләде. Шуның кебек, биредә дә, безгә диалектик карашка ия булырга тырышырга кирәк. Чөнки безнең һәр көнебездә үткәннең китеп бетмәгән очы һәм киләчәкнең конкрет форма алырга өлгермәгән башлангычы бар. Шуңа күрә, минем уйлавымча, заманның рухи тормышын тулаем ачу шул заманның үз эчендә генә мөмкин түгел. Сергей Есенинның «Лицом к лицу лица не видать» дигән сүзләре бар. Алар дөрес сүзләр дип саныйм. Ә болай уйлаганда, алгарак йөгереп чыгып, шушы заманга ерактан, киләчәктән, карарга теләү — бусы һәрбер шагыйрьнең хыялы. Шуңа омтылу һәм ирешә алмау — озын гомерле иҗади стимулятор.

**М. Вәлиев.** Җавап биргәндә сез минем сүзләрдән бер моментны искә алмадыгыз. Ә ул, кайбер төсмерләрне ачыклау өчен, бик мөһим булыр иде. Сүз 60 нчы һәм 70 нче еллар тормышының поэзиядә чагылу дәрәҗәләрен чагыштырып карау турында бара. Биредә бит шактый кызыклы һәм игътибар ителердәй бер күренеш күзгә ташлана: аерым алганда, ул сезнең буын шагыйрьләрнең иҗатында да сизелә. Ул буын 60 нчы елларда үзенең шигырьләрендә нәрсәгәдер каршы чыга, ниндидер яклый, ул — көрәшә, ул — даулый. Шигырьдә ярсып яшь йөрәк тибә, йөрәк яши. Һәм әнә шундый шигырьләр укучыга да якынрак, кадерлерәк, кирәгрәк кебек иде. Ничектер укучы үзенең күңелен ул шигырьләр белән тизрәк тоташтыра ала иде, алар белән бер җан булып яши башлый иде. Ә хәзер, сезнең буын шагыйрьләрнең соңгы елларда чыккан шигырьләрендә исә, йөрәк эчкәрәк күчкән кебек, ул хәзер сакланганрак һәм хәтта, шактый гына дәрәҗәдә, акылга таба якынайганрак бугай. Баштагы еллар шигырьләрендәге көчле хис, омтылыш, теләк хәзер күзәтү тирәнлеге, фикер куәте, нәтиҗәләр ясау көче булып әверелгән, әйтерсең кеше башта, дөньяны үзгәртәм дип, зур дәрт белән тотына да...

**Р. Харис.** Шулай ук булды микәнни?!

**М. Вәлиев.** Мин сезнең буынның 60 нчы еллар иҗатын нигездә шул омтылыш билгели дип саныйм... Иҗатның этәргеч көче һәр вакыт — ниндидер канәгать булмау, ләкин дөньяның нык каршылыгына очрап, кеше, гадәттә, дөньяны үзгәртү өчен башта аны аңларга, белергә кирәклегенә төшенә һәм, бөтен көчен куеп, олы дөньяны күзәтә, өйрәнә, нәтиҗәләр чыгара башлый. Зур мәгънәле, тормышның шактый тирән катламнарын колачлый торган нәтиҗәләр... Сүз уңаенда сорыйсы килә: сез шундый эволюция кичергән үз буыныгыз турында бүген ни уйлыйсыз? 60 нчы еллар һәм 70 нче еллар поэзиясендәге аның урыны хакында? Һәм шул вакыт аралыгындагы тормышның поэзиядә рухи ачылуы хакында?

**Р. Харис.** Бик сиздермәскә тырышсагыз да, сезнең тел төбегезне, әйтергә теләгәнегезне аңлыйм. Сез, заманның рухи әчтәлеген ачу дигән булып, шул проблема җирлегендә, безнең буынны бераз гаепләргә, аның чын тормыштан читә төшүенә канәгатьсезлек белдерергә телисез...

**М. Вәлиев.** Хәерле булсын, әйдәгез шулай дип уйлыйк!

**Р. Харис.** Ә мин болай дим: поэзия — ул һәр вакыт көрәш нәтиҗәсе! Аның максаты да көрәш! Әйтик, югары әхлак нормалары өчен, чын матурлыкны яклап, тормыштагы җитешсезлекләргә каршы көрәш. Ләкин ул көрәш төрле вакытта төрлечә импрессивлыкта (тәэсир көче) һәм югарылыкта, тонда була. Бүген шигырьнең тавыш көче кимрәк, ул тынычрак, ул зур аудиториягә түгел, ә күп чагында кешенең үзенә генә адреслана. Без поэтик күренешләргә дөрес бәя бирергә телибез икән — ул күренешләрне үсештә, үзгәрештә, перспективада күрергә һәм тормыш үзгәрешләре белән бәйләнештә карарга тиешбез... Ә заманның рухи эчтәлеген ачу дәрәҗәсенә килгәндә, ул, минемчә, поэзиядәге барлык иҗат итүче көчләр белән эшләнә торган эш. Безнең буын аңа күпмедер дәрәҗәдә үз өлешен генә кертә. Ләкин шуны әйтәсем килә: арабызда бер генә хатын-кыз шагыйрә дә булмау безнең буын шигъриятен ничектер китегрәк итә сыман. Әнә бит Саҗидә Сөләйманованың гаҗәеп лирик иҗаты безнең абыйларыбыз булган шагыйрьләр буынын ничек тулы канлы итеп, бизәп тора. Җыр текстлары авторы буларак Гөлшат Зәйнашева иҗаты да ул буынны баета, иҗатын күп кырлы итә. Бер буын әдәбиятның бөтен жанрларын колачлый ала икән — бу инде шул буынның үз-үзенә ышану көчен арттыра, аны мөстәкыйльрәк итә.

**М. Вәлиев.** Безнең сөйләшү өкренләп урта буын һәм сезнең буын шагыйрьләр иҗаты турында фикер йөртү яссылыгына күчте. Минемчә, бу поэзия турындагы дискуссиянең үзен дә киңрәк колачлы итә. Чөнки моңарчы басылып чыккан язмаларда күбрәк ике генә буын — өлкәннәр һәм яшьләр буыны гына телгә алына иде. Болай тулырак итеп күрергә тырышу безгә кайбер тенденцияләрне сиземләү мөмкинлеге дә бирәдер. Чөнки дәвамлы итеп караганда үзгәрешләрнең юнәлешен тоемларга, ачыкларга мөмкин. Әле менә югарыда сезнең буынның нинди эволюция кичерүен карап үттек. Ә киңрәк итеп караганда, гомумән, татар поэзиясен колачлап фикер йөрткәндә, без соңгы елларда ниндирәк тенденцияләр күрәбез соң? Поэзиянең бүгенге хәлен ачыклау нияте белән сөйләшкәндә бу момент бик мөһим булырга тиеш... Ә минем үз карашыма килгәндә: элегрәк сиземләнгән җанлылык, яшәешнең төрле-төрле күренешләрен аңларга һәм аңлатырга омтылу, шуның белән поэзиянең үзен дә зурайту, аның көчен, миссиясен арттыру тенденциясе соңгы вакытта бераз йомшара төште кебек. Бик примитивлаштырып әйткәндә, соңгы елларда безнең поэзиядә яңадан (минем яңадан диюем, 50 нче елларда булып алганнан соң тагын килде, дигән мәгънәдә) ниндидер бер шомалык, нормативлыкка буйсыну чаткылары сизелә кебек. Укучыларыбызның күпчелеге проза әсәрләренә ябырылуның да бер сәбәбе шул түгел микән, ягъни поэзиядә җанлы яшәеш нык кимегәнгә түгел микән?

**Р. Харис.** Андый ук нәтиҗә ясарга җөрьәт итә алмыйм. Әмма, соңгы елларда поэзиябездә булган үзгәрешләр турында сүз чыккач, шуны әйтергә кирәк: минем үземне куандырган хәл — ул шигъри сүзнең җегәре арту, аның күбрәк экспрессивлык (кичерешләр) һәм импрессивлык (тәэсир итә алу) сыйфатларына ия була баруы, сүзнең шигърилек функциясе алга чыгу. Сүзнең — җөмләдәге, җөмләнең шигырьдәге җегәре арту . Мисал өчен нибары өч сүз алыйк: йөрәк, колак, саңгырау. Гап-гади сүзләр. Ә шагыйрь Назыйм Хикмәт шул ук сүзләр белән менә нәрсә ди: «йөрәкләрнең колаклары саңгырау». Күрдегезме, өч сүзне ныклап бер тәртипкә тезеп куйгач, һәр сүзнең мәгънәсе ничек артты! Җөмләләрне дә шулай ук тезеп һәм тикшереп була. Минемчә, хәзер шигърият җөмләләр арасындагы мөнәсәбәтләрне дә кызыклы, интенсив итү буенча күп эшли.

**М. Вәлиев.** Сезнең бу нәтиҗәләр татар поэзиясенә дә тулысынча кагыла дип саныйсызмы?

**Р. Харис.** Кагылырга тиеш дип саныйм. Һәрхәлдә, поэзиябездә барган эзләнүләрнең иң файдалылары, иң кызыклылары шул өметне раслый. Ә ул эзләнүләрнең иң җитдиләре итеп мин мәгънәви яктан — риторикадан качырга тырышуны, ассоциация-

ләр аша сүзнең җегәрен арттырырга омтылуны, ә форма ягыннан — строфалар арсеналын төрлеләндерүне, ак һәм иркле шигырь мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итүне саныйм.

**М. Вәлиев.** Минемчә, сүзнең җегәре арту тенденциясе һәм аның белән бәйләнгән күренеш — поэзиянең көче, тәэсире көчәю мәсьәләсе чыннан да игътибар үзәгендә торырга тиешле мәсьәлә. Ләкин әле һаман — кеше үз өстенә ябырылган информация яңгырыннан кая керер урын тапмаган бер чорда да — бездә бик озын һәм күпшәк язылган шигырьләр еш очрый. Аларның күбесенең әйбәт ният белән язылган булуын да тоясың, ул әсәрләр җан җылысын җылы юллар, җылы интонация аша бирергә тели. Ләкин күп вакыт, әнә шул җылы интонация үзе генә калып, сүзләр артык җебеп, йомшап китеп, үз көчләрен югалталар. Алар игътибарны җәлеп итәрлек, үзләренең поэтик информациясен, эчке куәтен белдерә алырлык хәлдә була алмыйлар. һәм кайчагында бик талантлы гына шагыйрьләрнең дә әнә шундый шигъри әсәрләре очрап куя. Нәтиҗәдә, шигырь шагыйрьнең күңелендәге хис, кичерешне укучыга илтеп җиткерерлек булмый. Менә шушы күренешләр турында уйлануларның нәтиҗәсе буларак бер сорау туа: әллә соң бүген шагыйрь шәхесенә булган таләп бераз үзгәрдеме икән? Әллә ул бүген бераз башкачарак булырга, дөнья үзгәреше аркасында килеп туган яңа якларны да исенә алып яшәргә һәм иҗат итәргә тиеш микән?

**Р. Харис.** Шагыйрьләргә бер дә үзгәрми торган бердәнбер таләп бар. Ул — талант. Ләкин бүген мондый гади җавап кына дөрес булып ук бетмәс иде. Чөнки мәсьәлә катлаулырак. Талантка гына кайтарып калдыру тулы аңлату булмаячак. Элегрәк, поэзия турындагы чыгышымда, Сибгат ага Хәкимнең бер шигырен мин «бөтнек исен аэропорт исе белән органик куша белгән шигырь» дип бәяләгән идем. Шушы ук сүзләрне мин бүгенге көн татар шагыйренә карата да әйтер идем. һәм тагын шуңа өстәп «чын мәгънәсендә югары белемле булу» дияр идем. Әлбәттә, югары белемне турыдан-туры тормыштан алу да мөмкин. Ләкин югары уку йортында системалы югары белем алу «аңлы шарт» (осознанная необходимость) булырга тиеш. Шигырь нигезендә информация ята. Әнә шул информация инде сан ягыннан да (ул без белмәгән булырга тиеш), сыйфат ягыннан да (җиткерү ысулы, «кителмәгән» моментлары булу) югары дәрәҗәдә һәм компетентлы булырга тиеш. Ә моның өчен «ходай биргән» акыл һәм хис белән генә ерак китеп булмый, чөнки хәзер фән-техника революциясе заманы.

**М. Вәлиев.** Безнең поэзиядә әле һаман ниндидер бер «йомшак» як, аңа киң күләмдә яңгыраш табарга, башка халыклар укучыларының да игътибарын җәлеп итәргә комачаулый торган бер җитешсезлекме, тарлыкмы бар сыман. Без үз хәлебездән шактый канәгать яшәсәк тә, үз даирәбездә генә яшәвебезгә инде иянәнеп беткән булсак та — барыбер, үзәктә басыла торган журналларны кулга алып уку белән, андагы шигъри әсәрләр арасында үзебезнең халык рухын чагылдырган, аның күңел яңгырашы булган шигырьләр җитмәве үзен бик сиздерә. Билгеле, моңа тәрҗемә белән бәйләнгән кыенлыклар да тәэсир итми калмый торгандыр. Ләкин, минемчә, бу хәлнең төп сәбәбе, иң мөһим сере эчтәрәк ята кебек.

**Р. Харис.** Безнең шагыйрьләрнең бөтенсоюз аренасына чыгу мәсьәләсе — комплекслы мәсьәлә. Монда аерым шагыйрьләрнең шәхес буларак индивидуаль сыйфатлары да, безнең гомуми шигырь культурабыз да, бөтен әдәбиятыбызның абруе да, тәнкыйтьнең дәрәҗәсе дә һ. б. зур роль уйный. Ләкин бер факт бәхәссез: ел саен үзәк журналларда һәм китап нәшриятларында татар шагыйрьләренең әсәрләре чыгып тора, әмма алар бөтенсоюз укучысы алдында татар шигъриятенең абруен тагын да күтәрә алмыйлар. Без сан ягыннан җитәрлек чыгабыз, ә зур итеп яңгырый алмыйбыз. Ни өчен? Минемчә, чын мәгънәсендә олы шигырьләребез аз. Үзенчәлекле, чатнап торган образлы, олы фикерле шигырь, теләсә нинди тәрҗемә киртәләрен дә җиңеп, үзенең асылын саклап кала. Бөтен җитешсезлегебезне тәрҗемәгә генә сылтарга тырышу — безнең ваклыгыбызның, көчсезлегебезнең бер күрсәткече.

**М. Вәлиев.** Хәзер, минемчә, шундый фактны искә алу бик мөһим бугай: гомум культура үсү белән поэзия әсәренә караш бик нык нечкәрде, олыгайды, тирәнәйде. Укучының зәвыгы үсте. Тирән нәфислеккә омтылыш көчәйде... Ләкин «нәфислек» дидем дә, үзем дә бераз уйланып калдым. Без бит бүген үзләренең «кытыршы» ши-

гырьләре белән танылган Андрей Вознесенскийда да, Олжас Сөләймановта да нәфислек, зур шигърият табып, соклана-соклана укыйбыз. Алар бит югыйсә Сергей Есенин стилендәге шигырьләрдән бик нык аерылып торалар. Ә үзебездә алсак: С. Хәкимнән, Н. Арслановтан, Ә. Баяновтан шигъри дөньялары белән шактый үзгә булган Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миңгалимов иҗатлары да халыкта шулай ук киң танылу тапты. Бер карауга алар бик төрле, хәтта капма-каршы иҗат манерасына ия шагыйрьләр. Ләкин шигырьләрендә ниндидер бер уртак нәрсә бар кебек.

**Р. Харис.** Чын әдәби, югары художестволы әсәргә — нинди генә илнеке, кайсы чорныкы һәм нинди жанрда булуына карамастан — бер нәрсә хас: шигърияттелек. Шигърияттелек дип мин менә нәрсәне аңлыйм: олы язмыш, гыйбрәтле ситуацияләр, көтелмәгәнчә фикер йөртүләр белән очрашканнан соң, күңелдә уянган канәгатьләнү хисе ул. Шигърияттелек кеше гүзәллеге белән бәйле. Ул бер шигырь юлларына гына хас сыйфат түгел. Музыканы, скульптураны, графиканы, архитектураны да кеше күңеленә тоташтыручы, сәнгать итүче ул — шигърияттелек.

**М. Вәлиев.** Димәк, гадиләштереп әйткәндә, поэзиянең төп юлы да әнә шул шигъриятне тагын да тулырак итеп ачу булырга тиеш. Эзләнүләрнең юнәлеше әнә шул якка таба барырга тиеш. Чыннан да, бик олы һәм чиксез ерак, ләкин матур максат бит ул... Шуңа күрә безнең күп төрле сөйләшүләрдә «поэзиягә яңа эзләнүләр кирәк, алардан башка шигърият үсә, яши алмый» дигән сүзләр еш яңгырый. Ләкин менә реаль тормышта, әдәби процесста, еш кына, әнә шул чакыруның мәгънәсе онытылып китә, шигъри әсәрләрнең элек күнегелгәнчә, ияләнелгәнчә генә язылуы таләп ителә башлый. Мондый караш, әлбәттә, яшьләрнең поэтик индивидуальлеген сүндерә, аны гомум стандартларга якынайта.

**Р. Харис.** Дөрес, «эзләнү» турында без сөйләшергә яратабыз. «Эзләнергә кирәк, эзләнүсез поэзия юк», дип үгет-нәсихәтне дә еш бирәбез. Бер карасаң, «эзләнергә кирәк» дигән фикер — буш фикер, кысыр фикер, чөнки артык абстракт, артык гомуми, хәтта мәгънәсез. Эзләнергә өндәп була, хәтта эзләнү юнәлешен күпмедер билгеләп тә була, ләкин эзләнергә беркемне дә өйрәтеп булмый. Мин кемнәндер эзләнергә өйрәнәм икән, мин аның, ахыр чиктә, я игезәге, я начар копиясе булам. Сәнгатькә игезәкләр кирәкми. Икенче карасаң, «эзләнүләр кирәк» дигән фикер олы мәгънәгә ия. Поэзия — үзе эзләнү нәтиҗәсе. Хәтта графоман да эзләнә, ләкин ул, чын шагыйрьдән аермалы буларак, таба гына алмый, ачыш ясый алмый, чөнки таланты җитми. Эзләнү — иҗат итү, ягъни иҗат процессы. Ул процесс поэтик табыш белән тәгәлләнгәндә генә дөньяга яңа шигырь туа. Процесс күренмәскә, сизелмәскә тиештер дип уйлыйм. Эзләнү иҗатның эчкәреге, яшерен ягы. Аны күрсәтмичә генә укучы аңын шигъри табышка алып барып җиткерә белү осталыктан килә.

Кайвакытта безнең буын шагыйрьләрен формализмда гаепләп куялар. Әйтергә кирәк, татар поэзиясе беркайчан да формализм белән чирләмәде һәм чирләми дә. Эш шунда ки, безнең кайбер шигырьләребезнең әнә шул эчкәреге ягы, эзләнү процессы күренеп-күренеп китә. Билгеле, бу — осталык җитмәүдән генә.

Кыскасы, эзләнү — индивидуаль эш, һәр әдипнең иҗади сере. Эзләнү шагыйрьне үзе генә белгән юллар һәм ысуллар аша табышка, ачышка китерә. Табыш яки ачыш — сүзләр, җөмләләр тезмәсен шигырь итә. Фәкать табышка карап кына шагыйрьнең культура дәрәҗәсен, интеллектуальлеген, талантының зурлыгын чамалап була. Бер очракта шигъри табыш тормышның вак-төякләрен, ә икенче очракта иң актуаль проблемаларын колачлавы мөмкин. Бер үк шагыйрь иҗатында вак «балыкларны» да, эреләрен дә очратабыз. Кайберләребезнең иҗаты мең вак балык янына бер-ике эресе эләккән җәтмәне хәтерләтә. Андый табыш, реаль булса да, «булуы мөмкин түгел» дигәнрәк тәэсир калдыра. Табыш чор кешесе язмышының иң киеренке, югары нокталарын ни дәрәҗәдә чагылдырса, шигырь, шагыйрь шул дәрәҗәдә әдәбият өчен, укучы өчен кызыклы.

Шигырьләрнең үзебез күнеккән тәртиптә язылуын таләп итү, минемчә, табигый нәрсә, чөнки критерийлар яуланган казаныш биеклегендә генә була. Критерийлар һәр вакыт күпмедер дәрәҗәдә консервативлар.

Остазлар яки тәнкыйть тәэсире астында бетә торган индивидуальлеккә шул кирәк — бетсен. Тәнкыйтьне тыңлый белергә дә кирәк. В. Солоухин әйтмешли, худож-

ник һәркем сүзенә, бигрәк тә киңәшенә колак салып, беркемне дә тыңламаска тиеш. Безне аерым кешеләр түгел, ә әдәбиятның культура дәрәҗәсе өйрәтергә тиеш. Иҗади шәхесләрне күреп ала белү, аңа, индивидуальлегенә кагылмыйча, уңай йогынты ясый белү — югары культурага ирешкән әдәбиятларга гына хас олы сыйфат.

**М. Вәлиев.** Сүзебезне поэзиянең гражданлыгы турындагы уйланулардан башлаган идек, инде менә аның культура дәрәҗәсе кебек мәсьәләләргә дә килеп чыктык. Һәм, минемчә, бу бәйләнеш дөрес, табигый, кирәкле бәйләнеш. Чөнки гражданлыкның яшәү җирлеге — кешенең реаль тормышы ул, аның ничек яшәвеннән килеп чыга торган күренеш. Чын гражданлык... Аның ныклыгы, ышанычлыгы... Ул нәрсәләргә бәйләнгән соң? Бу мәсьәләләр бүген поэзия өчен генә түгел, ә, гомумән, олы тормышта да бик җитди итеп куела. Бигрәк тә яшь буынны тәрбияләү, аның формалашуы белән бәйле рәвештә караганда бу проблеманың әһәмияте зурая. Чөнки гражданлык шәхеснең иң асыл сыйфатлары булу-булмавын күздә тота. Ә ул сыйфатларның нигезе, иң беренчесе, минемчә, һичшиксез кешенең табигый, үз күңеленә тугры яши алуы. Бары тик шул чакта гына без шәхеснең һәр урында кешелекле, гуманистик адым ясаячагына ышана алабыз. Минемчә, бүген әле бездә гражданлыкны әнә шушылай итеп — кеше күңеленең табигый дәвамы һәм органик өлеше итеп карау җитми. Кеше җанының бер ягы итеп, олы җанның бер чагылышы итеп. Чын мәгънәсендә көчле, олы җан илгә, халыкка мөнәсәбәтендә дә олы һәм кешелекле була, гражданлык аның асылының, кешелек үзәгенең бер табигый ягы гына була. Ул шәхес өчен бернинди каршылык, трагедия дә тудырмый. Ягъни шәхес омтылышы белән гражданлык омтылышы арасында аерма булмый.

Ә безнең поэзиянең гражданлык көче ни өчен без теләгәнчә түгел соң? — диген сорау куйсак, шигъриятебезнең үз җаны тормыш белән әнә шулай органик берлектә яши алу дәрәҗәсенә ирешкән олы шәхесләрнең, шагыйрьләрнең азрак икәнен күрербез... Олы шәхес бит ул үзенең яшәвендә һәм иҗатында бернинди чикне, кискен бүленешне белми. Без еш сөйли торган темалар бүленеше, актуаль яки искергән нәрсәләр, ярый торган яки ярамый торган фикерләр, хисләр аның өчен, гомумән, юк. Аның яшәве, аның поэзиясе — бер бөтен катлаулы реальлек ул. Олы шәхеснең һәр шигырендә әнә шул тирән катлаулылыкның бер чагылышы була. Бик күп тамырлары, бәйләнеш җепләре белән бергә. Шулай иҗат итүче шәхеснең һәр шигыре, һәр язмасы — ул чын гражданлык сүзе. Ул, иң беренче чиратта, кешене үзенең ихласлыгы, кешелеге, көче белән җәлеп итә. Ул, иң яхшы лирик шигырь кебек булып, кеше җаны өчен кадерле, аңа тансык сүз итеп кабул ителә.

**Р. Харис.** Әйе, әдәбиятның үсешен шәхесләр билгели. Әйтик, бик уңышлы бер әсәр, әдәбиятның бер жанрын гына түгел, аны тулаем үстереп җибәрә. Үз нәүбәтендә андый әсәр — әдәби шәхеснең үсеп китүе диген сүз... Әдәбиятка яңа исемнәр килә. Алар, әлбәттә, әдәби процесска да йогынты ясыйлар. Соңгы ун-унбиш ел эчендә безнең поэзиягә шактый кызыклы исемнәр килеп керде. Хәзерге көндә өлкәннәр белән бергә поэзиябезнең төп буынын тәшкил иткән Г. Афзал, Ә. Баянов, Ш. Галиев, М. Шабаев, И. Юзеев, Роб. Әхмәтҗанов, С. Сөләймановаларга тагын яшьләр — Р. Гатауллин, Р. Мингалимов, Г. Рәхим, Р. Фәйзуллин, Рәш. Әхмәтҗанов, Ф. Яруллин, бераз соңрак Зөлфәт, М. Әгъләмов, Ф. Сафин, М. Галиев, З. Насыйбуллиннар кушылдылар. Бу шагыйрьләрнең поэзия үсешенә йогынты ясаулары көн кебек ачык.

**М. Вәлиев.** Димәк, поэзиябезнең бүгенге торышын билгеләүдә башка шагыйрьләр белән бергә аларның иҗатлары да катнаша диген сүз. Ә ул иҗат дөньяларының көче, әйткәнебезчә, шагыйрь шәхесенең көче, аның дөньяны, тормышны тоемлау тирәнлеге белән билгеләнә. Шигърият, аның күп кенә төп сыйфатлары, шулай итеп, шәхестән, аның кем булуыннан, нинди булуыннан, ничек итеп яшәвеннән башлана. Димәк, безнең поэзия турындагы бу аңгәмәбез дә үз тирә-юнебездәге шәхесләргә багу, карашларыбызны иҗади шәхесләргә юнәлтү белән тәгәлләнә... Ышаныч һәм өмет тулы карашларыбызны...

# Фәннур Сафин

## ШИГЫРЬЛӘР ЯНӘШӘЛЕГЕ



Поэзиябездә шигъри фикернең юлдан-юлга, строфадан-строфага эзлекле рәвештә үсә бару күренешенең камил үрнәкләре бар. Мондый шигъри фикер дәвамлылыгы, аерым шигырь күләме белән генә чикләнмичә, бер рух-хистәге берничә әсәр буенча дәвам итәргә, үстерелергә дә мөмкин. Андый шигырьләр, төрле рәвештәге катлаулы бәйләнешләргә кереп, үзенә бертөрле әсәр шикелле булалар.

Шагыйрьләр шигырьләрен еш кына, әнә шундый күләмле бөтеннәр итеп, циклларга туплап бирәләр. Без мондый күренешне А. Блок, С. Есенин, В. Маяковский, А. Ахматова, Б. Пастернак, М. Цветаева, Н. Тихонов, Е. Евтушенко һ. б. иҗатында очрата алабыз. Шигырьләрне бер бәйләм итеп бирү татар совет поэзиясендә Һади Такташ, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Әнвәр Давыдов, Илдар Юзеев, Марс Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Ренат Харисов, Рәдиф Гатауллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов һәм башкалар иҗатында әһәмиятле урын тота. Поэзия турындагы әңгәмәдә Р. Фәйзуллин: «Ясалмарак поэмаларга караганда, тәзек шигырь цикллары күбрәк ошый төшә миңа. Гәрчә андый шигырь циклларына караганда, поэманың теләсә кайсына, хәтта беркадәр йомшаграгына да тәнкыйтьчеләр игътибарлырак», дигән фикер әйткән иде. Ә нәрсә соң ул цикл? Бай традициясе булган поэзиябездә кирәкле күренешме ул?

Бер бәйләм итеп бирелгән әсәрләрдә эчке кичерешләр һәм гомуми лирик образ берлеге була. Циклга кергән әсәрләр күп вакытта бер-берсеннән аерылгысыз булып, кушылып китәләр. Шигырьләр циклы, шактый киң контекстның бер төре буларак, һәр шигырьне мәгънәви югарылыкка күтәрә ала. Өстәмә төсмерләр белән баета.

Бу хәлне тою өчен, кайбер аерым шигъри бәйләмнәргә мөрәҗәгать итеп карыйк.

* * *

Сибгат Хәкимнең «Казан арты» (янсә «Кадерле почмак») дип исемләнгән шигырьләр циклы бар. Тематика һәм объект берлегенә нигезләнеп туган бу әсәр үзенең эчке логик үсеше белән кызыклы. Ул лирик геройның туган ягы — Казан арты турындагы сигез шигырьне берләштерә. Болар — 1939 елдан алып 1957 елга кадәр язылган әсәрләр. «Казан» исемле шигырьдән соң 18 ел үткәч кенә, цикл тәмам «өлгереп» җитә. Биредәге әсәрләрендә шагыйрь төрле еллар күзлегеннән, төрле ераклыктан һәм төрле яктан йөрәгенә якын булган почмакка — туган җиргә карый:

> **Тау башына басып карадым мин,**
> **Гашыйк итеп кичке утларың**
> **Кабындылар синең...**
>
> **(«К а з а н.»)**

Лирик герой үзен, кыядагы бөркет кебек, ялгыз сизми. Ул — әле тегермән белән тарихны кузгатучы балта осталары янында, әле тормыш кебек кайнап торган базарларда йөри, әле, җитенче кыз булып, йөрәк серләрен ача. Ул һәр вакыт хәрәкәттә, үсештә:

> **Октябрьдан соңгы яшьләренең**
> **Теркәлергә алгы сафына**
> **Теләдем мин, урамнардан үттем,**
> **Басып кызыл байрак астына.**

Ә бу үсеш беренче шигырьдәге «Мәхәббәтме, әллә тегермәнме Кешеләрне күбрәк елаткан?» дигән сораудан башланып китә. Һәм циклда бу сорауга җавап бирү, шигырьдән-шигырьгә үстерелеп, дәвам итә. Күз алдында торган җавабын шагыйрь әнә шул беренче шигырендә үк, лирик герой әле малай гына булган чакта ук, төрле лирик ассоциацияләр ярдәме белән укучының йөрәгенә, аңына сеңдерә башлый:

> **Онны алу белән Фролдан,**
> **Ычкынамын, инде абайлау ул:**

**Кайда — чокыр, кайда — борылмаң...**
**Үрне менгәч, үтерсәң дә чапмыйм,**
**Юк, язганга түгел һушымнан,**
**Күзләр талып, җилдән яшьләнгәнче**
**Карап тору рәхәт шушыннан.**

Туган җиргә булган олы мәхәббәт кадерле, изге онны да оныттыра, күзләрдән яшь чыгара икән...

Тора-бара героебыз юлга чыгып китә. Офыклар киңәйгән саен, кадерле почмак та күзгә күренеп үсә, күтәрелә бара. Саргылт онтаны җилләрдә туздырып, өч ташлы тегерменне дә сүтеп ташлыйлар... Ләкин туган җир барыбер туган җир булып, иң кадерле почмак булып кала бирә! Чөнки кешене үз ягына бәйләгән нәрсә — тегермән яки тамак колы булу гына түгел — ә туган якка булган олы мәхәббәт. Биредә — кешенең тәүге мәхәббәте, шагыйрь үзе генә белгән җырлар. Монда «әнкәй» дигән иң кадерле кеше бар.

Шигъри бәйләмдә туган як — Ватанның бер кисәге («Ватанымның якты почмагы син...»). Шул җанга якын кисәктән башка Ватанны һәм Ватаннан тыш «кадерле почмакны» күз алдына китерүе дә кыен. Бу турыда әдипнең үз сүзе — йөрәк тавышы бар:

**Әй, кадерле почмак, газиз почмак,**
**Синсез җирдә тордың-тормадың.**
**(«Кадерле почмак».)**

Казан арты — бөтен ил, дөнья кебек үк — изге, газиз. Ул — кешенең иҗатына, хезмәтенә һәм тормышына ялкын өстәп торучы сүнмәс мәхәббәткә лаек як икән.

**Яшәвемнең азагына тикле**
**Сүндермәмен синең чаткыңны...**

Цикл кадерле якка булган чиксез мәхәббәтнең бөтен катлаулылыгын, кайнарлыгын, кешелеклеген кечкенә күләмле бер шигырьдә генә түгел, ә шигъри бәйләмдә тулырак ачып бирү мөмкинлеген күрсәтә. Циклда эчке логик үсештә бирелгән фикерләр, хисләр системасының (аерым шигырьгә караганда) тәэсир итү һәм ышандыру көче дә артып китә.

* * *

Рәдиф Гатауллинның «Европада татар шагыйрьләре» дигән циклы «Казан утлары» журналында дөнья күрү белән үк шигырь сөючеләр күңелен үзенә тартты. Географик киңлеге белән генә түгел. Татар шагыйренең мәшһүр Париж шәһәрендә алган тәэсирләрен бер фокуска җыя белүе һәм шул хисләрне инде сагындырып та өлгергән туган якларга, «алтын Казан»га үреп, тасвирлап бирү осталыгы белән дә...

Менә без әйтерсең лә шагыйрь белән бергә Парижда, Люксембург бакчасында уйланып йөрибез, нурлы күз карашларыбыз француз балаларының башыннан сыйпап уза... Ул да түгел, борынгы замокларга, Сена ярларына килеп чыгабыз, атаклы «Нормандия-Неман» дивизиясе вәкиле — чал полковник белән очрашабыз, Жанна д'Арк һәйкәле янында Орлеан кызлары белән рәсемгә төшәбез.

Әлеге шигырь бәйләмен (һәм, гомумән, Рәдиф Гатауллинның иң уңышлы шигырьләрен) укый башлауга ук, хисләр ташкыны сине шигъри-романтик дөньяга бөтереп алып кереп китә, җаның яшәрә.

Шагыйрь безне Париж урамнары белән таныштырып йөртә, үзе һәр даим туган ил, халык турында уйлана. Күңеле белән шунда ук туган-үскән җирне юксына. Чагыштыра, искә төшерә:

**Маяковский әйткәнчә,**
**«Яшәп синдә үләр идем,**
**Шундый җир — Мәскәү булмаса»,**
**һәм... алтын Казаным минем!**

Шигырьләрне планетаның әдәбиятыбыз өчен яңа бер төбәгенә сәяхәт кылу вакыйгасы бер бәйләмгә туплый, алар туган җир турында уйланулар булып бер-берсенә үрелә баралар.

...Шагыйрь, Эйфель манарасына менеп, француз яулыгын болгый.

**Ул яулыкка —**
**Эйфель үзе,**
**Версаль,**
**күперләре белән Сена —**
**гүя Париж төшкән.**

Ә героебыз күңелендә — туган як:

**[Казан сурәте ясалган яулык ник юк!! —**
**Җилфердәтер идем аны биектән!]**

Жанна д'Аркның девизы: «Францияне коткарырга...» Шагыйрь: «Һәрчак яңа Жанна туа тора... Бүген соң коткарырга кемне — нидән? Кемнән?»— дип сорау куя һәм моңа җавап та бирә төсле:

**Фикер коллыгыннан!**
**Тук фикердән!**
**Аек акыл җитмәүдән,**
**түбән төшүдән!**
**Коткарырга ярый хәтта**
**үзеңнән-үзеңне!**

Рәсемгә төшүче Орлеан сылулары һәм туган як турында уйланып, шагыйрь Жанна д'Арк һәйкәленә мөрәҗәгать итә:

**Алар белән син дә**
**Иделемә —**
**Дуслык лагерена бер килерсең төсле!**

Әлеге дә баягы «тук фикердән, аек акыл җитмәүдән, түбән төшүдән» саклау өчен кирәк ул Жанна. Һәр халыкка, һәр мөхиткә, һәр кешегә кирәк.

Шагыйрь күңеле туган ягын, Казандагы дусларын сагыну белән тулы.

**Миндә — сагыну катыш бер моңсулык хисе!**
**Сагындыра Казан.**
**Читтә нинди генә гүзәллекләр күрмә,**
**Казанымнан язмыш аермасын!**
**Безгә шунда язган.**

Шагыйрь Париж белән саубуллаша. Ә күңелдә һаман — Париж, Казан, Европа... Аның җанына татар шагыйрьләре турындагы уйлар тынгылык бирми...

**Хәтта чит илләргә сәяхәткә**
**сирәк чыга татар шагыйрьләре —**
**Европада ләкин каберләре.**

Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян...

Европага аларны сугыш җиле алып килгән...

Биредә һәрбер шигырь аерым да яши ала. Мондый циклларга мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Мәсәлән, XIV йөздә иҗат иткән Италия шагыйре Ф. Петрарка үзенең сонетларын «На жизнь мадонны Лауры», «На смерть мадонны Лауры» һ. б. исемнәр астында аерым бәйләмнәр итеп бирә. Монда да һәрбер сонет аерым яши ала, ләкин башка сонетлар белән янәшә куеп укыганда, аларның төсләрен һәм кыйммәтләрен җуймас җәүһәрләр икәнлегенә тагын бер кат инанасың.

Ләкин бу фикерне барлык циклларга карата да әйтеп булмый. Әйтик, А. Блок шигырьләрендә эш башкачарак тора. Шагыйрь үзе үк күп шигырьләренең шигъри бәйләмнән аерып алган вакытта, кыйммәтләре югалуын әйтә.

* * *

Символик мәгънәгә ия булган образның шигъри бәйләм үзәгенә куелуын һәм шул образның шигырьдән-шигырьгә эзлекле рәвештә үстерелеп, яңадан-яңа мәгънә төсмерләре белән баетыла баруын берникадәр Р. Харисовның «Яралар» циклында күзәтергә мөмкин.

Яра. Күңел яралары була. Сугыш яралары... «Яралар» циклында яра сүзе көрәш эзе мәгънәсендә килә:

**Кан онытса,**
**Аң онытмас яраны —**
**Көрәш эзен**

Беркайчан да
Онытырга ярамый!..
(«Тән онытса...»)

Хәтта яра сүзе үзе үк көрәш сүзен хәтерләтә, ә **көрәш** сүзе — **яраны.** Бу сүзләрнең икесендә дә «р» тартыгы булуы һәм татар телендә «р» авазының кайбер башка телләргә караганда көчлерәк, катырак әйтелүе ярдәмендә, бу сүзләр бер-берсенә тагын да якыная төшәләр кебек.

Автор, гомумән, көрәш сүзен яратып куллана. Бу җәһәттән аның циклларының яисә китапларының исемнәрен генә булса да искә төшереп узыйк: «Сабан туй» циклы, «Ак сөлге» исемле шигырьләр җыентыгы һ. б....

«Яралар» циклында кулланылган яман, яна, кара (фигыль һәм төс), яла, ара, ярамый, янартау кебек сүзләр дә яңгырашлары ягыннан күпмедер дәрәҗәдә яра сүзе белән тәңгәлләшеп киләләр. Аларның күбесе мәгънәви яктан да «яра»га якын тора. Лирик герой өчен Җирне, Илне яралардан саклау, хыянәткә, ялганга каршы көрәштә калкан булу — сәгадәт. Бер шигырендә «илгә озын юл барасы» ди шагыйрь. Ә анда — киләчәктә:

Карап безнең яраларга
Оныклар
Тарихларын бәһаләрләр.
Онытма!

Шул рәвешчә, «Яралар» циклындагы Яра образы, Көрәш образы белән үрелеп, киләчәккә юл алырга омтыла, сүзнең мәгънәсе тирәнәя, киңәя төшә. Әгәр дә циклның башыннан ахырына кадәр шигъри фикер һәм лирик кичерешләр дәвамлылыгы тагын да табигыйрәк эзлеклелектә алып барылган булса, бу әсәр олырак образ да тудыра алган булыр иде.

* * *

Хәзер циклларның тематик яктан төрлелегенә игътибар итик.

Шигъри цикллар авторның политик-агитацион, фәлсәфи, героик-патриотик, сәяхәт, истәлек-автобиографик, мәхәббәт һәм портрет шигырьләрен берләштерергә мөмкин. Билгеле, болар бөтенләй, «саф» көе генә башка төркемнәрдән аерым яшәмиләр. Мәсәлән, М. Кәримнең «Европа-Азия» һәм Р. Харисовның «Яралар» циклларында героик-патриотик хисләр, фәлсәфи фикерләр һ. б. төсмерләр юк дип булмый. Ләкин, шуңа да карамастан, болар политик-агитацион цикллар. Аларның берсендә («Европа-Азия») тынычлык өчен көрәш темасы шигъри бәйләмнең башыннан азагына хәтле ал-су тасма төсле сызылып бара. Бу цикл үзендә **тынычлыкны**, бәхетне саклау өчен барган көрәш идеясе эзлекле рәвештә үстерелгән шигъри бәйләм диясе килә. Икенче цикл («Яралар») өчен түбәндәге юллар характерлы:

Ил өчен, җир өчен көрәшкә әзер мин
һәр секунд,
һәр минут,
һәр сәгать...

С. Хәкимнең «Кадерле почмак» һәм Роберт Әхмәтҗановның «Идел-йорт» дип исемләнгән шигъри бәйләмнәрен туган җиргә булган мәхәббәт тәэсирендә язылган шигырьләрен берләштергән цикллар рәтенә кертергә була. «Кадерле почмак» хакында югарыда сүз алып барылган иде. «Идел-йорт»та: «Нигез иске, йортыбыз яңа...» дигән юллар бар. һәм автор әнә шул борынгы нигезнең дә, бүгенге йортыбызның да җанлы сурәтләрен күз алдына китереп бастыра. Бирeдә хәтта туган туфрак өне дә колакка пышылдый:

«Кайт иленә, Иделенә!..
Идел-йортта әнием елый,
Күктән сине сорый...
Калдырма, ди, җиде ятка,
Кайт син, гәүдәм йөргән чакта.
(«Шәүләм мәңге йөрер...»)

Шагыйрь өчен туган як ул — «томанлы-яңгырлы киңлек», «тургай тавышлары», «агарган борчак басулары», «кояшлы ишегалды», эңгер төшкәч, карт-корылар белән

алган күрше тау. Ул — бәрәңгегә спас яңгырлары сибәләгән як. Ул — хыялдагы Йолдызстан. Әсәрдә борынгы Болгар хәрабәләре дә терелә. Бер шигырь икенчесен күчәйтә бара.

Автобиографик цикллардан Н. Арслановның «Еллар-язмышлар» һәм Х. Камаловның «Әнкәй истәлеге» шигъри бөтеннәрен күрсәтергә була. Истәлек рәвешендә язылган шигъри бәйләмнәргә Х. Туфанның «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар», портрет циклларыннан Нажар Нәжминең «Шагыйрьләр», сәяхәт циклларыннан С. Хәкимнең Берлинга бару уңае белән язылган «Торыгыз, Мусалар», Р. Гатауллинның «Европада татар шагыйрьләре» исемле шигъри бәйләмнәре мисал була алалар.

Героик-патриотик цикллар төркеменә мисал итеп Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» җыентыгындагы шигъри бәйләмнәрне күрсәтергә мөмкин. Әмма В. Воздвиженскийның «М. Җәлилнең Моабит дәфтәрләре һәм аларның сугыш еллары совет әдәбиятындагы урыны» дип исемләнгән хезмәтендә әйтелгән бер фикер белән һич тә килешеп булмый. В. Воздвиженский «Моабит дәфтәрләре»н аерым цикл итеп күрсәтергә тели. Ләкин монда, безнең карашыбызча, берничә шигъри бәйләм тупланган. Әйтик, сугыш турындагы һәм лирик герой язмышына бәйле цикллар, сугыштан соңгы тыныч тормыш турындагы тәмамланмаган цикл һ. б. Бөтен җыентыкны аерым бер цикл гына итеп карау цикл контекстына караганда киңрәк контекстка алып килер иде. Андый контекстны бәлки шигъри җыентык контексты дип атарга кирәктер. Әдипнең бөтен иҗаты яисә аерым китабы контекстын алып тикшерергә дә була. Ләкин андый ерак янәшәлекләрне цикл контексты итеп карау гадәткә кергән әдәби нормаларга сыймый кебек. Бу шигырьләр җыентыгын Гази ага Кашшаф биргән исем белән «Моабит дәфтәрләре» дип атау дөресрәк.

* * *

Композицион яктан караганда, шигъри циклларны дүрткә бүлеп карарга мөмкин шикелле.

Эчке логик үсеше булган шигъри бәйләмнәр төркеменә М. Кәримнең «Европа-Азия», Р. Харисовның «Яралар» циклларын кертергә була.

Тематик бер төслелеккә нигезләнгән цикллардан Х. Туфанның «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар», С. Хәкимнең «Суд залында», Н. Нәжминең «Шагыйрьләр», Роберт Әхмәтҗановның «Идел-йорт» исемле шигъри бәйләмнәрен күрсәтергә мөмкин.

Вакыйгаларга бәйләнешле рәвештә бергә тупланган шигырьләр циклы төркемендә С. Хәкимнең «Торыгыз, Мусалар», Н. Арслановның «Еллар, язмышлар», Х. Камаловның «Әнкәй истәлеге», Р. Гатауллинның «Европада татар шагыйрьләре» дигән әсәрләре урын ала.

Болардан тыш катлаулы цикллар төркеме дә булуы мөмкин. Мәсәлән, С. Хәкимнең «Кадерле почмак» циклы шуңа тартымрак.

* * *

Тематика һәм объектны нигез итеп, берничә шигырьне берләштергән вакытта, художник палитрасының тәэсир итү көче бермә-бер арта. Шигырьләрне циклларга туплап бирү элекке чор шагыйрьләрендә дә, бүгенге поэзиядә дә билгеле урын тота. Әдипләр үзләренең әсәрләрен төрле исемнәр астында шигъри көлтәләргә яисә бәйләмнәргә туплап бирәләр: Г. Тукай «Беренче көлтә», «Икенче көлтә», Х. Туфан «Эскизлар», Н. Арсланов «Парчалар», Х. Камалов «Әнкәй үлеменә язылган шигырьләр» дип исемлиләр. Боларның һәрберсе, әнә шул аерым цикллар өчен, аларның кайбер үзенчәлекләренә дә ишарәле торган дөрес исемнәр.

Заманыбыз тизлек, төгәллек, кыскалык таләп итә, бүгенге көнне узып яшәргә куша. Һәм шуңа күрәдер, иң талантлы яшь шагыйрьләребез ачык фикерле кыска шигырьләре белән үзләрен таныттылар. Ләкин шигырь сөючеләрнең яшь шагыйрьләрдән зуррак, күләмлерәк әсәрләр көтүе дә хак. Һәрхәлдә, шигырьләрне бәйләм итеп бирү яшь талантлар иҗатындагы бөтенләй яңа, әлегә без күрмәгән якларны да ачарга булышуы бик мөмкин. Әйе, киләчәктә дә шигырьләр янәшәлеге, һичшиксез, образлар палитрасын яңа мәгънәви буяулар белән баетыр, яңадан-яңа ассоциацияләр тудырырга ярдәм итәр.

**Бәян Гыйззәт**

# ХӘЙ ВАХИТ ҺӘМ АНЫҢ ГЕРОЙЛАРЫ

*Драматургның 60 еллыгы уңаена*

Х. Вахит драматургиясе хәзерге театр сәнгатендә күренекле урын тота, актерлар һәм режиссерларның осталыгын үстерүдә, бүгенге көн темаларын үзләштерү юлында әһәмиятле роль уйный. Югары музыкаль белемле язучы буларак, ул татар опера сәнгатен үстерүгә дә зур өлеш кертте, күп санда либретто һәм музыкаль комедияләр язды.

Хәй Вахит драматургиядә үз проблемаларын, үз юлын тапкан язучы, ул һәр әсәре өчен яңа, оригиналь конфликтлар, образлар иҗат итәргә омтылды, жанр һәм стиль өлкәсендә туктаусыз эзләнде.

Бу драматургның аеруча яраткан геройлары бар иде. Аларның язмышы, тормышы, уй-хыяллары аны һәр вакыт кызыксындырып торды. Х. Вахитның үз иҗаты турында уйланулары сакланып калган. Анда мондый юллар бар: «Геройларым — бүгенге көн яшьләре (һәр әсәр диярлек). Тәрбияләсәң, яшь чакта тәрбиялә!» Алар Х. Вахит иҗатының идея-эстетик үзенчәлеген аңлау өчен кызыклы ачкыч бирә: яшьләр мәсьәләсе яңа кешене тәрбияләү бурычы белән бәйләнгән һәм аның уңышы кешене яшьтән ничек тәрбия итүгә бәйләнештә карала икән. Күлмәкне яңа вакытта, намусны яшьли сакла дигән мәгълүм мәкаль шушы турыда әйтелгән кебек яңгырый.

Академия театрының 1963 елда Уфа шәһәрендәге гастрольләре вакытында, башка спектакльләр белән беррәттән, Х. Вахитның «Рәхим итегез!» исемле комедиясе дә күрсәтелгән. Шул уңайдан «Кызыл таң» газетасында шагыйрь Әнгам Атнабаев мәкалә белән чыгыш ясый һәм тамашачы авызыннан ишетелгән кызыклы бер фикерне китерә: «Мин Хәй Вахит пьесаларын карарга яратам. Гади кешеләр турында яза ул. Безнең турыда. Молодец!» Әйе, Х. Вахит хезмәт кешеләрен данлый, яшьлекне җырлый иде. Нәкъ менә шул сыйфат аның иҗатын заманның актуаль идея-эстетик проблемалары белән бәйли иде. Әле кайчан гына җанлы характерлар арасындагы конфликтлар, фикерләр башкалыгы нәтиҗәсендә туган бәрелешләр урынына еш кына хезмәт урыны таләп иткәнгә күрә генә көрәшкә керергә мәҗбүр булган персонажлар сәхнәне тутырган иде. 60 нчы еллар башында. Х. Вахитлар иҗаты белән башланган борылышның үзенчәлекләреннән берсе — әнә шул «вазифа конфликтларын»нан чын драматургик конфликтларга күчүдә булды.

Х. Вахитның беренче пьесалары язылгач та, тәнкыйть аларның проблемалылыгына игътибар итте. «Совет әдәбияты» журналында (1960 ел, 3 сан) Г. Кашшаф «Беренче мәхәббәт» драмасы турында язган мәкаләсендә болай диде: «Хәй Вахит бу драмасы белән драматургиябезне баета дияргә кирәк. Менә шушы Сәлим — Тәлгать сызыгы буенча аның оригиналь образлар иҗат итүенә югары бәя бирмичә мөмкин түгел. Монда язучының олы фикере, тирән фәлсәфи карашлары салынган... Әсәр, әлбәттә, көчле драма, психологик драма».

Башка тәнкыйтьчеләр дә, хаклы рәвештә, Хәй Вахит драматургиясенең театральлелегенә, мавыктыргыч, кызыклы сюжетка корылган булуына игътибар итә килделәр. Драматургның һәр әсәрен тамашачы яратып каршылады. һәрберсе сәхнәдә йөзәрикешәр йөз мәртәбә аншлаг белән барды. Драматургия серләрен яхшы белән Х. Вахит сәхнә сәнгатенең төрле компонентларын — музыка, бию, җыр һәм шартлы сәхнә алымнарын эшкә җигә белде. Телнең, һәр сүзнең кадерен белергә өйрәнгән автор боларак остарганнан-остара барды.

Х. Вахит драматургиясенең бу сыйфатлары аның олы сәхнәгә күтәрелгән беренче әсәрендә үк теге яки бу күләмдә чагылыш тапты. «Беренче мәхәббәт» исемле бу драма 1960 елда Академия сәхнәсендә куелып, зур уңыш казанды һәм театр репертуарында күп елларга сакланып калды. Автор һәм аны сәхнәгә куйган Рифгать Бикчәнтәев Г. Тукай бүләгенә лаек булдылар. «Беренче мәхәббәт» илебезнең 40 театрында куелды, бик күп республикаларда һәм өлкәләрдә төрле телләрдә уйнала башлады. Әсәр тормышны тирәнтен белеп язылган. Чөнки язучы үз геройлары арасында яшәп, авыл тормышын бөтен нечкәлекләренә кадәр өйрәнгән иде. Хәер, үзе дә тормышта яңалык өчен актив көрәшүче геройларның берсе булды ул.

«Беренче мәхәббәт»тә үзәк фигура — Тәлгать. Аның язмышы, аның кичерешләре, яшүсмер егетнең кеше буларак формалашу юлы авторның игътибар үзәгендә. Тәлгать һәм аның тормыш юлында очраган Рәхилә яшьтән дөрес юл сайлап, зур максатларга омтылып үсәләр. Әмма Тәлгатьнең тормышы җиңеллләрдән булмый...

Әсәрдә күтәрелгән икенче бер әһәмиятле проблема — беренче мәхәббәткә тугрылык мәсьәләсе. Менә шушы сызык тирән драматик ситуацияләр аша сурәтләнеп, тамашачыны тетрәтә торган күренешләр тудыра, бу изге хисләр белән уйнауның фаҗигале нәтиҗәләре турында уйланырга мәҗбүр итә. Заманында бу мәсьәләгә Сәлим шактый җиңел караган булган, аның нәтиҗәләре, соңы турында уйламаган. Ә «соңы» — аталы килеш атасыз үскән Тәлгать, аның кителгән күңеле, яралы йөрәге. Дөрес, сугыштан кайтмаган аталарның балалары да ятим үсә, әмма алар бит үзләренең аталарының кем булганын, аларның ни өчен, нәрсә хакына башларын салганын беләләр. Ә Тәлгать исә атасының кем булганын да белми, ул бөтенләй нәселсез-нәсәпсез бер кеше. Бу кайгыларга аны заманында «егетлекләр» эшләп йөргән Сәлим дучар иткән. Сәлимнең үз тормышы да тыныч түгел, ул авыр кичерешләр белән тулы. Ул Тәлгатьнең дөньяда бар икәнен белеп яши, унсигез ел инде ул бала хәтереннән чыкмый, ләкин аңа «улым» дип дәшә алмый, үз баласыннан «әтием» дигән сүзне ишетә алмый.

Драматург торган саен мәсьәләнең эченәрәк керә барып, тамашачының игътибарын яулап ала. Менә әнисен җирләгән Тәлгать Сәлимнәр торган авылга килә, алдында әтисе басып торганын белмичә, аңа әнисеннән язу тапшыра. Үлгәнче үзе генә караган ана баланың киләчәк язмышын хәзер атасына тапшырырга мәҗбүр була. Бу очрашу Сәлимнең кичерешләрен тагын да тирәнәйтеп җибәрә. Күрешү язучы тарафыннан үзәккә үтәрлек драматизм белән язылган. Бу күренеш хәтта сүзсез генә барса да, тирән тәэсир ясарга сәләтле булыр иде — драматург очрашуны оста итеп алдан ук хәзерләп килә һәм геройларның рухи халәтен тирән сурәтләүгә ирешә.

Башка шартларда тәрбияләнгән Тәлгатьнең Сәлимнәрнең иркә кызы Рәхиләгә зур тәэсире булмый мөмкин түгел (соңыннан аның тәрбиягә алып үстерелгән бала икәне ачыла). Әле балалыктан чыгып бетмәгән шушы кыз нәкъ менә Тәлгать белән танышкач, күзгә күренеп үзгәрә башлый. Тәлгатьнең тормышка, эшкә, укуга, киләчәккә карашы Рәхиләгә хәлиткеч йогынты ясый. Хезмәт белән үскән Тәлгатьнең фигыль-холкы драмада хәзерге яшь буынның иң гүзәл сыйфаты итеп сурәтләнә.

Сәхнәгә менә шундый тирән психологик кичерешләр белән яши торган образлар күтәрелде һәм әсәр тиз арада тамашачылар күңелен яулап алды. Бу — драматургиягә талантлы, үзенчәлекле язучы килүе турында да шатлыклы хәбәр иде.

Х. Вахитның «Рәхим итегез!»е дә (1961) яшьләр темасына язылган. Мәсьәләнең куелышы һәм чишелеше ягыннан ул матбугатта шактый кайнар бәхәскә очраган иде. 1961 елда театр һәм драматургиянең торышы турында зур дискуссия барган вакытта бу әсәр күп тапкырлар искә алынды.

Әсәрдә төп вакыйга яшьләр бригадасында эшләүче Рәисәнең, рецензент әйтмешли, «алама юлга кереп барган Рәисәнең», иптәшләре ярдәмендә айнуы һәм яңадан сафка басуы тарихын эченә ала. Вакыйга автор тарафыннан бик җентекләп, тәфсилләп языла. Драматургның бу коме-

диясе хәрәкәткә, вакыйгаларга бай, бигрәк тә төп геройларның тормышындагы, язмышларындагы хәлләрнең үзгәреп, алмашынып торуы белән тамашачының игътибарын үзенә тартып тора.

Әмма әсәрдә күңелне борчыган бер момент бар иде. Анда соңыннан акылга утырган Рәисәнең килешмәгән эшләрен күрсәтү, аның ялгышларын, абынуларын сурәтләүгә зур урын бирелгән. Һәм менә шул бәхәскә сәбәп булды да инде. Уңай герой дип тәкьдим ителгән Рәисә, чыннан да, бу зур исемгә лаекмы, аны шулай сурәтләү дөресме — менә бу сорауларга җавапны әсәр үзе биреп бетерми иде.

Х. Вахит, югарыда әйтелгән дискуссиядә катнашып, үз әсәренә һәм, гомумән, драматургиягә карата карашларын, фикерләрен әйтеп чыга. «Тормыш дөреслеге өчен!» («Социалистик Татарстан», 1961 ел, 11 ноябрь) исеме белән аталган мәкаләсендә ул болай язды: «Уңай герой — автор кулындагы иң көчле корал ул. Автор уңай герой аркылы үзенең исбат итәргә теләгән фикерләрен, идеяләрен исбат итә, аның йөрәге аша тормышның җиңеп баручы тойгыларын үткәрә, аның күзләре белән киләчәккә карый, аның сүзләре белән тамашачыны алга өнди. Ләкин бу әле һәр уңай образ да сөттән ак, судан пакь булырга тиеш, йөз проценты белән җитлеккән, идеаль кеше булырга тиеш дигән сүз түгел. Алай булса, ул, гомумән, кеше булмас иде. Минем әсәрне тәнкыйтьләгән иптәш һәр уңай образны нәкъ менә шундый итеп — үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән дә йөз процентлы идеаль кеше итеп һәм бары тик шулай итеп кенә күрергә тели». Бу кискен әйтелгән сүзләрдә үзенә күрә бер әдәби полемика чагылганын күрми мөмкин түгел иде, әлбәттә. Чыннан да, озак еллар сәхнәне бер-берсенә игезәкләр кебек охшаган, кичерешләрсез, эчке драматизмы булмаган, баштан азакка кадәр үзгәрмәс геройлар басып алган иде. Бу хәлдән чыгу юлларын драматурглар төрле юнәлешләрдә эзләп карадылар. Х. Вахитның бу эзләнүләре аеруча әлеге «Рәхим итегез!» әсәрендә чагылды. Әмма Хәй Вахит та югарыдагы карашына озак ябышып ятмады. Чөнки Хәй Вахит үзе үк бер калыпка сугып эшләнгән схематик персонажларга каршы чыгудан башлаган иде бит. Инде кимчелекле, хаталанучы геройлар гына җанлы образ булып чыга дип куйсаң, тагын да бер схемага юл ачылачак иде. Менә шуның өчен дә ул бераздан бу мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайтырга булды. «Тирәнрәк сөрергә!» исемле мәкаләсендә («Социалистик Татарстан», 1972 ел, 29 сентябрь): «Тискәре геройлар белән, тормышында гөнаһ эшләгән, ялгышкан, хәтта җинаять юлына баскан кешеләрне әсәрнең үзәгенә бастырып куеп, аның рухи дөньясында казыну, аның драмасын сурәтләү белән кирәгеннән артык мавыкмыйбыз микән, драматург иптәшләр?» — дип, бу күренешне кискен тәнкыйтьләп чыкты, «сәхнәгә чорның алдынгы кешеләрен» күтәрергә өндәде. Язучының бу чыгышы аның идея-эстетик яктан үсешен генә күрсәтеп калмый, ул тагы бер гүзәл сыйфатны ачу ягыннан да әһәмиятле. Автор бирелә заманында үзе үк яклап чыккан карашларыннан җәмәгатьчелек алдында баш тарта, аларның әдәбият өчен хезмәт итә алмавын таный. Әлбәттә, моны иҗат эшенә аеруча җаваплы караган, аны үзенең шәхси интересларыннан, үз дәрәҗәсен саклаудан өстен куйган язучыдан гына көтәргә мөмкин.

Язучының яңа карашларын белдерү ягыннан «Кайда соң син?» (1963) комедиясе кызыклы. Әсәрнең үзәгендә әһәмиятле мәсьәлә — хезмәткә, хезмәт кешесенә мөнәсәбәт тора. Вакыйга үзәгендә торган образларның берсе Ринат мондый фәлсәфәгә бирелә: Шәүкәт гади маляр гына бит ул дип, аңардан Сәриянең күңелен суреләндермәкче, аны үзенә каратмакчы һәм шул максат белән төрле интригалар кора башлый. Әмма Ринат Шәүкәтнең дәрәҗәсен төшерү өчен ничек кенә тырышмасын, Сәрия ялганны чыннан аера белә. Аның алдында Шәүкәтнең гүзәл сыйфатлары ачыла бара. Шәүкәт бер дигән мастер, җитмеш төрле һөнәр иясе, ул гаиләнең башлыгы да. Музыкага гашыйк Х. Вахит Шәүкәтне дә музыкага сәләтле кеше итеп күрсәтә, ул хәтта һәвәскәр композитор буларак көйләр яза. Эшче егет һәр яктан талантлы булып чыга.

Драматург, шул ук позицияләрдән чыгып, «Карлыгач канат кага» (1965) комедиясен яза. Монда ул «Образларның эчке хәрәкәтен, җитлегүгә таба үсүен» Җәүдәт, Кәүсәрия (монысы яшь кеше булмаса да) образлары аша күрсәтә.

Кәүсәрия купьяклы характер, җанлы кеше булып чыккан. Усал да, хәйләкәр дә. Өй түбәсен ябарга такта кирәк булганда, мөдирнең «подхалимлыкны» яратуын белеп, аның шул йомшаклыгыннан файдаланып калудан да тайчанмый: аны зурлагандай була, матур тавыш, күз-караш белән

тәэсир итәргә тырыша, бөтен хәйләләрен эшкә куша. Инде моның да файдасы тимәгәч, тамашачыны аяктан екканчы көлдергән, ә мөдирне куркуга салган (янәсе, мөдир моңа төнлә һөҗүм иткән!!) кетелмәгән тактикага да күчә ул. Шунысы кызык, әлегедәй алымнар куллануга җитсә дә, Кәусәриягә булган җылы мөнәсәбәт үзгәрми, аның үсүе, әкренләп иҗтимагый актив кеше буларак үсүе, торган саен тирәнрәк кызыксыну уята бара.

Ләкин үсү-күтәрелү һәркем өчен бер юл, бер сызык буенча гына бармый. Менә Җәүдәт өчен ул шактый катлаулы. Механиклыкка укып кайткан һәм илһамланып эшкә тотынган. Ләкин совхозның элекке бүлек мөдире Хәсәнов, аңарга һәм аның иптәшләренә ышанмыйча, фермада «карусель» кую эшен туктаткан. Бу таш йөрәкле кеше шуның белән чын күңелле егетнең намусына, эшче горурлыгына тупас бәрелгән. Ләкин егетнең дә җавабы дөрес үк булмаган. Ул, «карусельгә» дигән двигательне башка урынга файдаланганнарын ишеткәч, аны яшереп куйган. Кайберәүләр бу двигательне, тикшерү органнарыннан кеше чакыртып, авылның астын-өскә китереп булса да табу яклы. Ләкин бүлекчәнең вакытлы мөдире булып эшли торган Айтуганов моңа каршы. Заманы ул түгел, кешеләре дә ул түгел, ди Айтуганов. Ул кешеләрнең намусына нык ышана, органнар катнашыннан башка да двигатель табылыр, аны яшергән кеше үзе үк китереп бирәчәк, ди һәм ялгышмый...

Шулай итеп, бу әсәрдә дә тырышып эзләнү, яңаны, бүгенгене табу омтылышы бар, төп игътибар кешенең үзенә юнәлтелгән.

«Беренче мәхәббәт»тән кала югарыда искә алынган әсәрләр Х. Вахитның комедия жанрында эзләнүләренең нәтиҗәсе иде. Аларның нигезендә комик конфликт һәм характерлар ята, геройларның үз максатлары өчен көрәшләре дә шул ук рәвештә бара. Күргәнебезчә, драматург шактый җитди мәсьәләләрне комедия жанрында чишәргә омтыла. Бер үк вакытта бу әсәрләр комедия өлкәсендә тәҗрибә туплау, көч сынау ролен дә үтәгәннәр. «Күк капусы ачылса» (1967) кебек татар драматургиясе тарихында күренекле әсәр барлыкка килгәннән соң, шушы фикер тумыйча мөмкин түгел.

«Күк капусы ачылса» язучының «Беренче мәхәббәт» драмасыннан соң, бөтен союз аренасына чыгып, зур уңыш казанган икенче әсәре, милли драматургиянең өлгергәнлеген, җитлеккәнлеген күрсәткән зур уңышы. Бу әсәр, рус, әзербайҗан, казакъ, үзбәк, башкорт һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп, дистәләрчә театр сәхнәсенә күтәрелде.

«Советская Башкирия» газетасы (1968 ел, 9 июнь) комедияне түбәндәгечә бәяләгән иде: «Аның эч катканчы көлдерә торган вакыйгалар белән тулы фабуласын сөйләп бирүе авыр, ул вакытта комедиянең бөтен текстын баштанаяк сөйләп чыгарга кирәк булыр иде». Әйе, «Как капусы ачылса» Х. Вахитның сюжет һәм образ, хәрәкәт һәм характерларны бергә бәйләп төзү осталыгы ягыннан иң зур казанышларыннан булды. Биредә бер вакыйга икенчесеннән табигый үсеп чыга, авторның фантазиясе шулкадәр иркен, сюжет иң яхшы классик комедияләргә хас җиңеллек белән үстерелә һәм катлаулана. Шул ук вакытта әсәр тирән мәгънәгә дә ия. Ул Х. Вахитның комедия өлкәсендә эзләнүләренең югары ноктасы булып исәпләнергә хаклы әсәр.

Моннан соң язылган «Илһамия» (1968), «Ике килен-килендәш» (1976) комедияләре «Күк капусы ачылса»ның үзенчәлекле дәвамы булып, аның кайбер сыйфатларын, мәсәлән, сюжет төзү осталыгы, актуаль һәм мөһим проблемаларны күтәрү ягыннан әһәмиятле казанышлар иде. Алар да төрле театрлар репертуарында зур урын алды.

Хәй Вахит комедия белән бергә драма жанрында да эшләде һәм торган саен аңа игътибарын көчәйтә барды. Соңгы ун ел эчендә язылган тугыз әсәрдән алтысының драма булуы әнә шул турыда сөйли. («Соңгы хат», «Туй алдыннан», «Мәхәббәтең чын булса», «Давыл», «Онытa алмасаң, нишләрсең», «Ялгышасың, Нәзирә».)

Аларның нигезендә иҗтимагый әһәмиятле конфликтлар ята. Һәм ул конфликтлар кешеләрнең эчке дөньясында барган көрәш белән үрелеп бара.

Х. Вахит мәкаләләреннән китерелгән өзекләрдә психологик анализга нигезләнеп язылган әсәрләрнең кайбер үзенчәлекләре турында әйтелгән иде. Шул исәптән геройның «үткәне, бүгене, киләчәге» булырга тиешлеге күрсәтелгән иде. Драма жанрында язылган әсәрләрендә ул, чыннан да, бу моментларны аеруча нык истә тота. Шушы максаттан чыгып, драматург Ибсен, Шоу уңышлы кулланган аналитик драма поэтикасына еш мөрәҗәгать итә.

Аналитик драмада вакыйгаларның, конфликтларның төенләнеше әсәр башланганчы ук хәл ителгән була. Геройлар күп кенә вакыйгаларда катнашып, төрле мөнәсәбәтләргә кереп, мәсьәләнең чишелешенә килеп тукталган булалар. Сәхнәдә геройлар тормышында туган хәлләр, эчке, психологик кичерешләр төп урынны ала, шуларга анализ ясала. Бу алым хәрәкәтне тагын да киеренке итә, бәрелешләр кискен төс ала, драматизм югары дәрәҗәгә җиткерелә.

«Беренче мәхәббәт» һәм «Туй алдыннан» драмасында геройлар арасындагы мөнәсәбәтләр күптән формалашып, югары драматик хәлгә җиткән. «Давыл», «Оныта алмасаң, нишләрсең» геройларының хәзерге язмышын ачыклауда да үткәндәге вакыйгалар хәлиткеч роль уйный. Аларның үзара мөнәсәбәтләре ничек формалашуын, ничек башлануын күрсәтү яки сәхнәдә аларны таныштыру максаты бирелдә куелмый. Болар инде булып үткән. Аналитик драма алымын кулланып, драматург сюжетны шундый итеп төзи ки, ул персонажларның эчке дөньясына тирән психологик анализ ясарга мөмкинлек бирә. Бу Х. Вахитның драматургиядә мөһим казанышларының берсе иде.

«Беренче мәхәббәт» тән соң язган «Соңгы хат» (1966) драмасында да Х. Вахит бу жанр алдында үзе куйган таләпләрне тормышка ашырырга омтылды. Әсәрнең геройлары Нияз, Зөфәр, Зөһрә инде югары мәктәп бетергән кешеләр, хезмәт юлына чыгу алдында торалар. Кем нинди эшне сайлар — менә шунда һәркемнең тормыш максаты ачылыр, кемнең кем икәне күренер. Драматург тагын чын драматик ситуация сайлаган, геройлар тормышындагы иң кискен, борылыш моментларын алган, характерларны тирән ачар өчен драматизмга бай вакыйгалар тапкан.

Персонажларның беришесе башта ипле, әдәпле генә күренсәләр дә, эшкә килгәч, шактый шомарган, хәйләкәр зат булып чыга. Әйтик, Зөфәр башта алдынгы, актив кеше булып күренә һәм үзен шулай күрсәтә белә. Ләкин эшкә бирелеп, бөтен көчен биреп хезмәт итү аның планнарына керми, ул төрле хәйләләр белән тизрәк җылы урын яуларга омтыла. Нияз Зөфәр белән бергә укыган, аны дус күреп йөргән, ә соңында килешмәс дошманына әйләнгән. Ике арага Зөһрә дә килеп кергәннән соң бу бәрелешләр тагын да көчәеп китә.

Әсәрдә аналитик драма элементлары бар. Чөнки биш ел буе институтта бергә укыган вакытта алар арасындагы мөнәсәбәтләр урнашып, формалашып өлгергән була инде. Менә шуның чынлыгын, дәреслеген, ныклыгын тикшереп карау, сынау пьесаның үзәгендә тора.

Беравыздан драматургның нәүбәттәге уңышы дип табылган «Туй алдыннан» драмасы нәрсәсе белән игътибарны җәлеп итә, анда нинди вакыйгалар бар?

Әсәрдә күтәрелгән үзәк проблема — чын дуслык мәсьәләсе.

Әлеге проблема Рафаэль белән Маратның үзара мөнәсәбәтләрендә чагылыш таба. Марат, якын иптәше Рафаэльнең гаебен дуслык хакына үз өстенә алып, аның урынына җәзага тартыла һәм биш елга хезмәт белән төзәтү урыннарына җибәрелә. Күрәсең, гадәттән тыш булган ситуация алынган, моның тормышта булуына тиз генә ышанып та бетмәскә мөмкин. Әгәр тикшерү органнары җентекләп караган булса, моның судны алдарга маташу, саташтыру булуы бик тиз беленер иде. Әмма эш анда түгел. Драматургны бу вакыйгага үзе түгел, ә Маратның һәм башка геройларның шушы вакыйгага уңае белән үзләрен ничек тотышы кызыксындыра. Нинди уйларга килгән, нинди нәтиҗәләр ясаган алар? Ә нәтиҗәсе бик кызганыч: Рафаэль чын дуслыкка лаек булып чыкмый, ул, Марат уйлаганча, зур йөрәкле, киң күңелле кеше булмаган. Киресенчә, адым саен кире сыйфатлары ачыла бара, соңыннан чеп-чи эгоист, карьерист булуы аңлашыла. Моның шаһиты булу Марат өчен икеләтә авыр. Җинаять эшләгән исем тагып, авыр хезмәт белән узган еллар, акланмаган өметләр Маратны авыр кичерешләргә дучар итәләр. Драматург Рафаэльнең чын йөзен ачкан кебек, Маратка карата да рәхимсез. Ялган дуслык, ул нинди генә формаларда булса да, ничек кенә әйбәт күренергә маташса да, кешене рухи яктан түбәнәйтә, кимсетә, рәнҗетә.

Шулай итеп, таләпчән дуслык, чын дуслык турындагы сүзен драматург моның киресен, фаҗигале нәтиҗәләрен күрсәтү аша белдерергә омтыла. Әлбәттә, бу теманы уңай үрнәк аша да күрсәтә алган булыр иде. Әмма ул тормышның тискәре күренешләрен алып та үз алдына куйган максатка ирешә алган. Төп ситуациянең уңышлы алынуы һәм аналитик драма алымын куллану бик нык ярдәм иткән.

Х. Вахит драматургиясе тематик байлыгы белән аерылып тора, ул тормышның төрле өлкәләренә үтеп керә. Ә һәр өлкәнең үзенә генә хас проблемалары була.

«Мәхәббәтең чын булса» (1972) (башта «Мин, укытучы» дип атала иде) драмасы, иҗая эчендәгә исеменнән күренгәнчә, сәхнәдә бик сирәк күренә торган, әмма бик мөһим проблемаларны күтәрә. Укытучы булу, яшь буынны тәрбияләү кебек изге эшкә алынырга һәркемнең хакы бармы? Чын укытучы кем ул? Гомумән укытучы булу, башкаларны өйрәтер өчен нинди кешелек сыйфатлары кирәк? «Мәхәббәтең чын булса» менә шул турыда сөйли. Аның геройларыннан яшь укытучы Мөршидә, мәктәп классларында чәчләре агарган Хәят, фронтовик Нурислам — менә кемнәр лаек бу зур исемгә. Аларның төп сыйфаты — балаларны ярату, ә яратуга ярату белән җавап бирәләр. Ә менә мәктәп директоры булган Әнвәр өчен мәктәп каядыр өскә үрмәләү өчен баскыч кына. Әгәр бер җай чыкса, ул, уйлап та тормыйча, класс журналларын мәңгегә ябарга бүген үк риза. Әсәрдә менә шушы көчләр, шушы караштагы кешеләр бәрелешкә керә. Һәм бу көрәш Х. Вахит каләменә хас драматизм белән сугарылып, тормыш һәм хезмәт турында уйландыра торган җитди сөйләшүгә әйләнә.

«Давыл» (1974) әсәре шулай ук аналитик драма алымы белән язылган. Хәзерге вакыйгаларны китереп чыгарган сәбәпләр моннан дүрт ел элек булып үткән. Заманында ашык-пошык кына су астыннан электр үткәргеч кабель салынган булган, шуның нәтиҗәсендә ул өзелеп тә чыккан һәм хәзер зур завод эштән тукталып калган. Монда гаепле кешене эзләү юлы белән китеп, детектив драма язарга да мөмкинлек ачыла кебек. Әмма Х. Вахит, сюжет төзү остасы булып танылган драматург, бу юлга басмый, ул һаман да персонажларның эчке кичерешләрен тирәнтен тикшерү белән кызыксына.

Х. Вахит иҗатында күтәрелгән мәсьәләләр торган саен җитдиләнә, тирәнәя бара. Моңа аның соңгы әсәрләреннән булган «Оныта алмасаң, нишләрсең» драмасы мисал була ала. Минзәлә театры бу әсәрне «Хыянәт» исеме белән сәхнәләштергән иде. Әсәрнең исемен болай атау да урынлы, әсәрнең эчтәлегенә туры килә. Чөнки драманың баш герое булган Заһитның яшьлек идеалларына, керсез, мәкерсез теләкләренә хыянәте һәм шуның нәтиҗәсендә туган тирән фаҗигасе аның бөтен тормышын чолгап ала. Бу — бик гыйбрәтле язмыш.

Бу әсәрдә бер генә мәсьәлә белән чикләнелми. Әмма Заһит образы белән бәйләнгән тема әсәрнең үзәгенә куелган. Бер дөрес юлдан тайпылган, түбән таба тәгәрәп киткән кеше, әгәр дә вакытында туктапып калмаса, котылгысыз рәвештә һаман шул юлдан бара бирә, ямьсез эшләр берсе өстенә берсе өелә бара. Заһит та аңа гына кагыла торган мәсьәләне егетләрчә хәл итә алмаган, бергә тору, бала тәрбияләү мәшәкатьләре алдында чигенгән, беренче мәхәббәтенә хыянәт иткән. Менә шушы беренче абынудан соң икенчесе, өченчесе кабатланган. Тормышта авыр хәлләр белән очрашканда, Заһит урау юлны сайлап алган. Шулай итеп, яшьтән яратып сайлаган геолог һөнәреннән дә мәшәкатьле эш дип (югары мәктәп дипломын читкә ташлап) баш тарта. Әлбәттә, Заһитны җинаять кодекслары ягыннан гаепләргә урын юк. Әмма ул совет җәмгыятенең мораль кодекслары нигезендә хөкем ителә, аның намуслы кешеләр арасында яшәргә хаксыз булуы күрсәтелә.

Шулай итеп, драма совет җәмгыятенең югары мораль принципларының ни дәрәҗәдә тормышка үтеп керүен, яңа җәмгыятьнең нигезләре әнә шулай ныгып баруын сурәтли.

Кайвакыт тормыштагы тискәре күренешләрне күрсәтү җитди мәсьәлә күтәрү билгесе дип аңлатыла. Әмма чынында исә бу әле бер нәрсә турында да сөйләми. Зур конфликтлар менә шул кимчелекләргә каршы көрәшне күрсәткәндә генә барлыкка килә ала. Ул булмаса, әлеге тискәре күренешләр коры бер иллюстрацияне, чүп-чар җыеп тутырылган капчыкны гына хәтерләтә.

Х. Вахит тормыштагы нинди генә күңелсез хәлләрне сурәтләмәсен, аның әсәрләреннән таза рух, оптимизм бәреп тора, ул укучы-тамашачыны гыйбрәтле язмышлар мисалында уйландыра, сискәндерә. Күңелсез хәлләр күргәзмә өчен түгел, ә алардан котылу, җиңеп чыгу өчен күрсәтелә. Х. Вахит драматургиясенең иң яхшы сәхифәләренең берсе, бәлки беренчесе, әнә шуннан гыйбарәт. Аның иҗатында җәмгыятебездә туктаусыз барган яңару, сафлану, үсү процессы чагыла.

Л. И. Брежневның КПССның XXV съездында алдынгы совет язучыларына карата әйткән сүзләре Х. Вахитка да туры килә: алар, диде ул, «коммунистик әхлагыбызның какшамас принципларыннан чыгып, кешенең иң яхшы сыйфатларын — аның принципиальлеген, намуслылыгын, тирән хисләрен күрсәтергә омтылалар».

Дөрес, Х. Вахит әсәрләрендә җитешмәгән җирләр, төрле кимчелекләр дә булмый калмады. Баштарак ул мелодраматизмга шактый урын бирде, кайбер әсәрләренә характерлар бөтенлеге җитмәде, катлаулы сюжет белән артык мавыгып киткән вакытлары да булды һ. б. Әмма ул шушы кимчелекләрне бетерү өстендә туктаусыз эшләде, укыды, уйланды.

Теге яки бу образның эшләнешенә, конфликтларның чишелешенә һ. б. карата төрлечә искәрмәләр ясарга юл калса да, идея-эстетик планда Х. Вахит совет сәнгатенең югары принципларына һәр вакыт турылыклы булды.

Х. Вахит — күпкырлы талант иясе. Ул шагыйрь дә, балалар өчен дә матур-матур әсәрләр язды. Барлыгы 20 китап авторы.

Х. Вахит дүрт опера либреттосы («Самат», «Дим буенда», «Җиһангир», Т. Гыйззәт әсәре буенча «Наемщик»), ике музыкаль комедия («Мәхәббәт җыры», «Кияүләр») иҗат итте. «Җиһангир» либреттосының бөтен союз конкурсында җиңеп, югары бүләккә лаек булуы Х. Вахитны бу жанрда да чын оста итеп таныта.

Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Х. Вахитның барлыгы 12 әсәре куелды. Күчмә театрлар сәхнәсендә «Соры кортлар», «Канлы куллар», «Нәзер», «Яшерен эзләр», «Ялгышасың, Нәзирә» исемле әсәрләре уңыш белән барды.

Хәй Вахитның кулъязмалары арасында 1971 елның 26 мартында язылган бер кызыклы хат сакланган. Аңлашылганча, авылдашлары туган авылдагы күренекле вакыйгалар һәм кешеләр турында альбом төзергә булганнар һәм шул уңай белән материал сорап Х. Вахитка да мөрәҗәгать иткәннәр. Х. Вахит үзенең кайда, ничек укуы турында гаҗәп үзенчәлекле җавап яза: «Мәмдәлдә 7 сыйныфны (ул чакта шулай сөйли идек) бетергәч (ул чакта Мәмдәлдә урта мәктәп юк иде), Казанга киттем, театр техникумында ике ел укыдым. Аны япкач, бер ел укытучы булып эшләдем, музыка училищесында укыдым, ансамбльдә җырладым, сугышта булдым, Польшага, Германиягә барып җиттем. Сугыштан соң консерваторияне тәмамлагач, Мәскәүдә ике еллык югары әдәбият курсларын тәмамладым. 1952 елдан СССР Язучылар союзы члены».

... Хәй Вахитның үзе турында, үз тормышы турында үз кулы белән язган сүзләре. Ул үзенең зур тормышын әнә шулай бернечә җөмләгә сыйдырган. Хатның күп өлешен ул үзләренең туган Мәмдәленә колхоз төзегән, аны аякка бастырган кешеләргә, укытучыларга багышлый һәм «Менә кемнәр турында альбом төзергә кирәк!» дип тәмамлый.

Бу юлларда никадәр тыйнаклык, никадәрле самимилек!

Хәй Вахитка 1978 елның 20 декабрендә 60 яшь туласы иде. Шуңа багышлап, Академия театры аның яңа әсәрен сәхнәгә әзерләде, ә китап нәшрияты иң яхшы әсәрләрен эченә алган җыентыгын басып чыгарачак. Кызганычка каршы, ул бу көннәрне күрә алмады. Шушы елның 7 июлендә ул бик вакытсыз, зур талантының чәчәк аткан чорында, көтмәгәндә арабыздан китте. Канлы фронтларны кичкән, күп еллар буе туктаусыз иҗат белән типкән йөрәге артык түзмәде. Шуның белән әллә никадәр яңа әсәрләр, матур теләкләр эшкә ашмыйча калды.

Әмма Хәй Вахит исеме татар совет культурасы тарихында зур урын алачак. Хәй Вахит безнең арада яшәр, чөнки аның күп сандагы гүзәл пьесалары озак елларга сәхнәдә калачак.

# ИДЕАЛГА ТУГРЫЛЫК

Халыкның үткәне һәм бүгенгесе, киләчәк идеаллары һәм революцион көрәш традицияләре аерылгысыз рәвештә бергә бәйләнгән. Шуңа күрә ул үзенең узган юлы, бу юлда тирән эз калдырган тарихи эшлеклеләре белән даими кызыксынып тора, аларны фәнни китаплардан укып кына түгел, ә сәнгатьнең могҗизалы нуры белән яктыртылган тере шәхесләр, үзенчәлекле характерлар буларак та күрергә, белергә тели. Мәсәлән, татар халкының сөекле улы, ленинчы революционер Хөсәен Ямашевның киң планда тарихи-конкрет сурәтләнгән җанлы образын, эшчәнлеген күрү теләге безнең күңелләрдә инде еллар буе үсә килгән рухи бер ихтыяҗ булып өверелгән иде. Шуңа күрә Атилла Расихның «Ямашев» романы укучылар тарафыннан зур кызыксыну белән көтеп, тансыклап каршы алынды. Романның беренче китабы әдәби тәнкыйтьтә дә нигездә уңай бәяләнде, русчага да тәрҗемә ителде.

Бу уңайдан шуны да искә алып үтәргә кирәк: тарихи темага язылган әсәрләр, бигрәк тә киң планлы романнар, бездә көн саен, ай саен туып тормый. Чөнки тарихи роман, В. Г. Белинский сүзләре белән әйткәндә, «тарих фәне белән сәнгать тоташкан бер нокта кебек» булганга күрә, язучы алдына зур җаваплылык һәм кыенлыклар куя, аның художниклык осталыгы өстенә чын мәгънәсендә тарихчы галим һәм философ булуын таләп итә. А. Расихның әлеге әсәрне озак еллар буе язуын шуның белән аңлатырга мөмкин.

Һәм менә, ниһаять, романның беренче китабы чыгуга ун ел тула дигәндә, «Айлы төннәр» дип аталган икенче китабы дөньяга килде [1].

Беренче китапта без Хөсәен Ямашевны Казанда 1905 елгы революция хәрәкәтләре эчендә күргән булсак, икенче китапта аның җитәкчелегендә Оренбургта большевистик «Урал» газетасын оештыру, чыгару, халык массалары арасында тарату белән бәйләнешле вакыйгалар сурәтләнә. Бу чор — Х. Ямашев эшчәнлегендә зур һәм әһәмиятле этап. Әсәрдә без Хөсәен, Хәдичә, Гафур, Фәрхетдин, Җәгъфәр һ. б. образлар белән кабат очрашабыз, шул ук вакытта күп кенә бүтән персонажлар белән танышабыз.

Бу ике китап арасында органик уртаклык, гомуми тыгыз бәйләнеш булу белән бергә, алар арасында күп кенә аермалы яклар да бар. «Айлы төннәр» китабы үзенең тормыш материалы, сюжеты, проблематикасы, образлар системасы, структур төзелеше белән чагыштырмача мөстәкыйль бербөтен тәшкил итә.

«Айлы төннәр»не укый башлагач та, вакыйгаларның урыны, характерыннан кала, ике китап арасында иң элек күзгә ташланган аерма һәм үзенчәлекләр — аларның структур төзелешләрендә. Мәгълүм булганча, беренче китап, нигездә, чагыштырмача мөстәкыйль новеллалардан тора. Мондый төзелешне, күрәсең, әсәрдә тасвирланган тормыш материалы үзе таләп иткән. Революция ил күләмендә бара, халыкның төрле катлаулары тормышына үтеп керә, аларны хәрәкәткә китерә. Гаҗәп чуар, катлаулы күренешләр, бәрелешләр, көтелмәгән ситуацияләр килеп туа. Язучыга мондый вакыйгаларның әле берсен, әле икенчесен алып, мөстәкыйль новелла характерындагы бүлекләр рәвешендә бирү кулайрак күренгәндер. Аерым-аерым исемнәр белән аталган бу бүлек — новеллаларның һәркайсының үз конфликты, образ-характерлары, чагыштырмача тәгәлләнгән микросюжеты бар. Мәсәлән, беренче бүлектә — үлем түшәгендә яткан ата һәм аның улы арасында кат-

---

[1] Атилла Расих. Ямашев. Айлы төннәр. Икенче китап, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1977.

лаулы идея каршылыгы, Хөсәен күңелендә «ике юл» бәрелеше. Герой авыр, мең төрле газаплар кичкән юлны сайлый. Икенче бүлектә — прокламация басучылар һәм шул ук өйдә чәй эчеп, «имансызлар», «фетнәчеләр» турында сөйләп утырган бутышник Гайнулла. Прокламацияләрнең халыкка барып җитүе турында «сөенчене» дә Хөсәенгә нәкъ менә шушы бутышник «китерә». Өченче бүлектә — кер урлап тотылган батрак Фәрхетдин һәм «бай улы», җитмәсә, «Якуп бай кодасы» Хөсәен. Алга таба да без, новеллаларга хас булганча, күп очракта характерлар бәрелешенә, көтелмәгән төрле хәлләргә, борылышларга корылган бүлекләрне күрәбез. Бу новеллалар, турыдан-туры, теге яки бу ягы белән Хөсәенгә килеп тоташкан хәлдә, бер ноктадан үсеп чыгып, һаман тармаклана баралар. Аларга яңадан-яңа геройлар килеп керә, вакыйгалар исә Хөсәеннәр өеннән Казанга, Чистай, Әлмәт якларына җәелә, хәрәкәт мәйданы торган саен киңәя. Биредә автор кулланган һәм әсәрнең нигезенә салган төп философик принцип — хосусыйдан гомумигә бару. Шәхси язмышлар халык язмышына кушыла, аерым микроконфликтлар, бәрелешләр зур бер иҗтимагый конфликтка — революция һәм контрреволюция көчләренең кораллы, канлы бәрелешенә кадәр үсә.

Әсәрне болай кору авторга революцион хәрәкәтнең киң панорамасын сурәтләргә, зур вакыйгаларны, аларда катнашкан күп шәхесләрне колачлап, иңләп алырга мөмкинлек биргән. (Киң колачлылыкның уңышлы үрнәге буларак, Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын хәтерлик.) Ләкин бу алым әсәрдә аерым элементларның (бүлек-новеллаларның һ. б. компонентларның) үзара бик тыгыз бәйләнгән бербөтен система булып тәмам оешып җитүен дә таләп итә. «Ямашев» романының беренче китабы шушы якка бераз аксый төшеп, урыны-урыны белән гомуми сюжет бөтенлегенә зыян килә, логик эзлеклелек йомшап китә. Шуңа күрә китап бераз таркаурак тәэсир калдыра.

Инде романның икенче китабына килсәк, аны язу процессында автор беренче китаптагы әлеге кимчелекләрне үзе дә сизенгән һәм искә алган булса кирәк. «Айлы төннәр»дә аның тагын да эзләнүе, төрле алымнар кулланырга, сюжетны җыйнакландыра төшәргә омтылуы күренә. Бу кисәк өчен сайланган тормыш материалы да аны шуңа этәрә. Биредә сурәтләү объекты итеп шулай ук зур, ләкин инде нигездә бер вакыйга — «Урал» газетасын чыгару алынган. Шуңа күрә әсәрнең сюжеты, композициясе дә эзлекле юлга төшә. Бүлекләр, аларда сурәтләнгән вакыйгалар сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре чылбырын хасил итеп, берсе икенчесенең логик дәвамы булып бара. Безнең күз алдыбыздан үзара тыгыз бәйләнгән төп өч этап уза. Беренче этап: газета чыгаруга әзерлек, «мөхәррир» мәсьәләсе, Хәдичәнең губернаторда булуы, Хөсәеннең оештыру эшләре, Уральскига бару, Әбелхәер Әбелмамбетов, К. Мотыйги, Г. Тукай, Г. Кариев, Ш. Мөхәммәдев, З. Рәмиев һ. б. белән очрашу-танышулар, ниһаять, газетаның беренче саны чыгу, аны халык арасында тарату. Шул уңайдан, «Урал»га параллель һәм аңа бәйләнешле рәвештә, татар демократик культурасын, киң массаларга аңлаешлы татар әдәби телен үстерү мәсьәләләре дә чагылыш таба. Бу этапта, татарча беренче спектакль куелган кичне Печән базары «изгеләре»нең җәнҗал куптарырга маташуын исәпкә алмаганда, ачыктан-ачык кискен бәрелеш эпизодлары юк. Конфликт әлегә «яшерелгән» хәлдә, потенциядә кала бирә, ул эчтән куерып кабара, үсә тора.

Һәм менә үндүртенче бүлектә — «Урал»ның халыкка килеп җитү күренешләре... Крестьяннар арасында газета һәм брошюралар таратып йөрүче Фәрхетдин белән Чынбулат, авылга атлы казаклар килеп җиткәнче, төнлә торып, тиз-тиз «ычкынырга» мәҗбүр булалар. Аларның юлында, төнге дала уртасында, күзләрен уттай ялтыратып, бүреләр күренә. «Әз генә чигенәләр дә юл буена тезелешеп тагы утыралар...» Күңелгә шом төшә. Йөрәкне кышкы яланда ач бүреләр өере белән йөзгә-йөз калган җәяүле ике юлчы өчен тирәнтен борчылу биләп ала...

Бүреләр белән очрашу — зур гомумиләштерү көченә, символик мәгънәгә ия булган сыйдырышлы эпизод икән ул. Нәкъ шуннан соң ук әсәрдәге вакыйгалар үсешендә яңа этап башлана. Контрреволюция көчләре өстендә бомба булып шартлаган, «кешеләрнең онын онга, көрпәсен көрпәгә» аерган газетага идея дошманнары — ике аяклы «бүреләр» һөҗүм итәләр, алар белән ачыктан-ачык бәрелешләр башланып китә. Вакыйгалар, еш кына беренче китаптагы кайбер ситуация һәм эпизодларны хәтерләтеп, кискен, маҗаралы төс ала бара, дулкын-дулкын булып бер дәрәҗәдән — икенче, өченче дәрәҗәгә күтәрелә. Башта — Хөсәенне «юан кеше» кисәтүләре, редакциягә милләтче хаты, газетаның нәширы

Тимерша Соловьев ризасызлыгы, Хәдичәнең икеләнүләре. Шуннан соң — корректор Басыйрга һөҗүм, урамдагы төнге бәрелеш, «дин вә мәгыйшәт»челәр башлыгы Вәли мулла белән Хәсәеннең йөзгә-йөз «очрашуы». Алга таба — полициянең төн уртасында килеп тентү ясавы, охранкага чакырулар, карагруһчылар доносы.

Иҗтимагый-идея каршылыклары хәтта гаилә, туганлык мөнәсәбәтләрен дә икегә ярып үтә. Хәдичәнең атасы Зариф Бадамшин кызы һәм кияүеннән тәмам йөз чөерә. Якуп бай белән Хәдичәбикәнең арасы өзелә. Боларга Фәрхетдиннең гаилә фаҗигасе һәм үзенең кулга алынуы, Т. Соловьевның нәширлыктан баш тартуы, Хәсәен белән Хәдичә арасындагы каршылыклар өстәлә.

Вакыйгалар шул рәвешле ашкынучан төстә үсеп, кульминациягә җитә — Хәсәен белән Хәдичә жандарм идарәсенә чакырылып, соңгы тапкыр кисәтелә. Шәһәрдәге хәлләр дә бик чуалчык төс ала.

Ниһаять, «чишелеш»— газетаны ябу һәм Хәсәеннәрне шәһәрдән сөрү.

Ләкин мондый финал конфликтның тулысынча сыйнфый дошманнар файдасына хәл ителүеме? Көрәшченең рухи яктан сынып җиңелүеме? Һич юк. Әсәрнең кызыклы бер үзенчәлеге шунда: аның әлегә басылып чыккан ике китабында да сюжет схемасындагы, вакыйгаларның тышкы кабыгындагы «чишелеш» белән конфликтның эчке мәгънәви яктан хәл ителеше туры килми, алар хәтта капма-каршы. «Айлы төннәр»дә вакыйгалар дәһшәтле финалга якынлашкан саен, укучы күңелендә, беренче китапны укыгандагы кебек үк, геройның язмышы өчен тирәнтен борчылу белән бергә, икенче дулкын — тарихи оптимизм белән сугарылган дулкын күтәрелә бара. Беренче китаптагы мәгълүм цикл, спираль рәвешендә, икенче китапта да кабатлана, ягъни шуңа охшап яңа бер әйләнеш ясала. Әнә ул, Хәсәеннәр чәчкән орлыклар чиксез киң Россиянең төрле почмакларында шытып килә. Газета эшчеләр, крестьяннар, приказчиклар, шәкертләр, демократик интеллигенция арасына барып керә, татар, башкорт, казакъ һ. б. халыкларга ирешә, аларда яңа фикер чаткылары кабыза. «Һәр җирдән афәрин һәм рәхмәт сүзләре ишетелә». Әнә ул, гади кешеләрнең елмаеп сәламләве, ерак-еракләрдан күпләп килгән, «күңелләрне шатлык, өмет белән тутыра торган җылы хатлар»... Казанда, Оренбургта, башка төбәкләрдә татар театр хәрәкәте, әдәби хәрәкәт үсеп килә, Г. Тукайлар, Г. Кариевлар киң, олы юлга җыена. Гаделсез тормыш һәм явыз көчләр тарафыннан туктаусыз кыйналып торган Фәрхетдиннәр, рухи яктан җебеп төшмичә, Хәсәеннәр йогынтысында чыныга баралар. Яшьлеге ятимлектә, ялчылыкта узган, мәхәббәте, башыннан үткәннәре үзе бер романтик легенда булган башкорт егете Чынбулат кебек кешеләрне дә тормыш һәм көрәш логикасы котылгысыз рәвештә Хәсәеннәр ягына китереп чыгара. Хәтта милекче крестьян «аумакайлыгын канына сеңдергән», төрле каршылыклар чытырманлыгында адашып, «дәһшәтле урталыкта» калган Җәгъфәрдә дә мәгълүм бер борылыш билгеләнә.

Боларның һәммәсе — көрәшнең әлеге этабында Хәсәеннең һәм аның фикердәшләренең рухи җиңүе, большевистик идеяләр сферасының киңәя баруы.

Шул рәвешле, романның беренче китабындагы нигез принцип — хосусыйдан гомумигә бару — «Айлы төннәр»дә дә саклана, ул тагын да киңрәк колач ала. Алдагы китапта Хәсәеннең эшчәнлеге яшерен түгәрәкләрдән, прокламацияләр басудан башланган иде, ә хәзер инде ул газета чыгара. Элек вакыйгалар, нигездә, Казан һәм аның тирәсендә барган иде, ә хәзер инде «бөтен мәмләкәт масштабындагы аренага» җәелә.

Шушы уңайдан язучы кулланган бер символик сурәткә дә игътибар итми мөмкин түгел. Югарыда без Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын телгә алдык. Бу романда Г. Ибраһимов, киң һәм куәтле хәрәкәт символы буларак та, зур әсәрнең төрле өлешләрен бергә бәйли һәм берләштерә торган чара буларак та, шаулап килгән дулкын образын кулланган иде. Куәтле дулкын шәһәр-авылларга килеп җитә, завод-фабрикаларга, мәдрәсәләргә бәреп керә һ. б. А. Расих исә икенче бер образ тапкан. Бу — романның ике китабында да әледән-әле күренгәләп, ялтырып киткән, хәрәкәт, аралашу, алга бару, «милли кабык»ка гына бикләнмичә, тагын да киңрәк дөньяга чыгу символы буларак кулланылган юл образы. Бер үк вакытта ул композицион чара булып та тора. Автор әсәрне Хәсәеннең «юл сайлавы» белән башлап, беренче китапны аның яңа ерак сәфәргә чыгып китүе белән «түгәрәкләп» куйган иде. «Айлы төннәр» дә юлны тасвирлау белән башлана. Бу сурәт ике китапны бер-берсенә ялгап, тоташтырып торучы алка, бәҗра хезмәтен үти. Ике китапта да әледән-әле геройларның юлга,

халык арасына чыгуы сурәтләнә (язучы бигрәк тә кызыкты юлны тасвирларга ярата). Икенче китапны автор шулай ук Хөсәеннең янә ерак сәфәргә юнәлүе, «кыңгыраулар чыңы» белән тәгәлләп, «түгәрәкләп» куя.

Әйе, Хөсәен, авыр сынаулар, кыенлыклар алдында баш имичә, алда тагы да бик күп хәвефле билгесезлекләр көткән юлга чыгып китә. Иҗтимагый-идея конфликтының хәл ителешендә оптимистик тенденция билгеләнә. Ләкин романны тулаем алганда, әлеге гомуми конфликт чишелеше бетмәгән, ул, күрәсең, алда булыр. Әсәр нигезенә салынган принцип белән барсак, көрәш тагын да киңрәк мәйданнарга җәелеп, төрле формаларга кереп дәвам итәчәк, дигән фикер туа.

Шушы урында без «Айлы төннәр»нең проблематикасына, әлеге китапта язучыны иң нык кызыксындырган төп мәсьәләгә килеп җитәбез. Беренче китапта автор төп проблема итеп революция һәм шәхес мәсьәләсен куйган иде. Инде бу китаптагы төп проблеманы ике сүз белән әйтсәк, идеалга тугрылык дип атау дөрес булыр кебек. Язучы образлар системасын да, нигездә, шушы мәсьәлә тирәсенә оештыра. Нәкъ менә революция идеалларына, демократик һәм социалистик идеалларга тугры булып калу Хөсәен һәм аның фикердәшләренең калку һәм күркәм сыйфаты буларак ачыла. Бу ягы белән Хөсәен, беренчедән, үзенә параллель сурәтләнеп килгән Җәгъфәр кебек «эзләнүче»ләрдән, икенчедән, күп кенә матбугат эшлекләләреннән аерылып тора.

Контрреволюция һөҗүменең көннән-көн көчәя баруы бик күпләрне сыный, бик күпләрне элекке караш-омтылышларыннан ваз кичтерә. Аларның «халыкка хезмәте» вакытлы мавыгу булып чыга. Бу уңайдан автор образлар системасында Т. Соловьев, К. Мотыйги кебек реаль шәхесләрне алудан да тайчанмаган. Һәм моның белән откан. Аларның берсе — Хөсәен чанасыннан «сикереп төшеп кала», икенчесе исә — шапырынырга яратучан һавалы каһарман — кыенлыкларны җиңеп чыга алмыйча, матбагасын сатып, «җырлап та тамагымны туйдыра алам» дип юана. Хәтта Хөсәеннең тормыш иптәше һәм хезмәттәше, «Урал»ның рәсми редакторы Хәдичә ханым да, алҗып, юлдан тайпыла башлый. Ә Хөсәен исә, нинди генә авырлыклар, кыенлыклар кичерүенә карамастан, көрәш идеалларына тугрылыклы булып кала.

— Идеягә бирелгәнлек, Габдулла,— ди ул саубуллашу кичендә Тукайга.— Иманың камил булса, нервыларың да нык булса, тайпылышсыз рәвештә үз кыйблаңа карап барасың. Олы идеаллар олы гамәлләр тудыра.

Ә каян килә соң аңа бу рухи чыдамлык, көч-куәт? Хөсәен дә бит күктән иңгән, гадәттән тыш сыйфатларга ия булган мифик пәһлеван түгел. Автор сурәтләгәнчә, башкалар кебек үк гади кеше.

Монда, әлбәттә, шәхеснең ныклы характеры үз ролен уйный. Ләкин бөтен хикмәт шунда: Хөсәен ялгыз түгел.

— Камил бит ул — ялгыз каһарман. Ә без — күп,— ди ул Тукайга. Хөсәен «Урал»ны чыгаруны үзенең шәхси эше итеп тә, партия тарафыннан зур ышаныч күрсәтеп тапшырылган бик җаваплы вазифа буларак та башкара. Ул партия оешмасы, хезмәт иярләре, Г. Сәйфетдинов, Г. Коләхметов һ. б. кебек фикердәшләре тарафыннан күрсәтелгән ярдәм һәм булышлыкларны да һәр вакыт тоеп тора, иң авыр минутларда алар белән киңәшә, аларның ярдәмнәренә таяна.

Димәк, Хөсәенгә бетмәс-төкәнмәс ышаныч һәм энергия биргән көч — хезмәт иярләре белән, демократик катлаулар белән бәйләнештә, әлеге җиңелмәс көч — партиядә, Ленин партиясендә.

Язучы әсәрнең төп проблемасы белән бәйләнгән шушы үзәк идеяне, декларатив рәвештә «маңгайга бәреп» әйтмәстән, әсәрнең буеннан-буена сәнгать чаралары белән сурәтләп килеп, укучының күңеленә сала. Шушы идея безнең күңелләргә якты нур сирпеп, коммунистик инангалылыгыбызны, халык көченә, партиягә булган ышанычыбызны тагын да ныгыта.

Автор теге яки бу идеяне көчәйтү өчен еш кына парлы образлар куллана. Мәсәлән, икесе дә ялчылыктан эшчеләр, революционерлар арасына килгән Фәрхетдин һәм Чынбулат. Яисә бер-берсеннән шактый ерак торган Җәгъфәр белән Хәдичәбикәне алыйк. Революциягә ярдәм итәрмен дип, аларның берсе бай хатынга йортка кергән, икенчесе Якуп байга кияүгә чыккан. Ләкин аларның икесе өчен дә кырыс нәтиҗә бер: «кеше беркайчан да мәхәббәт кебек олы, саф бәхетне сату бәрабәренә нинди дер эш, хәтта файдалы эш башкарырга хаклы түгел! Ул инде шул олы бәхетне инкяр итүе белән үзе дә ваклана, зур эшләр башкару сәләтен югалта».

Әсәрдә образларны сурәтләгәндә язучы тапкан кечкенә, ләкин сыйдырышлы, уңышлы детальләр бар. Аларның кайберләре

алда күрсәтелде инде. Шуларга өстәп, Вәли хәзрәтнең уң азау төшен суырып куюларын, юан сәүдәгәр Мортаза Гобәйдуллинның «бик нечкә тавыш белән» сөйләшүен һ.б. күрсәтергә мөмкин. Янсә мена кечкенә генә бер эпизод бутышник Гайнулланың бөтен бер мәзәк образын ача да куя. Бу полицейский атылып-бәрелеп Г. Камалның өенә килеп керә. «Галиәсгар энекәш,— ди ул,— мин әйтмәдем, син ишетмәдең, ярты сәгатьтән тентү ясау өчен синең кибетеңә килеп җитәчәкләр».

Дөрес, әсәрдә тулы көченә бик үк файдаланып бетелмәгән эпизодлар, вакыйгалар бар. Әйтик, Г. Тукайның атаклы «Китмибез» шигырен язуы һәм шуңа бәйләнешле хәлләрне киңрәк һәм җанлырак биреп булыр иде. Янсә татарча беренче спектакльне алыйк. Бу вакыйга — халкыбыз, культурабыз тарихында иң якты, иң тантаналы сәгатьләрнең берсе. Ләкин автор әлеге кичә турында язганда шактый коры итеп һәм өстән-өстән генә йөгертеп уза. Спектакльне дә Г. Камал берүзе генә оештырган булып чыга. Хәлбуки, истәлекләрдән һәм архив документларыннан күренгәнчә, татар театрын тудыру һәм аның эшен юлга салып җибәрүдә Г. Камал белән бергә Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, С. Рәмиев, И. Терегуловлар турыдан-туры катнашалар. Алар арасында Х. Ямашевның дусты һәм фикердәше Габдрахман Мостафин һ.б. яшьләр дә бар. Беренче спектакль Хөсәен Ямашевның «Учительская школа»дагы укытучыларыннан һәм тәрбиячеләреннән булган Ибраһим Терегулов җаваплылыгында уза. Казан губернаторы аңардан хәтта «бернинди речьләргә юл куймаска» дигән подписка ала. Шулай да, пәрдә ачылыр алдыннан С. Рәмиев чыгыш ясап, туган телдәге театрның татар халкы өчен әһәмияте турында сөйли. Боларны әсәрдә җанландырып, тәэсирле һәм истә калырлык итеп «уйнатып» булыр иде, әлбәттә. Гафур Коләхметов та театрга уен башланыр алдыннан гына килеп, «яхшы оештыргансыз», дип читтән карап йөрүче, «дружинниклар» башлыгы сыйфатында гына күренә. Ә бит Гафур һәм аның сеңелесе Суфия,— Ширгалиев һәм Морадова фамилияләре белән,— спектакльдә турыдан-туры катнашалар.

«Спектакль бетте. Гафур өенә кайтып китте»,— дип хәбәр итә автор коры гына. Болай гына булуы һич мөмкин түгел. Кайда ул бер-берсен котлаулар, чиксез дулкынланып, тәэсирләр уртаклашу, бергәләшеп яңа планнар корулар?.. «Кызганыч бала» әсәре исемен «Бәхетсез бала» дип үзгәртү дә кирәк булдымы икән?

Әсәрдә очы-очка ялганып җитмәгән, тиешенчә мотивлаштырылмаган урыннар да бар. Беренче китапта, мәсәлән, авылдан килгән, белеме дә, һөнәре дә булмаган Фәрхетдиннең заводта иң кара эштә эшләп, тиз арада гына атлык-сыерлык акча туплап өлгерүе бик тә шикле. Хәтта тылсымлы әкиятләрдә генә була торган могҗиза дияргә мөмкин. Икенче китапта, газетага ярдәм өчен дип, «экспроприация» оештырган, моңа төп башкаручы итеп Галимҗан Сәйфетдиновны тарткан Воинов провокатор булып чыга. Шушы авантюрасы аркасында «берничә революционерның һәм Фәрхетдиннең» башын ашый. Ләкин ничек итеп ул Г. Сәйфетдиновны, янсә бу эшкә кискен каршы булса да, барыбер азмы-күпме катнашырга мәҗбүр булган Хөсәенне сатмаган? Монысы да аңлашылмый.

Әсәрнең телендә, авторның сүз сайлавында кайбер кимчелекләр очрый. Мәсәлән, «большевистик идеалларны таратучы» диелә 244 биттә. Бирелә идеал һәм идея сүзләренең мәгънәсе бутала. Идеалны таратып та, өләшеп йөреп тә булмый. Алга куелган бөек максат, теләк-омтылышларның иң югары ноктасы ул. Аңа омтылырга гына мөмкин. Г. Кариев турында сүз барганда «әйтеп карады карый» (258 бит), «карый китаплар карап» (293 бит), «карый дустына карап» (шул ук биттә!) кебек гыйбарәләр очрап тора. Берәр персонаж телендә булса бер хәл иде, ә автор сөйләмендә аларның буталчык тудырудан, әледән-әле «карылдап» торудан башка мәгънәсе юк, минемчә. Романда күп кенә геройлар бер-берсенә һаман саен «тәнбиһ белән» карыйлар. Персонажларның карашында гына түгел, сөйләмендә дә азмы-күпме бертөрлелек сизелә. Бик үк табигый яңгырамаган репликалар да очрый. Әйтик, безгә инде таныш булган Фәрхетдин Хәдичә белән «Урал»ның теле турында сөйләшкәндә:

— Алай булса инде, эш икенчерәк **формада** икән,— дип куя. (38 бит.)

Янсә бер-ике урыннан Г. Тукай сөйләмен китерик. Уральскида үз номерына Х. Ямашев килеп кереп, үзара танышкач, Тукай аңа болай ди:

— ...Берәр шигыремне укып күрсәтүдер ниятегез. Читтән килгән мөсафир авызыннан әйбәт яңгырый микән минем шигырь?..

Мортаза Гобәйдуллин белән булган сөйләшүдән:

— ...Мине тәкәллефсезлегем өчен кичерегез, мине шулай булырга мәҗбүрият куша. Мин сезнең белән Русиянең төрле почмакларында яшәүче мөштәриләр исеменнән сөйләшәм. Мин Габдулла Тукай булам, тагы бер тапкыр исегезгә төшерәм.

Чын Тукай сөйләмендә, бигрәк тә кешеләр белән беренче танышып сөйләшкәндә, «мин-мин» ләр шул кадәр яңгырап тордымы икән?..

Бер мәкаләдә зур әсәрнең барлык үзенчәлекләрен, уңай һәм җитешсез якларын тәфсилләп күрсәтеп бетереп булмый, әлбәттә. Кайбер искәрмәләр теләк рәвешендә әйтелде, кайбер кимчелекләрне бик тиз редакцияләргә мөмкиндер.

Якын киләчәктә без Хөсәен Ямашев турындагы зур әсәрне тулы көенә һәм тагын да камилрәк төстә күрербез. А. Расихның хезмәте безнең әдәбиятта тарихи роман жанры үсешенә әһәмиятле өлеш булып керер дип ышанасы килә.

**ШӘЙХИ САДРЕТДИНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ЙОЛДЫЗДАН ДА ЗАМАН ҖИЛЕ ИСӘ

**Ике кеше сез күрәсез миндә —**
**Ике шагыйрь... яхшы кайсысы!**
**Кайсы аның — фәкать нәфес колы!**
**Ә кайсында — Ватан кайгысы!**

Р. Гатауллин («Халкым белән»).

Шигырьләрен укыгач, ирексездән, шагыйрьнең үзен күз алдына китереп карыйсың. Кем ул? Тормышта да шигырьдәгечә уйланучымы, әллә хис-фикерне ясаучы гынамы? Шигырьләрендә шагыйрьнең, гадәттә, үз яшәеше, характеры, темпераменты, сөйләү манерасы һ. б. чагылыш таба. Юкса, кайбер шагыйрьләрне бер-берсеннән аеру да кыен. Һәркемнең үз җыры, үз кыйбласы булу гына поэзия үсеше өчен әһәмиятле, халык өчен кадерле.

Шагыйрь Р. Гатауллинның 1978 елда дөнья күргән «Ирләр булыйк» исемле шигырьләр җыентыгын укыгач, моңа тагын бер кат ышанасың. Күбесе элекке китаплары буенча таныш, ләкин, шуңа да карамастан, аларны өр-яңа шигырьләр кебек итеп укыйсың. Шигъриятнең бөтен кыйммәте дә шундадыр, мөгаен.

Р. Гатауллин хисси-экспрессив планда иҗат итә. Бу, әлбәттә, аның үз табигатеннән, романтизмыннан килә. Шуның өстенә ул — Байрон, Һейне, Лермонтов, Шиллер кебек бөекләрнең романтизмы белән сугарылган. Шулардан өйрәнеп формалашкан шагыйрь. Һәм хәзер дә санап кителгән дөнья классикларының тәэсирен аның иҗатында сиземләргә мөмкин.

Кайберәүләр Р. Гатауллинны, нигездә, мәхәббәт җырчысы дип бәялиләр. Ә ачырак телләре «сөю-гыйшрәт турында тагын күпме язарга була» дип тә җибәрәләр. Ләкин болар поэзиянең асылын аңламаудан гына килә. Рәдиф Гатауллинны һич тә мәхәббәт турында гына язучы диясе килми. Аның тирән фәлсәфи, һәр кешене уйландырырлык шигырьләре аз түгел.

Сөйлә, китап, нинди гамьнәр кичеп,
төрле илләр үтеп, шулай да
бирдең алмаз телебез ачкычларын,
бабамнарның газиз тавышларын
ништердең ничек Тукайга?!
(«Татар китабы».)

Яки:

Биек булу — җиңел язмыш түгел, юкса,
Сөембикә манарасы!
Нигезе халык күңелендә булса гына
Нык торадыр баганасы...
(«Биеклеккә карап».)

кебек юллар халык язмышы белән борчылып, аның өчен янып-көеп яшәүче шагыйрьне күз алдына китереп бастыралар. «Кала» исемле шигырьдә шагыйрьнең туган җире белән аерылышу вакыты сурәтләнә:

Кала туган туфрак, кара!
Бәрәкәтле, дымлы, кара,
ата-бабам тире анда —
кала!

Ата-бабалар җире булган туган яктан китү авыр. Мөмкин булса, ул анда мәңгегә калыр иде. Юк, болар һич тә тема актуальлеген күздә тотып кына язылган шигырьләр түгел. Болар — күңелдә кристаллашкан, җан теләгән, вөҗдан кушканнан туган юллар. Җыентыкта шагыйрьнең сөйгәненә багышлаган «Идел-йортка чакыру» дигән әсәре бар:

Әйдә,
чакырам сине илемә, Иделемә...
Күр барысын да! Кайт әле син
көткән җиреңә, туган телеңә,
халкың күңеленә, моң күңенә!...

Шагыйрь һич тә әллә нинди катлаулы сурәтләр эзләп азапланмый. Гап-гади сүзләр... Ә шуларда күпме җылылык, халыкка күпме ихтирам. Шигырьдә сөю хисләре халыкны борчыган, уйландырган мәсьәләләргә килеп тоташа, бергә үрелеп китә, димәк, хис һәм фикер синтезы барлыкка килә. Р. Гатауллинның күп шигырьләренә шул сыйфат хас. Шуңа күрә монсы — фәлсәфи, монсы — мәхәббәт турындагы шигырь дип, катгый рәвештә бүлү дә кыен була.

Әлбәттә, Р. Гатауллинның мәхәббәт лирикасы хәзерге татар поэзиясендә үзенчәлекле урын тота. Яшьләргә хас хыял-омтылышлар шагыйрьнең мәхәббәт шигырьләрендә табигый рәвештә сурәтләнә. Шагыйрь һаман яшь, һаман ярсу. Аның уй-хисләрен син үзең дә кичергәнсең һәм кичерәсең, тик шигырь юлларына гына сала алмагансың. Шигырьне укыгач, хәтер чоңгылында яткан хатирәләрең хәрәкәткә килә. Ул чакта сиңа шул шигырьдән дә кадерлерәк нәрсә юктыр кебек тоела.

Ярат табигатьне!
— Мине ярат,— димим.
...Ә табигать үзе юлларында
Очраштырыр беркөн безне!
Аңлашырбыз, шикләнмим мин.

(«Мине ярат, — димим сиңа»...)

Яисә:

Апрель булып килдең, юк, май түгел,
мәңге миңа апрель булып кал;
мәңге шулай якты булсын кичләр,
сабый яшьле булсын болытлар.
Апрель булып кал син!

(Кал җырымда, апрель булып кал син!..»)

Табигать — шагыйрь өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы, шигъриятнең яшәү чишмәсе. Р. Гатауллин элегрәк язган шигырьләрендә табигатькә, аның предмет-күренешләренә мөрәҗәгать итә. Шагыйрьнең ассоциатив фикерләү үзенчәлеге дә нәкъ менә шунда чагыла булса кирәк. Китапка кергән иң яхшы әсәрләренең һәрберсендә диярлек табигатьтә булган күренешләр образ итеп алынган.

Мин дә, мин дә шундый бер гөл, чибәр,
Чәчәк аттым — йөрәк ашкынды...
Синең алда җилдән бөгелгән бер
Чәчәк итеп идем башымны.

(«Нигә тапкыр инде йөрәк мине...»)

Әлбәттә, мондый алым романтик шагыйрьләргә гомумән хас нәрсә. Бу тип шагыйрьләр үзләренең эстетик идеалларын кеше җаныннан, табигатьтән эзлиләр.

Ачуланып, тамырларын өзделәр...
Ә гөлләрем үлмәделәр,
гел кояшка үрләделәр.
(Син янымда идең.)

(«Ачуланып, тамырларын өзделәр...»)

Күренгәнчә, шагыйрь кеше күңелендә була торган уй-кичерешләрне, үзгәрешләрне табигать күренешләре аша күрсәтә. Табигатьтән күңелдә яшәгән тойгыларга туры килә торган яки контраст булган хасиятләрне эзли.

Тик Р. Гатауллинның соңгы еллардагы иҗатын күзәтеп чыккач, шул күзгә ташлана: шагыйрьнең элеккеге фикерләү рәвеше, шигъри алымы үзгәреш чорын кичерә. Шигырьләрдә абстракциягә, хикәяләүгә омтылыш көчәя. Шуның белән бергә әсәрләренең күләме арта, әмма күләм зурлыгы һәрчак фикер зурлыгына китерми. Һәм шулай ук ялгызак исемнәрне кирәгеннән артык күп куллану да шигырьнең тәэсир итү көчен киметә.

Париж
Эйфель манарасында мин,
яулык болгыйм бүген.
Ул яулыкка —
Эйфель үзе,
Версаль,
күперләре белән Сена —
гүя Париж төшкән.
(Казан сурәте ясалган яулык ник юк?! —
Җилфердәтер идем аны биектән!)

Бу юллардан шигъри мәгънә табу читен, әлбәттә. Шагыйрь иҗатының кыен бер чорын кичерә кебек. Ләкин болар һәммәсе дә табигый һәм зарури күренеш. Р. Гатауллин, гомумән, эзләнүчән, эксперимент-лардан курыкмаучан булуы белән аерылып тора. Шундый эзләнүләр нәтиҗәсендә генә татар шигъриятә сыйфат үзгәрешләре кичерә алды да.

Хис-экспрессия белән билгеләнә торган хасиятләр янәшәсендә рациональ башлангычның да Р. Гатауллин иҗатында үзенчәлекле яңгыраш табуын күрәсең. Соңгы вакытта шагыйрьдә рациональлеккә омтылыш сизелерлек көчәйде («Халкым белән», «Җирдә тагын нинди өн?..», «Ирон фандыр», «Европада татар шагыйрьләре» циклы һ. б.). Ул әлеге ике башлангычны синтезлау юнәлешендә туктаусыз эзләнүләр алып бара — иҗатының фикри куәтен арттырырга, тирәнәйтергә омтыла. Дөньяда бара торган вакыйгалар, үз халкының язмышы, әхлакый мәсьәләләр шагыйрьне торган саен ныграк уйландыра, дулкынландыра. Шагыйрь эзләнә, үзгәрә. Дөнья үзгәрә. Йолдыздан да заман җиле исә...

**ГАЗИНУР МОРАТОВ.**

# БАБАЙЛАРДАН КАЛГАН ИСТӘЛЕК

Садрислам бабай Сагындыков...

Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан бу бабайның ягымлы күзләре мәңгегә йомылганга байтак еллар инде. Шулай да күршесе Солтангәрәй абзыйның үзе ясаган скрипкасында борынгы көйләр уйнаганда, Садрислам бабайның элекке бәетләрне көйләве күпләрнең хәтерендә саклана. Сарман районындагы Яхшыбай авылының җанлы тарихы булган бу картлардан ул чакта ник бер генә бәет язып алынсын да, ник бер генә көй отып калынсын! Шуның аркасында электә булган вакыйгаларның күпме шигъри авазы хәзерге буыннарга ишетелми.

Хәер, Садрислам бабай үзе варисларына кордашларының һәм замандашларының иҗат мирасын калдыру хәстәрен күрә белгән.

Менә минем алда аның килене Рәсиха Сафиуллина тарафыннан сакланып калган берничә битле кульъязма. Хәтта хәзерге хәрефләр белән язылганнары да бар. Шуларның берсе — «Нигә бу ызгыш, нигә бу сугыш?» дип аталганы — беренче бөтендөнья сугышы бәете булып чыкты. Садрислам бабай аны 10—15 яшьләрдәге оныгы Земфирага әйтеп торып яздырткан.

«Тарихның бер бите ул, аны китаплардан да, күңелләрдән дә ертып ташлап булмый», — дигән ул. Сөйләүләргә караганда, әлеге бәетнең үз көе дә булган.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында солдатлар арасында туган бу бәет заманында телләрдән төшмичә җырланып йөргән. Ул соңыннан өйләренә кайткан солдатлар белән төрле өлкәләргә таралган. һәм аерым өлешләре махсус җыр булып формалашкан. Мәсәлән, әле күптән түгел генә басылып чыккан «Татар халык җырлары» китабында (Төзүчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов. Казан, 1976, 55 бит) «Урдык уракны» дигән 6 юллык җырның әлеге бәетнең бераз үзгәртелгән строфаларын тәшкил итүе әнә шул хакта сөйли.

**ДАМИР ГАРИФУЛЛИН.**

## Нигә бу ызгыш, нигә бу сугыш?

**Беренче бөтендөнья сугышы бәете**

Милади тарих ундүртенче ел,
Уртасын узып барадыр июль.

Хәсрәт башланды бу җир йөзендә,
Чыны июльнең унсигезендә[1].

---

[1] Германия Россиягә каршы сугышны 1914 елның 19 июлендә игълан итә. Әмма күпчелек бәетләрдә авылга тирән хәсрәт-кайгы көненең килүе итеп 18 июль күрсәтелә. Моның сере шунда: 18 июль көненә күпчелек авылларга мобилизация хәбәре килеп җиткән була. Мәсәлән, «Кайгылы көннәр» дигән бәеттә шундый юллар бар:
«унсигезе җомга көн килде хәбәр авылга».

Күрмәгән идек, белмәгән идек,
Бабайлардан да ишетмәгән идек.

Инде белдек тә, барып күрдек тә,
Сугыш җирендә канлар түктек тә.

Кыр эшләрендә иде һәр халык,
Эшлибез кызу бик арып-талып.

Урып уракны, куйдык зуратны,
Кайтырга кырдан җиктек тиз атны.

Бу кайтулардан булдык бәхетсез,
Аш-чәй үтмидер, булдык рәхәтсез.

Бөтен авылда, бөтен шәһәрдә,
Сугышка дип үк килгән хәбәр дә.

Бу хәбәр килеп язу да биргәч,
Тетридер тәннәр: «На войну!» — дигәч.

Әткәм кайда, дип балам юксыныр,
Без кайталмасак канаты сыныр.

Сугышка киту инде мәҗбүри,
Бер нарасыем янымда йөри.

— Әткәм! Әткәм! — дип сөйлидер һаман,
Яра салды бу күңелемә тәмам.

Үбә дә коча, алдым кулыма,
Бер бакыр акча бирдем кулына.

Илтифат итми сабый акчага,
Әткәм, ди, һаман, әйдә, кайтсана.

Шул сүзләр бигрәк өзде үзәкне,
Йөз парә итеп телде йөрәкне.

Җыендык бергә, төрендек бергә,
Гүя ки безне кертәләр гүргә.

Аһ, нә бу халәт, мисле кыямәт,
Юкса, булдымы яумел гарасат.

Бигрәк вәхшәтле кара көн туды,
Һәркем өстенә зур хәсрәт яуды.

Инде китәбез чыгып бу илдин,
Туган һәм үскән мөкатдәс җирдин.

Чыгабыз хәзер урам буенча,
Карыйм илләргә күзләр туйганча.

Әткәм-әнкәем, бала-чагасы,
Аерылып калды бездин барчасы.

Калды туганнар, калды илләр дә,
Ниләр күрермез барган җирләрдә.

Башым әйләнди, күзем бәйләнди,
Салкын су алып эчтем бер кәнди.

Файда булмады аннан йөрәккә,
Чөнки хәсрәтдин яна йөрәк тә.

... Барамыз хәзер тимер юл берлән,
Хәсрәткә катыш төрле уй берлән.

Барабыз инде солдат булырга,
Ачлык җитмәгән, корбан булырга.

Ә нәрсә өчен корбан булабыз?
Патша өчен, дип сүли муллабыз.

Ә халык өчен һаман да җәфа,
Патшалар анда коралар сафа.

Һаман барамыз тимер юл берлән,
Хәсрәткә катыш төрле уй берлән.

Шулай итеп без ерак барабыз,
Төрле сүз сөйләп гыйбрәт алабыз.

Киләдер кайсы яңа өйләнеп,
Имеш, җәл калган, килә сөйләнеп.

Әйтәдер кайсы: бер анам калды,
Хатыным берлән бер балам калды.

Калды, ди кайсы, магазиннарым,
Бар да алынды агай-энеләрем.

Сөйлидер кайсы Себер якларын,
Солдат хезмәтин иткән чакларын.

Качкан икән ул службасыннан,
Тотып алганнар күпер астыннан...

Килдек Варшауга, кундык алты кич,
Ходай язгачтын, чаралар юк ич!

Килеп төшәдер тупның ядрәсе,
Күрергә язгач, күрә бәндәсе.

Анда шатырдый, монда гөтерди,
Байтак солдатны бер туп бетерди.

Флаг күтәргәч сугыш башлана,
Безгә каршы дошман ташлана.

Сугыш башлангач, куба барабан,
Герман туплары уза арадан.

Ачылды хутлар, ватылды туплар,
Халык хәсрәтен кем ничек чутлар.

Никулай патша каушамый бер дә,
Сугыш дип игълан иткән һәр җиргә.

Калтырап эчтән, ялтырап тыштан,
Рәчәй ничек чыгар сугыштан?

Туп килеп төшкәч, җиргә чумадыр,
Җирне актарып янә чыгадыр.

Туплар атканда ятабыз җиргә,
Башны саклыйбыз көрәкләр берлә.

Туп атларыни солдатлар җигә,
Без туп атканда германнар чигә.

Янә германнар туп ата башлый,
Безнең солдатлар окопны ташлый.

Җиктем тубыма пар кара алаша,
Без туп атканда алар караша.

Без туп атканда алар кешниләр,
Ашарга сорап шинель тешлиләр.

Күренми һаман сугышның чиге,
Җиргә таралды патшалар чире.

Мәктүпләр килә туган илләрдин,
Хәсрәтләр төяп үскән җирләрдин.

Нигә бу ызгыш, нигә бу сугыш,
Хөррият кирәк, булсын ил тыныч!

# ФӘННИ КЫЮЛЫК

*Гыйбад Алпаровның тууына 90 ел*

*Г. Алпаровның тууына 90 ел тулу уңае белән мәкалә язу өчен материаллар караштырып утыра идем. Шунда институтның гыйльми хезмәткәре Г. К. Якупова бер кулъязма китереп тоттырды. Бу — мәрхүм профессор Л. Җәләйнең «Татар совет тел белеме һәм Гыйбад Алпаров» дигән мәкаләсе булып чыкты. Язылу вакыты — 1958 елның ноябрь ае. Күрәсең, хезмәт Г. Алпаровның 70 еллыгына багышлап язылган булган, ләкин ни сәбәптәндер матбугатка чыкмыйча калган.*

*Кулъязманы игътибар белән укып чыкканнан соң, мин мәкалә язу ниятеннән кире кайттым. Кайбер кыскартулар, төзәтмәләр белән, исемен дә үзгәртеп, «Казан утлары» редакциясенә шушы әйберне тәкъдим итәргә булдым. Чөнки, беренчедән, мәкалә эчтәлекле, җанлы язылган, Г. Алпаровның фәнни эшчәнлегенә объектив бәя бирелгән, аның татар тел белемен үстерүдәге роле тулы, матур ачылган һәм бүген язылгандай яңгырый. Икенчедән, Г. Алпаровны якыннан күреп белгән, аның фәнни хезмәтләре белән яхшы таныш булган күренекле тел белгеченең үз остазы турындагы фикерләре укучылар өчен, һичшиксез, кызыклырак булачак. Өченчедән, остазымның бу хезмәтен дөньяга чыгаруны үземнең изге бурычым дип санадым.*

**МӘХМҮТ МӨХӘММӘДИЕВ,**
**Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.**

Г. Алпаров — патша Россиясендә сыйнфый каршылыклар кискенләшә барган дәвердә, ике революция чорында, мәгърифәт, культура мәйданына чыккан татар укымышлыларыннан берсе. Ул да Бөек Октябрь социалистик революциясен зур теләктәшлек белән каршы алган алдынгы татар яшьләре сафында була.

Гыйбад Хәбибулла улы Алпаров 1888 елның 3 декабрендә элекке Уфа губернасы Эстәрле өязе (хәзерге Авыргазы районы) Корманай авылында дөньяга килә. 8 яшенә чаклы өендә ата-аналарыннан укый, аннары авыл мәктәбендә башлангыч белем ала. Соңыннан — «Госмания», «Галия»[1] мәдрәсәләре шәкерте. 1913 елда Казанда «Татарская учительская школа»ны тәмамлый. «Госмания» мәдрәсәсендә укыган елларын Г. Алпаров болай дип искә ала: «1904—1905 нче елларда инде мин газета аркылы бөтен дөнья әхвәле белән танышып баручы идем. Якыннан катнашмасам да, 1905 ел революция хәрәкәтләрен беркадәр аңлап, эчемнән аның яклы булып үткәрдем. Мәдрәсәдә мантыйк укуга каршы забастовкаларда катнаштым. 1907 елны, хәзрәтнең «бәддогасына» карамыйча, «Галия» мәдрәсәсенә күчеп киттем. Атам мине тәрбияләүдән кул селтәде».

1905—1907 нче еллар революциясе белән рухланган татар халкының прогрессив яшьләре милли культура — тел, әдәбият, халык иҗатын үстерү проблемаларын

[1] «Госмания», «Галия» — Уфадагы мәдрәсә исемнәре.



яңабаштан күтәреп чыгалар. Моның беренче аваз салучысы Ф. Әмирхан булды. Ул, мәсәлән, 1908 елны «Әлислах» газетасының 15 санында «Тел мәсьәләсенә бер караш» дип аталган декларатив мәкалә белән чыга. Анда тел һәм әдәбиятыбызны халыкчанлык рухы белән сугарырга, орфографияне яхшыртырга, тел буенча дәреслекләрне рус теле дәреслекләре өлгесендәрәк төзергә кирәклеге кебек заманы өчен бик тә мөһим бурычлар куела.

Ф. Әмирханның бу өндәмәсе һавада асылынып калмый, үзенә шактый бай җирлек таба. 1910—1911 нче елларда инде аның беренче җимешләре күренә башлый. Мәсәлән, 1910 елны Г. Тукай үзенең «Мәктәптә милли әдәбиятыбыз» дигән китабын дөньяга чыгара, Г. Нугайбәк, Г. Ибраһимовларның грамматикалары басыла. Шул ук елларны Габдрахман Сәгъди тел һәм әдәбият өлкәсендә эшчәнлек курсәтә башлый. 1912 елда Җ. Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» дип аталган, үз чоры өчен шактый әһәмиятле эзләнү, тикшеренүләрдән торган китабы матбугат дөньясына килә. М. Корбангалиев, Х. Бәдигый кебек галимнәребез дә үзләренең эшчәнлекләрен шушы елларда башлап җибәрәләр.

Күргәнебезчә, Бөек Октябрь социалистик революциясенә әзерлек чорында татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә эш алып баручы бер төркем үзешчәннәр — күренекле филологлар җитешкән була. Г. Алпаровның иҗади хезмәт юлы да шушы агымга килеп кушыла. Дөрес, башта ул (1908—1911 нче елларда) әдәби һәм фәннипопуляр әсәрләр яза. 1911 елда, мәсәлән, «Шура» журналының 2, 3, 4 саннарында «Дөнья эчендә дөньялар» дигән зур бер мәкалә белән чыга. Мәкаләсенең азагында «киләчәктә үсемлекләрдәге яшел матдәләрнең бөек хезмәтләре турында язармын» дип вәгъдә бирә. Ләкин чорның таләпләре аңа үсемлекләр дөньясына кереп китәргә юл куймыйлар. Шул ук елны «Шура»ның 12 санында ул инде хәреф, имла, ягъни тел өлкәсенә караган, фәнни-практик яктан әһәмиятле мәкаләсен бастыра. 1912 елда аны, киңәйтеп, «Хәреф вә имлабыз» атамасы белән аерым китап итеп чыгара. 1913 елда «Татар әлифбасы» дигән китабы укучыларга ирешә. Шулай итеп, ул тел өлкәсенә караган актуаль проблемалар өстендә эзләнүләр, тикшеренүләр, фәнни хезмәтләр иҗат итү юлына баса, һәм бу өлкә аны татар совет тел белеменең иң эшлекле, иң талантлы вәкиле дәрәҗәсенә күтәрә. Шуның белән бергә, Г. Х. Алпаровның Октябрьга чаклы һәм гражданнар сугышы еллары хезмәт мәйданы тәрҗемә, публицистик, журналистлык эшчәнлеге белән бизәлгән булуын да онытырга ярамый.

Җыеп әйткәндә, Г. Алпаров Советлар властен шактый киң колачлы тел галиме, мораль тотнаклы гражданин, халыкка, илебезгә хезмәт дәртендә янган яшь укымышлыларның берсе сыйфатында каршылый һәм гомеренең калган өлешен тулысынча совет фәнен үстерүгә багышлый. Ул татар теле белеменең гадәти вәкиле генә түгел, бәлки шактый киң колачлы тюрколог, ягъни төрки телләр белгече дә. 1922—1925 нче еллар аралыгында галим төрекмән, үзбәк, казакъ, башкорт теле орфографияләрен фәнни эшкәртү, алар буенча дәреслек һәм кулланмалар төзү эшенә якыннан катнаша. Мәсәлән, «Төрекмән дилинең грамматикасы», «Дил сабаклары», «Ололара сабаклык» (төрекмәнчә); «Башкорт теленең имласы» һ. б. Г. Алпаров тарафыннан язылалар.

Г. Алпаров, тел белгече буларак, аеруча үзенең «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (Казан, 1926 ел) белән зур танылык ала. «Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә» буларак язылган бу зур күләмле хезмәт совет татар теле фәне үсешенең яңа этабын башлап җибәрә. Дөрес, үз вакытында һәм соңрак та авторга бу кыю адымы өчен бик күп тәнкыйть йөге күтәрергә туры килә. Һәм еш кына хаксызга тәнкыйтьләнә иде. Тәнкыйтьнең төп юнәлеше, бу грамматикада телнең тик тышкы, ягъни шәкли ягы гына алынып, эчке — мәгънә ягы читләтелгән диюдә иде. Болай бәяләү тәнкыйтьнең берьяклырак булуыннан килә. Аңлашылганча, беренчедән, формаль нигезгә корылган грамматика телнең тышкы ягы белән эш итми булдыра алмый, юкса, ул шәкли грамматика булмас та иде. Икенчедән, автор ачыктан-ачык: «Дөрес, кайбер урыннарда мәгънә ягына да кагылмый булмас. Чөнки телнең тышкы әйтелеш ягы белән эчке мәгънә ягы бер-берсенә бик нык бәйләнештә була»[1], — дип әйтә. Аның, мәсәлән, сүз төркемнәрен эчке һәм тышкы яклардан карап классификацияләве, сүзләр ясалышын фонетик, морфологик, синтаксик төрләргә бүлеп каравы нәкъ әнә шул принципка корылган.

Галимнең төрки телләрнең килеп чыгышына карата әйткән фикерләре дә үз вакытында тәнкыйтькә очрады. Ул үзенең «Шәкли грамматика»сының керешендә: «Бер Урал-Алтай тамырыннан чыгып, төрле үзгәрешләр нәтиҗәсендә төрек (төрки), монгол, манжур, фин, самоед телләре туган. Шулардан, ялгыз бер төрек тармагыннан үсеп, хәзерге уйгур, үзбәк, кыргыз, казакъ, төрекмән, анатоли (госманлы), татар, башкорт, чуваш һәм башка бик күп аерым төрек телләре килеп чыккан»[2], дигән тезисны куя. Ш. Рамазанов аның бу тезисын Марр карашларын төшенмәү, буржуаз лингвистика йогынтысында булудан килә дип тәнкыйтьләгән иде[3]. Бу мәсьәләнең хәзерге көнге торышы Г. Алпаровны аклады. Төрки телләрнең бер тел-нигездән үрчегән булулары инде дәгъвасыз, инкяр ителми торган тарихи дөреслек булып әверелде.

«Шәкли нигездә татар грамматикасы» өч бүлектән тора: 1. Фонетика; 2. Морфология; 3. Синтаксис. Боларның өчесе дә, Ш. Рамазанов әйткәнчә, Г. Алпаровның фәнни сәләтен, талантын күрсәтеп торган үзҗирлекле (оригиналь) хезмәтләр. Ул, гомумән, әзер материал яки компиляция юлы белән эш итми торган, үзе тикшереп ышанган фактларны гына фәнни эшкәртә торган галим иде. Моны хәтта бер генә момент белән дә исбатлап була. Мәгълүм ки, Г. Алпаров фонетист-экспериментаист булмый. Шуңа карамастан аның грамматикасында татар теленең фонетик төзелеше тирәнтен тикшерелгән һәм үзенчәлекле яклары тулысынча ачылган. Мәсәлән, татар телендәге «а» авазының (басымсыз иҗектә) иренләшү үзенчәлеген беренче башлап ачучы, дәлилләүче Г. Алпаров була. Аның бу ачышын әлегә берәү дә юкка чыгарганы юк, киресенчә, раслыйлар гына. «О-ө» сузыкларының сүз эчендә әйтелеш үзенчәлекләрен билгеләүдә дә аның фикере аксиома итеп йөртелә. Төрки телләргә хас сингармонизм күренеше дә, беренче буларак, Г. Алпаров тарафыннан җитди тикшерелә һәм аңа «авазлар гармониясе» дигән гаять төгәл фәнни билгеләмә бирелә.

Татар телендә дә фонетик чаралар белән сүз ясалу булганлыгына башлап игътибар итүче һәм аны теоретик нигезләүче — шулай ук Г. Алпаров[4].

«Шәкли грамматика» татар телендә яшәмәктә булган формаларны тиешле кагыйдәләр челтәренә урнаштыру белән генә чикләнми, бәлки ул формаларның килеп чыгу тарихларын да яктырта. Аның «Кушымчалар тарихы» (65—66 нчы битләр) бүлекчәсендә кушымчалар формалашу тарихына кыскача гына экскурс ясала. Шуңа нигезләп, автор кушымчаларны «җанлы» һәм «җансыз» төрләргә бүлә һәм бик

[1] Г. Алпаров. Сайланма хезмәтләр. Казан, 1945 ел, 28 бит.
[2] Шунда ук, 24 бит.
[3] Шунда ук, 15 бит.
[4] Бу турыда Ф. Ә. Ганиевнең «Фонетическое словообразование в татарском языке» (Казан, 1973 ел) дигән хезмәтен карарга мөмкин. — М. Мөхәммәдиев.

дөрес эшли. Галимнең бу эзләнүе дә татар грамматикалары тарихында күрелмәгән бер яңалык булып тора. Хәзерге телчеләребезнең кушымчаларны «актив» һәм «пассив»ларга бүлеп йөртүләре, түбәндә, профессор Г. Алпаров тарафыннан ачылган фактның икенче бер атамалар белән йөртелүеннән башка нәрсә түгел.

«Шәкли нигездә татар грамматикасы» төрки телләргә бәйләнешле чагыштырма материалларга, мисалларга бай. Бу яктан караганда да, Г. Алпаров татар теле белеме тарихында беренче галим-белгеч саналырга хаклы. Чөнки татар телчеләреннән берәү дә аңа чаклы чагыштыру методын кулланмаган, һәм әле бүген дә моңа тиешле урын бирелми.

1927—1936 нчы еллар арасында Г. Алпаров татар теленең грамматик төзелешенә караган түбәндәге фәнни хезмәтләр өстендә эшли һәм дөньяга чыгара: «Татар теленең ялганмалык табигате турында» (1927 ел), «Татар телендә кушма төрләр» (1928 ел), «Функциональ сүзләр» (1933 ел), «Татар телендә иярчен җөмләләр бармы?» (1936 ел).

Боларның беренчесе гомумән төрки телләрнең морфологик төзелешенә хас ялганмалылык — аглютинативлык табигатен фәнни күзәтүгә багышланган. Биредә Г. Алпаров яңадан кушымчалар тарихына киң туктала, аларның борынгы мөстәкыйль сүзләрдән килеп чыккан булуларын исбатлый. Профессор Г. Алпаровның бу эзләнүләре эзсез югалып калмыйча, билгеле бер күләмдә киңәйтелде, тирәнәйтелде дип әйтә алабыз. Мәсәлән, аның иң талантлы шәкертләреннән берсе Ш. Рамазанов бер хезмәтендә фигыль ясагыч кушымчаларга җентекле тикшерену ясый һәм йөз егермеләп кушымчаның тулы төрләре унлап сүзгә генә кайтып калыр кебек күренә»[1] дигән нәтиҗәгә килә.

«Татар телендә кушма төрләр» дигән мәкаләсендә Г. Алпаров, аңлы рәвештә, төп классификацион принципларның берсе итеп компонентларның мәгънә бәйләнешләрен ала. Икенче төрле әйткәндә, формаль (шәкли) грамматика авторыннан көтелергә тиешнең киресе килеп чыккан. Ләкин монда искитәрлек берни дә юк, чөнки формалист саналган Г. Алпаров беркайчан да эчтәлекне инкяр итү юлыннан бармый. Бу хезмәтнең хәзерге көн өчен дә фәнни әһәмияте, галимнең бу теманы эшкәртүдәге җентеклелеге турында бик озын сөйләргә булыр иде. Урын тар.

Татар телендә дә, гомумән башка телләрдәге кебек, ярдәмлекләр, Г. Алпаров атаганча, функциональ сүзләр формалашкан. Алар безнең сөйләмебезгә мәгънә аныклыгы, стилистик төсмерләр бирүгә хезмәт итәләр. Ләкин бу төркем тел чаралары озак заманнар буенча, хәтта К. Насыйри грамматикаларыннан алып Г. Алпаров тикшеренүләренә чаклы (1933 елгача), тәртипкә салынмаган, мәгънәләре һәм синтаксик функцияләре ягыннан төркемләнмәгән килеш кала киләләр иде. Татар теле грамматик төзелешенең менә шушы таркау яткан байлыгы «Функциональ сүзләр (ярдәмлекләр)» дип аталган хезмәттә киң фәнни планда тикшерелә, системага салына. Бу хезмәтнең фәнни кыйммәте әле хәзер дә бәяләп бетергесез. Мәкаләнең кереш өлешендә автор: «Без монда сүзләрнең ялангач-формаль үзләрен генә төркемнәргә бүлмибез, бәлки аларны грамматик-функциональ категорияләргә аерабыз», — дип, һәр вакыт һәм һәр урында форма белән генә эш итәргә ярамаганлыгын ачык әйтә.

Шушы хезмәтендә Г. Алпаров татар телендә дә мөнәсәбәтле сүзләр булуын ача һәм аларга фәнни билгеләмә бирә. Тик шуннан соң гына бу төр чаралар мәктәп грамматикаларына да кертелеп, татар теленең иярченле кушма җөмләләре төзелешендәге үзенчәлекле аналитик формаларны өйрәнү җайга салына. Тик шуннан соң гына «Кайда ярлы, кайда зарлы, кайда моңлылар була, мин шулар янында булам...» (М. Гафури) яки «Кем эшләми, шул ашамый» кебек җөмләләрнең төрләрен дөрес билгели алу мөмкинлеге туа.

[1] Ш. А. Рамазанов. Татар теле буенча очерклар. Казан, 1954 ел. 153—178 битләр.

Тынгысыз, яшәүнең түмен дә, ямен дә тик эштән генә эзләгән галим, вафатыннан өч-дүрт ай гына элек, иярченле кушма җөмләләрнең төзелеш үзенчәлекләрен тикшерергә керешә. Хезмәтен «Татар телендә иярчен җөмләләр бармы?» дип, сорау җөмлә белән атый. Аның теләге бу проблеманы киң планга салып күзәтүдән гыйбарәт була. Ләкин хезмәт тәгәлләнеп бетмичә, беренче каралама килеш тукталып, өзелеп кала. Автор иярченле кушма җөмләләрнең табигатен, аларның аналитик һәм синтетик төрләрен җентекләп өйрәнеп, тиешле калыпларга салып өлгерә алмый. Ләкин, ничек кенә булмасын, аның бу хезмәте дә игътибарга лаек. Беренчедән, шундый зур проблеманы күтәреп чыгуы кыйммәт. Икенчедән, төрки телләр өчен бәхәсле саналган мәсьәләгә Г. Алпаров татар теле материалында шактый ачыклык кертә, бу юнәлештәге тикшеренүләрне дәвам иттерү өчен юл сызып калдыра.

Проф. Г. Алпаровның гомум тел белеменә, тел фәлсәфәсенә караган хезмәтләрен дә берничә сүз белән булса да искә алып үтмичә мөмкин түгел. Бу — «Тел гыйлемендә марксизмга таба» дигән җыентыгы. Хезмәт галимнең академик Марр җитәкчелегендә (Ленинградта) институт, аспирантура үткән елларында (1926—1930) язган доклад һәм мәкаләләреннән тора. Аларның барысы да Н. Я. Марр карашларын яктырту, үзенчә нигезләү күзлегеннән карап язылганнар. Шуңа күрә без аның бу хезмәтләрен бүгенге көнне тик тәнкыйть белән генә, марксистик тел белеме таләпләренә җавап бирерлек чамада гына файдалана алабыз. Аннары, гомумән, маррчыларның совет тел белеменә керткән өлешләре, яңалыклары инкяр ителмәгән кебек, безгә дә Г. Алпаровның татар теле белеменә керткән яңалыкларын исәпкә алу, уңай бәя бирүдән баш тартырга ярамас. Чөнки аның эзләнүләрендә бүген дә безгә кирәкле ачышлар бар. Мәсәлән, «су» сүзенә этимологик анализ, авазлар корреспонденциясе һ. б.

Г. Алпаров этимологик анализның нидән гыйбарәт икәнлеген аз-маз теоретик ачыклау белән генә чикләнми, үзе әйтмешли, үрнәк итеп, «су» сүзенең палеонтологиясен тикшерә. Монда автор чагыштырма-тарихи методны тулы һәм киң мәгънәсендә куллана, семантик ояга салу алымыннан да файдалана. Нәтиҗәдә аның тикшерүе киң җәймә төсен ала һәм, дөрестән дә, үрнәк булырлык бер хезмәткә әверелә. Ләкин сапламның очын гомуми глоттогоник процесска илтеп тоташтыруы белән генә, ягъни «су» төшенчәсенең дөньядагы барлык телләр өчен уртак булуын исбатларга тырышу белән генә мәсьәләне артык катлауландырып җибәрә һәм укучыны шиккә төшерә. Шиккә төшмичә дә булмый, чөнки тикшерүче тарафыннан китерелгән фактик материаллар Урал-Алтай телләренә генә карыйлар. Һинд-Европа, семит һ. б. төркем телләрдән алынган бер генә мисал да юк. Әмма аның «су» сүзе тирәсенә тупланган материаллары ифрат бай һәм ышандыргыч. Без бу хезмәтне татар теленә нигезләп ясалган этимологик анализлардан беренчесе һәм иң зурысы итеп санарга тиешбез.

Телнең иҗтимагый күренеш булуын, ягъни тел белән җәмгыять арасындагы тарихи бәйләнеш мәсьәләсен татар тел белемендә күтәрүе, беренче башлап аңлатуы Г. Алпаровның тел фәлсәфәсе өлкәсендә диалектик материализмны, тел турында марксизм-ленинизм тәгълиматларын торган саен тирәнрәк үзләштерә баруын күрсәтә иде.

Шулай, татар совет тел белемен фәнни эшкәртүдә, үстерүдә профессор Г. Алпаровның хезмәтләре санап бетергесез зур. Бу — дәгъвасыз. Безнең яшь телчеләребез аның бай фәнни мирасын бик нык өйрәнергә, үзләренең һәм фәнни, һәм практик эшләрендә аны файдаланырга тиешләр.

Г. Алпаров турында сөйләгән кеше аның тагын бер сыйфатын әйтми калдыра алмый, әлбәттә. Ул үз эченә, үз кабинетына бикләнеп, чокчынып ята торган галим генә түгел иде. Ул үзенә алмашка кадрлар, белгечләр әзерләү эше белән янып яши торган, хәтта авыру хәлендә дә студентларыннан, аспирантларыннан аерылмаска тырышып эшләүче җитәкче иде. Совет чоры тел белемендә үзләренең зур хезмәтләре белән танылган Ш. Рамазанов, Г. Хәбиб, В. Хангилдин, Ф. Хәмидуллин һәм башкалар — Г. А. Алпаров кулында тәрбияләнеп, аспирантура тәмамлап җитешкән тел белгечләребез. Әйтергә кирәк, мин дә Гыйбад ага аспиранты, шәкерте була алу бәхетенә ирешкәннәрнең берсемен.

Аның уйчан, тыйнак һәм үтә эшчән йөзен һәм: «Эшләргә кирәк, иптәшләр, эшләргә! Партиябез, халкыбыз, Ватаныбыз бездән эш көтә. Бөтен мөмкинлекләр бирелгән, эшчәнлек, тырышлык белән коралланыйк!» дигән сүзләрен мин беркайчан да хәтер түреннән төшермәячәкмен.

# ВАХИТ МОНАСЫЙПОВКА 50 ЯШЬ

Вахит Монасыйпов әдәбиятыбызга бай тормыш тәҗрибәсе белән килгән автор. Ул 1928 елның 20 декабрендә Актүбә шәһәрендә эшче семьясында туып, әдәбиятыбызга күп кенә талантлы авторлар биргән тугандаш Казахстан җирендә үсә. Хезмәт юлын ФЗӨ мәктәбен тәмамлап, слесарь булып эшләүдән башлап җибәрә. Аннан геология экспедициясендә коллектор вазифасын үти.

Беренче хикәяләре Ерак Көнчыгышта Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә хәрби газета битләрендә басыла.

Аннан ул Актүбә радиосында корреспондентлар челтәре белән җитәкчелек итә, авыл хуҗалыгын механикалаштыру училищесында укый һәм тракторист булып эшли — чирәм җир күтәрә.

Әдәбиятка мәхәббәт В. Монасыйповны 1959 елда Казанга алып килә. Җор тел белән язылган кыска хикәяләре һәм актуаль проблемаларны күтәргән үткен фельетоннары белән тиз арада укучыларны үзенә җәлеп итә. «Чаян» журналында эшли һәм даими рәвештә журнал сәхифәләрендә басыла килә. В. Монасыйповның сатира һәм юмор әсәрләре илебезнең күп кенә журналлары һәм хәтта башка ил вакытлы матбугаты сәхифәләрендә дә еш кына басыла тора. Ул бер үк вакытта балалар прозасы өлкәсендә дә актив эшләп килүче авторларның берсе, аның шаян хикәяләре нәниләр тарафыннан аеруча яратып укыла. Иҗаты һәм яше белән дә олыгаеп килүче, үзенчәлекле каләмгә ия язучыдан укучы киләчәктә яңа һәм кызыклы әсәрләр көтәргә хаклы.

# УКУЧЫ УЙЛАНА, ШАТЛАНА, БОРЧЫЛА...

*Укучылар конференциясеннән*

Тау ягы... Идел төбәге... Апас районының Борнаш авылы... Күпләргә мәгълүм шигъри як, якты як... Биредә иген игәләр, икмәк үстерәләр. Биредә хезмәт сөючә, шигъри җанлы, әдәбиятыбызны яратучы кешеләр яши. Алар «Казан утлары» журналын да яратып укыйлар икән. Саннарга игътибар иткәч, Борнашның район күләмендә «Казан утлары»н иң күп укучы авыл булуын күрдек. Без моның шулай икәнлегенә авылда уздырылган журнал укучылар конференциясендә тагын бер кабат ышандык. Ул көнне авыл клубына әдәбият сөючеләр җыйналган иде. Араларында өлкән яшьтәге абыйлар-апалар да, мәктәп укучылары да, колхозчылар да, авыл хуҗалыгы белгечләре дә, укытучылар да бар. Аларны монда татар әдәбиятына хөрмәт һәм мәхәббәт алып килгән. Журнал турында, гомумән, әдәбият турында чыгып сөйләүче иптәшләрнең сүзләренә, фикерләренә, теләкләренә караганда, алар журналның чын дуслары икән, журналда басылып барган һәр яңа әсәрне җентекләп укып баралар икән, укып кына калмыйлар, борчылалар, шатланалар, уйланалар, бәхәсләшәләр һәм фикер дә алышалар икән...

Гомерен җиргә, икмәккә багышлаган, пенсия яшендә булса да, әле һаман, кирәк була калса, колхоз эшендә катнашучы Лотфулла абый **Булатов** «Казан утлары» журналының авыл кешесе өчен аерылмас юлдаш булуы турында сөйләде. Ул үзе Г. Әпсәләмов романнарын, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романын, «Тау ягы повесте»н кызыксынып укуын әйтте. Соңгы сүзендә: «Татар полководецларының мемуарлары журналда ешрак басылсын иде. Безнең кебек карт солдатлар өчен, ветераннар өчен олы бүләк булыр иде андый материаллар»,— диде ул.

Укытучы Гайшә **Нуруллинаның** чыгышы да тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. Ул үзе мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта икән. Шуңа күрә аның чыгышы, нигездә, «Казан утлары»ның тел-әдәбият укытучыларына күрсәткән ярдәме турында булды. «Без журналны көтеп алабыз,— дип башлады ул үзенең чыгышын.— Берәр атна соңлабрак килми торса да, авылыбыз белән борчыла башлыйбыз. Чөнки журнал күптән инде безнең көндәлек тормышыбызның аерылгысыз бер өлешенә әверелгән. Аннары журналны укучы балалар да яратып, кызыксынып укый. Моның, әлбәттә, кечкенә бер сере дә бар. Без, укытучылар, кечкенәдән үк балаларда «Казан утлары»на мәхәббәт тәрбияләргә тырышабыз, аның нинди кыйммәткә ия булуын, нинди олы хәзинә икәнен төшендерәбез. Тырышлык бушка китми. Укучылар журналны, журнал аша татар әдәбиятын яратып үсәләр. Алар бүгенге әдәбиятны да иң элек «Казан утлары» аша күз алдына китерәләр. Журнал безнең өчен аеруча кадерле, чөнки дәрес уздырганда да, дәрестән тыш эшләр башкарганда да һәрчак шул ук журналга мөрәҗәгать итәбез. Әдәби әсәрләрдән тыш «Безнең календарь», «Сәнгать», «Публицистика» рубрикалары да безгә кызыклы, бай һәм яңа материаллар алып килә. Соңгы елларда басылып чыккан әдәби әсәрләрне дә яратып укыдык. Мәсәлән, Ә. Баяновның «Тау ягы повесте», Ш. Маннурның «Чын сөю бармы?» әсәре, Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы»... Алар бик күп. Х. Сарьян әсәренең теле әйбәт, җиңел укыла, күңел туларлык урыннары да байтак. Тик миңа повесть геройлары үлеп бетә башлагач кына авторга ачу килә. Чөнки табигый түгел, ышандырмый».

Колхозда ат караучы булып эшләүче Габбас **Хафизов** журнал турында шагыйрьләргә хас ялкын белән сөйләде. Ул үзе дә шигырьләр яза икән: район газетасы янындагы әдәби берләшмәнең актив члены, ул анда шигырьләр, очерклар белән катнаша. Быел «Рабоче-крестьянский корреспондент» журналы матбугатта актив эшләгәне өчен аны Почетлы диплом белән дә бүләкләгән.

— Мин кырларда туып-үскән кеше. Шуңа күрә дә мин әдәбиятны шул кырлар аша күрәм. Үзем үскән шул кырларга карап, укыган әсәрләремне дә бәялим. Мин бүген «Агыла болыт» романының авторы Габдрахман ага Әпсәләмов турында берничә сүз әйтмәкче булам. Ул бездә иң яратып укыла торган язучы. Бәхетле язучы. Ул үзе күргән, үзе кичергән бик күп вакыйгаларны безгә җиткереп тора. Әдәбият солдаты әле дә сафта, ул һаман яза, иҗат итә. Безнең өчен зур шатлык бу. Менә ул безгә тагын бер әсәр бүләк итте. Дөрес, Ш. Маннур Җәлил турында роман язган иде инде. Әмма Г. Әпсәләмов Җәлилнең батырлыгына үзенчә якын килә, үзенчә күрә. Без анда Җәлилнең батырлыгында коллективның да роле зур булуын күрәбез. Әсәрдә әнә шул ачык чагыла. Романда башка җәлилче-геройларның да легендар батырлыгы калку итеп сурәтләнә. Һәйкәлгә лаек батырлар алар!

Аннары мин Фатих ага Хөснинең яңа повестен мавыгып укыдым. Башка әсәрләре шикелле үк монысы да берничә этажлы, тирән мәгънәле, кинаяле әсәр. Хәтта бераз гына куркам да мин Фатих агадан. Газетада берәр хикәя бастырсаң, колагыңны борыр сыман.

Журналда басылган шигырьләрне дә укып барам. Соңгы вакытта «Казан утлары» битләрендә төрле стильле, төрле формалы шигырьләр күбәеп китте. Хәзер өлкән шагыйрьләребез яшьләр белән шигъри ярыш алып баралар бугай. Бу алышта, миңа калса, яшьләр өстенлек алыр кебек. Гомумән, яшьләр күбрәк басылсын иде журналда. Минем теләгем шул.

Аннары сәхнәгә урта мәктәп укытучысы Кәфил **Минһаҗев** күтәрелде. Ул журналны яратып укуы турында әйтте. Журналда басылган тарихи материалларны күтеп алуы хакында сөйләде. «Казан утлары» еш кына дәресләрдә ярдәмгә килүен, тарихыбызга багышланган очеркларны, истәлекләрне өстәмә әдәбият итеп файдалануын билгеләп үтте. Балалар, яшүсмерләр турындагы, аларның олы тормышка әзерлекләре турындагы әсәрләр күбрәк басылсын иде дигән теләк белдерде. «Озакламый колхозлар төзелә башлауга илле ел тулачак. Шул уңай белән колхозлашу чорына багышланган әсәрләр дә журнал битләрендә басылсын иде»,— диде.

Нәҗия **Шиһапова** укучылар исеменнән кайбер әсәрләргә тукталды:

— Журналны дүртенче ел рәттән укып барам мин. Басылган әсәрләр арасында ошаганнары да, ошамаганнары да очрый. Соңгы вакытта «Агыла болыт» романын кызыксынып укып чыктым. Х. Сарьянның повесте дә әйбәт тәэсир калдыра. Мин аеруча яшьләр иҗаты белән мавыгам. Мәсәлән, яшь язучы Нәбирә Гыйматдинованың «Су хикәяте» минем өчен ачыш булды. Журналны даими укып бару безгә һәрьяклап файдалы. Аерым әсәрләр бәхәсләр кузгата, җыелышып фикер алышу өчен сәбәп була. Хәтта дәресләрдә сочинениеләр дә әйбәтрәк языла. Киләчәктә журнал битләрендә күбрәк яшьләр турында, яңа төзелешләр турында язылган яңа әсәрләр күрәсе килә.

Язучы һәм журналист Мәрди **Рафиков** үзенең чыгышында журналның сыйфатына, бизәлешенә кагылышлы мәсьәләләр күтәрде:

— Мәктәпләрдә татар язучыларының, шагыйрьләренең, культура-сәнгать эшлекләренең портретлары юклыкка зарланалар. Алар төрле стендлар төзү өчен дә, дәресләр үткәрү өчен дә бик кирәк. «Казан утлары» бу җәһәттән бик әйбәт эш эшли алыр иде. Журнал тышлыгының эчке якларына портретлар биреп баруны гадәткә кертеп булмас микән. Югыйсә барыбер күп чакта ак килеш чыга бит алар. Аннары язучыларыбызның иҗат портретларын бирүне дә җайга саласы, берәр формасын табасы иде. Алар ничектер бик төрле-төрле булып, чуар булып чыга. «Безнең календарь» рубрикасы турында да уйлыйсы бар, минемчә.

Район газетасы редакторы Александр Филиппов зур төзелешләргә багышланган очеркларның азрак булуын, публицистик әсәрләрне мөмкин кадәр күбрәк күрәсе килүен әйтте. «Аннары журнал битләрендә республикабыздагы талантлы рәссамнарның иҗатын яктыртып барганда яхшы булыр иде. Яңа иҗат ителгән әсәрләренең

репродукцияләрен даими биреп барсаң, укучыларның кызыксынулары тагын да артыр иде»,— диде ул.

Китапханә мөдире иптәш **Әхмәдуллина**, журналда басылган әсәрләр белән беррәттән, гомум татар әдәбиятына киңрәк тукталды:

— Сүз дә юк, без журналны яратып укыйбыз. Журнал да безне ярата: безне татар совет әдәбиятының өр-яңа үрнәкләре белән, яңа әйбәт әсәрләр белән таныштырып тора. Әмма, кызганычка каршы, кайбер очракларда укучы кулына начар сыйфатлы журналлар килеп керә. Мәсәлән, журналның узган елда авылга килгән 7 нче, 8 нче һәм 11 нче саннары брак булып чыкты. Инде кызыксынып кына укый башлаган әсәрнең я ахырын укый алмый каласың, ә булмаса бөтенләй башы булмый. Шуннан соң укучының кәефе кырыла. Журнал белән укучы арасындагы дустанә мөнәсәбәт бозыла да куя. Редакциядә эшләүче иптәшләр моны истә тотсыннар иде. Журнал бит укучыда әйбәт зәвык тәрбияли, аны матурлыкка өйрәтә. Әмма начар сыйфатлы журналлар белән әйбәт зәвыкны да бозарга мөмкин. Сирәк булса да, әсәрләргә дә зәвык бозарлык детальләр килеп керә. Әйтик, Әхәт Гаффарның «Кашан җыры» повестенда кыз бала (җитмәсә, татар кызы бит әле) рәхәтләнеп тәмәке тартып утыра. Ә бит журналны укучы балалар да укый. Шуннан соң малайларны ничек итеп тәмәке тартмаска өндәргә мөмкин.

Аннары ул китапларның, бигрәк тә балалар өчен чыгарылган китапларның бик аз чыгарылуын, аларның китапханәгә бөтенләй диярлек килмәве турында әйтте. 1—3 класс укучылары өчен матур әдәбият таба алмаулары турында да сөйләде. Әдәбият сөючеләрнең китапларны, аеруча татар язучыларының китапларын яратып укуларын дәлилләп, ул таушалып, тузып беткән, хәрефләре танымаслык хәлгә килгән китапларны күрсәтте.

Конференциядә чыгыш ясаучы башка иптәшләр дә «Казан утлары» журналы турында кызыклы-кызыклы фикерләр әйттеләр, киңәшләрен, теләкләрен белдерделәр, журнал коллективына һәм авторларына яңа иҗат уңышлары теләделәр.

Конференция эшендә «Казан утлары» журналының баш редактор урынбасары, язучы Әхсән **Баянов** та катнашты. Ул журналның эше турында, журналның авторлары — язучылар, шагыйрьләр турында сөйләде, журналның киләчәккә билгеләнгән планнары белән таныштырды. Язучы үзенең иҗат планнары белән дә уртаклашты. «Тау ягы повесте»ның, «Төлке тоту кыен түгел» повестеның язылу тарихы белән кызыксынучыларга җаваплар бирде, журнал турында әйтелгән кыйммәтле фикерләр өчен конференциядә катнашучыларга рәхмәт белдерде...

Конференция шуны күрсәтте: журнал укучылар һич тә битараф түгел. Алар журналны яраталар, үз итәләр. Алар язучылардан, шагыйрьләрдән бүгенге матур тормышыбызны чагылдырган, замандашларыбызның хезмәттәге батырлыкларын чагылдырган, үзләрен яңа хезмәт җиңүләренә рухландыручы яңа әсәрләр көтәләр.

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН**,
журналның хатлар бүлеге редакторы.

# МАРИ МӘЗӘКЛӘРЕ

*Бу мәзәкләр букетын безгә халык иҗаты белән аеруча кызыксынучы мари язучысы Виктор Соловьев төзеп бирде. Аларда мари халкының үткән тормышындагы кайбер яклар, көнкүреш детальләре, традицияләр һәм гореф-гадәтләр чагыла. Һәм, әлбәттә, үткен телле фольклор әсәрләренә гомумән хас булганча, ялкаулыктан һәм комсызлыктан, куркаклыктан һәм намуссызлыктан, шапырынудан һәм тинтәклектән, әдәпсезлектән һәм усаллыктан көлү ярылып ята. Арада күңелләрне ача торган самими елмаюлар да аз түгел. Бу тезмә хөрмәтле укучыларыбызга хезмәтчел һәм күңелле мари халкының характерын һәм уй-хисләрен киңрәк аңларга һичшиксез булышыр дип ышанабыз.*

## СЫЕРЛАР КЕМНЕКЕ

Күләгәгә ятып йокыга китә бер көтүче. Сыерлар исә чәчүлек җирләргә таралышып бетәләр. Шуны күреп, көтүчене уялар:

— Сыерларың игенне таптый бит!

— Әгәр ул сыерлар минеке булса, көтүчесе мин булмас идем,— дип җавап бирә көтүче.

## ХАТЫН ГОРУРЛЫГЫ

Берәүне писарь итеп эшкә алалар. Шуны ишеткәч, хатыны әйтә икән аңа:

— Писарь хатыны булып яшәрмен дигән уй кайчан да булса башыңа килгәне бармы синең?

## КУЛЫ ПЕШМӘДЕ

Килен өстәлгә ашти китереп куя.

— Бармагың ашка тигән бит! — дип кисәтә аны кайнана.

— Курыкма, әнкәем, — ди килен, — ашти кайнар түгел ич.

## БУРЫЧЛЫ БУЛАСЫҢ

— Биш сум акча бир әле?

— Минем өч кенә сумым бар.

— Алайса, өчне бир, ике сумы миңа бурычың булып калыр.

## ҮГИЛӘР ҺӘМ ТУГАН КЫЗ

Бер үги ана сабан туй бәйрәмендә дүрт кызчыкка берәр йомырка пешереп бирә икән, ә үз кызына бернәрсә дә бирми.

— Ник аңа йомырка бирмисең? — диләр үгиләр.

— Нигә аңа бер бөтен йомырка? Һәркайсыгыз үз йомыркасының яртысын бирсәгез — аңа шул җитә.

## КАЯ КУСАҢ, ШУНДА АТЛЫЙ

— Нигә ат асрыйсың син?
— Печән ташыр өчен.
— Ә печән сиңа нигә кирәк?
— Ат ашатырга.

## КҮПМЕГӘ АЛСАҢ...

Бер карак күлмәк урлый һәм шуны сатарга малаен базарга җибәрә.

— Күпмегә саттың? — дип сорый ул малай кайткач.

— Син күпмегә алган булсаң, мин шул бәягә саттым, — ди малай.

## ТАВЫК ТА КҮРКӘ

Бер абзый кечкенә улын төннәрен кыяр урларга җибәрә икән. Малай исә чит кешеләр бакчасына керүдән курка да кыярны үз бакчаларыннан җыеп керә. Әтисе шуны икенче көнне базарга чыгарып сата. Малай икенче юлы да нәкъ шулай эшли. Һәм тагын берничә тапкыр...

Көзен әйтә икән ата үзенең улына:

— Молодец, улым! Әгәр син булмасаң, без үз кыярларыбыздан берниндә доход алмаган булыр идек. Кемнәрдер менә дигән яшелчә үстергәннәр бит. Безнеке ише түгел инде!

— Күршенең тавыгы да күркә булып күренә, — дип кенә әйтә бала.

## ЯХШЫ СЫЕР

— Сыер алдым әле.
— Ничек соң, әйбәтме?
— Менә дигән!
— Нәрсә, әллә сөте бик күпме?
— Юк, анысы әллә нихәтле түгел. Акыллы мал. Кичә кич кайнананы тибеп аяктан екты! Әле бүген дә түшәктән тора алганы юк, имеш.

## ЧИРАТНЫ БОЗМА

Ике кеше бергәләп ауга китә. Юлда берсе сорый икән:

— Әгәр бер куян атсак нишлибез?

— Ничек нишлибез? Пешерәбез дә ашыйбыз. Син кабасың, мин кабам, син кабасың, мин... мин...

Икенче аучы моның яңагына китереп суга һәм әйтә:

— Чиратны бозмаска кирәк! Берьюлы рәттән ике тапкыр капма итне.

## КЫЮЛЫК ӨЧЕН

— Әнә теге аучы урманда ник эт белән йөри?
— Курыкмас өчен, әлбәттә.
— Ә ник тагын мылтык та тоткан әле ул?
— Күрәсең, эттән куркадыр.

## ҮРДӘКНЕ КЕМ ҮТЕРДЕ!

Бергә ауга чыккан ике сунарчы суда йөзгән бер үрдәкне үтерәләр.

— Мин үтердем! — ди берсе.

— Юк, мин! — ди икенчесе.
— Син миннән соң аттың, үрдәк инде үлгән иде.
— Юк, синеке тимәде, ә мин тидердем.
Шул чакны бер абзый килеп чыга да әйтә боларга:
— Кем атты үрдәккә? Әллә өй үрдәген кыр үрдәгеннән аера белмисезме?
— Әнә бу атты! — ди аучыларның беренчесе.
— Юк, мин түгел, ул үзе үтерде аны.
— Әле хәзер генә әйттең бит мин тидердем дип.
— Юк, минеке тиде дип син әйттең...
Абзый кеше боларның мылтыкларын тартып ала да әйтә:
— Сез үз хәлләрегезне үзегез ачыклагыз, ә мин киттем. Үрдәкне кайсыгыз үтергәнен ачыклагач, акчасын китереп түләрсез. Мин авылның теге башындагы иң кырый йортта торам.

## КАЛАГА КИЛГӘЧ

Авылдан бер ханым зур калага килә һәм урамнарда бик күп кеше күргәч әйтә икән аптырап:
— Мин, ичмасам, эш белән килдем, ә бу халык бирedә нишләп йөри икән соң?

## ТӘРТӘЛӘРЕН БОРГАННАР

Казанга барышлый олаучылар ялга туктый. Барасы якларын онытмас өчен арба тәртәләрен Казан ягына каратып куялар. Төнлә, мужиклар йоклагач, бер узгынчы, шаяртып, шул тәртәләрне кире якка борып куя.
Иртән торалар да атларын җигеп тагын юлга кузгала мужиклар. Кичен алар бер авылга килеп җитә һәм гәп башлыйлар икән:
— Яман яхшы авыл. Йортлары төзек.
— Әйе, шәп яшиләр монда.
— Карале, безнең авыл шикелле үк ич бу! Менә бу йорт нәкъ минеке кебек. Ай, әнә теге ханымның минем хатыннан бернинди аермасы юк...

## ЯҢА ЧАБАТА КИГӘЧ

— Нишләп болай бик зур адымнар белән атлыйсың әле син?
— Чабатам озаккарак чыдасын өчен.

## АЧЫКЛАУ

Бер олаучыдан сорый юлчы:
— Нурыялга хәтле утырт әле!
— Төкерәм мин синең Нурыялыңа, — ди теге.
— Ә кайсы Нурыялга төкерәсең син: Олысынамы, әллә Кечесенәме?

## ӨЧ ПАР АЯК

Берәү атын тезгененнән тотып атлый икән юлда. Кемдер сорый:
— Кая барасың болай?
— Казанга ашыгам.
— Ә ник атыңа атланмыйсың?
— Өч пар аяк белән атлаган, юлны тизрәк узасың.

## БЕР ВАГОНДА

Шелангер станциясендә бер вагонга ике әби кереп утыра.

— Кая барышың, кәбәм?

— Казан тарафларына. Ә син кая?

— Мин Йошкар-Олага.

— Кара син аны, нинди көннәр килде: бер вагонда утырып икебез ике якка барабыз бит!

## ТАНЫМАДЫ

Бер агай өенә тәмам сәрхуш булып кайта. Хатыны аны ишек ачып каршылый. Ә агай исә аптырап чигенә икән:

— Әх, шайтан алгыры, тагын кеше өенә килеп кергәнмен бит.

## ТАГЫН ЭЧӘСЕҢМЕ!

Исерек ирен яңаклый икән бер ханым һәм сорый аңардан:

— Тагын эчәрсеңме? Әйт, эчәрсеңме?

Ир дәшми. Хатын, ярсыйрак төшеп, аның икенче яңагына менеп төшә.

— Мин сорыйм: эчәрсеңме, юкмы?

— Ярый алайса, сал берәр чәркә! — ди ир, кул селтәп.

## МАШИНА

— Әнкәсе, теге лотерея билетларын бир әле, менә таблица чыккан. Бәлки отканбыздыр.

— Мә! Әгәр машина чыкса нишләрбез?

— Права алам да сине утыртып йөртәм.

— Юк, синең белән бер кая чыгасым юк. Әле велосипедта да адәм рәтле йөри белмисең. Акчалата гына алырбыз отышны.

— Юк, акчаны син бер-ике айда туздырып бетерәчәксең. Ә машина машина инде ул: мал!

— Ничек инде туздырып бетерәм ди? Ник шулай начар уйлыйсың әле минем хакта?

— Ярый, шаулама. Теләмисең икән — машинада үзем генә йөрермен.

— Син һаман шулай инде — минем белән исәпләшергә гомердә теләмәдең, — ди хатын һәм үксеп елый башлый. — Ал машинаңны, беренче канауга мәтәлеп төш һәм шунда муеның сынсын...

— Балавыз сыкма. Тикшердем — отыш пычагым да чыкмаган, — ди ир кеше тыныч кына итеп.

## САРАННАР

Танышы кунакка килгәч әйтә берәү:

— Май булса коймак пешерер идек тә, он юк шул.

Аннары шул кеше танышына кунакка бара һәм ишетә:

— Күмер булса самавар куяр идек тә, су юк шул.

## ЧАКЫРУ

— Син бүген төштән соң буш буласыңмы?

— Әйе, буш.

— Ә иртәгә иртән?

— Иртәгә дә буш.

— Ә иртәгәдән арыга кичен?

— Эштә булам.
— Кара, нинди кызганыч! Берсекөнгә мин сарык суеп сине кунакка чакырмакчы идем бит...

### ИКЕ КУНАК

— Шулай иртә таңнан килмәсәң, соңгарып идеңме әллә? — диләр кунакка кичә кичтән үк килгән берәүгә.
— Иртән килгән кунак шул ук көнне китә, — ди тегесе, — ә кичтән килгәне кунарга кала.

### КҮРШЕСЕ СЫЙЛЫЙ

Берәү хәмер шулпасын чөмерүне бик ярата икән дә, тиң хатыны эчәргә ирек бирми. Ә ул шундый бер әмәл таба: аракы сатып алгач, күршесен ияртеп өенә керә дә:
— Хатын, — ди, — менә күрше мине сыйларга керде, кабарга берәр нәрсә куй әле тиз генә.
Утырышкач хуҗа хатынын да бераз сыйлыйлар. Һәм аннары әйтә хуҗа:
— Әнкәсе, кешенекен генә эчүе ничектер уңайсыз. Бар әле булмаса үзең дә тиз генә бер яртыны алып кайт.

### БӘЯЛӘҮ

Бер сукыр белән бер чукрак туйда булалар.
— Туй ошадымы? — дип сорыйлар икән соңыннан алардан. Сукыр әйтә:
— Бар да яхшы, әмма начар биеделәр.
— Юк, җырлый белүләре чамалы, — дип, үзенекен өсти чукрак.

### ТЫЙНАК КУНАК

— Хөрмәтле бу кунакны нәрсә белән генә сыйларга инде?!
— Әгәр закускасы тәмле булса, тамак чылата торганы ачы булса да ярый.

### КИНАЯ

Инде кичке якта күрше авылдан бер кунак килеп төшә берәүгә. Карыны ачкан икән. Әмма хуҗалар аны сыйларга ашыкмыйлар. Утыра-утыра да әйтә шулчакны кунак:
— Ә ашагач кайда ятып йоклармын мин?

### КАЙТАСЫ БУЛМА

— Кая чабасың, улым?
— Коеныргa...
— Әгәр батсаң, өйгә кайтасы булма.

### ОЗЫН ИСЕМ

— Нишләп син икенче авыл кызына өйләндең әле? Күрше кызын ярата идең бит.
— А-а-аның и-и-и-се-ме би-би-бик о-о-зын.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

Сентябрь аенда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Язучылар союзының ачык партия җыелышы булып, анда «КПСС Үзәк Комитетының июль (1978 ел) Пленумы карарлары һәм язучылар оешмасының бурычлары» дигән мәсьәлә каралды.

Пленум карарларын тормышка ашыруда Татарстан язучыларының эше турында докладны Язучылар союзы җитәкчесе Гариф Ахунов ясады. Докладчы табигый шартларның авыр вакытында барган урып-җыюга язучыларның якыннан катнашуын, егерменче язучының авыл проблемаларына, колхозчы хезмәтенә кагылышлы, алдынгы механизаторларның эшен зурлаган очерклар, мәкаләләр белән газета-журналларда чыгыш ясауларын хуплап сөйләде. Бүгенге көн проблемаларын чагылдырган зур күләмле әсәрләрнең, замандашларыбызның характерларын ачкан тулы канлы образларның әдәбиятыбызда әле җитәрлек булмавын искәртте.

Фикер алышуларга Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Әдип Маликов, Союзның партия оешмасы секретаре Туфан Миңнуллин һ. б. язучылар катнашты.

## МУСА ҖӘЛИЛ УРАМЫ

Шушы елның августында Төзүчеләр көне хөрмәтенә БАМдагы Беркакит поселогының үзәк урамына герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелде.

## ДУСЛЫК ҖЕПЛӘРЕ

Татарстан Язучылар союзы БАМ төзүчеләр белән тыгыз элемтәдә тора. Язучылар ярдәме белән Беркакит эшчеләр поселогында китапханә оештырылды.

Сентябрь аенда язучы Самат Шакир Беркакитның «Маяк» культура йортында уздырылган әдәби кичәдә катнашты. БАМ төзүчеләргә Муса Җәлилнең сугышчан тормышын сөйләде. Китапханәгә Җәлил бюстын, «Моабит дәфтәре» китабын, Муса турындагы фоторәсемнәр альбомын һ. б. сувенирлар бүләк итте.

Язучы Беркакитта Советлар Союзы Герое М. Җәлил исемен йөртеп алу өчен көрәшүче бригада членнары белән, Тында шәһәрендә, Могота, Лакри, Чульман поселокларында яшәүче БАМ төзүчеләр белән дә очрашты.

## ТОЛСТОЙГА БАГЫШЛАНГАН КОНФЕРЕНЦИЯ

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Актлар залында бөек рус язучысы Л. Н. Толстойның тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды. Анда әдәбият галимнәре, язучылар, республика һәм шәһәр җәмәгатьчелеге вәкилләре, студентлар катнашты.

Шушында ук Л. Н. Толстойның үзе исән чакта басылып чыккан һәм бүгенге көндә Казан университетының фәнни китапханәсендә саклана торган китапларыннан күргәзмә оештырылган иде.

Фәнни конференцияне кереш сүз белән Казан дәүләт университетының фәнни эш буенча проректоры, профессор Ш. Т. Хәбибуллин ачты.

Конференциядә «В. И. Ленин Л. Н. Толстой турында» дигән доклад белән Казан университеты доценты Л. Г. Юдкевич чыкты. Аннары КДУ доценты Т. С. Карпова, профессор М. Х. Гайнуллин, Казан дәүләт педагогия институты профессоры Е. Г. Бушканец, Казандагы А. М. Горький музее директорының фәнни бүлек буенча урынбасары Н. Х. Тур докладлары тыңланды.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## АБДУЛЛА АЛИШНЫ ИСКӘ АЛУ

ТАССР Дәүләт музеенда Муса Җәлилнең фашист лагерендагы көрәштәше, балалар язучысы Абдулла Алишның тууына 70 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде. Аны музейның әдәбият бүлеге оештырды.

Кичәдә А. Алишның иҗаты һәм тормыш юлы турында язучы Ләбибә Ихсанова чыгыш ясады. Аннары шагыйрь Галимҗан Латыйп һәм юбилярның бертуган энесе Галимҗан Алишев үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар. Ә Казанның 55 нче урта мәктәбе укучысы Гүзәл Булатова А. Алиш музеен оештыру тарихы, аның яшь буынны тәрбияләүдәге роле турында сөйләде.

ТАССРның халык артисты Айрат Арслановның А. Алиш шигырьләрен укуын тамашачылар бик яратып кабул итте.

Кичәдә Абдулла Алишның туганнары, язучылар, шәһәр җәмәгатьчелеге вәкилләре, студентлар һәм мәктәп укучылары катнашты.

## БӨЕК ГАЛИМ ХӨРМӘТЕНӘ

А. М. Бутлеровның тууына 150 ел тулу хөрмәтенә Казан шәһәренең Университет һәм Пушкин урамнары кисешкән җирендә һәйкәл куелды.



Бөек галимнең бу һәйкәлен скульптор Ю. Г. Орехов, архитекторлар В. А. Петербуржцев һәм А. В. Степановлар иҗат иткән.

## ХЕЗМӘТ һӘМ ӘДӘБИЯТ ДУСЛЫГЫ

Сентябрь аенда Украина ССРның Херсон өлкәсендә совет әдәбияты атналыгы булып узды. Илебезнең төрле республикаларыннан җыелган язучылар делегациясен СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, «Дружба народов» журналының баш редакторы Сергей Баруздин җитәкләде. Бу атналыкта Татарстаннан Равил Фәйзуллин катнашты. Язучылар Херсон өлкәсенең күп кенә шәһәрләрендә һәм авылларында булдылар, хезмәт ияләре белән очраштылар, әдәби кичәләрдә чыгышлар ясадылар.

## ШАГЫЙРЬ ТУГАН АВЫЛЫНДА

М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким туган авылы Күлле Кимедә булып, клубта авылдашлары белән очрашты. Аларга яна шигырьләрен укыды, сорауларга җаваплар бирде.

— Мин тәэсирләр, хисләр кешесе. Язу өчен миңа үз күзем белән күрү кирәк. Сезнең белән очрашкач, миндә горурлык хисе туа, туган авылыма һәм аның кешеләренә карата мәхәббәтем, аларны яратуым тагын да арта, — диде шагыйрь бу очрашуда.

## ДУСЛЫК БӘЙРӘМЕ

Ленин комсомолының 60 еллык юбилеена багышлап, Волжск шәһәрендә шигырь һәм җыр фестивале үткәрелде. Анда Идел буендагы өч республика — Татарстан, Чувашия, Мари АССРдан килгән шагыйрьләр, артистлар катнашты. Татарстаннан килгән яшь шагыйрьләр Фәннур Сафин һәм Госман Садә ялкынлы яшьлеккә багышланган шигырьләрен укыдылар.

## ЧАКМАГЫШТА ОЧРАШУ

Шагыйрь Галимҗан Латыйп Башкортстанның Чакмагыш районы хезмәт ияләре белән очрашты. «Герой» колхозының культура йортында һәм басуларда, район газетасы редакция хезмәткәрләре һәм типография эшчеләре белән булган очрашулар күңелле үтте.

Язучының якташлары ана төрле сораулар бирделәр, Казан хәлләре белән кызыксындылар. Авыл үзешчәннәре язучының җырларын, шигырьләрен башкардылар.

## РӘССАМНЫҢ УҢЫШЫ

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам Илдар Зарипов исеме республикабыз тамашачыларына якыннан таныш. Аның әсәрләре безнең илдә генә түгел, Монголия, Румыния, Чехословакия, Америка Кушма Штатларында үткәрелгән күргәзмәләргә дә куелды.

Совет сынлы сәнгатенең 60 еллыгына багышлап, Германия Федератив Республикасының Висбаден шәһәрендә, Франциянең башкаласы Парижда илебез рәссамнарының күргәзмәсе оештырылган иде. Анда Илдар Зариповның «Зөлфия» һәм «Казан чибәре» дигән картиналары куелды.

Хәзер рәссам «Зур Идел-79» күргәзмәсенә катнашу өчен «Сабан туе» дигән зур полотнолы әсәр өстендә эшли.

## ИҖАТ ОТЧЕТЛАРЫ

ТАССР Художниклар Союзы партия җыелышында сынлы сәнгать осталары В. Маликов, Р. Нурмөхәммәтов, В. Аршиновның иҗат отчетлары тыңланды.

Рәссамнар «Зур Идел-79» зона күргәзмәсенә ничегрәк әзерләнүләрен сөйләделәр.

Җыелышта СССР Художество академиясе член-корреспонденты, РСФСРның халык художнигы Харис Якупов, РСФСР художество фондының Татарстан бүлеге директоры Е. Макаров һ. б. чыгыш ясады.

## «ЯШЬЛЕК» БИЮ АНСАМБЛЕ ЧЫГЫШЛАРЫ

«Органик синтез» производство берләшмәсенең культура сараенда оешкан «Яшьлек» бию ансамбле Польша Халык Республикасында булып кайтты.

Алар Варшава, Вроцлав, Краков шәһәрләренең культура сарайларында, эшчеләр клубларында, ачык эстрадаларда концертлар бирделәр, эшче яшьләр белән очраштылар, Польша үзешчән сәнгать көчләре белән таныштылар.

## АЗНАКАЙ ҮЗЕШЧӘННӘРЕ

Болгариянең София, Варна, Плевен шәһәрләрендә татар җырлары яңгырады. Республикабыз хезмәт иияләре яратып тынлый торган Азнакай үзешчәннәренең чыгышлары иде ул. Болгар дуслар да, данлы Дунай буйларында ял итүче туристлар да, Георгий Димитров исемендәге Халыкара яшьләр үзгенә килгән поляк егетләре һәм кызлары да татарстанлыларның чыгышын хуплап каршылады.

Болгар-Совет дуслыгы атналыгы уңае белән бирелгән концертта катнашып, Азнакай үзешчәннәре лауреат исемен яулады, 4 көмеш, 5 бронза медальгә лаек дип табылды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет сынлы сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен рәссам **Тавил Гыйният улы Хаҗиәхметовка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әлмәт драма театры директоры **Фазыл Хәйретдин улы Хәмәтдиновка РСФСРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Лениногорскидагы «Чишмә» әдәби берләшмәсенең 20 еллыгы уңае белән, шәһәрнең Калинин исемендәге техника йортында зур әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Берләшмәнең эшчәнлеге турында язучы Бикчурин сөйләде.

«Чишмә» иҗат берләшмәсендә шагыйрьләрдән Гәрәй Рәхим, Шамил Маннапов, Мәхмүт Газизов, Җәүдәт Дәрзаманов, прозаиклар Җәмит Рәхимов, Альберт Хәсәнов, филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов һәм башкалар беренче әдәби чыныгу алдылар. Иҗат коллективы хәзер егермедән артык яшь каләмне берләштерә.

Юбилярны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Илдар Юзеев, идарәнең оештыру эшләре секретаре Мөсәгыйть Хәбибуллин, «Казан утлары» журналы редколлегиясе исеменнән язучы Атилла Расих, Татарстан Язучылар союзы Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Әдип Маликов, КПССның Лениногорск шәһәр комитеты пропаганда бүлеге мөдире Марс Исхаков, «Иркеннефть» идарәсе вәкиле Әнвәр Мусин һәм башкалар котлады. Әдәби берләшмә эшендә актив катнашулары өчен шефконсультант Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, Альберт Хәсәнов, Разим Вәлиуллин Татарстан Язучылар союзы идарәсенең, шәһәр оешмаларының Мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Икенче көнне язучылар ике группага бүленеп, район колхозларында үткәрелгән әдәби кичәләрдә чыгыш ясадылар.

* * *

Бүлек утырышында «Язучы һәм авыл темасы»на багышланган фикер алышу үткәрелде. Бүлек җитәкчесе Ә. Маликов, язучылардан Р. Төхфәтуллин, Җ. Рәхимов, М. Хәсәнов, Ш. Бикчурин, Х. Хәйруллин КПСС Үзәк Комитетының 1978 ел июль Пленумы карарлары яктылыгында язучылар алдында торган бурычлар һәм үзләренең иҗат планары турында сөйләделәр.

Шул ук утырышта Җәмит Рәхимов «Очерк — сугышчан жанр» дигән темага доклад ясады.

# 1978 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

*1978 ел өчен республиканың Габдулла Тукай исемендәге премияләрен бирү турында. № 6.*
*Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Дәүләт гербы турында Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы. № 8.*

М. И. УЛЬЯНОВАНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Н. Крупская. **Владимир Ильичның сеңелесе. № 2.**
Е. Стасова. **Ульяновлар гаиләсе хатын-кызлары. № 2.**
В. Карпинский. **Каһарманлык. № 2.**

СОВЕТ АРМИЯСЕНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

М. Галиев. **Җиңүчеләр мәрхәмәте. № 2.**
С. Кальметов. **Хурлык тамгасы. № 2.**

«СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Ш. Хамматов. **Әдәбият һәм сәнгать елъязмасы. № 3.**

ПРОЗА

Ч. Айтматов. **Әйләнеп кошлар кайтканчы. № 12.**
С. Айни. **Беренче тәэсирләр.** Хикәя. **№ 5.**
Батулла. **Китек күңел.** Хикәя. **№ 9.**
Б. Камалов. **Ярсөяр әрәмәсе.** Повесть. **№ 6.**
Р. Кәрами. **Очар кошлар белән янәшә.** Повесть. **№ 9, № 10.**
Ш. Маннур. **Чын сөю бармы!** Лирик повесть. **№ 3, № 4.**
Ш. Маннапов. **Туган якка кайту.** Нәсерләр. **№ 4.**
М. Мәһдиев. **Кеше китә — җыры кала.** Повесть **№ 11.**
Г. Рәхим. **Саргаймагыз, каштаннар.** Повесть. **№ 8.**
Р. Солнцев. **Көймә ватылса — утын.** Повесть. **№ 5.**
Ә. Сәйфетдинов. **Җырла, иркәм!** Повесть. **№ 6.**
К. Тимбикова. **Агым уртасында.** Повесть. **№ 12.**
М. Хәбибуллин. **Туй балдагы.** Хикәя. **№ 12.**
Фатих Хөсни. **Картая белмәс картлык.** Повесть. **№ 2.**
Ф. Яруллин. **Курку.** Хикәя. **№ 11.**
Г. Әпсәләмов. **Агыла болыт.** Роман. **№ 1, № 2.**
Т. Әйди. **Божра.** Маҗаралы повесть. **№ 7.**

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

Ш. Бикчурин. **Рекомендация.** Хикәя. **№ 12.**
Ә. Гаффар. **Ак каен дегете.** Хикәя. **№ 8.**
Р. Мингалимов. **Мәскәү, Токио, Нью-Йорк...** Хикәя. **№ 1.**

К. Кәримов. **Тәнәфес.** Хикәя. № 4.
Р. Фәизов. **Мәдинә.** Хикәя. № 11.
С. Хафизов. **Согданелла.** Хикәя. № 6.
М. Хуҗин. **Ике бөртек күз яше.** Хикәя. № 10.

## ПОЭЗИЯ

Ш. Анак. **Көн белән саубуллашу.** Шигырьләр. № 11.
Н. Арсланов. **Бакча юлы.** Шигырьләр. № 6.
Г. Афзал. **Рухым.** Шигырьләр. № 1.
Ә. Атнабаев. **Сау булыгыз.** Шигырьләр. № 2.
Ә. Баянов. **Яңа шигырьләр.** № 9.
С. Баттал. **Кышкы урманда төн.** Шигырьләр. № 11.
С. Баттал. **«Татарлар елмаеп үлделәр».** Шигырь. № 2.
К. Булатова. **Яз, газиз углым.** Шигырьләр. № 3.
Р. Гатауллин. **Йолдыз җавап язмый.** Шигырьләр. № 10.
А. Гадел. **Италмас.** Шигырьләр. № 4.
И. Ганиева. **Җиргә кушылып.** Шигырьләр. № 4.
Ш. Галиев. **Безне Ленин үстерде.** Шигырьләр. № 4.
М. Галиев. **Еллар чалымы.** Шигырьләр. № 11.
Ф. Гыйззәтуллина. **Болыннарда атлар утлый.** Шигырьләр. № 3.
Р. Гәрәй. **Туган як шигырьләре.** № 8.
С. Гәрәева. **Яңа шигырьләр.** № 5.
Ә. Давыдов. **Төрле еллар авазы.** Шигырьләр. № 1.
Г. Зәйнашева. **Иң моңлы көй.** Шигырьләр. № 1.
Н. Измайлова. **Юлга чыгам.** Шигырьләр. № 8.
Г. Латыйп. **Тау тәкәсе.** Шигырьләр. № 9.
З. Мансуров. **Кояш чыгышы.** Шигырьләр. № 6.
Н. Мадьяров. **Кыска шигырьләр.** № 3.
Р. Миңнуллин. **Ленин Язы.** Шигырь. № 4.
Р. Миңнуллин. **Шундый минем туган ягым.** Шигырьләр. № 5.
Р. Миңнуллин. **Күзләреңә карап сөйләшәм.** Шигырьләр. № 7.
Р. Мингалимов. **Кышкы шигырь.** Шигырьләр. № 12.
М. Рафиков. **Кыска шигырьләр.** № 4.
Г. Рәхим. **Туган илем, Татарстан.** Шигырь. № 10.
Ә. Рәшитов. **Тормыш әлифбасы.** Поэма. № 7.
Ә. Синугыл. **Тауларга карап.** Шигырьләр. № 4.
К. Сибгатуллин. **Кар шыгырдый.** Шигырьләр. № 10.
Г. Садә. **Мәхәббәт елы.** Шигырьләр. № 10.
Ф. Сафин. **Казан гомере.** Шигырьләр. № 6.
Ф. Сафин. **Игенчегә.** Шигырьләр. № 10.
С. Сөләйманова. **Сер алдым.** Шигырьләр. № 3.
С. Сөләйманова. **Сузган ике кулым.** Шигырь. № 11.
Р. Фәйзуллин. **Кыска шигырьләр.** № 5.
Р. Харис. **Бәхетлерәк кем бар бездән!** Шигырьләр. № 2.
С. Хәким. **Кырның бер төшендә кояш.** Шигырьләр. № 2.
Ф. Чанышева. **Әнкәй килә минем каршыма.** Шигырьләр. № 3.
М. Әгъләмов. **Тагын бер Көн...** Шигырьләр. № 4.
Х. Әюпов. **Бәхет.** Шигырьләр. № 5.
Ф. Яруллин. **Бер сүз әзлим.** Шигырьләр. № 6.

## ОКТЯБРЬНЫҢ БӨЕК БАЙРАКЧЫСЫ

Я. Димов. **Яз бәйрәме.** Шигырь. № 11.
Л. Кондрашенко. **Ленин.** Шигырь. № 11.

Л. Хьюз. **Җир шары буйлап.** Шигырь. № 11.
М. Хәсәен. **Бүген дә ул түргә уза.** Шигырь. № 11.

## КЛАССИК ПОЭЗИЯ ҮРНӘКЛӘРЕ

Р. Гатауллин. **Җәлилнең рухи туганы.** № 8.
Ф. Гарсиа Лорка. **Кереш моң.** Шигырьләр. № 8.
**А. С. Пушкиннан яңа тәрҗемәләр.** № 12.
Т. Әйди. **Гаделлек һәм ирек җырчысы.** № 7.
**Уйгыр шагыйре Билал Назыйм газәлләре.** № 7.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

Бердах. **Диңгез балыгын бирмәде.** Шигырьләр. № 11.
М. Гали. **Сигезьюллыклар.** № 9.
В. Давыдов-Анатри. **Эшче Вәкил Сабитов янында кунакта.** Шигырь. № 9.
М. Казаков. **Яңа икмәк.** Шигырьләр. № 9.
Ж. Жаббаров. **Мәңгелек.** Шигырь. № 9.

## ӘДӘБИ МИРАС

М. Ногман. **Кошлар базарында.** Поэмадан өзек. № 8.
Г. Хуҗиев. **Ярата идем мин сезне...** Героик драма. № 6.

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Х. Вахит. **Ике килен-килендәш.** Комедия. № 7.
И. Юзеев. **Кыр казлары артыннан...** Драма. № 10.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Н. Габбасов. **Төн — караңгы, төн — кара.** Шигырьләр. № 12.
Н. Гыйматдинова. **Су хикәяте.** Хикәя. № 3.
Р. Гыйззәтуллин. **Казлар.** Хикәя. № 8.
Р. Имаев. **Тынгысызлар.** Шигырьләр. № 9.
М. Латыйпов. **Яңара уйларым.** Шигырьләр. № 9.
Ф. Мәүлетов. **Кичке якта.** Шигырьләр. № 12.
Ш. Маннапов. **Күпләр чакыра мине...** Шигырьләр. № 12.
Р. Рәкыйпов. **Диңгездә.** Шигырьләр. № 4.
Т. Сәгыйтова. **Осталар өй сала.** Шигырьләр. № 3.
Р. Фахразиева. **Авылымда икмәк исе.** Шигырьләр. № 3.
Ф. Хәлиуллина. **Туган җирем.** Шигырьләр. № 3.
Р. Хәлиуллина. **Җиреңнең ал-гөле.** Шигырьләр. № 12.
В. Хәбибрахманова. **Җилләр иссә.** Шигырьләр. № 3.
М. Хәбибуллин. **Йолдызларга күктә кыен микән!..** Шигырьләр. № 9.
К. Шафикова. **Сер сөйләдем...** Шигырьләр. № 9.
С. Шәрипова. **Игенче.** Шигырьләр. № 3.

## ОЧЕРКЛАР

Г. Ахунов. **Без бит Арча яклары.** Репортаж. № 8.
У. Алиев. **Гомерлек сабак.** № 5.
У. Белялов. **Ир асылы—илгә таяныч.** № 7.
И. Буркова. **КамАЗда очрашулар.** № 1.
М. Васин, Р. Сабиров. **Варислар.** № 9.
Г. Волков. **Казан — мәхәббәтем минем.** № 6.
Л. Ихсанова. **Профессор Равилә.** № 1.
Ж. Кәлимуллин. **Егет булсаң — даның китсен.** № 3.

А. Литвин. **Революция солдаты. № 3.**
М. Маликова. **Камчатка ерак та, якын да. № 11.**
М. Мөлеков. **Егерме алтының берсе. № 12.**
Г. Паушкин. **Идел тугаенда. № 9.**
М. Рафиков. **Иделкайнең ак ташы. № 11.**
А. Ремакль. **КамАЗ турында легенда. № 6.**
Җ. Рәхимов. **Күпер. № 10.**
Ш. Рәкыйпов. **Днепр ярларында таллар бар. № 5.**
Ш. Рәкыйпов. **Кайту. № 10.**
А. Сәләхетдинов. **Сынатмас Сомовлар. № 7.**
И. Хәбиб. **Полкташыбыз Муса Җәлил. № 12.**
М. Хәсәнов. **Камил гүзәллекне яклап. № 4.**
А. Хәсәнов. **Гәрәбә диңгез ярларында. № 4.**
Г. Хәбибуллин. **Галим, җәмәгать эшлеклесе. № 6.**
Д. Шәрәфетдинов. **Сабан туе — халык яшьлеге. № 6.**

## ПУБЛИЦИСТИКА

Р. Бәдыйгов. **Бердәм сафта. № 11.**
Г. Бәширов. **Әле соң түгел. № 10.**
М. Госманов. **Саклап каласы иде. № 10.**
Ш. Хамматов. **Дәһшәтле еллар авазы. № 5.**
М. Хәсәнов. **Бөтен халык эше. № 10.**

## ӘДӘБИ БӘЙРӘМНӘР

**Ш. Мәрҗанинең тууына 160 ел**

М. Йосыпов. **Күренекле тарихчы. № 4.**

**Н. Г. Чернышевскийның тууына 150 ел**

К. Фасеев, Я. Абдуллин. **Чернышевский һәм татар иҗтимагый фикере. № ..**

**Л. Н. Толстойның тууына 150 ел**

О. Кадыйров. **Тәрҗемәләр һәм цензура киртәләре. № 9.**

**Хөсәен Фәезхановның тууына 150 ел**

М. Госманов. **Тарихыбызда Хөсәен Фәезханов урыны. № 9.**

**С. Айнины тууына 100 ел**

**Таҗик совет әдәбиятына нигез салучы. № 5.**

**Фәтхи Бурнашның 80 еллыгына**

А. Әхмәдуллин. **Коммунистларча принципиальлек белән. № 1.**

**Ш. Усмановның тууына 80 ел**

А. Яхин. **«Пуля тизлегенә ияләшкән каләм». № 12.**
М. Маннурова. **Ш. Усманов әсәрләрендә интернационализм идеяләренең чагылышы. № 12.**
Ш. Усманов. **Беренче адым. № 12.**

**Абдулла Алишның тууына 70 ел**

Р. Кукушкин. **Шигъри әкиятләр остасы. № 9.**

Фатих Хөснигә 70 яшь

М ә т ә с к ә н е ң фантазер малае. № 2.

Чыңгыз Айтматовка 50 яшь

М. Госманов. Олы мәхәббәт, якты моң җырчысы. № 12.

Шәүкәт Галиевкә 50 яшь

Р. Кукушкин. Витаминлы шигырьләр. № 11.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. Бикмөхәммәтов. Татар прозасында эшче образы. № 4.
М. Вәлиев. Язмышлар турында уйлану. № 1.
М. Вәлиев. Рухи тәҗрибә турында. № 8.
Б. Гыйззәт. Хәй Вахит һәм аның геройлары. № 12.
Р. Миңнуллин. Киләчәк буын хакына. № 11.
Ф. Мусин. Хәзерге авыл һәм әдәбият. № 6.
Э. Нигъмәтуллин. Прозабыз турында уйланулар. № 11.
Ф. Сафиуллина. Сүзне башлау җиңелме! № 9.
Р. Свеṙигин, Ф. Хатипов. Тормыш моңын тоеп. № 1.
Р. Шириязданов. Аның дәрте, дәрманы белән. № 10.

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

И. Нуруллин, Р. Фәйзуллин. «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе. № 3.
Х. Госман. Яшьләр һәм остазлар. № 5.
Т. Галиуллин. Җитмешенче еллар авазы. № 7.
М. Глухов. Сабыр төбе — саф алтын. № 9.
А. Әлмиев, Р. Сәлимуллин, С. Ихсанова, Ә. Габиди хатлары. № 9.
Р. Мөхәммәдиев. Әгәр син язмасаң, әгәр без язмасак. № 10.
Ф. Сафин. Шигырьләр яңашәлеге. № 12.
Ш. Әхмәдуллин. Әдәби тәнкыйть һәм эстетик тәрбия. № 10.
Р. Харис, М. Вәлиев. Шигърият шәхестән башлана. № 12.

ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ РЕЦЕНЗИЯСЕ

Х. Янов. Шифалы яңгыр сыман. № 9.

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. Абдуллин. Ниятләре яхшыдан түгел. № 10.
Т. Галиуллин. «Туган җирем, сөйгән ярым». № 3.
Р. Гыйззәтуллин. Тарихыбызның яңа сәхифәсе. № 6.
А. Литвин. Татар совет китабы узган юл. № 5.
Х. Максудов. Муса Җәлилгә багышланган китап. № 10.
Р. Мостафин. Галимҗан Ибраһимов турында яңа хезмәт. № 1.
Р. Мостафин. Хис һәм фикер берлеге. № 2.
Р. Мостафин. Арышларның исе тәмлерәк. № 8.
М. Мөләков. Бердәм гаиләдә. № 6.
Г. Моратов. Йолдыздан да заман җиле исә. № 12.
Р. Низамиев. Мәңгелек сәяхәт. № 2.
Ф. Сафиуллина. Дөньяны сүз бизәр. № 7.
Ш. Садретдинов. Идеалга тугрылык. № 12.

А. Тимергалин. **Сүзлектә фәнни терминология. № 4.**
В. Хаков. **Катлаулы мәсьәләләрне хәл итү юлында. № 11.**
Ф. Хәкимҗанов. **Күп көч куелган. № 4.**
Ф. Урманчеев. **Тукай томнарын укыганда. № 5.**
Ә. Шәрипов. **Сәйф Сараи иҗатын өйрәнү юлында. № 1.**
Н. Шәфигуллин. **Хакыйкатьне таплап булмый. № 7.**
Р. Ягъфәров. **Акыл һәм шигърият китабы. № 3.**
А. Әхмәдуллин. **Әдәбиятның яшәү көче турында. № 6.**

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Л. Мәгъсумова. **Нәвои һәм татар әдәбияты. № 1.**

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

В. Воздвиженский, М. Маннурова. **Муса Җәлил һәм Каршылык хәрәкәте поэзиясе. № 2.**
Н. Юзиев. **Әдәбият фәне методологиясенә — камиллек. № 5.**

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ш. Абилов. **Поэзиябез тарихына яңа исем. № 10.**
Ү. Гыймадиев. **Тукай мирасы турында «Ялт-йолт». № 6.**
М. Мәһдиев. **Бүген дә хәрәкәттә. № 7.**
Н. Хисамов. **Тукай иҗатында борынгы әдәбият традицияләре. № 4.**

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. Абдуллин. **Галимҗан Ибраһимов һәм татарларда иҗтимагый фикер тарихы. № 9.**
Г. Дәүләтшин. **Борынгы болгар тарихи риваятьләре. № 9.**
Ә. Кәримуллин. **Гөлнар ханым. № 5.**
М. Әхмәтҗанов. **Татар шәҗәрәләре. № 3.**

## СӘНГАТЬ

А. Алмазова. **Илләр гизәр алдыннан. № 7.**
Ф. Вәлиев, Г. Вәлиева. **Татар декоратив сәнгатендә кош сурәте. № 8.**
Л. Домрачева. **Актер шәхесе. № 11.**
И. Илялова. **Сәхнә остасы. № 1.**
Б. Урманче. **Архитектор Исмәгыйль Гайнетдинов. № 2.**
В. Лукъянов. **Халык җыры — тәрбия чарасы. № 3.**
М. Нигъмәтҗанов. **Тибрәтмәктә күңелнең кылларын. № 4.**
Ш. Рахманкулов. **Бию—егет һөнәре. № 6.**

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

Д. Гарифуллин. **Бабайлардан калган истәлек. № 12.**
М. Садри. **Себер халык җырлары һәм әкиятләре. № 9.**
Л. Җамалетдинов. **Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым. № 3.**

## ИСТӘЛЕКЛӘР

М. Гайнуллин. **Мин әдәбиятка ничек килдем! № 9.**
Ә. Еники. **Хәтердәге төеннәр. № 11.**
М. Зорин. **Хәтернең кайнар күмере. № 8.**

А. Расих. Әнием хатирәләреннән. № 4.
В. Хаҗиев. «Әллүки» ничек туган! № 4.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Д. Бaһаутдинова. Шагыйрь китапханәсе. № 5.
А. Михеев. Шершель көндәлеге. № 6.
И. Надиров. Багланышлар ныгый. № 1.
Г. Таһир. Финляндиядә төрки телләрне тикшерү тарихыннан. № 1.
Әбелфәрәҗнең «Кызыклы вакыйгалар китабы»ннан. № 6.

## БЕЗНЕҢ САФКА

Илдус Ахунҗанов. № 1.
Владимир Мальцев. № 1.
Җәмит Рәхимов. № 1.
Ш. Галиев. Альберт Яхин. № 3.
Ә. Еники. Мансур Вәлиев. № 3.
А. Шамов. Лирон Хәмидуллин. № 3.
И. Юзеев. Роберт Миңнуллин. № 3.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Шамил Бикчуринга 50 яшь. № 1.
Зариф Бәшири. № 5.
Рәшит Ваһапов. № 6.
В. Воздвиженскийга 50 яшь. № 2.
Ф. Вәлиева. Сон суларын эчкән ул. № 10.
Н. Гамбәров. Учак җылысы. № 3.
Н. Гыйззәтуллинга 50 яшь. № 6.
Н. Гыйззәтуллин. Җиң сызганып эшләр чак. № 10.
Х. Зарипов. Тын алан шаулый. № 4.
Л. Ихсанова. Дәрҗия Аппакова. № 3.
Р. Ишморат, һ. Мәхмүтов. Бәян Гыйззәткә 60 яшь. № 7.
Әгъзам Камал. № 1.
Әнәс Камалга 70 яшь. № 2.
В. Монасыйповка 50 яшь. № 12.
М. Мөхәммәдиев. Фәнни кыюлык. № 12.
Р. Мөхәммәдиев. Фатих Сәйфи-Казанлы. № 3.
М. Роберт. Мөнир Мазунов. № 4.
Ә. Тенишев, Ф. Сафиуллина. Үр артыннан үрләр күренә. № 8.
Тынгысыз әдәбиятчы. № 11.
М. Шәрифуллинның тууына 50 ел. № 2.
С. Шакир. Истә, һаман да истә. № 3.
С. Шакир. Күңелләрендә чорыбыз сулышы. № 4.
Р. Ягъфәров. Кайнар йөрәкле галим. № 5.
Шаһит Әхмәдиев. № 1.

## МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Төрекчәдән ике мәсәл. № 3.
Түребездә: айсорлар. № 10.

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Г. Афзал. Уены-чыны беләң. Шигырьләр. № 5.
Г. Бакир. Склероз түгел, пылау. Ташлады да башлады. № 1.

Ш. Галиев. **Әз-мәз мәзәк яки Котбетдиннең кырык тартмасы. № 8, № 9.**
Р. Гарипов. **Сер бирмәү.** Нәни хикәяләр. **№ 6.**
Гөр-Гөри. **Пародияләр һәм эпиграммалар. № 2.**
**Кашфел Задә. Чехов язганча.** Шигырьләр. **№ 5.**
Г. Луч. **Авыл склерозы.** Юмореска. **№ 11.**
**Мари мәзәкләре. № 12.**
Т. Миңнуллин. **Ике әби, бер бабай. № 1.**
К. Мостафин. **Пародияләр. № 10.**
З. Нури. **Алтын балык ялвара.** Шигырьләр. **№ 4.**
З. Нури. **Хатка каршы хатлар яздык.** Хикәя. **№ 5.**
З. Нури. **Нәниләр һәм зурлар.** Шигырьләр. **№ 11.**
Ф. Садриев. **Ал да гөл. № 1.**
И. Туктар. **Җөмләләр. № 6.**
Ә. Шамин. **Эх, Гата, Гата.** Парча. **№ 11.**
А. Яхин. **Күргәзмә әсбап.** Хикәя. **№ 2.**
М. Әпкәли. **Балык тотканда.** Парчалар. **№ 11.**

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Р. Мингалимов. **Миңа ничек ышанырсың!** Шигырьләр. **№ 5.**
Ү. Саттаров. **Кызым хикәяләре. № 9.**
Җ. Тәрҗеманов. **Шуктуган.** Әкият. **№ 1.**
Х. Халиков. **Әллә нинди.** Шигырьләр. **№ 1.**
Ф. Яруллин. **Көз.** Шигырьләр. **№ 4.**

УКУЧЫ СҮЗЕ

**Укучылар сүзе. № 5.**
Р. Миңнуллин. **Укучы уйлана, шатлана, борчыла. № 12.**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—12.**

ҖЫР

А. Монасыйпов музыкасы, З. Насыйбуллин шигыре. **Кеше булсаң. № 10.**
Ф. Әхмәтов музыкасы, С. Хәким шигыре. **Мин беренче чәчәкләрне эзлим. № 7.**
Р. Яхин музыкасы, М. Мазунов шигыре. **Казан утлары. № 4.**

# СӘРВӘР ӘДҺӘМОВА



Шушы елның 10 ноябрендә 78 нче яшендә озакка сузылган каты авырудан соң танылган балалар язучысы һәм тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова вафат булды.

Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова 1901 елның 5 апрелендә Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә туа. Башлангыч һәм урта белемне шунда ала. Соңыннан Казанда совет хокукы һәм төзелеше институтын тәмамлый.

Сәрвәр Әдһәмова 18 яшеннән хезмәт юлын башлап җибәрә. Совет дәүләтенең беренче елларында ук ул укытучы булып эшли, аннары балалар йортына тәрбияче булып күчә.

1924—29 елларда ул Татарстан АССР Үзәк крестьян йорты каршындагы юридик бүлекнең мөдире була. Шул ук вакытта «Крестьян газетасы» редакциясендә укучыларга юридик консультация бирү бүлегендә әдәби хезмәткәр булып эшли.

Сәрвәр Әдһәмова әдәби иҗат эше белән бик яшьли шөгыльләнә башлый. Томскида балалар йортында эшләгәндә ул балалар өчен «Авыл тормышыннан бер күренеш», «Хәзер бул!» исемле пьесаларын яза. 1946 елда аның мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Песи белән чыпчык», 1953 елда «Минем апалар», 1959 елда «Дуслар» исемле хикәя җыентыклары басылып чыга.

1945 елдан ул — СССР Язучылар союзы члены.

Сәрвәр Әдһәмова иҗатында әдәби тәрҗемә аеруча зур урын алып тора. Озак еллар буена тәрҗемә өлкәсендә армый-талмый эшләү аны тәрҗемә остасы итеп танытты. Рус классикларыннан М. Горький повестьларын, А. Пушкин прозасын, Л. Толстой, А. Чехов хикәяләрен, казакъ әдәбияты классигы М. Ауэзовның «Абай» эпопеясын татар укучылары аның тәрҗемәсендә укыйлар.

Ярты гасырдан артыкка сузылган иҗат эшчәнлеге дәверендә Сәрвәр Әдһәмова татар әдәбиятын балалар өчен язган кызыклы әсәрләре, күп кенә тәрҗемә әсәрләре, күп кенә тәрҗемә китаплары, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми кебек әдипләребез хакындагы истәлекләре белән баетты.

Киң күңелле, ярдәмчел, җәмәгать эшләрендә башлап йөрүче каләмдәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләрдә озак сакланыр.

## *Яңа ел белән, хөрмәтле укучыбыз!*

Озакламый журналыбызның яңа елдагы беренче санын алырсыз.

«Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналының бу саны Роберт Әхмәтҗановның «Интернационал» исемле шигырьләр циклы белән ачыла. Равил Фәйзуллинның яңа шигырьләре, Рафикъ Юнысовның «Элемтәчеләр» дигән шигырьләр циклы да шушы ук санда басыла.

Проза бүлеге Мирсәй Әмирнең «Үсә төшкәч» дигән автобиографик повестен урнаштыра. Ул — «Без бәләкәй чакларда» дигән әсәрнең дәвамы. Марсель Галиев журналга «Ул чакта...» дигән повесте белән катнаша.

Мәгъсум Гәрәевның академик Роальд Сәгъдиев турындагы очеркы кызыклы материалларга бай.

Январь аенда татар әдәбияты классигы, драматург Галиәсгар Камалның тууына 100 ел тула. Шул уңай белән журналыбыз күп кенә кызыклы мәкаләләр, истәлекләр, фоторәсемнәр туплап чыгара. Шушы ук айда Фатих Кәримнең дә тууына 70 ел тула. И. Юзеевның «Озын гомерле шагыйрь» исемле мәкаләсе, Габдрахман Минскийның «Шагыйрьнең яшьлеге» дигән истәлеге фронтовик-шагыйрь биографиясен тулыландыруда ярдәм итәчәкләр. Фатих Кәримнең үз шигырьләре исә поэзия сөючеләргә кадерле бүләк булыр.

Журналыбызның беренче санында Сез яңа китапларга рецензияләр, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары, «Безнең календарь» бүлегендәге материаллар белән дә танышырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210